# казан утлары

3

МАРТ-1971



# XXIV

*Партия җитәкли,*
*партия — юлбашчы! —*
*Тик шулай беләбез*
*һәммәбез аны без.*
*Ул — безнең теләкләр,*
*өметләр кояшы,*
*Ул — безнең үлемсез*
*һәм сүнмәс данибыз.*
*Хакыйкать сүзенең,*
*гаделлек сүзенең*
*Күңелләр кырына*
*чәчә ул орлыгын.*
*Халыклар күрә*
*бу сүздә үзенең*
*Эше дә,*
*көче дә,*
*хисе дә зурлыгын.*
*Бу сүздә берләшә*
*бердәмлек, кыюлык,*
*Шат ГИМН итеп*
*җырлыйбыз без аны.*
*Язылды йөрәккә*
*мәңгегә уелып:*
*— Яшәсен партия —*
*чорыбыз вөҗданы!*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

3

МАРТ
1971


## Бу санда:


И. ГАЗИ. Съезд каршылаганда . . . . . . 3

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

С. РАФИКОВ. Тын елга буенда. Роман . . 8
С. БАТТАЛ. Чирмешән ярларында. Шигъри роман . . . . . . . . . . 62
А. ШАМОВ. Мәхәббәт трагедиясе. Повесть . . 71
Ә. БИКЧӘНТӘЕВА. Көзге моңнар. Җилләрең, бураннарың. Шигырьләр . . . . . . . . 100
К. БУЛАТОВА. Шушы яктан, шушы туфрактан без. Февраль. Пушкин белгән... Бишек җыры. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 101
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Безнең апай — королева. Хикәя . . . . . . . . . . . . . 104
М. ФӘЙЗУЛЛИНА. Җәйнең тынлыгы. Нәни поши. Шигырьләр . . . . . . . . . . 112
Р. ХӘЛИУЛЛИНА. Тесләр. Түгим әле... Гөлләр-сөмбеләр. Шигырьләр . . . . . . . 113

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ. Югары нокта. Очерк . . 115

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

М. САДРИ. Нури Арсланов портретына берничә сызма . . . . . . . . . . . . . 121

ДУСЛАР ҖЫРЫ

А. ГАВРИЛОВ. Әзләр. Шигырь . . . . . . . 125
А. АНТОНОВИЧ. Яз белән саубуллашу. Шигырь . 126
А. БАЙЗУЛЛАЕВ. Зәңгәрсу кыялар. Шигырь . . 126
З. ШАҺБАЗОВ. Кайтмадыгыз. Шигырь . . . . . 127
Б. БЕДЮРОВ. Тулган ай әкияте. Шигырь . . . . 127
А. КОМЕНДАНТАС. Төн. Шигырь . . . . . . . 128
А. СТАРОСТИН. Мин Себер, тундра улы... Бүләсем минем... Шигырьләр . . . . . . . . 128
М. КАЛМЫКАЕВ. Сагыну. Шигырь . . . . . . 129
Ш. АЛИШЕВА. Еллар үтә... Бераүгә. Шигырьләр . 129
Р. ВӘЛИЕВ. Әнкәйгә хат. Шигырь . . . . . . 130



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

Р. МОСТАФИН. «Оҗмах»ка сәяхәт . . . . . . 131

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

М. ЕЛИЗАРОВА. Кешеләр аңа ышана. Очерк . . 154

АЛАР БЕЗДӘ БУЛГАННАР

В. КЛИМЕНТОВСКИЙ. Бер генә килсә дә . . . 161

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Ф. ХАТИПОВ. Эпик жанрлардан повесть . . . 165

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. ГОСМАНОВ. Хөсәен Фәезхан улының бер хыялы . . . . . . . . . . . . . . . 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ВӘЛИЕВ, Р. ХӘЙРЕТДИНОВ. Яшь Ульянов турында яңа китап. . . . . . . . . . . . . 178

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . 181

Безнең календарь. . . . . . . . . . . . 185

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Г. РӘХИМ. Моңлы бер җыр. Шигырь . . . . 187
Г. ГАТАУЛЛИН. Ышандыр . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 188

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52.
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.* Корректоры *Р. Сулейманова.*

Производствога бирелде 30/XI-1970 ел. Басарга кул куелды 29/I-1971 ел. ПФ 09008. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 81646 экз. Заказ С-652. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1971 ел.



XXIV

**Ибраһим Гази**

# СЪЕЗД КАРШЫЛАГАНДА

Партия съездлары илебез тормышында зур вакыйга. Ике съезд арасы киеренке зур хезмәт эчендә уза, яңа съезд халык хуҗалыгы каршына хәл ителәчәк яңа мәсьәләләр, яңа зур проблемалар куя.

Без, язучылар, партиябезнең XXIV съездын зур кызыксыну белән каршылыйбыз, чөнки идеология хезмәткәрләре каршына да съезд яңа бурычлар куячак, әдәби хәрәкәтебезгә яңа, киң перспективалар ачачак.

Татарстан язучыларының эшләгән эшенә юбилейлар елында беркадәр йомгак ясалган иде инде. Эшләнгән эшне бездән берәү дә тартып ала алмас, эшләнергә тиешлесе хакында уйланыйк.

РСФСР язучыларының моннан бер ел элек булып узган III съездында баштан ахырга кадәр Ленин рухы хөкем сөрде. Докладчылар да, чыгып сөйләүчеләр дә язучыларның Ленин идеологиясенә турылыклы булуларын, иҗатларында партиялелекне, халыкчанлыкны нигез принцип итеп алуларын әйттеләр. Съезд, әдәбиятка һәм гомумән тормышка кагылган күп кенә мәсьәләләрне тикшереп, әһәмиятле карарлар кабул итте. Башка милләт язучылары белән рәттән, съездда татар язучылары да мактап телгә алынды. Мактадлык дип, без борын чөймибез, чөнки үзебезнең уңышларыбызны һәм җитешсез якларыбызны яхшы беләбез.

Безнең иң зур уңышыбыз шул: революция нәтиҗәсендә, социалистик җәмгыять төзү барышында яңа тип язучы, совет язучысы барлыкка килде. Совет язучысы акчага яки данга алданып язмый, ул ялланып эшләүче түгел, ул социализм идеалларының ирекле көрәшчесе. Ул күңелендәге кыйбласына, рухи иманына таянып хезмәт итә, шәхес буларак, пролетариат партиясе идеологиясенә инана, шул идеологияне алга сөрә. Яңа тип язучы — ул сәнгатьтә Ленин эстетикасын үзенә корал итеп алган яңа кеше, социалистик җәмгыять кешесе.

Ирекле язучы, дидек. Кешелек җәмгыятендә бервакытта да чикләнмәгән, абсолют ирек булганы юк. Абсолют ирек ахыр чиктә ул анархия дигән сүз. (Ни телим — шуны эшлим. Нәрсә телим — шуны язам). Ике зур лагерь — хезмәт лагере белән хезмәтне талап яшәүчеләр лагере — каршына «Кем кемне!» мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән

куелган бер заманда, язучы, язучы гына да түгел, һәр аңлы кеше ике лагерьның берсен сайлап ала. Намусы саф булган барлык гадел кешеләр хезмәт лагере ягында торып көрәшәләр. Ике лагерь арасында битараф басып тору мөмкин түгел, икенең берсен барыбер сайларга туры киләчәк. Әгәр син, язучы, аңлы рәвештә хезмәт иманының үз иманың дип белдергәнсең икән, син шул иманга ирекле рәвештә хезмәт итәсең дигән сүз. Художник социаль прогресс өчен көрәшкә үз ихтыяры белән килеп кушылса, эшче сыйныф һәм аның партиясе көрәшенә үз иҗаты белән үзе теләп хезмәт итсә, андый художник ирекле художник. Шулай итеп, ирекле булу «ни телим — шуны язам» түгел, ә билгеле бер сыйныф идеологиясенә, мәгълүм бер социаль катлауга аңлы рәвештә хезмәт итү дигән сүз. Шул мәгънәдә, бары тик шул мәгънәдә генә язучы ирекле кеше.

Инде язучы нинди әдәби алымнарны сайлый, нәрсә яза — роман язамы, хикәяләрме, поэмалар яки лирик, интим шигырьләрме — анысы үз эше, анысы язучының характерыннан, тормыш тәҗрибәсеннән килә. Бер генә әдәби жанр да, бер генә алым да, бер генә стиль дә — бары мин генә социалистик реализм жанры, алымы яки стиле дип дәгъва итә алмый. Зур полотнолы роман, хикәя, новелла яки юмор, сатира, гротеск — берсе дә безнең өчен үги түгел. Язучы, үзенең характерына, темпераментына, тәҗрибәсенә карап, теләсә кайсысын сайларга ирекле. Берсен кагып, икенчесен канат астына алып, ниндидер нормалар куюю социалистик реализмга ят нәрсә. Язучының иҗат табигатенә, талантына мөмкин кадәр киңрәк юл бирү — социалистик реализм әнә шуны яклый.

Язучыны язучы иткән нәрсәләр — иман һәм талант. Иман турында, ягъни билгеле бер идеология солдаты булып сугышу хакында әйттек инде. Хәзер талант һәм талантлылык хакында берничә сүз. Ленинчыл эстетика талантка бик зур әһәмият бирә. Талант, матурлык кебек үк, кешегә табигать биргән кадерле бүләк. Ләкин талант матурлык кына түгел, талант зуррак, иҗтимагый әчтәлеге белән матурлыктан чагыштыргысыз әһәмиятлерәк. Тик бары зур һәм тырыш хезмәт ярдәмендә чарланган талант һәм социаль тормыш тәҗрибәсе язучыга чынбарлыкны бөтен катлаулыгы белән танып белергә һәм әдәби образлар тудырырга мөмкинлек бирә. Талант үткен күзле була, ләкин талантның табигый көченә генә таяну җитми. Талантны тәрбияләргә дә кирәк, һәм сәяси яктан, һәм профессиональ яктан өзлексез чарларга, чыныктырырга, иҗтимагый зирәклеген үткенәйтергә кирәк. Иҗтимагый үткен карашлы талант кына чын талант, шунсыз ул матур уенчыкка әйләнеп кенә калырга мөмкин. Дөньяга дөрес карашы булмаган талант — сукыр талант, компассыз талант, ә компассыз хәзерге заманның өермәле тормыш океанында дөрес юл салу кыен.

Буржуаз тәнкыйтьчеләр, талант кемгә, кайсы сыйныфка хезмәт итсә дә, гүзәл бер сыйфат, диләр. Юк, талант тик бары үз халкына, үз сыйныфына бирелеп хезмәт күрсәткәндә генә асыл һәм кадерле сыйфат, дошманнарга каршы үткен кылыч булып күтәрелгәндә генә талант матур. Чын талантны кадерсезләргә, юкка-барга әрәм-шәрәм итәргә талант иясенең хакы юк, чөнки талант аның хосусый милке түгел. Талант ул халык байлыгы, халыкка хезмәт итәргә тиеш, өстәвенә бик яхшы, бик талантлы хезмәт итәргә тиеш.

Талант, табигый көч буларак, сыйнфый битараф. Талант иясе кем! Ул кайсы сыйныфка хезмәт итмәкче! Кыйбласы кая таба караган! Талантның иҗтимагый активлыгы әнә шуның белән билгеләнә.

Язучы үзенең әсәренә герой итеп кемне сайлый — шушы факт үзе генә дә бик әһәмиятле. Чөнки әдәби әсәрнең герое гади бер фамилия генә түгел, әдәби герой ул — эстетик категория, мәгълүм бер иҗтимагый шәхес, билгеле бер идеягә инанучы. Үзе сайлаган геройга авторның мөнәсәбәте язучының позициясен билгели: яратамы ул үзенең героен, әллә аңардан көләме, әллә аңа битарафмы! Аның герое бүгенге тормышта нинди урынны тота! Тыкрыклардан гына йөриме ул, әллә олы юлдан барамы! Авторның ятатып яза торган мохите — эшчеләрме, крестьяннармы! Җәмәгать байлыгын бар итүдә ул герой нинди урында! Кашык тотып кына чыгамы, әллә тормышны иҗат итүче актив көчләргә керәме! Язучыга бәя биргәндә шушыларның барсының да әһәмияте бик зур.

Язучы кем турында язса да язсын, тик мавыктыргыч кызык һәм осталарча гына язсын, дип куеп булмый. Язучыга осталык, әлбәттә, һава кебек кирәк, оста кулы гади

агачтан да бик матур сәнгать әсәре иҗат итеп бирә, осталыгы такы-токы кеше аңардан балта сабы да юынып бирә алмаска мөмкин.

Безнең укучыларыбыз арасында матур балта сабына алданучылар очрыйлар әле. Матурлыгы, сәнгатьчә оста эшләнгәнлеге өчен балта сабын күкләргә күтәреп мактаучы тәнкыйтьчеләребез дә очраштыргалый. Матурлык алдаучан була, матур итеп елмаеп торучының күңелендә ниләр ятканын кинәт кенә төшенеп булмый.

Зурдан кубып, иҗтимагый әһәмиятле темаларны кузгатырга, ләкин материалны ботарлап кына атмыйча, осталарча эшләп бирергә талант иясенең генә кулыннан килә, анда да кыю булса, тормышка үз урамыннан, үз тәрәзәсеннән генә карамаса, кабыгына бикләнеп ятмыйча, кайнап, гөрләп торган бүгенге тормышның үзәгендә йөрсә, тик шул чагында гына язучыдан яхшы әсәр көтәргә була.

Кайнап торган тормышны эзләп әллә кая барасы юк, ындыр артында гына нефтьчеләр дөньясы яши, Кама буенда зур автомобиль заводы салына. Анда яшьләр, анда мең дә бер төрле характер, анда тулып яткан конфликт (сүз әдәби әсәргә пружина булырлык конфликтлар хакында бара), анда безнең шагыйрьләр яратып яза торган мәхәббәт, анда, китап теле белән әйтсәк, күп кырлы характерлар чыныга, анда олы эшне, дәүләт масштабындагы эшләрне башкарырлык кешеләр үсә, ниһаять, анда зур түзелеш, иҗат эше, хезмәт поэзиясе, көрәш героикасы, анда безнең булачак китапларыбызның каһарманнары, анда безнең тискәре һәм уңай геройларыбыз... Тик күзне ачыбрак карарга, колакларны торгызыбрак тыңларга гына кирәк. Гадәти кешенең гадәттән тыш сыйфатларын күрә белергә генә кирәк.

Язучы үзенең тормышка карашын уңай һәм тискәре геройлар ярдәмендә әйтеп бирә. Тискәре герой ярдәмендә мөнәсәбәтне сиздерү ансатрак, ә уңай герой аркылы — кыенрак, ләкин күркәмрәк. Совет язучысы, инкарь итүче булудан бигрәк, раслаучы, куәтләүче, яклаучы. Инкарь итү асылда җимерүне аңлата. Җимерү белән генә яшь буыннан яхшы кешеләр тәрбияләп булмый. Кеше рухы өчен барган каты көрәштә җиңим дисәң, яшь буынга үрнәк булырлык зур һәм күркәм характерлар, героик характерлар бирергә кирәк, ә андый характер безнең шартларда тик бары уңай геройда гына булырга мөмкин.

РСФСР язучыларының III съезды әдәбиятта уңай герой мәсьәләсен тагын бер тапкыр күтәрде. Без, язучылар, идеология сугышының алдынгы сызыгында көрәшәбез. Безнең эш четерек тә, бик җаваплы да. Коммунизм җәмгыятен төзеп җиткерү кемнәр, нинди кешеләр кулына күчәчәк, без нинди алмаш калдырабыз! Бүгенге яшьләргә тормышта үзләренә чын урын табарга ничек булышабыз! Китапларыбыздагы уңай геройларыбыз яшь буынны коммунизм рухында тәрбияләрлек иҗтимагый кешеләрме! Язучы үз алдына шундый сорауларны куярга тиеш.

Уңай герой кем ул! III съездда проза турында доклад сөйләүче Михаил Алексеев уңай геройга мондыйрак характеристика бирде: уңай герой ул минем идеалларыма тугрылыклы минем якын кешем, минем фикердәшем, минем иптәшем. Аның тышкы матур яки ямьсез булуы ихтимал. Ниндидер кимчелекле сыйфатлары да булырга мөмкин. Ләкин ул безнең идея кешесе, аның кыйбласы безнең кыйбла, аның кылган гамәлләре безнең максатыбызга хезмәт итә. Шуның өстенә ул әле иҗтимагый кеше, ягъни ямьсез яки матур кеше генә түгел, ягымлы, ягымсыз, сөйкемле яки сөйкемсез, юмарт яки саран, ялкау яки тырыш, акыллы яки гадәти кеше генә түгел, ә җәмгыятьнең социаль тормышында җиң сызганып эшләп йөрүче кеше. Икенче төрле әйтсәк, ул үз кабырчыгына качып, үзе өчен генә яшәми, ә җәмгыять һәм халык өчен яши.

Мин монда Алексеевның фикерләрен үземчәрәк сөйләп бирдем, яки-якиләрне күп куйдым. Асылда уңай герой гел матур, гел сөйкемле, гел акыллы, гел кешелекле булса да һич зарар юк. Киресенчә. Тормышта барлык матур һәм күркәм сыйфатларны үзенә җыйган кешеләр азмыни! Язучы үзенең әдәби героен һәр яктан килгән кеше итеп күрергә теләп икән, аның ихтыяры — күрә бирсен. Тик бу герой катыргыдан ясаган бер схема яки акыл көчә белән генә корыштырылган бер җансыз күләгә генә булмасын. Аның үз чырае, үз характеры, үз психологик сурәте, үзенчәлекле кызык, матур, хәтта сәер сыйфатлары булсын, тик берәүгә дә охшамаган бер уникум, чудак, заманыбызга ят бер сәер зат кына булмасын, заманның иң матур сыйфатларын, һич югында кайберләрен, үзендә гәүдәләндерүче, безгә таныш та, таныш түгел дә кеше булсын. Мондый образны иҗат итү өчен язучының теләве генә җитми, талант һәм

бары талант, хезмәт, тик авыр хезмәт белән генә тормыштан, бары тормыштан гына андый образны табарга була.

Безнең язучыларыбыз, бигрәк тә урта буын дип атала торган язучыларның кайберләре, зур активлык белән эшкә тотынып, романнар, повестьлар, поэмалар бирделәр. Әдәби хезмәттә шактый гына осталык күрсәткән бу иптәшләрнең бер зур кимчелеге шул булды, алар күбрәк үз тәҗрибәләренә, үз күргәннәренә таяндылар, нәтиҗәдә берьяклырак әсәрләр иҗат иттеләр. Язучының үз тормыш тәҗрибәсенә таянып кына язылган, заман философиясе белән яктыртылмаган әсәрләр күпме генә кызыклы, хәтта сенсацион булмасыннар, чын мәгънәсендәге әдәби вакыйга була алмыйлар, чөнки әдәбиятның бурычы укучыны кызыксындырырлык җанлы, катлаулы, каршылыклы образлар бирүдә генә түгел, заманны канәгатьләндерү өчен безнең чорыбызга характерлы уңай яки тискәре яктан, бигрәк тә уңай яктан характерлы образлар иҗат итәргә кирәк. Сугыш елларын һәм сугыштан соңгы авыр елларны тасвирлаган әсәрләр гыйбрәт була алалар. Елларның кырыслыгын, кешеләрнең катылыгын күреп тә, ул елларның тирән мәгънәсен шушы кырыслыкка, рәхимсезлеккә генә кайтарып калдырып та, авыр заманның героикасын, романтикасын бирә белмәү, кешеләрне кыерсытылган, мәсхәрәләнгән итеп кенә биреп, шул кешеләрнең рухи каһарманлыгын күрмәү — язучының үз шәхси күзәтүләре белән генә чикләнүеннән килгән дияргә була. Чөнки язучы маңгай күзенә кадалып торган вакыйгаларны күргән, ә шул чуар вакыйгалар астындагы героизмны, халыкның героизмын, дошманны тар-мар иткән героизмны күрмәгән.

Авыр заманнар узды. Авыл бөтенләй икенче төрле сулый, иске мөнәсәбәтләр урынына яңалары килде: яңа кешеләр, яңа каршылыклар, яңа конфликтлар, яңа проблемалар туды. Сугыш һәм сугыштан соңгы авыл тормышы, аның кешеләре, вакыйгалары ничек язылса да язылды, ничек керсә дә әдәбиятыбызга керде (Рафаил Төхфәтуллин повестьларын, хикәяләрен мактап телгә аласы килә), ә бүгенге авыл, бүгенге конфликтлар, колхозның бүгенге көне, бүгенге кешеләре әле хәтта очеркларда да рәтләп күренгәннәре юк.

Рәссамнар этюдка йөриләр. Этюд — булачак зур рәсемгә, зур әсәргә әзерлек. Очерк та этюд кебек. Ул язылачак зур әсәр өчен характер, типаж, вакыйга эзләү һәм табу өчен кирәк. Авылны тану, өйрәнү кыенлая төште, махсус белем кирәк. Авыл турында бала чактан күңелгә сеңеп калган, искергән, шаблонга әйләнгән карашларны сындырырга кирәк, ә бу ансат эш түгел, караш белән бергә үзеңне дә сындырырга, иске тәҗрибәңне онытырга, яңаларына өйрәнергә мәҗбүрсең. Бәлки шуңадыр, безнең бүгенге язучыларыбыз арасында үз заманының Гариф Галиләре юк, Гомәр Бәширләре, Афзал Шамовлары, Мирсәй Әмирләре, Фатих Хөсниләре юк. Атилла Расих, авыл темасына күп язган кеше, авылдан галимнәргә, тарихка күчте, авылны ташлады. Авылга мөкиббән киткән, авыл проблемаларына социаль сизгер күңелле булган яңа «авылчыларыбыз» әлегә күренми. Иске авыл, кулаклы авыл хакында үз заманында язучыларыбыз күп яздылар. Заманга битараф, иҗтимагый саңгырау булмыйк дисәк, бүгенге авылдагы зур үзгәрешләр турында уйланырга, бу гыйбрәтле үзгәрешләрне әдәбият битләренә чыгарырга кирәк. Язучы кеше — уйланучан, анализлар ясаучан кеше, яхшыга шатлана, начарга көенә белүче сизгер җанлы кеше — тормыштагы матур үзгәрешләргә битараф кала алмый.

Бүгенге колхоз авылында, һәрвакыттагы кебек, матур яңалык үзенә юл яра. Анда яңа тип җитәкчеләр үсә, үзенчәлекле, менә дигән колоритлы характерлар барлыкка килә. Тормыш дигәнең чынбарлыкны иҗат итүдән бервакытта да туктап тормый. Авылны яраткан, белгән, авылның мәшәкатьләрен, шатлыкларын күңеленә якын иткән, авылдагы язмышлар, характерлар белән кызыксынган язучы авылдагы бүгенге күңелле үзгәрешләргә салкын гына карап тора алмый, очерклар ярдәмендә башта разведкалар ясап, техникалы заманның яңа кешеләрен өйрәнеп, кешеләр арасындагы үзгәргән социаль мөнәсәбәтләрне тикшереп, яңа романнар, повестьлар бирер дип өмет итәбез.

Дөньяны кит балыгы сыртында тора дип уйлаган чаклар үтте. Дөнья хезмәт җилкәсендә тора. Җир йөзендәге бөтен байлык — бәрәңгедән алып реактив самолетларга кадәр — барсы да кул һәм акыл хезмәте белән барлыкка китерелгән. Безнең иң зур хыялларыбыз һәм иң бөек идеалларыбыз хезмәт көче белән тормышка аша. Татар

әдәбиятында хезмәт темасы гомер-гомергә зур урын алып торды. Хезмәт кешесе әсәрләребезнең төп герое булып килде. Моңа кадәр без күбрәк авыл хезмәтен яздык, чөнки язучыларыбыз авылны беләләр, ә завод-фабрика тормышына килгәндә, безнең күпчелек язучыларыбыз өчен бу тормыш — яңа планета әле.

Нефтьтә эшләүчеләр шул ук крестьяннан «азган» кешеләр булсалар да, алар инде башка кешеләр: хезмәтләре, психологияләре, гореф-гадәтләре белән ук бүтән. Шул ук вакытта алар безнең шикелле үк кешеләр: аларда да шул ук совет кешесе характеры, шул ук совет кешесе психологиясе, шул ук интереслар, шул ук максат. Ул яктан без барыбыз да бертуган, агай-эне, кардәш... Димәк, һич курыкмыйча эшчеләр темасына барып ябышырга була. Була гына түгел, без ябышырга тиеш, бу безнең бурыч, чөнки эшче сыйныфның роле республикабызда артканнан арта: эшчеләр бездә тормыш яңартучы зур социаль көч, иҗат көче, бөтен байлык алар кулы белән бар ителә, шундый зур иҗат көче язучылар игътибарыннан читтә кала алмый, читләтеп узарга безнең хакыбыз юк. Халык алдында чиксез җаваплы һәр язучы бу хакта уйлансын иде һәм үзе өчен нәтиҗәләр чыгарсын иде.

Әдәбият турында сүз барганда әдәби тәнкыйтьне кырыйда калдырып узып булмый. Тәнкыйть — әдәби хәрәкәтнең җитәкчесе, әйдәүчесе, юнәлеш бирүчесе. Әйдәүче булу өчен тәнкыйтьче тормышны язучыдан да яхшырак белергә тиеш. Интуиция белән генә, китаптан алган белем белән генә хөкем йөртмәскә тиеш.

Бездә бик хәзерлекле тәнкыйтьчеләр бар: өлкән буыннан да, урта буыннан да... Ник шулай да басылып чыккан әсәрләрнең күбесе тәнкыйть күрми, чөнки тәнкыйтьчеләребезнең бүгенге әдәби хәрәкәтне күзәтеп, өйрәнеп барырга вакытлары юк, алар педагоглар, төрле вузларда укыталар, язганда да күбрәк үзләре укыта торган үткән заман хакында язалар, агымдагы әдәби хәрәкәт тәнкыйтьсез ага бирә. Язучылар, шагыйрьләр бер-берсе хакында язышырга мәҗбүр булалар. Андый хәлдә субъектив карашлардан, макташулардан котылып булмый. Әлбәттә, язучы турында, шагыйрь турында шагыйрь һәм язучы да язарга тиеш, тик бу чын, гыйльми тәнкыйтьне алмаштыра алмый. Безгә яшь тәнкыйтьчеләр үстерергә кирәк. Бу эш әдәби журналлар өстенә төшә, Язучылар союзының тәнкыйть секциясе җилкәсенә төшә.

Булган кадәр тәнкыйтебезнең кимчелеге шул: берәүләрне тәнкыйть еллар буе калкан өстендә йөртә, икенчеләрне бөтенләй телгә алмый, я, башларын чабып, куак ырасына тондыра. Гел тиргәү ишетү яки еллар буе телгә кермәү язучыга үсәргә комачауласа, гел мактау гына ишетеп тору, гәрчә бу мактау күпмедер дәрәҗәдә хаклы мактау булса да, язучыны, шагыйрьне рухи яктан сукырайта, масайта, кимчелекләрен күрмәс итә, үсәргә комачаулый. Димәк, мактау ахыр чиктә иҗат кешесенә зарар китерә. Өстәвенә, дифирамб җырлаганда тәнкыйтьче, гыйльми принципларны бер якка куеп, симпатия белән антипатия дигән ике принципсыз принципка атланып йөри башласа, мактаучыга гына түгел, гомумән әдәби хәрәкәткә зыян итә. Мактаучы, бик күп мактый башласалар, үзе дә сагаерга тиеш: мактаган булып, тәнкыйтьче үзенә әдәби капитал җыймыймы! Янсә мактала торган язучы һәм шагыйрь үзе объектив тәнкыйтьне күтәрә алмас өметсез картка әйләнеп бармыймы!

Тәнкыйтьне мактау дип кенә белеп, тәнкыйть сүзе ишеткәндә үпкәләүче, дошманга әйләнүче иптәшләрнең исләренә төшерәсе килә: бүредән курыккан — сарык асрамасын! Гәрчә кайвакытта сарыкларны артыграк ботарласа да, бүре файдалы ерткыч, фән һәм тормыш моны һәрдәм әйтә килә.

...Әдәби хезмәтебез һәм язучылар җәмәгатьчелеге алдында торган мәсьәләләр, әлбәттә, болар белән генә бетми. Ләкин бер мәкаләдә генә аларны күтәреп тә, хәл итеп тә бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә мин әлеге фикерләремне әйтү белән чикләнергә булдым.

Барлык хезмәт ияләре кебек, без, язучылар да, партиябезнең XXIV съездын яңа иҗади хезмәтләребез белән каршыларга тырышабыз.

Сөббух Рафиков

# ТЫН ЕЛГА БУЕНДА

РОМАН [1]

## 11



Закир картның балалары күптән аякларына басып, күптән кеше булганнар, төп йорттан кайсы кая таралып беткәннәр, Василдан гайре иң кече төпчек уллары солдат хезмәтенә алынган, җиткән кызлары исә тормышка чыкканнар иде. Авылдагы кызлары Тәгълимә дә бу араларда еш килә, һич югында, олы кызын әбисенә иптәшкә җибәрә иде.

Карчык чәй куйды. Өстәл каршына аналы-уллы утырып, берәр чынаяк чәй эчәргә өлгермәделәр, Закир картның ыңгырашканы ишетелде. Икесе дә түр якка чыктылар. Ни күрсеннәр: Закир карт мендәргә сөялгән, башын калкыткан. Ул Василны шундук танымады, бераз карап торгач, эчке зәгыйфь аваз белән йомшак кына итеп әйтте:

— Бәй, улым, кайттыңмыни? Кил әле яныма.

Закир карт улы белән ике куллап күреште дә карчыгына карады:

— Бик киселдем,— диде,— тамагымны ялгап алыймчы, шуннан хәл кереп китмәсме,— диде.

Гашүрә карчык, өнме бу, төшме бу дигән сыман, бер картына, аннары улына карашын йөртте. Һәм тиз генә поднос белән төрле җиңел ашамлыклар китерде. Закир карт, бау кебек юан зәңгәр тамырлы ябык кулларының калтырануын басарга тырышып, беркадәр тәгам җыйды: сөт эчте, чәй эчте дә карчыгына баш астын рәтләбрәк җәяргә кушты.

— Берегез дә янымнан китмәгез. Сез үз катымда булгач рәхәт.— Аннары ул Василга карады. Улы этисенең ябык, каты кулларыннан тотты. Бик тә кадерле иде аңа бу куллар. Шушы куллар бит инде өз-

---

[1] Дәвамы. Башы 2 нче санда.

лексез эшләп, аларны туйдырган, йорт-җирне барлыкка китергән, ару-талуны белмичә дөнья куган. Шушы куллар бит инде Василны да, башка туганнарын да иркәләгән, аларның башыннан сыйпаган, аларны кадерләп күтәреп йөрткән. Гел эш белән, гел хәрәкәт белән әвәрә килгән бу кулларның тик торулары, ул гына да түгел, хәлсезләнүе Василның һич акылына сыймый, уена ятмый иде.

Закир карт хәлсез тавыш белән сөйләшә бирде:

— Бик тә аякка басасы килә, улым. Күкрәкне китереп кыса, бугаз төбендә нидер утыра, тынны буа, бер генә дә түзәрлегем калмый кебек иде. Әле менә, әйтмәгәнем булсын, бушатып җибәрде, янадан хәл керә башлады сыман. Рәхмәте белән шулай, сырхаулык зәхмәтен кумасмы язгы җилләр!?

Василның күңеле дә этисенең кәефе килә башлаган саен күтәрелә барды. Төсе качкан әнисе карчыкка да тереклек яңадан кайта башлады. Икенче көнне картның кәефе тагы да яхшыра төште. Ул инде уртак табынга да утырып ашады. Өченче һәм дүртенче көннәрдә чыраена нур, кызыллык йөгерде.

Андый-мондый хәл, ягъни картның яңадан авырып китү яки өзлегү ихтималы булганда, турыдан-туры үзенә ашыгыч телеграмма сугарга кушып, Васил китеп барды.

Көн урталары үтүгә Васил шәһәргә кайтып төште. Нурзилә бу вакытта эштә булганлыктан, Васил больницага китте. Хатынын чакырып чыгарып, аннан ачкычны алды да ясле-бакчадан улы Ринатны алып кайтты. Улының уенчыкларын барлаган итте. Ринат менеп атланырлык сүс яллы, сүс койрыклы ат, автомобиль, тепловоз, үзе баш селкеп йөреп китә торган аю — һәркайсы, иң элек берсе, аннары икенчесе хәрәкәткә килде. Малай баштарак этисен ничектер шунда ят иткән сыманрак кыланса да, берничә минут үтүгә инде андый тискәрелекләре үзеннән-үзе юкка чыкты. Алар өйдә бергә торган чакта этисе дә, әнисе дә татарча да, русча да сөйләшәләр иде. Бала теле ачылгач ук һәр ике телдә сөйләшә башлап, һәр икесен тигез белә иде. Күрәсең, ясле-бакча малайга күбрәк тәэсир итә торгандыр, ул этисенең туган телендә әйткәннәренә русчалатып җавап кайтара. Ничек кенә булмасын, бер-берсен яхшы аңлыйлар. Уенчыклар, теге-бу турыда сөйләшкәч, Васил әйтә куйды:

— Улым, мин сине алып китәм бит.

Ринат кашларын җыерды:

— Я не поеду.

— Нигә?

— Не хочу, там глязно, волков много...

— Анда бүреләр юк, улым.

— Я боюсь, без мамы как будем жить?

— Әниең дә барыр, менә күреп торырсың.

— Нет, она туда не поедит, не за что не поедит...

Шушы сөйләшүдән соң, Василның эчендә вакытлыча басылып торган көяләнү уты, күңелен борчыган хис тагы баш калкытты. Бала белән шулай сөйләшү ярыймы, педагогик яктан ничектер, ул тиклесен уйлап тормастан, авыр сулап куйды ул. Димәк, ул югында Нурзилә үзенең уй-тойгыларын вакыт-вакыт тышка чыгаргалый булса кирәк.

Хәзер менә этисенең дә хәле рәтләнә төшкәч, ялкын, хис, күңел күзе белән башлаган эшен кайтып дәвам итәсе калды аңа. Нурзиләне дә алып китә калса, алай булмаган тәкъдирдә, киләчәк көннәргә карата аның белән уртак тел тапса, ул нинди бәхетле кеше булыр иде. Менә Нурзилә кайтып кына житсен, Васил аңа барысын да тәфсилле рәвештә сөйләп бирер. Таш йөрәкле түгел лә Нурзилә. Төшенми калмас. Һәммәсен дә әйтер... «Һич куркып торасы юк, Нурзилә, анда да безнең

мондагы кебек үк ике аяклы, ике куллы кешеләр яши. Бүреләр мәсьәләсенә килгәндә, син Ринатны юкка куркытасың. Юк анда бүреләр, юк! Поликлиника да бар, больница да бар, балалар тудыру йорты да бар. Дөрес, алар әле хәзергә махсус яраклаштырылган йортларда түгел, баракларда. Ә менә поселокның бер башында, ямьле Тын елга буеннан ерак түгел, саф һавалы киң кырлар, болыннар күкрәгендә, үзебезгә күрә бик дәү, хәзерге заманча больница шәһәрчеге салынып ята. Сиңа җиң сызганып шунда эшләп йөрү искиткеч күңелле булачак. Ул якларның үсеш перспективалары гаять зур. Кем белә, бәлки шунда гел төпләнеп тә калырбыз. Киләчәктә Яңа Наратлының шәһәр буласына да тулы ышаныч бар. Аннары... халык! Кая карама — яшьләр, көч һәм янып торган гайрәт дөньясы анда безнең!»

Тукта әле, кайтып кына керсен, шуларның һәммәсен әйбәтләп сөйләп бирер ул аңа. Ничек карар икән боларга Нурзилә?

Юк! Василның уйларында хаклык һәм киләчәккә карап яшәү бар! Ни хәтле генә кыен булмасын, ул аның белән уртак тел тапмый калмас, барыбер үз ягына аударырга тиеш ул Нурзиләне.

Нурзилә эшеннән иртәрәк кайтты. Ринатны күршеләрендә калдырып, кинога да барып килделәр. Аннан калган вакыт гел аларның икесенеке булды. Нурзилә бертуктаусыз сөйләде дә сөйләде. Башка чакларда да ул үзенең эшендә булган һәр төрле яңалыклар турында кайткан саен дәртләнеп, аеруча бер кайнарлык белән сөйли торган иде. Бүген бигрәк тә шулай булды. Ул якындагы бер авылдан килгән, яше илледән ашкан бер хатынның игезәк бала тудыруын җентекләп сөйләде. Бу хатын үзе колхозда кош караучы булып эшли икән. Тик менә хатын өйләнгән улыннан, кияүгә чыккан кызларыннан бик тә ояла икән. Җитмәсә оныклары... Әле кичә генә шул хатынны алырга авылдан ире килгән. Алтмышка житеп килә торган карт икән анысы да. Нечкә генә ак мыек, таза гәүдәле кеше. Аларны бөтен больницада эшләүчеләр хөрмәтләп озатып калганнар. Шунда иренә теге игезәк бала тудырган апа әйтә икән: «Бигрәк читен инде кеше алдында, шушы яшьтә кем бала китерә инде, улларыма, кызларыма ничек кайтып күренім»,— ди икән.

Ире аптырап, югалып калмаган: «Алар тудыралар ич, синен кай жирең алардан ким? Әле тагы бер малай алып кайтырсың исән булсак. Картлык көнебезгә терәк булырлар»,— ди икән. Нурзилә тагы да шуңарга охшашлырак кыйссалар сөйләп, ире белән үзенең хисләрен уртаклашкан итте.

Иртәнге чәй янында китү-күченү турында берсе дә сүз ачмады. Һәркайсы көтте. Васил, Нурзиләгә сынаулы рәвештә карап алгач, телефон трубкасына үрелде. Такси сорады. Бу чагында инде Нурзиләнең күзләрендә моң һәм яктылык артты кебек. Ул иренә карап саран гына елмайды да киенә башлады. Аннары икәүләп ишектән чыктылар. Янтыклары шакмаклы, елкылдап торган өр-яңа җинел машина алар торган йорт подъезды алдына килеп туктаган иде инде. Васил белән Нурзилә парлап артка утырдылар. Тигез шома юлдан суда йөзгән шикелле бару рәхәт тә, күңелле дә иде. Ләкин юлның бик кыска булуы икесен дә кинәт айнытып җибәргәндәй булды.

Нурзилә Василны самолетка утыртып, кул селки-селки озатып калды. Василның күңелендә юксыну тойгылары көчле булса да, Нурзиләнең болай җылы озатуы аның өмет канатларын ныгытып җибәргәндәй булды. Әле аларның яшь тормышлары алда, хатыны моны аңлар, ул аны аңлый да, аннары һәммәсе дә үз тәртибенә утырыр,— дип уй йөртте Васил.

Казанга килеп төшкәч тә озак көтәргә туры килмәде. Башка эчкәре районнарга самолетлар йөри башлаган кебек, Яңа Наратлыга да юллар ачылган иде инде. Самолетта Яңа Наратлыга кайтучы тагы берничә кеше бар иде. Барысы да диярлек яшьләр, алар арасында өч кыз.

Хәзергечә тар балаклы чалбар, кыска җылы куртка кигән бу яшь кызлар кешеләрнен әле берсенә, әле икенчесенә күзләрен йөртәләр иде. Чүмәлә кебек чәчен кабартып куйганы әле самолет киткәнче үк Василның кая баруын сораган иде. Кызлар Яңа Наратлыга эшкә баралар икән.

Васил янәшәсендәге буш креслога бераү килеп утырды:

— Гафу итегез, сез төзелештәнме?

— Әйе.

— Яңа Наратлы?..

— Әйе.

Бу ят кеше буыннары шешенке калын кулын Василга сузды.

— Таныш булыйк: Кукушкин Сергей Сидорович.

— Безнең якка барасызмыни?

— Әйе, менә чакыру кәгазе.

Ул телеграмма күрсәтте. Анда баш инженер Юлдашев кул куйган иде.

Кукушкинның кыяфәте кызык кына, әллә ничек кенә, аңа карагач көлемсерәми түзмисең. Чыннан да юнып төшерәсе урыннары бар сыман аның: бит алмалары калкып салынып тора, ияк очлары да шулайрак, пальтосын төртеп эче дә бүлтәеп тора. Менә шушы яклары белән ничектер көлке күренә иде ул. Василның ялгыз калып, уйланып барырга теләвен башына да китермичә, ул ихлас күңелдән сөйләшмәкче иде шикелле. Шул кыска гына танышудан соң бер-берсен бик күптән белгән кешеләр шикелле тезеп китте:

— Мин бит Павловскида да, Красноярскида да булган кеше. Ул яклар таныш миңа. Ике электростанциянең утларын гөлт итеп кабындырдык без. Менә хәзер инде сезнең белән дә контактка керергә туры киләчәк. Сезнең анда зур колачлы төзелеш бара диләр. Үзәк газеталарда укып гаҗәпкә калдым. Дәртләнеп барам мин анда. Баштарак кыенлыклар булмый калмас, билгеле.— Кукушкин тәмләп кенә, авыз суларын корытып сөйләгән җиреннән сүзен икенчегә борды: — Зариф Салихович ничек яши анда, саулык-сәламәтлек яклары ничек аның? — Ул, үзенең сорауларына тыңлаучының җавап кайтаруын көтеп тормастан, тагы дәвам итте: — Минем, югыйсә, яшь ягы да байтак инде. Ләкин бер урында озак торырга яратмыйм. Гадәт! Һаваны аны ешрак алмаштырып тору яхшырак. Бер урында озак эшләсәң, бер урындыкта күп утырсаң, мүкләнә башлыйсың. Хөрмәтле Зариф Салихович та чакырып торгач, ник бармаска! — Кукушкин тагы сорап куйды.— Анда сезнең квартира мәсьәләсе кыенрактыр инде. Һәр яңа төзелештә шулайрак була инде баштарак. Сез ничегрәк урнаштыгыз?

— Гостиницада торам,— дип әйтеп кала алды Васил, Кукушкинга карамаска тырышып. Түземсезлек белән аның сүздән туктавын көтә иде. Туктатырсың! Бар икән армый торган тел, бар икән сүз тегермәненнән туймаган бәндә... Васил аңарга туктарга кушып тупас сүз әйтүдән көч-хәл белән тыелып калды. Алар идарәсе участокларына да белгечләр кирәк иде. Васил бу турыда Кукушкинга әйтергә теләсә дә, тегенең әлдереп алып, әллә ниләр такылдаячагын уена китерде дә ул турыда эндәшмәүне артыграк санады.

Самолет кинәт кенә дырык итеп аска төшеп китте дә кешеләрнең йөрәкләре оеп киткәндәй булды. Күрәсең, һава чокырына, һава бушлыгына туры килде.

Васил тәрәзәдән аска карады. Менә аның каршысында үзенең кечкенә өйләре, агачлары һәм идәндә яткан каеш кебек тар юллары белән «тау» үсә, янтаеп күтәрелә башлады. Димәк, килеп җиттеләр, самолет тукталышка бара. Яңа Наратлыга якынлашкан саен Василның башындагы бүтән төрле уйлар артка чигенә башлады.

## Икенче бүлек

### I

Җир-су кибеп килгән чаклар.

Агачлар яфрак яра, җир өстен сафландыргыч яшеллек каплый һәм табигатьнең матурлыгы артканнан арта бара. Яз күге, барлык тарафларга зәңгәр яулык болгап торган шикелле, күңелләргә рәхәт сала. Шундый кояшлы якты көндә район үзәгеннән кайтып килүче Солтан Сабиров, поселокка җиткәндәрәк, бәбкәле каз күрде дә машинадан төшеп калырга ашыкты. Бер бөкре әби чирәмлектә казлар саклап йөри. Нинди матур, нинди нәфис һәм нинди сокландыргыч каз бәбкәләре! Бер караганда сары тал бөреләрен, бер караганда сары чәчәкләрне хәтерләтәләр алар. Солтан Сабиров озак карап торды бәбкәләргә. Бәләкәй чакта аның да каз бәбкәләре саклап йөргән чаклары булды ич. Ул вакытларда мондый язгы көннәрдә рәтләп уку да булмый. Бала-чага якындагы болынлыкта мәш килә торган иде. Хәзер инде менә бәбкәләрне әбиләр саклый. Кая ул бала-чагага дәрестән бүлену? Укулар да җиңел түгел, җитмәсә өйгә тау хәтле өеп эш җибәрәләр. Уйнарсың! Хәзерге балалар анадан туганда ук җидене бетереп туалар дип юкка әйтмиләр булыр...

Толымын киң җәйгән Тын елга болынлыктан үз ярына төшкән иде инде. Әллә ничек кенә күнеле нечкәреп китте Солтанның. Ташу артыннан бака кашыгы җыюлар, аякларының ярылып, чебиләп бетүләре... Ул гынамы соң әле! Алар бәләкәй чакларда ниләр генә кыланмыйлар иде. Көннәр язга авыша башлау белән үк лапас түбәсендәге саламда кызынып ята торганнар иде. Шулай бер елны, әле карлар эреп бетмәс борын, кыш буе пешеп яткан тирес өеме янындагы чокырга бик иртә су җыелды. Малайлар лапас түбәсендә кызынып яттылар да, кайсыдыр шунда «су керергә» кыстый башлады. Солтан иң беренчеләрдән булып, ыштан-күлмәкләрен салып, тирес базына чумды. Бу кыланышның рәхәте ни чамада булгандыр, мәгәр малайларны әниләренең кычкырта-кычкырта тирес базыннан сөйрәп чыгарулары һәм арт якларын чәбәкли-чәбәкли өйләренә алып кайтулары һич онытылмаслык булып аның хәтерендә калды. Менә бит нинди чаклар булган, дип, башын болгап көлеп куйды ул.

Аның туган авылы Яңа Наратлыдан ерак түгел. Шушы якларда туып-үскән кеше булгангадыр инде, Тын елга буендагы олы үзгәрешләр өчен аның кебек куанучы кеше бар микән? Каз бәбкәләре янынннан киткәч, Солтан төзелеш идарәсе йортына керде.

Урта гәүдәле, текә маңгайлы, кешеләр белән ягымлы итеп сөйләшә белә торган бу кеше башта үзенең туган авылы Акъярда укытучы, аннан соң дүрт-биш ел партоешма секретаре булып эшләде. Соңыннан аны райком инструкторы итеп алдылар. Бу вазифасын үтәгәндә дә ана үзенең туган авылында бик сирәк булырга туры килә иде. Югары партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, Солтан Сабиров шул ук районда райкомның берәр бүлегендә эшләүне өмет итте. Ләкин аның бу уйлары гамәлгә ашмый калды. Әле күптән түгел, райком тәкъдиме буенча, төзелеш коммунистлары аны партком секретаре итеп сайлап куйдылар. Аның да квартир яклары башка бик күпләрнеке кебек үк җайланмаган хәлдә иде. Ул башта үзләренә чыбык очы кадәр генә кардәш тигән берәүләрдә торды. Әмма хуҗаның хатыны бала тудыргач, болай да әллә ни иркен булмаган өй тагын да тарайды. Шуннан соң ул гостиницага күчте.

Васил кайтып кергәндә кояш баеп килә иде инде. Ул үзе тора торган бүлмәдә партком секретарен күргәч, яхшы ук гаҗәпләнә калды. Ничек болай булырга мөмкин әле? Васил белән бергә торучы карт инженер каядыр командировкага китеп барган иде. Бүлмәдәге өченче кеше Ген-

надий исемле булып, Васил аны бик сирәк күрә, чөнки бу кеше ул кайтканда өйдә булмый, соң гына кайтып ята. Дөрес, иртән бергә-бергә торып эшкә китәләр. Васил тиз генә шуларны уеннан кичереп, Солтан Сабиров белән барып күреште.

— Яхшы гына торумы, Солтан Сабирович?

— Сезнең үз хәлләрегез ничек? — дип кызыксынды Солтан.

Васил гаиләсе, әти-әнисе турында тәфсилле рәвештә сөйләп бирде. Аннары партком секретаренең монда ничек килеп чыгуы турында кызыксынып сораштырды.

— Әйе, күченергә туры килде. Үзем монда, семья кәҗә авылында дигән кебегрәк килеп чыга инде бу.

— Шулай шул, төзелешнең шундый кырыс яклары бар инде аның,— дип раслады Васил. Аннары кинәт сорап куйды:— Ниндирәк яңалыклар бар?

— Сез белмәгән әллә ни яңалыклар юк,— диде Солтан.— Хәзер бетон гадәттәгедән күбрәк салына. Җайланмалар тоткарсыз эшли. Беренче труба өчен нигез казылып бетте, аны да бетонлау бара.

Солтан, бүлмәнең урта бер җирендәге өстәлгә якынрак килеп утыргач, сүзне дәвам иттерде:

— Тик менә цемент мәсьәләсендә һаман кыенлык.

— Вагъдә иткәннәр иде ич.

— Үтәргә генә ашыкмыйлар тик. Бөтенсоюз комсомол төзелешенә карата моны һич гафу ителерлек хәл дип санап булмый. Чарасына керешми булмас,— диде Солтан.— Без иптәш Никитин белән болай уйлашкан идек, ВЛКСМ Үзәк Комитетына телеграмма сугып карыйбыз. Аларның ярдәме тими калмас.

Васил беркадәр тын торгач әйтте:

— Хәзер бит илнең барлык төзелешләрендә дә яшьләр эшли. Белмим, барысына да комсомол цемент җиткерә алырмы икән?

— Ник җиткермәсен, үзәк оешманың ярдәме тими калмас, менә күреп торырсыз.

— Берүк уң булсын,— диде Васил.

Партком секретаренең Василга әйтәсе сүзләре тагы да юк түгел иде. Төзелештә узган елгы күзгә күренми торган кимчелекләрнең быел кабатланмавы, эшнең яхшырак оештырылуы турында әйтергә теләгән иде ул. Ләкин әлегә бу хакта сүз ачмауны артыграк санап тел тибрәтмәде. Ни әйтсәң дә мактарга иртә әле, дип уйлады. Аның күңелен аннан башка да борчыган нәрсәләр җитәрлек иде. Менә шуларның һәммәсе турында ничегрәк итеп сүз кузгатып җибәрергә соң аңа? Инде күрше тирә-якта язгы чәчү башланганга да ничә көннәр үтте. Шул чәчү өсләре җиттеме, аны урында тыеп тора алмыйсың инде. Солтанның авылга барасы килә, мондый чәчү өсләрендә авылны күрә алмый түзә торганнардан түгел иде ул. Ләкин ялгызы гына ничектер читенсенә иде.

Шушы көннәрдә төзелеш начальнигы Никитин белән колхозларга шефлык итү турында сөйләшкәннәр иде. Тын елга буена утырган, берничә авылны берләштергән Акъяр колхозы җирләренә барып кайтасы бар иде. Колхоздан үзләре килгәнче, бу хакта төзелештәгеләргә кайгыртырга кирәктер. Шуны истә тотып Солтан Василга да сүз ирештерде. Васил аның әйткәннәренә каршы килмәде. Шушы арада икәүләп Акъярга барып кайтырга булдылар.

Озакламый ул көн килеп тә җитте.

## 2

Дөньяда күпне күргән «газик» сикәлтәле болын юлыннан алга әлдерде. Һәрвакыт хәрәкәттә булу, ел буена чокыр-чакырлы юлларны таптау аны хәтсез картайткан, кояш нурлары машинаның төсен яхшы ук уңдыр-

ган иде. Шоферның ниндидер кичектергесез эше булганга, Васил Сафин рульгә үзе утырды. Аның белән янәшә партком секретаре Солтан Сабиров урын алды. Әле аларның икәүдән икәү генә машинада беренче тапкыр булулары. Әрсез «газик» хуҗаның каулавына сабыр гына буйсына. Болынны тиз генә үттеләр. Әле яңарак кына чәчү тәмамланган басуга кереп, бик нык сикертә башлагач, Васил тизлекне әкренәйтте. Анда-санда бер-ике сүз алышуны искә алмаганда, һәр икесе дә тын бардылар. Василга калса, аның өчен монда һәр күренеш яңа, сыртланып торган калкулыклар да, сыек яшел төскә манылган үзәнлекләр дә яңа иде. Васил әледән-әле тирә-якка карашын салып барды. Уҗым басуына килеп кергәч, юл әйбәтрәк булып китте. Биредә инде тагы да ямьлерәк күренеш: куе саф яшеллек чын матурлык булып үз алдына аерылып тора. Уҗымнар, үрдәк керсә, үрдәкнең дә башы гына күренерлек иде.

Солтан арыш игеннәренең әйбәт кышлавына һәм басуларны тутырып, балкып утыруына сөенеп бетә алмады. Бала чактан таныш бу кырлар, бу җирләрдә аның да эзләре бар. Сугыштан соңгы авыр елларда шушы кырларда пар ат җигеп сабан сөрүләре, тырма тырмалаулары, җилянгырга карамыйча һаман саен кырда кайнашуы бер-бер артлы хәтеренә килде. Ул еллар күптән артта калды инде. Хәзер атлар да ул чагындагы кебек төп эш көчләре түгел, аларның баш исәбе дә бик нык кимеде, үзләре дә хуҗалыктагы вак-төяк эшләрдә генә файдаланылалар. Солтан шуларны башыннан кичереп, карашын алга юнәлтте. Сабан ашлыклары әле тишелеп кенә килә, басуларның күп өлеше каралып ята. Шактый еракта сыек яшеллек йөгертелгән бер төстә урман күренә. Юлның сул ягында, аста, бөдрә әрәмәле киң болын җәйрәп ята. Бу турыда тирән ярлары астына яшеренгән Тын елга борылмалы тугайлы урыннарда ара-тирә күзгә чагылгалап китә. Аның ялтыр тонык суы, каяндыр кинәт кенә пәйда булган зур көзге кисәге шикелле, күзләрне камаштыра. Солтанга боларның һәммәсе дә таныш. Сандугачлар концертыннан башлар әйләнгән чаклар була иде болын әрәмәләрендә.

Шомыртлыклар!

Алар бит әллә кайларгача сузылалар, очына-кырыена чыгарлык түгел. Менә тиздән шомыртлыклар катык кебек ап-ак чәчәк белән капланыр. Мондагы һаваның сафлыгы, татлылыгы ул чагында берни белән дә чагыштырырлык булмый инде. Тын елга буена утырган авыллар сабан туйларын да шул гүзәл болыннар куенында үткәрәләр.

Нинди генә истәлекләре юк аның монда! Шунда ул беренче тапкыр йөгерешкә барып, икенчеме-өченчеме малай булып килде. Аңа суган сарысына манган ике йомырка тоттырдылар. Шул болынга башлаш чишмә тавы буена ул үзе кебек яшь-җилбәзәкләр белән кичке уеннарга чыкты. Шунда беренче мәртәбә кызлар кулын тотты. Солтанга ничектер ямансу булып китте. Ул якын елларда болын һәм әрәмәлекләрнең су астында калачагын, ул гына да түгел, аның туган авылы Акъярның да Тын елга буена утырган башка авыллар белән бергә күчереләчәген уена китергәч, үз алдына каушап калды. Күңелендә туган юксыну хисен Василга әйтергә ничектер базмады.

Шундый зур төзелеш! Элек гомергә чабата һәм сукадан башка берни күрмәгән бу караңгы якларга хәзер шәһәр атлап килүе никадәр күңелле булмасын, туган авылы Акъярның күчүе турындагы уй Солтанны шулай да борчый иде. Әкренләп аның башындагы бер уйны икенчесе алмаштыра барды: хәзер шулай. Ике меңенче елларда ниләр булыр? Атларны тракторлар, автомашиналар алыштырды. Еллар үткәч, боларын да башка тагын да уңайлырак машиналар алмаштырмасмы? Әйтик, кеше әллә кайдагы бинада пультта идарә итеп кенә утырыр. Ул чагында бары да тигез булыр. Авыл исә шәһәрнең бер өлешенә әйләнер. Тормыш, көнкүреш, культура һәркайда бер төсле булыр. Тик менә кешенең гомере кыскарак. Аның гомере дөнья артыннан куып үтә дә китә. Җитмәсә,

сугышлар... Минә ике меңенче еллар житәр... Безнең күбебез булмас та. Аны безнең балалар күрер, оныкларыбыз яшәр ул заманнарда. Кайсыдыр бер акыллысы әйткән ич: «Кеше тудымы, ул инде үлде, дигән сүз». Бәгырьгә үтәрлек авыр сүз, әмма аның дөреслеге аксиома. Әйе, әле алда яшисе булган кебек, үләсе дә бар... Юк, бу турыда уйламаска кирәк. Тере кеше тормыш һәм яшәү турында гына уйларга тиеш...

Солтан бу уйларны башыннан үткәргәндә күзләрен бер ачты, бер йомды. Аннары, ничек кенә булмасын, аларны онытырга тырышты.

Җимерек читәнле, каралып беткән салам түбәле ташландык бер каралтыга житүгә, Васил сорап куйды:

— Монысы нәрсә тагы?

— Колхозлар оешкач та салынган беренче ферма каралтысы бу.

— Аны соң ник торгызалар?

— Куллары житми, күрәсең.

— Кирәкле агачларын җыеп аласы да яндырасы калганын.

— Югарыдан күрсәтмә юк, мөгаен,— дип көлемсерәде Солтан.

Тар гына инеш аркылы салынган күпергә житәрәк, Васил машинаны туктатты, радиаторга су саласы бар иде. Шунда райүзәк ягыннан тарантас белән килүче бер атлы күренде. Ат бер юырта, бер әкренли, бер туктый. Мәзәк аңа. Берничә минут үтүгә инде ул күпергә якынлашты. Тарантаска икәү утырганнар — берсе олы кеше, икенчесе какча гына бер малай. Тиздән колакларны кытыклап карлыккан җыр тавышы яңгырап китте:

Алай итәбез генә,
Болай итәбез генә.
Колхоз — диңгез,
Без — корабль,
Дөмбердәтәбез генә...
Дөмбердәтәбез генә...

Минә җыр ияләре күпер янына килеп тә життеләр. Малай, дилбегәне тоткан килеш, атны юлның икенче ягына борды. Тарантастан бер аягы салынып төшкән, башы икенче якка кыйгайган, фуражкасын басып кигән кызыл борынлы кеше тагы көйләп җибәрде:

Әй, дөнья, дөнья.
Өй саен мәрья,
Мәрья саен мич,
Көн дә булса кич...

Авылдашы булса да, исерек тавышыннан бу кешене танырлык түгел иде. Якынрак баргач, тумпак кызыл борынлы, мыеклы бу адәмне Солтан таныды. Исерек зур кара портфелен ике куллап кочаклап утырган да болганчык күзләре белән нидер эзләгәндәй карана иде. Аннары ул арбадан төште дә туры басарга тырышып «газик» янына килде:

— Солтан энем, син икәнсең әле бу-уу!.. Бик ару-уу гынамы?

— Ә үзегез ничегрәк соң?

— Безнең, ни, апаем, үзең күрәсең инде. Әле менә районнан кайтып килгәнски.— Фарукның теле көрмәшә иде. Ул гадәтенчә тартып-сузып дәвам итте:— Берьюлы ике куян аттым мин, апаем. Ничекме? Менә ничек: иң элек банкыдан труддингә өләшергә акча алдым. Анда минем блат. Башкалар шикелле чиратта торасы юк. Кассирның үз янына арт ишектән керәм дә алам. Әйе, берьюлы ике куян аттым: акча да алдым, менә күрәсез, культурный ял итеп тә кайтам. Бетте-китте, апаем.

Фарукның колхоз хисапчысы булып эшләвен Солтан белсә дә, үзе авылда торган чакларында һәм аннан соң да аның болай аракы эчеп кәефләнеп йөргәнен бер дә күргәне юк иде. Аннары аның җыры да бик мәзәк, көлке дә, тозсыз да иде. Солтан, чыраендагы көлемсерәвен яшерә алмастан, Фарукка сүз кушты:

— Дөмбердәтәбез дисең, алайса, Фарук абзый?

— Дөнья булгач була инде, апаем. Безгә хәтле дә дөмбердәткәннәр, без дә дөмбердәтеп калыйк. Бездән соң да дөмбердәтерләр. Бу дөнья дигәнең әлмисәхтән бирле шулай корылган инде ул. нииндидер Котбетдин әйтмешли.

Бераздан инде Солтанның иренендәге елмаюы юкка чыккан иде.

— Шулай да акча белән сак кыланырга кирәк, Фарук абзый.

Теге, Солтанга әйтеп бетерергә дә бирмичә, үзенекен итте:

— Сакланмаган кая! Күрәсең, ничек тоткан мин аны. Килеп карасын бирәрсе, мин аның...— Фарук тарантасындагы салам астыннан тимер кендек чыгарып күрсәтте.

Колхозның үзәк авылы Акъярга килеп керделәр. Аларга идарәдә озак көтәргә туры килмәде, председатель дә килеп житте. Бу урта гәүдәле, киң жилкәле, ике сүзнең берендә диярлек «значится» сүзен кыстырып сөйләшергә ярата торган кешене Солтан күп еллардан бирле белә. Ә Васил өчен ул яңа кеше, аларның бер-берсен әле беренче мәртәбә күрүләре иде. Үз урынына түргә барып утырганчы, председатель килүчеләр белән кул биреп күреште:

— Безнең шефлар килгән, күптән кирәк иде. Әйдәгез, дуслар, рәхим итеп утырышыгыз.

— Ну, шуннан ниләр кырып яту, иптәш Нәриманов? — дип сүз башлады Солтан. Ул иң элек аны Васил белән таныштырды.

Нәриманов, куе кашларын сикерткәләп, беравык елмаеп торганнан соң, серле итеп бер Солтанга, бер Василга карап алды да мәгънәле генә итеп әйтте:

— Значится, килдегез. Кайдан сүтә башлыйбыз йомгакны?

Васил белән Солтан бер-берсенә карашып алдылар.

— То есть нишлибез? Хужалык белән таныша торыйк.

Василның бу сүзләрен ишетмәгәндәй, Нәриманов үз сүзендә булды:

— Әле тагы зур бер иптәш киләсе иде.

— Кем? — дип сорады Васил.

— Андрей Акимович үзе. Иртән телефоннан сөйләшкән идек. Ул менә-менә килеп чыгарга тиеш.

— Без аңа йөреп кайткач үз фикерләребезне әйтмәкче булган идек. Үзе килсә бигрәк тә шәп,— диде Солтан.

Председатель кабинетында хужалыкка кагылышлы эшләр, хәлләр турында сөйләшеп утырганда, урамда төзелеш башлыгының ялтырап торган кара машинасы күренде һәм тиздән ул үзе дә нык адымнар белән председатель бүлмәсенә килеп керде. Жылы гына күрештеләр. Никитинның да монда беренче тапкыр килүе икән. Ул ашыкмыйча гына стеналарга күзен йөртеп чыкты. Аннары өстәл тирәсен әйләндереп утырган кешеләргә сораулы бер караш ташлады да башлап китте:

— Менә, алдан сүз берләшкән шикелле, жыелдык без монда. Димәк, житешкән мәсьәлә. Ничек уйлыйсыз, иптәш Нәриманов?

— Минемчә дә шулай,— диде председатель.

Солтан папирос чыгарып көйрәтте:

— Без Васил Закирович белән башта монда уртак бер фикергә килеп, соңыннан сезгә житкермәкче идек,— диде ул.

— Бергә-бергә әйбәтрәк булыр,— диде Никитин.

Дөресен генә әйткәндә, колхоз председателе Нәриманов, төзелеш житәкчеләренең кинәт жыелышып килеп төшүләреннән беркадәр каушап та калды. Каушамаслык та түгел — бу көннәрдә ул бик хәтәр борчылып йөрде. Ни хәтле болынлык су астында кала, Тын елга буендагы уңдырышлы иң әйбәт жирләрнең шактый өлешен су басачак. Ул гынамы соң әле! Колхозның өч авылы яр буеннан күчерелергә тиеш. Тик алардан су агымының иң югары башындагысын гына күчерү-күчермәү әлегәчә хәл кылынып житмәгән иде. Юантык гәүдәле, ияге салыныбрак торган

Нәриманов җинел генә урынынннан кузгалды, ян як стенага куелган колхоз җирләре картасы янына барып басты. Йонлач юантык бармакларын карта өстендә йөртә-йөртә сөйли башлады:

— Җир белән күк арасында эленеп торган бер халәттәрәк инде без хәзер, значится. Ни хәтле төзи башлаган каралтылар ярты юлда кала... Чынын гына әйтсәң, бер эшкә кул барышлы түгел...

Васил, бу сүзләрне ишеткәч, иңбашларын сикертеп куйды. Солтан ни әйтергә белми читкә карады. Тик Никитин гына югалып калмады, үзенең калын тавышы белән көлеп куйды да әкрен генә тамак кырды. Башта салмак һәм йомшак аваз белән сөйләсә, торган саен тавышын күтәрә барды:

— Урындагы тар мәнфәгатьләрне беренче планга куеп, зур эшләрне кичектереп торырга өндисез дисәм, хәтерегез калыр, иптәш Нәриманов. Гасырлар буенча йоклап яткан билгесез бер елга буенда шундый гигант төзелә. Аның куәте, беләсезме, күпме булачак? Миллион ике йөз мең киловатт... Аның әле икенче чираты да булачак. Бу бит Европада иң зур станцияләрнең берсе дигән сүз.— Төзелеш башлыгы, үзенең маңгаена чыккан борчак-борчак тирләрне дә сизмичә, болай да зәңгәр төтен белән тулган тынчу һаваны тагын да куерта төшеп, папирос кабызгач, дәвам итте:— Аннары бит барлык расходларны дәүләт күтәрә. Аңлыйм, бер күнеккән җирдән күченеп йөрү ансат эш түгел. Бигрәк тә игенче кешегә. Ләкин шундый зур үзгәрешләр заманында аның белән генә хисаплашып торып булмый бит инде. Задача номер один...

— Һәммәсен дә аңлыйм,— дип сүз кыстырды Нәриманов.— Дәүләтебезнең дә андый чыгымнары аз түгел. Ул тиклесен дә истән чыгарырга ярамый, Андрей Акимович.

— Әлбәттә, анысы шулай. Ләкин бер тиенне кызганып ун сумны җилгә очырып булмый. Әйе, иптәш Нәриманов, шунысын да онытмаска кирәктер.

— Күченү безнең үсешне тоткарлаячак ич, Андрей Акимович.

— Булышырбыз. Без сезне үгәйсетеп караучылардан түгел.

— Яңа Наратлыдагы сыман бетон ярлар эшләп котылып булмасмы су басудан? Җирләр бик кызганыч.

Бу юлы моңарчы тын утырган Васил телгә килде:

— Булмый, проект, менә карагыз,— ул сумкасыннан карта чыгарды.

Никитин яңадан, ләкин инде тыныч рәвештә һәм басынкы тавыш белән үзенең сүз йомгагын алга сузды:

— Сезнең авыллар бигрәк яр буена урнашканнар шул. Түбән урамнарны ташу вакытында болай да су баса икән.

— Анысы дөрес,— диде Нәриманов.

— Шулай булгач?

— Суы ун метрга күтәреләчәк Тын елганың, менә нәрсәдән килеп чыга ул күченү,— дип өстәде Васил.

Председатель Нәриманов ияк очларын кашып куйды, кашларын кул аркасы белән сыпырды. Аның әле уң, әле сул күз кабагы әледән-әле тартып торганы сизелә иде. Күрәсең, күңел тынычсызлыгы гасабиландыра иде аны. Бер арада:

— Ә Күлбаш авылының язмышы ничек булачак? — дип сорау бирде Нәриманов.

— Ул да күчәргә тиеш. Хәзер мәсьәлә ачыкланды,— диде Никитин.

— Ә күл үзе?

— Күл сусаклагыч белән тоташачак.

Зурлыгы ун гектардан ким булмаган «Акчарлак күле» дип аталган күе камышлы бу күлдә Акъяр колхозы моннан берничә еллар элек карп балыклары үрчетеп, соңгы елларда аннан табыш та ала башлаган иде. Хуҗалыкта өч кешелек махсус балыкчылар звеносы да бар. Шуны күздә тотып булса кирәк, Нәриманов тагы кашларын җыерды:

— Ә балыклар нишләр безнең?

— Нишләсеннәр? Үрчерләр. Балыкка аңа су гына булсын. Без әле карп үрчетү белән генә калмабыз. Башка төрле кыйммәтле балыклар да китертербез сусаклагычка,— диде Никитин.

Төзелеш башлыгы белән председательнең бәхәсле сөйләшүләрен җитди рәвештә тыңлап утырган Солтан да сүзгә катышты:

— Ул чагында безгә балыкчылар бригадасы төзергә туры килер инде, авылдаш.

— Кем белә! — дип кулларын җәйде Нәриманов.

Нәриманов, электр станциясе төзелүгә бер яктан куанса, үзенә турыдан-туры кагылган күченү мәсьәләләрен күздә тотып, шактый көяләнә, шактый борчыла иде. Аныңча, ясалма ярлар эшләп, бик күп җирләрне су басудан саклап калырга мөмкин булыр сыман. Бу турыда ул район оешмалары белән дә берничә тапкыр сөйләшеп, сүз көрәштереп карады. Хикмәт чыкмагач, авыл хуҗалыгы министрлыгына барып, тиешле кешеләр белән сөйләште. Су басачак болын һәм чәчүлекләрне саклап калу өчен дамба — ясалма ярлар төзергә кирәклеген әйтте. Ләкин аның бу сораулары бер инстанциядә дә канәгатьләндерелмәде. Шуннан соң ул, бөтенләй кул селтәп, берничә вакытлар башын түбән салып йөрде. Тагы кабынды, тагы сүнде. Әле менә төзелеш җитәкчеләре белән сөйләшкәч, бу мәсьәләдә үзенең тәмам көчсез икәнен тоеп, беразга бөтенләй тугарылып калгандай булды. Ләкин үзен тиз кулга алды:

— Бу эшләрнең үзен аклаганын да бик яхшы беләм. Әмма ничек кенә булмасын, бер яктан без бик зур хата җибәрәбез.

— Нинди хата? — дип сорады Солтан.

— Шундый хата: кай чагында каш ясыйм дип күз чыгарабыз. Ни хәтле печәнлекләр су астында кала. Суны малга ашатып булмый бит. Күчү-күченүләргә дәүләтнең ни хәтле акчасы тотыла.

— Шунсыз булмый,— диде Васил.

Нәриманов өстәлгә карап дәвам итте:

— Беләм инде, сез торасыз да проект дисез. Анысын да безнең кебек ике куллы, ике аяклы кешеләр төзи бит аның. Әйтик, иң элек урынга килеп карап, бик уйлап кына, хуҗаларча гына дамбалар өюне планлаштырып булмас идемени? Әнә Казанка буенда шулай эшләгәннәр ич.

— Анда икенче хәл,— диде Васил.

— Ул ничек алай инде?

— Шәһәр. Аны күчерә башласаң, расходын хисаплап бетерә алмассың.

— Ә монда?

— Монда күләм кечкенә.

— Бер дә алай түгел,— дип каршы төште Васил сүзләренә Нәриманов.

Никитин бер папиросын тартып бетереп, икенчесен кабызды, маңгай тирләрен сөртеп алды. Аннары, җыелышларында өйрәнгән гадәтенчә булса кирәк, бер кулын күтәрде:

— Бәхәсне туктатсак та ярар. Һаман бер балык башы дигәндәй...

Нәриманов, таркалган уйларын җыеп, төзелеш кешеләренә тагы берничә тешле-тешле сорау бирде. Никитин исә аңа, колхоз хуҗалыгыннан тыш, һәр колхозчының йорт-җире, нинди каралтылары барлыгы һәм аларның бәяләрен, билгеле, хуҗалар белән килешеп, язып, барлап чыгарга тәкъдим итте. Бу эшләрне башкарганда, әлбәттә, төзелештән дә вәкилләр киләчәген әйтте. Нәримановка бары тик Никитин әйткәннәр белән килешергә генә калды.

Шуңа дип атап килгәч инде шефлыкка кагылышлы төп мәсьәләләрне дә ачыклап китәргә кирәк иде.

Барысы да диярлек шул турыда уй йөрттеләр. Шул ук председатель кабинетында тагы әңгәмә дәвам итте. Алар шулай киңәшеп утырганда

Василларга куперда очраган салмыш кеше — хисапчы Фарук кереп, ниндидер кәгазьләргә кул куйдырды. Аны күргәч, «дөмбердәтәбез генә» сүзе исләренә төшеп, Васил белән Солтан елмаешып куйдылар.

Берәр мәсьәләне хәл кылган чагында Никитин үзе катнаша калса, дилбегәне үз кулына тотарга ярата иде. Монда да шулай булды. Әлеге шефлык мәсьәләсенә кайтып, ул председательгә мөрәҗәгать итте:

— Әгәр шулай әйтергә ярасa, хәзергә монда бик иске кешеләр түгел, яңа кешеләр дисәк тә зур ялгыш китмәс кебек. Безнең урында утырган иптәшләр сезне бит инде безгә кадәр үк шефка алган булганнар. Яле тыңлап карыйк, алар ниләр эшләде соң? Без шуңа ялгап алып китәрбез.

Нәриманов, бу сорауга ни дип әйтергә дә белмичә югалып калгандай, башта тын торды. Аннары шефларның нәрсә эшләгәннәрен сөйләп күрсәтте. Әллә ни ерак китә алмаганнар икән шул.

Никитин кешеләрнең һәммәсенә сынаулы караш ташлап карап торды да үз фикерен әйтергә ашыкты:

— Чөгендер уташып яки ашлык тапшырганда машиналар биреп ярдәм итү кебек эшләр белән булышу ярый. Ләкин шефлык моның белән генә чикләнсә, ул әллә ни зур үсеш булмас, дуслар. Күп булса, бер елдан соң сез көченергә тиеш булырсыз. Шуларны искә алып... без бу турыда үзебезнең коллективта сөйләшкән идек инде...— Ул Василга карады.— Ягез, Васил Закирович, әйтеп күрсәтегез әле?

Васил ашыкмыйча гына папкасын ачты, күзләре кәгазьгә текәлде, шефлык буенча башкарылырга тиешле эшләрне берәм-берәм санап чыкты. Аны тыңлаганнан соң, Нәримановның ярым чытык йөзе беркадәр ачылып китте.

— Гамәлгә ашканда яхшы чаралар болар, значится,— диде ул. Аннары, үз колакларына үзе ышанмагандай, Васил укыган кайбер юлларны яңадан кабатлап укытты да сүзен дәвам иттерде:— Сыерлар фермасы, ашлык амбарлары салу, механикалаштырылган ындыр табагы кору, клуб... һәммәсе өр-яңадан, таштан, кирпечтән.

Васил хәтсез күп төзү эшләре билгеләнгән исемлекнең берсен Нәримановка тоттырды. Ул нидер әйтергә җыенган иде. Нәриманов аннан алда башлады:

— Шефларның планы шәп! Ләкин болар бит инде бушлай гына булмас!

Монысына Никитин җавап кайтарды:

— Күзләре бик матур икән дип яшь кызларга да бушка прәннек бирмиләр. Ләкин монда сез отасыз. Бердән, көчең расходы, икенчедән, шефлык бурычы. Чыгымнарның иң зур өлешен үзебез капларбыз.

Нәриманов колхозда салына башлап та ташланган берничә объект турында фикер йөртте. Хәер, аларны төзелештән килгән житәкчеләрнең үзләре дә күргәннәр иде инде. Мондый корылмаларның материалларын яңа урынга күчерергә кирәклеге үзеннән-үзе күренеп тора иде. Нәримановча, бик күп эшләр транспортка килеп терәлә. Ул, шуны күздә тотып, житәкчеләрдән машиналар белән ярдәм күрсәтүләрен сорады. Тегеләр кулларыннан килгәннең һәммәсен дә эшләргә булдылар.

Бераздан Нәриманов шефларын тамак ялгап алырга үз өенә чакырды. Берничә минуттан инде аның капка төбендә өч җиңел машина туктап тора иде.

Кояш төшлеккә авышуга, күк битендә берән-сәрән йөзгән болытлар да таралып беттеләр. Ачык аяз зәңгәр күк, якты чырайлы ана кебек, җиргә мәрхәмәтле нурларын түгә башлады. Һава кирәгеннән артык эсселәтеп җибәргәч, пиджакларын салдылар. Председательнең дә өе, авылдагы башка бик күп өйләр кебек, алты почмаклы, шифер түбәле, төзек каралты-куралы, ак мунчалы хуҗалык иде. Өй эчендәге җиһазмөлкәтләр дә заманча — никельле яңа караватлар, җыйнак өстәл-урындыклар һәм телевизор, түр яктагы тәрәзә буенда телефон тора.

Сарык ите белән токмач салып пешерелгән тәмле ашны барсы да яратып ашадылар. Җитмәсә хуҗаның яшь суганнары да өлгергән иде. Ашап туйгач, ишек алдындагы кечкенә бакчага чыгып, бераз ял итеп алырга да өлгерделәр. Никитин татар ашларын бик яратып ашавын монда да әйтми калмады:

— Сездә токмачны аеруча тәмле итеп әзерлиләр. Катыгы бигрәк тә шәп, башларны җиңеләйтеп җибәрә,— дип мактады ул.

Председатель, шефларның иркен күңелле булуларыннан файдаланып калырга теләп, тагы сүз ачты:

— Менә, дуслар, эш нәрсәдә,— дип мөрәҗәгать итте ул аларга.— Без авылны яңача төзәргә телибез. Моның өчен сезнең тагы бер ярдәмегез кирәк булачак.

— Нинди ярдәм? — дип сорады Никитин.

— Белгеч кирәк, инженер кирәк безгә.

— Ул турыда да уйлашырбыз,— дип, Никитин Васил Сафинга карады.

Васил аны-моны әйткәнче Нәриманов тагы җитеште:

— Тәҗрибәле инженер җәмәгать биналарын ничек урнаштыру буенча киңәшләр бирсә, калган ягын үзебезнең егетләр хәл кылырлар иде.

— Бездән эш калмас,— диде Васил.

Озакламый төзелеш башлыгы китеп барды. Васил белән Солтан тагы да кайбер мәсьәләләрне ачыклау өчен Акъярда калдылар.

## 3

Тамчы тама-тама таш тишә дигән кебек, төзелешнең киң колачы инде якындагы авылларга да килеп сугылгач, ачыграк әйткәндә, кучу-күчену мәсьәләсе үзенең бөтен болгавыр мәшәкатьләре белән каршыга килеп баскач, Солтан Сабировның да күңел тынычлыгы югала барды. Нигә болай борчый соң әле аны Акъяр хәлләре? Дөрес, аның Акъярда хәзер кияүдә үзенең ире һәм балалары белән тормыш кичерүче апасыннан башка һичкеме дә юк. Мәгәр, ничек кенә булмасын, якын иде, үз иде аңа туган авылы. Бәлки шуңардан чыгыптыр, Солтанның яңа гына канатланып килгән фикер-уйлары куера башлады. Ул гына да түгел, төзелешнең партком секретаре буларак та, ул бер төзелеш мәнфәгатьләре белән генә чикләнеп кала алмый. Акчарлак күленә килеп җиткәч тә мондый тойгылар аның күңеленнән китмәделәр. Монда Нәриманов колхозның ялтырап торган күксел төстәге «Москвич»ына, Васил белән Солтан әлеге «газик»ка утырып килделәр. Яңа авыл күчәчәк урынны җентекләп карадылар. Дөрес, аларны монда председатель үзе кыстап алып килде. Бу урын хәзергә әле текә ярлар астына качып, мыштым гына агып яткан Тын елгадан дүрт километрлар ераклыкта, калкулыкны узгач башлана торган тигез урында иде. Әлегә анда — иген кырлары. Тигезлекнең көнбатыш ягында берничә урында өзек-өзек урманнар китә.

Нәриманов, кулларын каш өстенә куеп, иң элек бер тарафка, аннары икенче тарафка карады да әйтә салды:

— Табигате матур, иркен урын. Шушында инде безнең яңа авыл үсеп чыгар.

Солтан, башын кагып аның әйткәннәре белән килешкәннән соң. сорады:

— Ә бүтән өч авылның язмышы ничек?

— Камышлыны урман итәгенә күчерергә туры килер. Ә Яңа Бүләк белән Артышны бергә кушып, Катыклы тау буена күчерербез дип торган көн. Хәзергә безнең уйлар шулайрак, авылдаш.

Солтан башында кайнаганнарны тышка чыгарырга вакыт җитте кебек сизде. Ул председательгә «уйлап бетермәгәнсез» дигән сыман сынаулы бер төстә карап торды да яңадан сорау куйды:

— Башкачарак булмыймы?
— Ә ничек тагы? — Нәриманов башын кашып алды.
— Бу авылларның һәркайсы уч төбендәге кебек ләбаса. Әнә Камышлы, әнә Яңа бүләкнең өй түбәләре, әнә Артыштан төтен чыкканы күренә...
Председательнең түземе житмәде:
— Шуннан?
Бу юлы Солтанерактанрак китереп суктырды:
— Ничек диләр әле? Аерылганны аю ашаганмы? Бүленгәнне...
— Нинди аерылу? Күченү!
— Мәсьәләнең тамыры, төбе дә шунда шул. Хәзер техника заманы, басулар ерак дип, хафаланасы юк. Өч күченү ясаганчы, бер күченәсе дә куясы!
Нәриманов, Солтанның тел төбе кайсы якка каерганын әле һаман абайлап житмәгәнлектән, күзләренә аптырашлы караш чыгарды.
— Ул ничек инде тагы, значится?
— Ул менә ничек,— дип ялгап алып китте Солтан.— Сайланган урын иркен, кочагы киң. Шулай булгач, барлык дүрт авылны да бер урынга, менә шушы урынга китерәсе дә саласы.
— Син шулай дисең инде, авылдаш?
— Бу минем хәзер генә башыма килмәде. Күп уйладым.
Нәриманов шунда гына өзеп бер сүз дә әйтмәде, карашын авыллар урнашкан тарафларга йөртеп чыкты, жиңел машина тирәсендә эре-эре атлап йөрергә тотынды. Аннары гына сүз ачты:
— Әйтү ансат. Ярый ла халык риза булса...
— Минемчә, халык моны хуплар. Ни өчен дисәң, бердән, аларга барыбер күченәсе, икенчедән, болай яшәү — киләчәккә карап атлау булачак.
— Басулар ераклаша,— дип каршы төште Нәриманов.
— Мин бу турыда баштук әйттем.
— Техника заманы дисең инде син.
— Билгеле.
Ике авылдашның тыныч кына фикер алышуын, дөресрәге, бәхәсләшүләрен тыңлап, Васил кинәт башын калкытып куйды. Күрәсең, аларны тыңлый-тыңлый аның да фикере түгәрәкләнгән иде булса кирәк:
— Бу идея! Миңа калса, мин Солтан Сабировичның фикерен бик тә дөрес дип саныйм. Якын киләчәктә бит авыллар болай калмас, бергә тупланырлар, зурайтылырлар. Чөнки тормыш үзе шуны таләп итә, үзе шулай куша.
— Киләчәк әле ул — киләчәк, ни әйтсәң дә... Без бүгенге көндә яшибез,— дип, үзенең икеләнүен белдерде Нәриманов.
— Киләчәк ул бүгеннән башлана, аны күрә белергә кирәк,— дип каршы төште Солтан. Аның бу фикерен Васил кайнар яклап, ялгап алып китте:
— Безнең бу заманда, әлбәттә, халыкның вак-вак авылларда яшәве үзен акламый. Әйтик, конкрет алганда, монда эшче поселоклар тибындагы яңа Акъяр үсеп чыга икән, анда инде шәһәрдәгечә тормыш уңайлыклары тудыру да жиңелрәк булачак.
Нәримановның чырае бер ачылды, бер болытланды, бер битарафлык күрсәткәндәй катып калды.
— Водопровод, канализация, трубадан өйләргә жылы китертүне күздә тотсагыз иде сез, егетләр,— диде ул.
— Билгеле,— диде Васил,— ашханәләр, пекарнялар... Саный китсәң, күп инде алар.
«Менә төшендеңме, инде каршы әйтерлек сүзең калмыймы? Тәки китереп terәдек сине»,— дигән кебек Солтан Нәримановка үтәли текәлеп карап алды. Ләкин тегесе тагы бер сәбәп тапты:
— Өстән ни әйтерләр?

Гомерендә табышмаклап сөйләшүне яратмаган Солтан турыдан-туры ярып салды:

— Район оешмалары да мондый акыллы киңәшне хупламый калмаслар.

Председатель тагы тын калды. Аннары, гел юлда йөрергә яскынгандай, купшыланып торган, кояш нурларында җылык-җылык килгән җиңел машинасының төрле урыннарын караган итте. Һәм чыраена ниндидер тантаналы елмаю чыгарып, Солтан янына килеп басты. Дустанә якын итеп аның аркасыннан какты:

— Ни генә уйламадык бу күчеңү турыннан. Мигә чөй каккан кебек, китми ул баштан. Ә менә Солтан әйткән уй ничек беребезнең дә башына килмәгән? — Ул авыл Советы һәм партоешма белән киңәшергә булды.

Хуҗалыкта йөреп, танышып чыкканнан соң, үзләренең шефлыгындагы «Акъяр» колхозының йөрәк тибеше, сулышы ныграк, ачыграк төсмерләнде төзүчеләргә. Төзү эшләре һәм техника белән ярдәм күрсәтүдән тыш, кыр эшләрендә дә булышырга булдылар. Председатель, шефлардан бик канәгать калса да, аның кәефен боза, алай гына да түгел, аны куркыта торган кайбер сәбәпләр дә юк түгел иде. Ул алар турында менә сүз кузгатырмын дип запаста саклап килсә дә, Никитин барында әйтергә онытхан булып чыкты. Инде исенә төшкәч, Солтан белән Василның икесенә берьюлы ирештерергә ашыкты:

— Кешеләр бик китә.

— Кая?

— Яңа Наратлыга, әлбәттә.

Тегеләр һәр икесе авыз ачмадылар. Бер дә җавап кайтармагач, Нәриманов текәлебрәк дәвам итте:

— Кешеләрнең дә төшләре генә китә — ни тотса шуны егып сала торган егетләр, житкән кызлар китә. Тормыш арбасын жырлатып алып барырлыклары китә...

— Әйе, безнең эшчеләрнең күбесе якын-тирә авыллардан шул,— дип куйды Солтан.

— Ерактан килгәннәре дә аз түгел,— дип өстәде Васил.

Председатель Нәриманов үзенекен итте:

— Рас сез безне шефка алгансыз икән, безне якларга тиешсез. Туктатыгыз бу эшне, егетләр.

— Нинди эшне?

Василның бу гаҗәпләнүле соравын да тиз генә каплап куймакчы булды Нәриманов:

— Безнең колхозчыларны төзелешкә эшкә алмавыгызны сорыйм. Үз күзегез белән күрдегез, авылда да эш житәрлек. Ни хәтле чөгендер үстерәсе, тегесе-монысы дигән кебек. Мал-туар ни хәтле...

— Әгәр кеше яңа һөнәр өйрәнергә тели икән, үсәргә тели икән?

— Кеше ни теләмәс? Безнең дә план бар, Васил Закирович.

Солтан да, Васил да председательне канәгатьләндерерлек җавап таба алмадылар. Авыр сорау куйды ул, шулай да, кешеләрнең эшкә бары тик паспортлары булган тәкъдирдә генә алынуларын, кемгә паспорт бирү-бирмәү авыл житәкчеләренең үз кулларында икәнлеген әйтеп күрсәттеләр.

— Баштарак авыл Советында да шәйләп житкермәгәннәр шул, хәзер инде аңладык, беркемгә бернинди язу бирелмәс,— дип башын кашып алды Нәриманов.

Алар кайтырга чыкканда көн кичегеп килә иде инде. Һәр икесенең колхозда алган тәэсирләре житәрлек, уйланырлык уйлар да, хәл кыласы мәсьәләләр дә байтак иде. Шунда бер уңайдан леспромхозга кереп чыктылар һәм анда озак юанмыйча юлларын дәвам иттерделәр.

Юллар... Юллар... Кайларга гына алып китми алар кешене. Тормыш үзе дә шушы тар басу юлларыннан башлана. Алар үз уйларына үзләре

бирелеп, тын гына кайткан чагында, алда ниндидер җәяүле күренде. Аның турына килеп җиткәч, Василга ул ничектер таныш сыман тоелды. Ә Солтан җәяүлене шунда ук танып алды.

— Бәй, Гөлзадә ич бу,— дип кычкырды ул.

Җәяүлене беркадәр узып киткәч, Васил машинаны туктатты. Юл буена чыгып тукталып калган Гөлзадәгә икесе бертавыштан диярлек әйттеләр:

— Әйдә, утыр.

Кыз башта нишләргәрәк белмичә карап торды, аннары итәкләрен җыеп, арткы кабинага менеп утырды. Шундук кузгалып та киттеләр. Кабинадагы шофер күзгесендә вакыт-вакыт кызның чырае яктырып китә, мәгәр Васил аңа карамаска тырыша иде. Солтан кызга сораулар биргән, ике авылдаш сүз алышкалап барган чагында Васил да Гөлзадә турында уйлангалады. Ул аны беренче мәртәбә кайда күрде соң әле? Яңа Наратлыга килгәч тә, төзелешкә барганда бер төркем хатын-кыз арасында күрде бит ул аны. Ул чагында кызның өстендә сырган пиджак һәм тар чалбар иде. Аны бит, ничектер шунда таеп егылгач, бер егет култыклап торгызып, ирексезләп күтәреп тә барды бугай. Аннан тагы, язгы былчыракларны ярып, төзелештәге эчке юллар өчен агач кисү, материаллар әзерләү вакытында Мәдинә Фатыйхова бригадасында икеөч тапкыр очратты ул аны. Ул көннәрдә кешеләр тырышып, көнне төнгә ялгап эшләделәр. Хатын-кызлар бригадасы бигрәк тә. Гомумән производствода хатын-кызларга карата Василның үз карашы бар. Ул моны эштә күрде һәм аларны һәрвакыт үрнәк итеп телгә ала торган булып китте. Шулай булмаслык та түгел. Хатын-кызлар бит алар прогул-мазар ясамыйлар, тәмәке тартып вакыт уздырмыйлар һәм ял көннәреннән соң башлары авыртып та интекмиләр.

Бара-тора бу тойгыларны яңалары алмаштырды. Менә ул хәзер юлдан кайтып килгән бу минутларда Нурзилә нишли икән? Аның бәгыре Ринат ни хәлләрдә икән? Каядыр читтә хатынсыз яшәү дә майлы ботка ашау түгел ич. Мондый билгесез һәм әчпошыргыч халәт озакка барырмы? Нурзилә дә бит инде таш йөрәкле түгел, аңларга тиеш. Аны әлегәчә һич тә шәһәрдән кузгатып булмый. Бу нигә алай? Ул элегрәк бер дә алай киреләнми иде ләбаса. Тик артык көнләшүе генә бар иде. Әллә югыйсә үзен шайтан котырта инде, мәхәббәтенең бер чите бозлана башлавы шушы түгелме? Ничек булып бетәр аларның тормышлары? Гомергә булмаса да, бик озак, әйтик, берничә еллар буе хатынлы килеш буйдак булып яшәүгә, ай-һай, кем генә түзәр икән?

Уйлары шул төшкә җиткәндә, аның күзләре тагы көзгегә төште. Гөлзадә! Аның һава төсендәге ефәк косынкасы астыннан кабарынкы коңгырт чәчләре бөселеп чыккан, төз борын яфраклары бер киңәя, бер тарая, озынча түгәрәк битенә кояш нурлары бронза төсле бизәк салган, күзләре соры да, зәңгәрсу да сыман. Ул күзләр нур һәм яшьлек белән тулы. Кызның кабарынкырак иреннәреннән менә-менә елмаю сирпелеп чыгар да синең күңелеңә куаныч салыр төсле. Василның бу минутлардагы кичерешләрен сизенгәндәй, әллә аның күз карашларыннан оялыпмы,— Гөлзадә аска карады. Озын кара керфекләр. Алар нинди генә серләр яшермәгәннәрдер? Бу күзләргә инде сөрмә тартып маташасы юк. Болай да сөрмәле алар, болай да сине тартып алырга гына торалар шикелле, болай да күңелгә ялкын салырлык!

Башында татлы уйлар чишмәсе ургылып кайнаганда, бер-ике сүз кыстырып куюдан артык ерак китә алмады Васил. (Дөньяда мондый сөрмәле күзләр күп очрый бит!) Ә Солтан? Ул артка таба башын кыйшатыбрак утырган. Күрәсең, яшьлек, матурлык аның да күңел кылларын кузгатып җибәрә булса кирәк.

— Калып-калып эшләгән көннәр өчен отгул алган идем. Берничә көн авылда булдым,— диде Гөлзадә.

— Әниең, туганнарың ни хәлдә? — дип сорады Солтан.
— Бары да исән-саулар.
— Төзелештә күптәнме әле син, сеңел?
— Икенче ел.

Гөлзадә тел ачуга, дөнья яктырып киткән сыман. Ләкин менә ул нигәдер башлап сүз катмый, күбесенчә Солтан Сабировның сорауларына саран-саран гына җавап кайтару белән чикләнә. Алай да күңелле, саф аның җаваплары... Солтан сорауларын бер-бер артлы яңартып кына тора:

— Колхозда нинди эштә идең?
— Төрле эштә йөрдем. Фермага эләгеп булмады. Төрле эштә йөрсәң, аяк хакы да кайтмый. Төзелештә, ичмасам, икенче хәл.
— Сезнең бригада бетон сала бит әле, әйеме?
— Төп эшебез анысы. Кирәк булганда изоляциясен дә үзебез ясыйбыз, штукатурлауны да. Берәүгә дә ялынып торган юк. Безнең бригадир куыра гына ул.
— Син ничә класс бетердең әле, Гөлзадә?
— Ун класс, Солтан абый.
— Укуны дәвам итәргә исәп юкмы соң?
— Бар, бик бар. Көзен ачылачак кичке техникумга керергә ниятләп торам.
— Общежитиедә торасыңдыр инде?
— Әйе.
— Ошыймы соң?
— Болай ярыйсы, күңектем кебек. Тик менә килем-китем бик күп, төрле борчулар...
— Ул ничек инде тагы?
— Кич булдымы — егетләр килеп тула, ул исерекләр дисеңме! Һич ял итәргә бирмиләр. Сагыз кебек сыланырга гына торалар.
— Ә комендантлар, тәрбиячеләр ни карый?
— Алары күзгә күренми.

Бүтәнчә сүзе калмаган шикелле, Солтан алдына туры карап утырды. Аңа ничектер бу кыз алдында уңайсыз булып китте. Ул арада инде машина поселок урамына килеп керде.

## 4

Шул сөйләшүдән соң Солтан төрлечә уй йөртте. Поселокта әледәнәле төрле җәнҗаллар да чыккалап тора. Вак хулиганлык күренешләре дә, унбиш көнчеләр дә бик туйдырды. Тәртип бозучыларның иң күпчелеге әлегә шул тулай торaклардан ич. Димәк, бу турыда коры сөйләнү яки партоешма секретарьларына акыл сату гына җитми. Ниндидер башка чаралар эзләргә кирәк.

Бер көнне ул, сәгать теле кичке тугызларны үткәч, ирләр тулай торагына юл тотты. Өч катлы зур кирпеч йортның тәрәзәләреннән урамга якты ут көлтәләре сибелә, гармун һәм җыр тавышлары ишетелә иде. Беренче подъездда әллә ни күзгә чалынырлык тәртипсезлекләр очрамады аңа. Ә менә икенче подъездда хәлләр башкачарак иде. Солтан килеп керү белән икенче катка күтәрелде. Иң элек вахтерның үз урынында булмавына гаҗәпләнде. Кешеләрдән сораштырып караса да, аның кайда икәнен берсе дә төгәл өзеп кенә әйтә алмады. Кемдер:

— Ул шулай инде, чыкканда чыга, чыкмаганда чыкмый,— диде.
— Чыкса да озак утырмый ул, аяк тавышлары басыла төшкәч, кухняга кереп, гыр-гыр боткасы пешерә,— дип өстәде икенчесе.

Солтан бүлмәләрнең берсенә барып керсә, кызып карта уйнаучыларны күреп, исәреп калды. Алты кешелек бүлмәдә ике караватны уртага

китереп, бер-берсенә терәп куйганнар да шулар тирәсенә җыелышып утырганнар, тетәләр генә, шалт та шолт... Кайсы фуражкасының артын алга әйләндереп кигән, кайсы, кырын ятып, карта суга. Солтан бу егетләрнең акчага карта уйнауларын сизенеп алды. Башта, карта уйнау кызулыгы белән, аның бүлмәгә килеп керүен берсе дә абайламаган, мөгаен. Кайсыдыр пышылдап кына: «Партком секретаре»,— диде. Яшьләрнең берничәсе, сагая калгандай, кырын яткан җирләреннән тураеп утырдылар. Калганнары, берни дә булмаган шикелле, уйнауларыннан бүленмәделәр. Солтан башта карта уйнаган өчен дәррәү кызу алып егетләрне тиргәргә дә уйлаган иде. Ләкин гадәтенчә монда да ул кинәт кабынып китмәде, кутәрелеп бәрелмәде. Кемнең кайда эшләвен, кайдан килгәнлеген сорашып сүзен башлап җибәрде. Солтан белән сөйләшкәндә егетләр уенны туктаттылар, кайсы карталарын кулларына тотты, кайсы караватка куйды.

— Акча салып уйныйсыз шикелле. Бу инде азгынлыкка сөйри,— диде ул салмак кына тонда.

Очлы борыны белән карчыганы хәтерләткән, үзе чепи күзле, фуражкасының артын алга әйләндереп кигән куе сакаллы бер егет, бер дә исе китмичә генә, калын тавышы белән әйтте:

— Бу нинди акчалы уйнау булсын, начальник? Бу ин простой уен: подкидной гына. Җаең бар икән бас, чамаң килмәсә, рәхим итеп кутәр...

Солтан аның белән ризалашмады:

— Ә фуражкада нинди акчалар соң ул?

— Бакыр акчалар,— диде теге.

— Барыбер акча ич.

— Нинди акча булсын, ди. Бу пустяк кенә. Төне буенча карта суккапда да илле тиеннән артык ота да, оттыра да алмыйсың ул бакырлар белән.

— Һәр нәрсә дә шулай кечкенәдән башлана,— дип, әйткәннәренә тирәү салырга тырышты Солтан.

Акчалы фуражканы каядыр алып яшерделәр. Башкалардан яшькә дә олырак күренгән, мөгаен, дөньяны да байтак күргән Карчыга Солтан янынарак килеп басты. Аның карашында ризасызлык һәм кемгәдер ачу чагыла иде шикелле. Аның калын тавышы тагы яңгырады:

— Күңелсез монда, начальник.

— Сезнеңчә нишләргә кирәк соң?

Карчыга үчекләгәндәй саран гына елмайган итте дә, бик мәгънәле сүз әйткән кеше кебек, тарта-суза ирештерде:

— Поселокны шәһәргә күчереп куярга кирәк. Бу караңгы почмакта барлы-юклы акылың да коелып бетәр.

Икенче берсе, олы гәүдәле, киң җилкәле, бөтен килеше белән батырны хәтерләткәне, ачулы төстә Карчыгага текәлде:

— Юк, иптәшкәем, болай диюең бер дә батмый синең. Бер заман, беләсеңме, монда нинди шәһәр булыр!

Солтан елмаеп куйды. Бу Виктор исемле егетне кыяфәтенә карап кына түгел, чын мәгънәсендә көчле-куәтле булганы өчен үзе белән бергә эшләүче татарлар Алып батыр дип йөртәләр иде. Солтан аның бик гади һәм тотнаклы булырга тиешлеген шунда ук уйлап алды. Беренче күрүдә үк ничектер салкын тәэсир калдыра торган Карчыганы исә, сөйләшүенә карап, азмы-күпме утырып чыккан кеше дип уйлады ул. Чөнки теге яки бу җаваплы хезмәткәр белән сөйләшкәндә андый кешеләрнең «начальник» яки «гражданин начальник» сүзен еш кыстырулары Солтанга мәгълүм иде. Карчыга нидер әйтергә авызын ачканда, Виктор аңа юл куймыйча тагы сөйләп китте:

— Эштә вакытның ничек үткәне сизелми дә кала. Тулай торакка кайткач күңелсезрәк шул. Кызыл почмак еш кына бикле була, телевизор бүлмәсе ишегендә дә йозак...

Яшьләр бик тиз арада караватларны яңадан үз урыннарына күчереп куйдылар. Кайсыдыр партком секретарена утырырга тәкъдим итте. Солтан бер мәлгә ни әйтергә белмичәрәк торды. Кая утырырга? Ярый әле, Виктор бүлмәдәге ике урындыкның берсен аның янына китереп куйды. Икенче өч аяклы гарип урындыкка Карчыга утырды. Калган егетләрнең һәркайсы диярлек үз караватларына урнаштылар. Ул арада башка бүлмәләрдән дә кешеләр җыела башлады. Тулай торактагы гадәти ятим тормыш белән килешеп яшәүчеләр булган кебек, монда куелган тәртиптән риза булмаганнарның да байтак икәнен төшенеп алды Солтан. Төрле почмактан төрле авазлар ишетелде.

— Нигә аккордеонны жиде кат бик астында тоталар?

— Нигә бильярд юк?

— Нигә?..

Бу «нигә»ләрне тыңлый-тыңлый Солтанның башы катып бетте. Бик житди һәм әһәмиятле сораулар белән бергә: «Нигә торакның яртысына кызларны күчермиләр? Ә кызлар торган йортка егетләрне...», «Нигә буфетта градуслы «су» сатмыйлар?» кебекләре дә колакка чагылып китә иде.

Солтан егетләрнең бу таләпләрен игътибар белән тыңлап торды да, урындыгына җайлабрак утырып, сорауга сорау белән җавап бирүдән башлады:

— Сезнең тулай торак советы бармы?

Секретарь сүзләренә берсе дә кайтарып әйтергә теләмәгәндәй тын тордылар. Тик ике-өч минут үткәч, теләр-теләмәс кенә әйтелгән сүзләр ишетелде:

— Белмибез.

— Юк.

— Беренче тапкыр ишетүебез мондый сүзне.

— Начальникларыгыз, прораб яки бригадирларыгыз киләме? — дип, тагы сорады Солтан.

Моннан соң егетләрнең күпчелеге колакларын торгызды, гаҗәпләнеп иңбашларын сикертеп куючылар да булды. Карчыга чыраен сытып әйтә куйды:

— Безнең прораблар эштә генә кысалар. Аларның бар белгәне — давай да давай. Монда килә торган юлны белмиләр алар, начальник...

Солтан уйланып торды. Күп житешсезлекләрне күңел дәфтәренә беркетеп куйды. Аныңча тулай торакта эшнең болай начар куелуында төзү оешмаларының һәм бигрәк тә торак-коммуналь бүлеге житәкчелегенең гаебе булган кебек, егетләр үзләре дә сөттән ак, судан пакь түгелләр иде. Бу турыда аларга Солтан һәркайсының аңына житәрлек үткен итеп әйтте. Ул аларга су уңаена гына йөзүнең ансат булуын, әмма суга каршы йөзүнең башкачарак икәнен төшендерергә тырышты.

— Алма, пеш, авызыма төш, дип кенә көтеп ятмаска кирәк,— диде.— Ишек алдында менә дигән урын бар. Әйтик, теләгәндә, сез шунда спорт мәйданчыгы ясый алмас идегезмени?

Секретарь һәр бүлмәдә булырга тырышты. Аның килү хәбәре тиз арада бөтен тулай торактагыларга ишетелгәнлектән, ул кергәндә инде күп бүлмәләрдә тәртип урнаша бара, урын-җирләр, өстәлләр җыела иде. Әмма комендант бүлмәсенең бикле булуы һәм, аннан да битәр, кызыл почмак ишегенә ат башы кадәр йозак эленгән булуы Солтанның кәефен бөтенләй җибәрде. Ул төрлечә уй йөртте. Билгеле, көн-төн тулай торакта була алмыйлар алар, үзләренең эш сәгатьләрен үткәргәч кайтып китәләр булыр. Ул тулай торакка хезмәт күрсәтүче комендант белән тәрбиячененң кешеләр эштә вакытта монда булуларын, инде алар кайткач тулай торактан китүләрен ачыклады. «Ә бит алар кешеләр эштән кайткач, әйтик, берсе көндез, икенчесе кич чиратлашып эшли алалар. Безобразие! Бу Гәрәев ни карый»,— дип уйлады ул. Вахтер хатынны кухняда мич артын-

да йоклап яткан жиреннән уятырга һәм аның белән күңелсез генә сөйләшергә туры килде. Тегесе яңагын кулына куеп ятканлыктан бармак эзләре төшеп кызарган битен угалап алды да, артка киткән яулыгын һәм тузып торган чәчләрен дә рәтләп тормастан, ризасыз төстә үз урынына барып утырды.

Почмак бүлмәләрнең берсенә барып керүгә, Солтан аптырап калды. Бу ике кешелек озынча бүлмәнең асты өскә килгән иде. Өстәлгә каршы, аңа аркасы белән, нидер язып утырган ак күлмәкле егет аның ишектән килеп керүен сизенмәде булса кирәк, башын чайкый-чайкый яза бирде. Караватларның берсендә бөтенләй рәт киткән, бөтен әйбер тузып ята. Ул гынамы соң! Солтанны иң гажәпләндергәне башы һәм гәүдәсе белән карават астына кергән, аяклары гына күренеп торган исерек булды. Ул, ара-тирә саташып сөйләнә-сөйләнә, йоклап ята иде. Янында бушаган шешәсе дә бар. Өстәл каршында аңа арты белән утырганы кинәт борылды да, ни әйтергә белмәгәндәй, бер мәл карап торды. Бу егет Солтанга таныш иде.

— Түрдән узыгыз, Солтан абый,— диде Рафис.

Солтан өстәл янындагы икенче урындыкка килеп чүкте. Ул әлеге карават астыннан күренеп торган аяклардан карашын тиз генә алмады. Аның кем икәнен сорады. Бусы әле күптән түгел генә Рафислар бригадасына каяндыр ерактан, Рязань якларыннан килгән бер егет икән.

— Салмыш белән бик дус, ахры? — дип куйды секретарь.

— Аның белән кем дошман? — диде Рафис, елмаерга тырышып.

Сүз барышында Рафисның да яхшы ук төшергән булуы беленде.

— Ахры, салгалыйсыз?

— Булгалый.

— Болай килешми, нинди кыяфәтсез, нинди күңелсез ята.

— Ул бер дә күтәрә алмый шул. Бөгелде дә төште. Сыек буынлы.

Өстәлдә тәртипсез рәвештә тузып яткан китап һәм дәфтәрләрдән Солтанның карашы кинәт стенага төште.

Рам эченә тезеп куелган байтак кына фотокарточкалар арасында, иң уртада анадан тума бер шәрә хатын-кыз рәсеме дә бар. Солтан якынрак барып карагач, кайчандыр дәүләт Эрмитажында караган һәм аннан тыш та төрле открыткалардан күргән атаклы Тицианның «Даная» картинасын хәтерләде. Анынча, бу рәсем Көнбатыш Европа сәнгате шедеврларыннан саналса да, аны кайдадыр аерым альбомда саклау әйбәтрәк булыр иде сыман тоелды. Бу турыда Рафиска әйтми түзә алмады. Тегесе каршы төште. Рамга Рафисның үз карточкалары һәм аның белән бер участокта эшләүче Мәдинә, Лиза, Гөлзадә, аларга өстәп тагы Солтанга таныш булмаган берничә хатын-кыз рәсеме дә урнаштырылган иде. Рафисның фотоаппараты бар. Җаена, кәефенә һәм аннан да бигрәк үзенә ошавына карап, теләгән бер кызны карточкага төшерә дә ала икән.

Рафис секретарьның искәртүен күздә тотып әйтә куйды:

— «Даная» картинасы репродукциясен уңышсыз чыккан дисез инде сез. Булыр. Мин художник түгел ич.

— Кызларны бик яратасың, ахры? — диде аңа Солтан.

Рафис серле генә көлеп тешләрен агартты:

— Аларны кем яратмый! Хатын-кыз булмаса, ирләр дә булмас иде. Алар сөелү-иркәләү өчен туганнар да бит, Солтан абый.

Солтан бу сүзләрнең Рафисның үз сүзләре түгел икәнен, аның кешеләрдән ишеткән булуын шундук чамалап алды. Күрәсең, башына беркадәр киткәч, егетнең теленә тапкырлык үрмәли. Ул каяндыр укыганнарын исенә төшереп булса кирәк, сөйләнүендә булды:

— Наполеон заманындагы министрлардан берсе Талерьян ничек дигән әле? — Рафис, бераз уйланып торгач, үз сүзенә үзе үк җавап

кайтарды:— Акча — тоту өчен, күз — карау өчен, хатын-кыз — сөю өчен яши бу дөньяда. Шулай булгач...

Солтан башын селкеп куйды, салмак бер тонда сүз катты:

— Талерьян ни генә димәсен, ул әле аны тормышка шәхси карашларыннан чыгып әйткән. Аннары син шуны да онытма — ул аксак министр бик эре хосуси милекче булган, байлык өчен, алтын өчен һәм типтерү өчен яшәгән, шуның өчен төрле хәйләләр корган.

— Монысын да беләм,— дип каршы төшәргә маташты Рафис. Ләкин Солтан аңарга юл куярга теләмәде:

— Иң элек син шуны онытма — ирләр хатын-кыздан башка тора алмаган кебек, хатын-кыз да ирләрдән башка тора алмый. Тормыш шулай корылган. Табигать законы шулай. Аннан да элек, сүз бу ике җенеснең кайсы турында барса да, беренче планда кеше тора. Аннан соң гына калган мәсьәләләр. Менә шуны бутамаска кирәк, егеткәй.

Рафис башкача бәхәскә кермәде. Кызларга булган ихтирамы, кайнар мәхәббәте турында берничә сүз әйтте дә тынып калды. Секретарь чырайндагы елмаюны яшерә алмыйча аңа текәбрәк карады:

— Йөрәгең мәхәббәт уты белән тулган икән, бик яхшы. Кеше мәхәббәтсез яши дә алмый. Синең тәбәп йөргән берәр кызың да бардыр инде?

— Юк,— диде Рафис мәзәк кенә итеп.

— Ә нигә алай?

— Просто шулай. Мин кызларның барсын да яратам.

— Мин сиңа төшенеп җитә алмыйм.

— Әйе, Солтан абый, кемне күрәм — шуңарга гашыйк булам.

— Аңламыйм. Син бераз төшереп алгач борчак сибәсең бугай.

Алар шулай сөйләшкәндә, караватастыннан аяклары гына күренеп торган теге исерек, бер сүз дә эндәшмәстән, дүрт аяклап мүкәли-мүкәли коридорга чыгып китте.

Соңлатып кына гостиницага кайткан Солтан яту белән йокыга китә алмады. Ә иртәгесен гадәти көннәргә караганда алдарак торырга туры килде. Ул иң башлап, беркемгә бер сүз әйтмәстән, әлеге өч катлы кызыл кирпеч йортка тагы сугылды. Ул килгәндә әле җиде тулмаган иде. Тулай торак хезмәткәрләреннән берсе дә күренми, алар эшкә сигездә генә киләләр икән. Бу хәл Солтанның тәмам ачуын кабартты. Җиде тулгач кына кайбер җыештыручылар күренә башлады. Тулай торакта дистәдән артык эшкә чыкмаучыларны, соңга калучыларны тапты ул. Алар арасында Карчыга һәм караватастыннан аяклары гына күренгән кичәге егет тә бар иде.

Кем белә? Бәлки Солтан кыстап, тынгысызлап йөрмәсә, бу кешеләр бөтенләй эшкә дә бармаслар иде.

Солтан парткомга гадәттәгегә караганда беркадәр кичегебрәк килде. Алда зур һәм кирәкле җитди сөйләшү тора иде. Солтан кайнарланып телефон трубкасын алды.

## 5

Гөлзадәнең ни сәбәптәндер күңеле бик төшенке иде.

Ул төзелеш мәйданындагы прорабльк участогы вагонына килеп кергәндә анда берәү дә юк иде. Кыз бераз көтәргә булды, стена буена куелган озын эскәмиянең ишек катындагы башына килеп утырды. Ул арада төрле сызмалар тулып яткан өстәлдәге телефон шалтырады. Нишләргә? Алыргамы, юкмы? Алса, ул монда кем, ни дияр? Ул шулай икеләнеп торганда вагон-конторага прораб Игнат Данилов килеп керде. Игнат Гөлзадәгә сүз әйтергә дип авыз ачканчы, тагы телефон шалтырады. Кайдадыр яр буе насосына бетон килү тукталган икән, бригадир шул турыда борчылып хәбәр итә һәм ашыгыч ярдәм көтә. Игнат телефон

трубкасын куйгач, берәр минут үз алдына карап, нидер исенә төшерергә тырышкан бер кыяфәттә тын торды да кызга сүз салды:

— Әйтеп җибәр, Гөлзадә, ни йомыш?

Кызның күзләрендә яшь бөртекләре күренде. Ул сүз әйтә алмыйча аптырап Игнатка карады да, кинәт кенә борылып, идәнгә күз салды. Бары шуннан соң гына тотлыга-тотлыга әйтте:

— Мин монда кала алмыйм, чыгарыгыз мине эштән.

— Бу нинди сүз тагы?

— Шулай, китәм...

— Кая китәсең?

— Бик еракка. Менә гаризам.

— Кесәңә кире сал кәгазеңне. Беркая да китмисең!

— Әгәр мин монда эшләргә теләмәсәм?..

— Нинди сәбәп? Нигә теләмисең?

Прорабның бу соравы җавапсыз калды. Кыз, гаризасын кулына тоткан килеш, куллары белән күзләрен каплап, йөгерә-йөгерә чыгып китте. Игнат аның артыннан чакыра чыкса да, Гөлзадә ишеттеме-юкмы, ләкин борылып карамады.

Игнат кулларын җәеп аптырап калды.

Гөлзадә икенче тапкыр эшен ташлап китә алмады. Бригадирлары Мәдинә сораусыз каядыр китеп йөргәне өчен аңа болай да бик каты бәрелде. Алар бригадасы бу көннәрдә төп корпусның идәннәренә бетон салу белән мәшгуль иде. Аны ни хәтле тизрәк бетерсәләр, монтажчыларга да эш мәйданы тизрәк ачылачак иде. Гөлзадә үзе кебек дисталәгән кыз һәм яшь киленнәр белән салынган бетонны тыгызлавын белде. Башкалар шикелле аның кулында да вибратор көндәм йөри башлады. Эшләре тиз үрчи, һәркайсының күңеле күтәренке иде, бу дулкын Гөлзадәгә дә сугылды. Төш авышкач, участокка тагы да кешеләр өстәлде. Соры төстәге бетон әйбәт изелгән камыр кебек трубалардан килә тора, аны тыгызлыйлар һәм мастероклар белән коеп куйган кебек итеп тигезлиләр. Бүтән чакларда теге яки бу кирәк-ярак артыннан чабып йөри торган Мәдинә үзе дә күтәрелеп тә карамый, идәнгә бетон түшә. Һич кенә дә туктап торучыны күрмәссең.

Шушындый ут өереп эш кайнаган минутларда кызның күңелен борчыган авыр уйлар, авыр тойгылар да каядыр чигенеп торалар. Әмма барыбер сүнеп бетмиләр. Гел эшләп кенә торып булмый бит. Эшне ял, тормышның башка мәшәкатьләре алмаштыра. Тагы тулай торакка кайтасы бар. Ашханәгә барасы... Кич җитәр... Гөлзадә өскәрәк күтәрелеп караса, бер төркем башлыкларны күрде. Барысын булмаса да, төзелеш җитәкчеләренең күбесен Гөлзадә таный иде. Алар бер баралар, бер тукталып, нидер киңәшеп торалар. Андрей Акимович Никитин, кулларын болгый-болгый, кай ара башын артка ташлап, кызып-кызып ниндидер бик мөһим эш турында сөйли булса кирәк. Аның янында Васил Сафин, ниндидер бик калын җилкәле, бераз бөкрерәк тагы берәү, аннары бөтенләй җилкәсез диярлек, муены белән гәүдәсе тоташкан, Гөлзадәгә таныш булмаган әллә кайсы шунда. Аларның прорабы Игнат Данилов та зур башлыклар белән бергә йөри. Менә алар аска төштеләр. Баш иеп эшчеләр белән исәнләштеләр. Башлыклар Гөлзадәләр турына җитүгә, Мәдинә, мастерогын кулына тоткан көе, тураеп аларга карады.

— Иптәш Фатыйхова,— диде аңа Никитин,— эшләрегез ничек бара?

— Ярыйсы, Андрей Акимович!

— Бетон вакытында киләме?

— Хәзер бетонны механикалаштырып бирә башлагач, жалу итәрлек урын калмады инде.

— Төзелештә «урак өсте»нең иң кызып барган чагы. Сезгә ике сменага бүленеп эшләргә туры килер.

Мәдинә бераз аптыраулы кыяфәткә кереп җавап кайтарды:

— Икегә бүленсәк, безнең кешеләр бик аз бит, Андрей Акимович.
— Сезнең ничә кызыгыз бар әле?
— Унтугыз.
Башлык, Сафинга карап аның колагына нидер әйткәннән соң, Мәдинәгә:
— Кәлимәттән ремучилищедан кызлар килә. Шуларны да сезгә өстәп кушарбыз. Шуннан соң бетте-китте: менә сиңа ике смена! — диде.
— Ул чагында икенче хәл,— диде Мәдинә, уйланыбрак.
Никитин китәр алдыннан, бер кулын күтәреп, үзенең калын тавышы белән барсына берьюлы мөрәҗәгать итте.
— Ну, кәефләрегез ничек, кызлар?
Алдан сүз куешкан шикелле, дистәләгән яшь аваз берьюлы җавап кайтарды:
— Яхшы, Андрей Акимович!
Башлыкның чырае тагын да ачылып, яктырып китте.
— Шулай, дуслар, сезнең хезмәт — мондагы эш — безнең беренче номерлы бурыч! — диде ул күтәренке бер тавыш белән, аннары туктап тын алгач, сүзен дәвам иттерде:— Сезнең күз алдыгызда поселокта йортлар салына, юллар түшәлә. Тиздән культура йорты сала башлыйбыз. Ә аннары сезгә кичләрен күңел ачарга бию мәйданы кирәк. Иске клуб янында бригада эшли иде. Күргәнсездер?
— Күрдек!
— Хәзергә шунда биеп торырга буламы?
— Була!
— Тик туфлиләрегез генә чыдасын — бетон идән.
Көлешәләр.
Башлыклар киткәч тә яшьләрнең чыраендагы елмаю яктылыгы тиз генә сүнмәде. Күңелләрдәге дәртнең үсүе, көннең матурлыгы эшне тагын да үрчетте, төзелешнең йөрәк тибеше кешеләрнең кайнар тойгылары белән бергә тоташты.
Шулай да эштән соң Гөлзадәнең күңелсез уйлары тагы баш калкытты. Ул иптәш кызларыннан аерылып калды да, төзелеш идарәсенең кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә ниятләп, бер катлы ак йортка керде. Ишеккә таба өч-дүрт адым атлавына ниндидер эчке тавыш аңа «йөрмә» дигән кебек булды. Ул коридорда кемнәрнедер күрде, кемнәрнеңдер үзенә каравын тойды һәм, шуннан ары күзләренә ак-кара чалынмыйча, йорттан кызу-кызу чыкты; эштән кайтучы бер төркемгә кушылып, поселокка таба юнәлде.
Башлык Никитин әйткәннәр бик тиз арада гамәлгә дә ашты: училищедан килгән яшь кызлар яңа көч булып Мәдинә бригадасына кушылды. Иске бригаданы икегә бүлеп, килүчеләрне шуның һәр икесенә дә өстәделәр. Беренче көннәрдә көндезге һәм кичке сменаларның һәркайсы белән Мәдинә үзе җитәкчелек итте. Аннары Мәдинә прораб Игнат Данилов белән киңәште дә төнге сменага кызларның берсен звено башлыгы итеп куярга булды. Башта аптырап бетте: кемне куярга, кемне сайларга? Уйлана торгач, ул Гөлзадәгә тукталды. Кыз исә бригадирының тәкъдименә шундук риза булды.
Гөлзадә эштә үзен тиз аклады, аның җитәкчелегендә эшләүче кызлар башкалардан бер тотам да калышмыйлар. Гадәттә звено төнге унберләргә эшен бетерә һәм кешеләр ялга китәләр.
Башкалар өчен әллә ни үзгәреш булмаса да, Гөлзадәгә көтелмәгән хәлләр очрый торды, аның кәефе китте. Әлеге дә баягы шул Рафис инде... Ул һәр көн эштән кайтканда аларның каршысына килеп чыга. Килеп чыгуы да башка егетләр шикелле, адәм рәтле булса икән. Ул каяндыр арттан пәйда булып, кызның янына янәшә килеп баса. Аннан инде Гөлзадәнең күңелен кайтарырлык әллә нинди төче сүзләр сөйләнә

башлый — колагын түзеп кенә торсын. Тулай торакка житү белән дә Рафис әйтәсе сүзен әйтеп, саубуллашып китә белми, кызга ияреп йортка керә. Кыз нишләсен, үзе белмәгән бәндәнең янагына чабып булмый бит инде.

Шулай бер ара тынып торгач, бер көнне ул Гөлзадәгә тагы килеп бәйләнмәсенме! Кыз, аның сүзләренә рәтләп җавап бирергә дә теләмичә, башкалар артыннан калмаска тырышып, кызурак атлый башлады. Ләкин Рафис һаман такылдап бара бирде. Алар башкалардан шактый артка калганнар иде инде.

— Бик күп йөрдем кызлар артыннан, хикмәт чыкмады...— диде Рафис.

— Чыкмаса, нигә аны миңа сөйлисең?!

— Именны сиңа сөйлим дә.

— Нигә миңа?

— Чөнки мин сине яратам. Күңелем гел синдә генә... Миңа бүтән беркем дә кирәк түгел.

— Ташла, Рафис, саруымны кайнатма ичмасам!

— Кайнамый торсын,— диде Рафис.— Без бит инде сабыйлар түгел, шулай берәр ел дуслашып йөрербез дә, аннары китереп, язмышларыбызны бергә бәйләрбез. Шундый матур тормыш корып җибәрербез, бөтен кешенең исе-акылы китәр. Колак сал инде минем әйткәннәргә.— Ул кинәт тагын да кайнарланып Гөлзадәнең кулларыннан тотты. Кыз җәһәт кенә кулларын тартып алырга теләп талпынып куйды. Кая ул ычкыну! Теге аның кулларыннан бик нык кысып тоткан иде шул. Гөлзадәнең ачуы һаман саен ныграк кабарды, ул кырыс бер аваз белән кычкырганын да сизми калды:

— Җибәр!

— Мин сине тотмыйм ич.

— Фу, хулиган...— Гөлзадә бу юлы бар көче белән кулларын тартып алды. Егет, бераз сүзсез баргач, кызны култыклап алырга маташты. Булдыра алмады. Үзе һаман бер балык башын чәйнәде:

— Сине уйлап инде мин ашаудан калдым, йокыдан...

Гөлзадә эндәшмәде, адымнарын кызулый төште. Беркадәр тын баргач, егет тагы сөйләнә башлады:

— Барыбер миннән артыкны таба алмассың...

— Эзләмим дә, беркемнең кирәге дә юк миңа.

— Әгәр син минем белән йөрергә теләмисең икән, мин ул чагында нишләргә белермен...

— Куркытмакчы буласыңмы?

— Анысы минем эш. Белеп тор: я үземне, я сине берәр хәл эшләтми калмыйм ул чакта. Менә шул! Уйла!

— Уйлыйсым юк, әйтәсе сүземне күптән кисеп әйттем инде. Миңа синең кирәгең юк, үз сукмагыңнан йөри бир шунда.

Поселок урамына килеп кергәч тә Рафис Гөлзадәдән калышмады, тулай торак ишек төбенә кадәр ябышкакланып ияреп барды.

Икенче һәм өченче көннәрдә дә шундый ук хәл кабатланды. Гөлзадәне иптәш кызлары ничек кенә яклап карамасыннар, Рафис һич кенә дә чигенергә уйламый иде кебек. Берәр көн кызны тынычлык калдырганнан соң, ул ял көнен туры китереп, аның янына көндез килде. Вахтер хатын аша кызны коридорга чакыртты. Гөлзадә чыкмады.

Гөлзадә белән бер бүлмәдә торучы кызлар аның кичерешләрен беләләр, сагыз кебек сыланып йөргәне өчен Рафисны тиргиләр иде. Әмма үзен тупас һәм җиңел тотуы өчен яшьләр һәм кызлар арасында «туксанга бер тулып житмәгән» саналган Рафиска артык әһәмият бирүче булмады. Аның инде әллә ничә кызга әнә шулай «гыйшык тотуын», аннары, барып чыкмагач, туктавын беләләр иде.

Ул көнне Гөлзадә, башка чаклардагы кебек, бүлмәдәшләре белән кинога да бармады. Көнозын керләр юып йөрде. Кызлар кинодан кайткач, тамакларын ялгап, танцага киттеләр. Гөлзаданең аяклары тартмады. Ул керләр үтүкләп, вак-төяк әйберләрен тәртипкә китереп кайнашты. Кыз авыз эченнән генә көйләп, бүлмәдә әрле-бирле йөргәндә балконда тагы шул Рафис күренде. Бу нинди хәл? Өченче кат... Ул ничек анда менгән? Кызның бөтен тәне ут кебек яна, йөрәге дөп-дөп кага, ә чигә тамырлары сикерә башлады. Теге әрсез күз ачып күз йомган арада ишекне ачып, бүлмәгә керде...

## 6

Күпләрне борчуга салды кыз.

Ул көнне аның ахирәтләре кичке уеннан шатланып биешеп кайтып керсәләр, гаҗәпкә калдылар: Гөлзадә бүлмәдә юк иде. Аны кая да булса чыгып киткәндер дип уйлап, йокларга кайтуын көттеләр. Ләкин ул кайтмады. Шуннан соң бүлмәдәге кызларның эчләрендә пошаманлык үсә, күңел тынычсызлыклары көчәя барды. Кызлар ул көнне гадәттәгедән шактый соң йокларга яттылар. Вахтер хатын кичтән булган хәлне аларга иртәгесен генә сөйләде. Бер егетнең бик озын баскыч куеп, балкон аша бүлмәгә кергән һәм Гөлзаданең бик хәтәр тузынып чыгып киткән әйтте. Балконнан кергән егет белән вахтер хатын үзе дә бик хәтәр телгә килгән, аның тәртипсезлеге турында милициягә хәбәр итәргә уйлаган. Егет, тасма телләнеп ялына-ялвара, вахтерны телефон шалтыратудан тыеп калган. Гөлзадә тулай торактан китеп ярты сәгатьләр үткәч кенә ишектән чыккан ул.

Кызлар, Рафисның Гөлзадәгә җан атып йөргән белгәнлектән, иртәгесен көндезге тәнәфес вакытында аңа ябырылдылар.

— Гөлзадә кайда?

— Белмим,— диде теге.

Бригадир Мәдинә, күзләрен түгәрәкләндереп, егетне якасыннан бөтереп алды. Башка кызлар да Рафис утырган өстәл тирәсенә җыелдылар. Һәркайсының карашы аптыраулы һәм ачулы иде. Башкалар күзләре белән ашардай булып Рафиска текәлешкән арада, Мәдинә чәрелдәп әйтә куйды:

— Балконнан кызлар бүлмәсенә керүче синме?

Рафис, җавап кайтармыйча, беркадәр тын торды да кинәт кенә урыныннан күтәрелде. Китәргә җыенган шикелле, як-ягына карап алды. Ләкин беркая да китәрлек түгел, ул кызлар уртасында иде. Мәдинә кабатлап сорагач кына егет җавап кайтарды:

— Булса... Мин булса ни...— Ул тотлыгып, тукталып калды. Аска карады, кызарынды, бүртенде, кая барырга урын тапмагандай, каушаган хәлдә утыра белде.

— Хулиган,— диде кайсыдыр кыз, бик каты үчекләп.

Рафисның чәчләре үрә торды.

— Хулиган булып мин нишләгән, тәрәзә ватканмы, берәрсенең танавын җимергәнме? Чамалабрак авыз ачыгыз сез.

Ләкин егет моның белән генә котыла алмады, аның исеменә әче-әче сүзләр ява торды. Мәдинә дәвам итте:

— Гөлзадә кайда?

— Мин каян белим... каравыл тормадым.

— Бел: аның югалуына син гаепле. Кемгә генә бәйләнмәдең, без синең арт ягыңа төшәрбез хәзер. Борыныңа киртләп куй аны.

Рафисның, алар әйтмәсә дә, каефе шәптән түгел, күңеле бик төшенке иде. Кызларның җан-фәрман ачуланып тозлы-төшле сүзләр ирештерүләре аны бөтенләй каушатып җибәрде. Егетнең аркаларыннан ниндидер салкын энәле бозлар йөгергән кебек булды. Рафис, милициягә чакыр-

ып, үзен ябып куюларыннан да шикләнә, вакыт-вакыт кая да булса качып китү турында да уйлана, нишләргә икәнен бер якка да хәл кыла алмый иза чигә иде.

Көн артыннан көн үтә торды, Гөлзадә кайтмады да, хәбәр-хәтере дә ишетелмәде. Кызлар тулай торагында гына түгел, башка җирләрдә дә аның турында сүзләр кузгалды. Участок прорабы Игнат беренче төзелеш башлыгы исеменә рапорт та язып җибәрде. Шуннан соң Васил озак кына уйланып утырды. Кыз турында аны белгән кешеләрдән төрлечә сораштырып карады. Рафисны да чакыртып сораштырды. Ничек кенә итсәләр дә, Гөлзадәнең кая китеп югалуын ачыклый алмадылар.

Моннан хәтсез вакытлар элек, күчәчәк авылларны ничегрәк урнаштыру буенча, колхоз председателе Нәриманов белән сөйләшенгәнчә, Акъярга бер тапкыр Игнатны җибәреп кайтарганнар иде инде. Ләкин моның белән генә эш бетмәгән иде әле. Аны тагы да җибәрергә туры килде. Васил аңа авылга киткән чагында Гөлзадә турында бик нык сораштырырга кушты.

— Бәлки ул кыз авылындадыр. Анда булмаса, кая китүе турында туганнарына әйтми калмагандыр,— диде.

Акъярга барып төшү белән Игнат кызның туганнарына сугылды. Ләкин ул да кешеләрне тынычландырырлык җавап таба алмады.

Бу дөнья шулай корылган инде — борчу өстенә борчу чыгып, калкып кына тора. Кеше шуларның һәммәсен дә ерып, җиңеп чыгарга тиеш.



## 7

Васил, өстәле артына кереп утырып, алдында яткан кәгазьләрне дә карарга өлгерә алмады, телефон шалтырады.

— Сездән ярты,— дип шаяртты Юлдашев.— Мин механизация участогына күрсәтмә бирдем. Хәзер төзелешне үз комыбыз белән тәэмин итәчәкбез.

Васил аңа салкын гына тонда рәхмәт әйтте. Аның үзен шулай салкынрак тотарга сәбәбе дә бар иде.

...Төзелешкә алтмыш километрдан артык ераклыкта булган Кама буендагы карьердан ком ташу Зиннурның акылына һич кенә дә сыеша алмады. Ул җирнең шәфкатьле булуын, аның куенында мең төрле җәүһәрләр ятуын, бу бәхеттән Тын елга буйларының да мәхрүм булмаска тиешлеген уйлап йөрде. Шул турыда Василга әйткәч, тегесе җанланып китте. Аның өстенә тагы Зиннурның ташландык «Бояр чокыры» турында Варвара карчыктан да ишеткәне бар иде. Карчыкның сөйләвенә караганда, Астахи бояры каралтыларына шуннан ком ташыганнар, комны измә ясауда файдаланганнар.

Поселоктан ерак булмаган ком базын Васил үзе барып карады. Тиздән үзәк лабораториядән дә килеп җиттеләр.

Шуннан башланды...

Мәгәр төзелеш өчен бу зур табышка Юлдашевның гына артык исе китмәде. Ул ком базыннан файдалануны, тегe-бу сәбәпләр табып, сузды да сузды. Василның әнә шул хәлгә борчылып йөргән көннәре иде.

Ул түзмәде, газигына утырып, карьерга юнәлде. Җир селкетеп эшләгән бихисап авыр һәм куәтле машина-экскаваторның зур чүмече белән бер-бер артлы килеп торган үзбушаткычларга алтын кебек саргылт ком төявен Васил сокланып карап торды. Бу минутларда юллардан чыккан тузан болыты да, көчле машиналарның, өзлексез үкерә-үкерә, киң күкрәкләре белән һаваны ярып барулары да — һәммәсе әйтеп бетергесез күңелле иде аңа. Ул якынрак барса, бу зур пәһлеван машинаның номерыннан ук үзенә таныш икәнен чамалап алды. Карьерда Зиннур Гафиятуллин экипажы эшли иде. Баш кагып кына исәнләштеләр. Монда шулай юана торгач, Васил көндезге тәнәфес җиткәнен дә сизми калды.

Зиннур кабинадан чыкты да хәтсез биектән җиргә сикереп төште. Аның куллары мазут-майга буялып каралган иде. Бу кулларның каралыгын күрмәгәндәй, Васил аның белән кул кысып күреште. Зиннур тиз генә кулларын комга ышкып, сыланган майларны бетерде. Аннары юл буендагы чирәмлеккә чыктылар. Бераз шунда басып тордылар да саф яшеллек белән өртелгән чирәм өстенә килеп утырдылар. Ул арада машинист ярдәмчесе, Зиннурның булышчысы проммәйдан ягына ашханәгә китеп барды. Бу араларда бер-берсен күргәннәре юк иде. Васил язгы былчыракларда, юл газаплары кичеп, Яңа Наратлыга бергә килүләрен исенә төшерде. Аннары Зиннурның хатыны килгәч, Игнатларга күченүләрен, ниһаять, «күселе төн» турында көлә-көлә искә алдылар. Зиннур сумкасыннан ашамлыклар чыгара башлады. Калын-калын икмәк телемнәре кисеп, май якты. Йомыркалар чыгарып куйды. Ул шешә белән чәй дә, сөт тә алган икән. Тик менә стаканы гына берәү. Башта Василның ашарга исәбе юк иде кебек. Ләкин дусты кыстый башлагач, каршы килмәде, Зиннур алып килгән шактый мул әбәтне бергәләп ашадылар. Үзенең зәңгәр күзе белән җиргә текәп караган җәй күге кояш нурларын да бик мул җибәрә, башта яхшы ук эсселәткән иде. Әмма каяндыр пәйда булган ак канатлы болытлар берсе икенчесенә кушылып, күперә барганга, тиз арада күләгәләтеп тә җибәрде. Сулышка иркенрәк булып китте. Моңарчы ничек ишетмәгәннәрдер, кошлар әле сайраудан туктамаганнар икән. Күктә үзләре күренмәгән тургайларның тормыш ямен мәдхия җырлаулары аларның да дикъкатен тартты.Ниләрне генә искә төшермиләр алар! Кешенең бала чагыннан колагына кергән тургай моңы ул картайганчы, гомергә яшь аваз, яшь моң булып, яз күрке булып шулай яңгырап тора. Бер арада Зиннур сүз катып җибәрде:

— Хатлар киләме соң, Васил Закирович?

— Килгәли сирәк-мирәк.

— Монда килергә исәпләмиме?

— Әлегә сизелми,— диде Васил, авыр гына сулап.

Зиннурның аның хатынына карата «таш бәгырьледер ул» дигән кебегрәк каты-каты сүзләр әйтәсе килсә дә, кешенең хәтере калырын уйлап, бу турыда сүз катмады.

— Үзегезнең хәлләр ничек? — дип сорады Васил.

— Ярыйсы.

— Хәмидәң эшлиме?

— Эшли.

— Балалар үсә?

— Үсәләр. Әле кызыбызны детсадка урнаштырдык. Тик менә аннан башка Варвара әби генә күңелсезләнә. «И кодаем, тагы яңгыз калдым. Көн буе каз бәбкәләре, тавык чебиләре белән генә сөйләшеп йөрергә калды миңа»,— ди.

Икесе дә җиңелчә генә көлешеп алдылар. Аннары болай утыру туйдырды, ялыктырды булса кирәк, йомшак чирәмгә чалкан яттылар. Күкнең бер читендә салмак кына болытлар ага. Ә зәңгәрлек, төпсез һәм очсыз-кырыйсыз зәңгәрлек, бөтен әтрафны каплап алган.

Җир!

Кеше!

Җиһан! Болар турында уй йөрткәндә Васил ничектер югалып калган шикелле булды. Бу мәңгелек, бу чиксезлек, бу кеше аңына сыймаслык киңлек алдында югалып калырлык та шул! Кеше, хәер, аның күңеле үзе бер дөнья чаклы булса да, табигатьнең гигант җисемнәре белән чагыштырып караганда кечкенә, бик кечкенә. Аның гомере дә әйтеп бетергесез аз, әйтеп бетергесез кыска... Әмма ничек кенә булмасын, кеше боларның һәммәсен тоя, белә, һәркайсына бәя бирә белә. Шул зәңгәрлек, шул бушлык чиксез һәм мәңгелек булган кебек, кешенең күңеле-хыялы да шулай киң, шулай чиксез һәм шулай мәңгелек! Кеше-

нең гомере сүнгәч, аны икенчеләр, ягъни яшь буыннар дәвам иттерә, уйлар, тойгылар һәм күңел киңлеге дә шуларга күчә...

Зиннур сүз кушмаса, ихтимал, Васил табигать турында шулай уйлана биргән булыр иде әле. Зиннур сүз башлады:

— Ифрат бай безнең бу тирәләр. Моннан берничә генә километр ераклыкта нефть чыга. Кызык кына: җир астында кара алтын, җир өстендә чын алтын дигәндәй, иген кырлары.

— Моннан ерак түгел күмер дә тапканнар. Ләкин шактый тирәндә икән, чыгару өчен уңайсыз,— дип өстәде Васил.

Ком базын эшләтә башлаганчы, баш инженер белән нихәтле тарткалашуы турында Зиннурга сөйләмәде ул.

— Монда инде аның комы булгач, ташы да булмый калмастыр. Тирә-як авылларда таш амбарлар хәтсез күренә ич. Ташны әллә кайдан ерактан китермәгәннәрдер бит.

Зиннурның болай кызыксынуы һәм чын хуҗаларча фикер йөртүе Василга охшап куйды. Аның бу гади, намуслы эшчене дусларча кочаклап аласы, аңа җылы сүзләр әйтәсе килде. Алар икесе дә җиргә яткан урыннарыннан торып утырдылар. Васил талчыккан беләкләрен язып алды да Зиннурның җилкәсенә кулларын салды, сүза төшебрәк әйтте:

— Мин барысын да күзәтеп йөрим. Таш турында да уйласы бар. Элек монда берничә урында таш чокырлары булган. Ләкин сыйфаты әллә ни түгел шикелле. Шулай да тикшереп карарга кирәк.

— Әйбәт булып куюы да бар,— дип каршы төште Зиннур.— Арматурасын булсын, агач материалын, ташын-комын дигәндәй, гел читтән китертү дәүләт җилкәсенә җиңелгә килми бит.

— Әйе шул,— дип аның сүзләрен хуплады Васил.— Кайчагында бездә шулай да килеп чыга әле, Әстерханда торабыз, Архангельскидан төзү материалы ташыйбыз... Чарасына керешкәндә шул ук материалны Әстерханның үзендә үк табып була.

Якындагы иген кырлары өстеннән яшел дулкыннар йөгерә. Бу күренеш гәүдәләргә җиңеллек сала һәм күзләргә үзенә генә хас бер рәхәтлек, бер ял бирә иде. Алар әкрен генә урыннарыннан кузгалдылар.

— Ничек соң, иялэнеп җитәбезме? — дип сорады Васил.

Зиннур эре-эре тешләрен агартып елмаеп куйды:

— Кешегә күп кирәкмени? Йокларга почмак булгач, хатын янда булгач, дигәндәй, башкасы турында артык борчылмыйсың инде. Менә тагы бер биш ел үтсен әле, бу як бөтенләй таныш та булмас.

Васил дәшмәде. Биредә ул әлегә ялгыз. Аның кебек яшь ирләргә хатынсыз торулар, ай-һай, читен икән. Еш кына аның күңелендә моңсулык канат җәя һәм йөрәкне кимереп гел эч поша. Шундый чакларда, йөрәкне басу өчен, хәтта ул ике-өч тапкыр нык кына төшереп тә карады. Ләкин бу каты йоклап эшкә соңга калудан һәм баш авырттырудан башка берни дә бирмәде.

Тагын бит әле күңел дигәнең бер урында гына тора алмый. Ул, күктә атылган йолдыз кебек, әллә кайларга җитә. Кайларда гына булмыйсың күңел белән! Төзелештә матур-матур гына хатын-кызлар бар. Аңа соңгы көннәрдә берничә тапкыр бригадир кыз Мәдинә белән клубта очрашырга туры килде. Бу шаян, соры күзле, калынрак иренле, урта буйлы, салмак хәрәкәтле кыз белән ике мәртәбә клубтан бергә кайттылар. Берсендә алар, клубтан чыккач, азрак сөйләшеп бардылар да, һәркайсы үз юлы белән китте. Икенчесендә инде ничектер шунда көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты. Алар караңгы урам буенча янәшә атладылар. Йортлардан төшкән яктылыкны исәпкә алмаганда, урамнарда электр лампалары янмый иде. Нигәдер берсенең дә ашыгасы килмәде. Тегe-бу турыда сүз алышкалап атлый бирделәр. Әле күптән түгел генә җитештерелгән бию мәйданына килеп җитәрәк, үзләре дә сизмәстән, тукталып калдылар. Мәй-

данда бик кызып биилэр, радиоладан көчле вальс моңнары сибелә иде. Алар мәйданга артык якын килмәделәр, аяклары тартмады бугай.

— Әйдәгез, әрәмә буеннанрак бер урап килик,— диде Васил.

Мәдинә риза булып та, каршы килеп тә сүз әйтмәде, Васил белән янәшә атлый бирде. Аларга уртак тема, уртак сүз табу кыен иде. Һәркайсы моны сизенми калмады шикелле. Өзек-өзек әйтелгән сүз әлеге шул эш, бригада, төзелеш хәлләреннән ерак китә алмады. Алар поселоктан чыкмадылар, әрәмә янына килеп тукталып тордылар. Мәгәр якында җайлырак урын очраса, бәлки утырып та торган булырлар иде. Бу инде аулак җир, тәрәзәләрдән ут яктысы төшеп тормый, күк битендә балкып йолдызлар янса да, төн хәтсез караңгы иде. Һәр икесенең баскан урыннарыннан тиз генә кузгалып китәселәре килмәде. Чөнки әрәмәлек ягыннан килгән саф һава аларны үзенә суыра, яфрак-чәчәкләрнең хуш исләре үзләренә тарта иде. Аннан да бигрәк якында гына ишетелгән сандугач сайравы, сандугач моңы йөрәкләрдәге нечкә хисләрне тирбәтеп уята һәм дөньяда барысын оныттырып, ниндидер тылсымлы көч белән үзенә чакыра, бөтен күңелләрне били иде. Кинәт кенә:

— Сандугачның флейтәсе дә, джазы да үзендә, менә ичмасам музыкант,— дип куйды Васил.

— Әйтәсе дә юк, Васил абый,— дип, Мәдинә аның сүзләрен куәтләде.

Васил башлаган фикерен дәвам иттереп тагы сүз кушты:

— Бу асыл зат турында никадәр шигырьләр укыганым бар. Ләкин алар берсе дә сандугачның үз сайравы кебек матур түгел.

— Минем дә,— дип, аның белән килеште Мәдинә.

Вакытның һаман соңгара баруын исенә төшереп булса кирәк, Васил кайту ягына борылуга, Мәдинәнең кинәт теле ачылып китте. Кыз караңгы урамдагы баракларның берсендә, җизнәләрендә тора иде. Васил аны барак ишек төбенә кадәр озата килде. Бу вакытта кешеләр инде йоклап беткән, бары тик бер-ике тәрәзәдә генә ут яктылыгы сирпелә иде. Баскыч төбенә килеп җиткәч тә, Мәдинәнең тиз генә баракка кереп китәсе килмәде. Икесе дә беркадәр югалыбрак, каушабрак тордылар да, бары тик шуннан соң гына Васил кызга тыныч төн, татлы йокы теләп китеп барды. Күңеленә ниндидер хәвеф һәм шуның белән бергә рәхәтлек салган бу төннең артта калуына әле күп гомер узмаган булса да, бу турыда берничә тапкыр исенә төшерде Васил. Барыннан да бигрәк Мәдинәнең баракка килеп җитәр алдыннан әйткән сүзләре аның башына менеп утырды. Ни диде әле Мәдинә? «Васил абый, безнең кызлар сезнең турыда сүз чыкса, бәхәсләшеп китәләр. Берсе әйтә: Васил Закирович — өйләнмәгән кеше. Берәүләр әйтә: өйләнгән. Берәүләр әйтә... Моның кайсы дөрес икән?» Нишләсен? Васил үзеннән-үзе кача алмый бит инде. «Минем хатыным һәм улым бар»,— диде ул аңа.

Шуннан соң ул Мәдинә белән очрашмады. Аны күргәндә дә ничектер читләтебрәк уза башлады. Аның күңелендә үз-үзенә ышанмау, үз-үзеннән курку кебек ниндидер ят хис баш калкыта кебек тоелды.

## 8

Бу көннәрдә яңа йорт житешеп, Васил белән бер бүлмәдә торучы Солтан Сабиров шунда торырга чыккан, авылдан хатынын да китерткән иде. Васил гостиницага кайтып керсә, аптырап калды. Почмакта ята торган карт инженер күптән инде ерак командировкада, Солтанның караватын чыгарганнар. Дөрес, бүлмә иркенәеп калган, әмма аның үзенә генә нигәдер чит һәм ямансу иде. Васил кулына китап алды. Ике-өч бит укырга өлгермәде, ишектә вахтер хатын күренде. Көннән-көн калыная барган бу өлкән яшьләрдәге апаның иңеннән буен аеруы кыенлашып бара иде инде. Аны күргәч, Васил көлемсерәп куйды. Вахтер хатын, тыенкы гына исәнләшкәч, аңа ике конверт тоттырды.

— Сез кайткач та бирергә онытканмын, ачуланмассыз инде,— дип гафу үтенде дә чыгып китте. Васил, дулкынланган һәм йөрәге дөп-дөп типкән хәлдә, Нурзиләдән килгән хатны ачып укый башлады. Нурзилә сәлам-мазар һәм яхшы теләкләрен әйткәннән соң, байтак кына үпкә сүзләре дә тезгән иде. Хатның аерым урыннарын Васил кайта-кайта укыды: «...Син һаман чакырып язасың, килергә кушасың. Өндисең. Ничә ел тордык. Әмма бер-беребезне аңламаганбыз икән. Үзең акыллы гына итеп, салкын кан белән исәп йөртеп кара, әгәр дә мин синең янга күчеп килсәм, бер мәгънәсезлек кенә эшләгән булыр идем. Турысын гына әйткәндә, җир белән күк арасында калыр идем. Ни өчен дисәң, моннан күченеп китсәк, зур шәһәрдәге бөтен уңайлыклары булган яхшы квартирдан колак кагабыз дигән сүз. Аннан инде, картлар әйтмешли, терсәкне тешләп булмас, соң булыр.

Син киләчәк турында уйламыйсың бугай. Анда бит төзелеш гомергә бармас. Бишме, алтымы ел үтеп китәр, аннан нишләрбез? Тагы кая булса да китеп олагыргамы? Белмим, төзелештән төзелешкә тузан йотып йөрүдән нинди тәм, нинди кызык таба торгансыңдыр инде син? Өйләнмәгән кеше булсаң, бер хәл иде. Аннары бит улыбызның киләчәге турында да уйларга кирәктер. Төрле җиргә күченеп йөрсәк, ул рәтле тәрбия дә, белем дә ала алмас. Аннары гомер буе күңеле китек булып калыр һәм безгә онытылмаслык үпкә тотар. Түз! Әле моның белән генә сүз бетми.

Синең инде канатларың нык, дипломлы инженер, белгеч. Ә мин урта мәгълүматлы медицина эшчесе. Мин бу килеш катып калырга уйламыйм. Институтка керергә исәп йөртәм. Синең янга, каядыр ерак авылга күченеп китсәм, минем бу хыялымны тормышка ашыру турында башка да кертеп карарга ярамый. Ә мединститутка читтән торып укырга алмыйлар. Син моны үзең дә бик яхшы беләсең.

Аннары бит, һич яшерен-батырын түгел, дөньяда яшәгәч, аның бар рәхәтен, ләззәтен татып яшисе килә. Анда нинди рәхәтлек булырга мөмкин? Ни киносы, ни театры, ни рәтле магазины юк димәсәм. Син минем белән сөйләшкәндә һәм язган хатларыңда, башкалар күченәләр, торалар, дисең. Әллә кайлардан киләләр, хәтта Мәскәүнең үзеннән килеп эшләүчеләр дә бар, дисең. Шуны да онытма: һәркемне мин үземә үрнәк итеп карый алмыйм. Тормышны шаблон белән үлчәп булмый. Һәркем үз акылы белән үзенчә яши бу дөньяда, беләсең килсә... Минемчә, ир янында тору гына әле тулы бәхет була алмый. Синең яныңа килдем, ди. Ну, эшкә йөргән булырмын инде. Кухняда узар ярты гомер. Сиңа бала ташырмын. Аннан берничә елдан ни булыр? Сиңа тагылган бер гади хозяйка булырмын да калырмын. Я, үзең уйлап бак: моның ни кызыгы һәм нигә кирәге бар? Ә безгә бер бала бик җиткән. Бүтән кирәк түгел...

Үзең безнең янга кайтмый тормассың әле. Тагы бер кат ныклап сөйләшербез. Әйтәсе килгәнем шул: синең үзенә әкренләп кенә яңадан шәһәргә әйләнеп кайту ягын карарга кирәк. Синең кебек кешегә һәркайда эш тулып ята. Мине һәм улың Ринатны яратсаң, үз итсәң, менә син шул турыда уйла.

Тиз вакыт эчендә җавап көтеп калам...»

Васил өстәл каршына утырган килеш бу хатны укыгач, ни кылырга белмичә, иң элек ике яңагына таянды, аннары бармакларын чәчләренә батырды. Нурзиләнең бу соңгы хаты аны бөтенләй тетрәтеп җибәргәндәй булды. «Аңламаса аңламый икән кеше. Кая каера бу? Тик бер сүзе хак: без бер-беребезне белеп яшәмәгәнбез икән»,— дип кычкырып әйтеп куюын да сизми калды Васил.

Коридорда кемнәрдер шаулашып алдылар, кайсыдыр җырлап җибәрде, кемнәрдер көлешеп узды. Васил һава алмаштырып керергә исәплап урыныннан торуга, өстәлнең бер читенә куелган икенче конвертка күзе төште. Шунда гына ул бүген берьюлы ике хат алуын исенә төшерде.

Хатның кайдан җибәрелгәне билгесез иде. Кулы да таныш түгел. Васил аптыраулы кыяфәт белән конвертны ачты. Хатны укый башлаганчы, аның ахырын карады да, имзасын күргәч кенә, вак һәм тигез хәрефләр белән язган юллар өстеннән күзләрен йөгертте:

«Васил Закирович!

Мин башта беркемгә, беркайчан, бер авыз сүз дә язмаска уйлаган идем. Ләкин тора-бара түзеп кала алмадым. Шушы хатым белән сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым. Төзелештән минем ник киткәнлегем хәзер сезнең һәммәгезгә дә билгеледер инде. Үзем белән бер бригадада эшләгән кызлар барысын да энәсеннән-җебенә чаклы беләләр. Алар сезгә дә ишеттерми калмаганнардыр. Мин бу турыда тәфсилле рәвештә язып тормастан, үземнең кайда икәнлегемне сезгә хәбәр итәргә тиеш дип саныйм. Мин хәзер Чистай шәһәрендә. Монда сәгать заводына өйрәнчек булып эшкә керергә барган идем, хезмәт кенәгәмне сорадылар. Ә мин аны алмадым ич. Барлык документларым да сезнең кадрлар бүлегендә. Башта турыдан-туры сездән расчет сорап җибәрергә уйлаган идем да, ничектер соңыннан күңел тартмады. Хәзер монда каласым килми. Иптәш кызларымны сагынам, әллә кай ягы белән үзенә тарта шул Яңа Наратлы, шул Тын елга буйлары...

Әгәренки мөмкин булса, мин яңадан анда кайтыр идем. Билгеле, беркемгә бер сүз әйтмичә, эшне ташлап киткән өчен сез миңа рәхмәт әйтмәссез. Нишлим? Сәбәпләре булды бит...

Шулай, Васил абый, әгәр сез миңа ачуланмасагыз, күрсәтелгән адрес буенча кош теле кадәр генә хат кисәге язып җибәрегез әле. Борчуым өчен гафу итегез.

*Сәлам белән Гөлзадә.»*

Нурзиләнең әче-әче сүзләрен укудан һәм аннан алган авыр тәэсораттан әле айнып җитмәгән Васил беркавым ишекле-түрле йөренеп алды. Аның күз алдында бер Нурзилә, аннары аны артка этәргән шикелле, якты карашлы, оялчан Гөлзадә килеп баскандай булды. Әллә ничек кенә шунда, Васил бер көенде, бер сөенде. Бу көннәрдә үзенең һич көтелмәгәндә юкка чыгуы белән күпләрне пошындырган һәм борчуга салган кызның исән-иминлеге һәм аннан хат килеп төшү Васил өчен дә күңелле иде. Кара син аны, кыю кыз икән бу Гөлзадә. Хат язуы шәп!

Васил бу кыю кыз белән бергә Акъярдан кайтуларын күз алдына китерде, бүлмәдән чыгарга ниятләп өстенә киенә башлады. Ул да булмады, ишек шакыдылар.

— Рәхим итеп керегез.

— Мөмкинме?

— О, Мәдинә! Әйдә, утырыгыз!

Төзелештә гадәти эш киеменнән йөргән Мәдинәне хәзер танырлык та түгел — өстендә җәйгә хас затлы юка күлмәк, аягында кар кебек ак туфли. Чәчләре тузып тора, калынрак иреннәреннән шатлык тамар шикелле. Гадәттә тәмәке исе килеп торган бүлмәгә Мәдинә хушбуйкершән исе таратып, болыннар сафлыгын аңкытты. Мәдинәгә дә хат килеп төшкән икән.

Мәдинә килгәнче үк Васил үзенә килгән хатларны өстәл тартмасына салып куйган иде. Ул бераз уйланып торды да Гөлзадәдән үзенә хат килгәнен әйтмәскә булды.

Мәдинә аңа Гөлзадәдән килгән хатны укып күрсәтте.

— Димәк, ул Рафистан качып киткән? — дип сорап куйды Васил.

— Шулай килеп чыга.

— Болай югыйсә Рафис усал егеткә охшамый бит?

— Усалын усал түгел инде ул анысы. Иллә бәйләнчеклеге бар. Мөгаен, үзенең әрсез әрләнлеге белән Гөлзадәнең саруын кайнаткандыр.— Ул сүзен раслау өчен хаттагы бер юлны кабатлап укып күрсәтте.

ына карамасаң, сине яки үземне бер хәл эшләтәм...» Менә ни дигән бит.

Васил башын селкеп гаҗәпләнеп куйды:

— Чудак бу Рафис дигән егет.

Мәдинә, аны ишетмәгән кебек, үзен кызыксындырганны әйтте:

— Сез ничек карыйсыз, Васил Закирович? Кайтсынмы?

— Гөлзадәме?

— Әйе.

— Кайтсын, әлбәттә, кайтсын! — диде Васил.

Мәдинә канатланып очып чыгып китте.



## 9

Баштарак нигәдер ул аңа шикләнеп, ышанмыйчарак караган иде. Самолетта бергә кайтканда күңеленә бер дә ятмаган иде ул кеше. Юлдашев аны күптән белә икән. Ул Кукушкин турында яхшы характеристика бирде дә аны яр буе насосыннан өлкән прораб итеп тәкъдим итте. Һәм менә хәтсез вакытлардан бирле инде калын гәүдәле, үзенең кыяфәте белән гамьсез күренгән Сергей Сидорович Кукушкин яр буе төзелешләрендә әвәрә килеп йөри. Килгәненә әле күптән булмаса да, ул кешеләр белән тиз аралашып, тиз танышып өлгерде. Кешеләрнең исем, фамилияләрен дә тиз хәтерендә калдыра икән үзе. Әле күптән түгел кертелгән, эш башланганчы уздырыла торган бишминутлыкларда Кукушкин эшлекле һәм кирәкле генә тәкъдимнәр ясады. Шуннан соң аңа Василның карашы да әкренләп үзгәрә барды һәм аңа ышанмый мөмкин түгел иде кебек.

Кукушкин икенче номерлы насос станциясен өлгертүдә дә бик зур тырышлык салып йөрде кебек. Ул аннары киңәшеп эшләргә ярата. Башта аның болай итүе Василга ярыйсы күренсә дә, бара-тора, ягъни атлаган саен, вак кына әйберләр турында дөнья хәтле фәлсәфә сатуы ошап бетми башлады. Ләкин аның үзенә генә хас тагы ниндидер сыйфаты бар: сүзеннән туя башлауны тиз тоя, тиз чамалый белә. Тик менә бара-тора Кукушкинның сәер генә гадәтләре ачыла башлады. Эшнең иң кызу вакытында ул кинәт каядыр китеп югалып-югалып тора. Шуның аркасында кайбер тоткарлыклар да чыкмый калмый. Инде Васил бик каны кызып, икенче шалтыратуга тагы үз урынында була. Үзенең объектта булмый торуын теге-бу материал артыннан чабып йөрүе белән аңлата да, шуның белән эш бетә.

Кукушкин башта гостиницада торды. Васил аны еш күрә, ул нича карасаң да коридорның бер башына куелган бильярд өстәле тирәсендә шар сугучылар арасында була иде. Соңгы көннәрдә ул күренми башлады. Озакламый аның Иске Наратлыга күчеп китүе турында Василның да колагына килеп сугылды.

Юан вахтер хатын, ул күченеп киткәч, аның караваты астыннан әллә ничә дистә шешә җыеп алды һәм, Кукушин шешәләре дип, күргән-белгәнгә сөйли йөрде. Ләкин бу сүзләргә илтифат бирүче булмады. Шулай булмый мөмкин дә түгел иде. Кукушкинның чырае кайчан гына булмасын, кызыл, ул аның табигый тазалыгыннан булса кирәк. Аның эчүчегә охшаган бер билгесе дә юк: күзләре дә чиста, үзеннән ис тә килми, гәүдәсендә дә чалышлык-фәләнлек юк, теле дисәң дә көрмәкләнми, киреҫенчә, тәтелдәп кенә тора.

Без капчыкта ятмый, дигәндәй, тиздән Кукушкин турында яңа хәбәрләр йөри башлады. Имештер, ул Иске Наратлыда бер тол хатынга өйләнгән. Бу хәбәр эшчеләр арасында анда-санда гына телгә алынса да, конторада утыручы хатын-кызның шактый вакытлар бер дә телләреннән төшмәде. Чөнки өлкән яшьләрдәге бу кеше алимент түли, аның каядыр

Красноярск ягында аерган хатыны һәм житеп килә торган кызы булуы турында конторада эшләүчеләрнең барысы да диярлек беләләр иде.

Бишминутлык үткәргәндә Васил Кукушкинга карашын текәп, басым ясап әйтте:

— Сезнең алда аеруча җаваплы эш тора, Сергей Сидорович, янгынга каршы резервуарларның сыйфатына аеруча әһәмият бирегез,— диде.

Кукушкин юмарт елмаеп җавап кайтарды:

— Сынатмабыз, Васил Закирович, беренче ел эшләү түгел. Андый резервуарлар ясый-ясый чәчләр коелып килә.

— Һәммәсен дә үзегез лично тикшереп торыгыз.

— Борчылмагыз. Нәкъ сез әйткәнчә үтәлер.

Төзелешнең һәр участогында кызып эш барган чагында, Васил һәр кайсын күз алдыннан кичерде дә бухгалтерия документларына күз куйды. Проммәйданга чыкты. Башкалар турында тукталгалап, Кукушкин участогына да килеп чыкты. Бергәләп арматураларны тикшерделәр, тышламаларны карадылар. Һәм шуннан соң Васил кешеләргә яхшы теләкләр теләп китеп барды. Аның икенче шалтыратуына Кукушкин:

— Хәзер бетон килә башлады, салабыз,— дип җавап кайтарды.

Моннан соң инде Васил, тынычланып, башка эшләр белән шөгыльләнергә кереште. Һәр задание, һәр эш өчен куелган җаваплы кешеләр бар. Әмма Васил, зур төзелешнең төп эшләрен алып баручы идарә башлыгы буларак, башкарылган эшнең һәркайсын диярлек үз күзе белән карап чыга, җибәрелгән ялгышларны кайнар эздән төзәтү чаралары күрә иде. Өч көннән соң Кукушкин резервуарларда эшнең тәмамләнүе турында хәбәр итте. Монда да Васил үз күзе белән барып карамыйча түзмәде.

Кукушкин алдан, аның артыннан Васил Сафин резервуар уентыгына төштеләр. Васил җентекләп карый башлады. Кукушкин сизәме, юкмы, мәгәр Василның төсе торган саен төкселәнә, күзләренә ачулы очкыннар чыга бара иде. Резервуарны карап чыккач, ул гаҗәпләнүдән бот чабып куйды. Ярты минут вакыт, бер сүз дә әйтмичә, башын селкеп торды. Аннары шул төксе, кырыс, ачулы карашы белән Кукушкинның каршына килеп басты. Сүз башлаганчы, тагы да башын селкеп торды.

— Димәк, бетердегез?

— Шулай дип торган көн инде.

— Бетон салганда гел шушында күзәтеп, күрсәтеп тордыгызмы?

— Бер урында гына торып булмый бит. Теге эш, бу эш килеп чыга, киткән чак та булгандыр...

Василның бик әче, бик тешле итеп сүгенәсе килде. Әмма тешен кысып булса да түзәргә тырышты.

— Беләсезме, Сергей Сидорович, нәрсә?

— Тыңлыйм сезне, Васил Закирович.

— Беләсезме нәрсә,— дип кабатлап дәвам итте Васил.— Утыз жиденче ел булса, бу эш өчен сезгә корткычлык маркасы ябыштырырлар иде дә башыгызны төрмәгә тыгарлар иде. Менә бу нәрсә? Ә менә монысы...— Васил аңа бармагы белән төртеп-төртеп, бик күп урында тигез түшәлмәгән, хәтта ярыклары булган бетон стенаны күрсәтте.

— Брак!

— Төзәтербез,— дип гаебен таныды Кукушкин.

— Моны икенче мәртәбә сезнең хисапка эшләтергә туры килер.

— Ничек инде ул тагы?

— Ник брак җибәрттегез?

— Э, ни, үзем дә аңламыйм...

— Монда эш тоташтан тукталмыйча башкарылмаган. Шуның аркасында брак киткән. Сез карамагансыз, каядыр китеп йөргәнсез. Бракның бөтен хикмәте шунда...

Кукушкин акланмады, аскы иренен тешләп сүзсез катып калды.

Васил дәвам итте:

— Моны каерып аттырыгыз да, үзегез карап торып, бер очтан бетон алдырыгыз.

— Тыңлыйм, Васил Закирович.

— Мондый хәлләр тагы да очрый калса, безнең дуслык бетә, белеп орыгыз, Сергей Сидорович.

Тегесе чыраена мескенлек чыгарган итте, уң кулын күкрәгенә куеп, өчәнеп елмайды да түбәнчелек күрсәтеп баш иде.

Васил берничә көннән соң резервуарны икенче мәртәбә барып карагач, бик канәгать калды, күңеле йомшарды. Ләкин үзе мактап та, хурлап та сүз катмады. Беренче караштa туган каты чаралар куллану: приказ язып шелтә бирү һәм икенче кат бетон салу бәясен Кукушкиннан тотып калуны гамәлгә ашырмады.

Кукушкинның, гәрчә хаклы булмаса да, Василга гаять хәтере калды. Аның күз алдына төрле куркынычлар килеп басты. Түзмәде. Ул-бу булмагае дип, Юлдашев кабинетына юнәлде.

— Хәтәр җилләр хәвефеннән саклап калыгыз, Зариф Салихович,— диде ул аңа.

— Нинди җил тагы? — дип кырыс кына сорап куйды Юлдашев.

Кукушкин гадәтенчә тигез тавыш, китаптагыча шома җөмләләр белән мескенләнгән кыяфәттә тезеп китте. Иң элек ул Зариф Салихович исеменә мәдхия укыды. Аннары Василның аңа карата кирәгеннән артык кырыс икәнен ирештерде. Барлык кыяфәте белән көлке сыман күренгән, аның исәбенчә, «әүлия җанлы» бу кешене Юлдашев күптән белә иде. Уртача сәләтле, телсез-тешсез, үзенә тапшырылган эшне булдыра алган хәтле үтәп, башлыкларга, бигрәк тә аның үзенә һәрвакыт турылыклы бу кешене Юлдашевның беркем тарафыннан да җәберләтәсе килми иде. Шуның белән бергә, Кукушкинның абына торган гадәтен белгәнгә, иң элек ул аны эттән алып, этка салып сүкте. Тегесе инсафлының инсафлысы кебек кызарып-янып утырды да керле кулъяулык белән маңгай тирләрен сөртеп алды. Башка төзелешләрдә эшләгәндә дә Зариф Салиховичның мондый сүзләрен күп ишеткән бу кеше, әйтерсең лә, минут саен юашлана бара һәм аның гәүдәсе кечерәеп, аяклары идәнгә сузыла иде.

— Син инде минем белән өченче төзелештә эшлисең,— диде Юлдашев.

— Шулай, Зариф Салихович.

— Нигә синнән картайганчы балалык чыкмый, юләрлек китми?

— Алай ук түгел инде, сез бигрәк, Зариф Салихович.

Юлдашевның төсендә елмаю сызыкларының арта баруын күргәч, Кукушкин аякларын җыебрак, калкыныбрак утырды һәм үсеп киткән кебек булды. Үзе дә вакыт-вакыт чыраена көлемсерәүгә якын яктылык чыгара башлады. Юлдашев аңа хәйләкәр генә карый-карый, салмаграк тонга күчте:

— Тагы өйләндеңме, шайтан?

— Юк. Нәрсә сөйлисез сез, Зариф Салихович!..

— Өйләнеп күченеп киткәнсең ич...

— Мин яңа квартирага гына чыктым.

— Кемдә торасың?

— Бер тол хатында.

— Кемнәре бар?

— Мавринаныңмы? Бер кечкенә малае бар. Малы-туары, кош-корты дигәндәй...

— Яшьме?

— Бик йомшак күңелле яшь хатын ул. Ямьсез дип тә әйтеп булмый. Инде сездән яшерер хәлем юк, бер үземә генә күңелсез бит... Кайчан да булса барыбер бер үләсе, миннән генә калмас бу дөнья...

Юлдашев, башын селки-селки урыныннан торып, идән буйлап йөргәләп килде һәм тагын урындыгына килеп утырды, аякларен кашып алды. Елмаю очкыннары аның күзләренә хәтле бәреп чыкты:

— Менә Дон-Жуан, менә плут, менә хамелеон,— диде ул Кукушкинга.— Барган бер җирдә өйләнә. Мин инде синең өченчеме-дүртенчеме тапкыр өйләнүеңне ишетәм...

— Алай ук түгел түгелен... Шулай туры килә бит, тормыш үзе куша,— дип акланырга тырышты Кукушкин.

Юлдашев аның бу сүзләрен ятышсызрак тапты, күрәсең, каршы төште:

— Ничек итеп инде, мәсәлән, тормыш кушсын?! Эшләгән бер җирдә хатын калдыру, бу инде газеталарда язылганча әйтсәң, әхлакый тотнаксызлык була. Бу турыда да уйлап карыйсы бар сиңа, Кукушкин...

— Уйлап кая барасың? Бер төзелеш беткәч, миңа икенчесенә күчәргә кирәк була. Ә хатыннар калалар, күчәргә теләмиләр. Хуҗалыкларын ташлыйсылары килми.

— Кодаласаң, күчми калмаслар иде. Ныклы семья...

— Күчмиләр, Зариф Салихович, миңа шундыйлары туры килә дә тора...

— Менә плут, менә Дон-Жуан... — Юлдашев, түзмичә, тагы кычкырып көлеп җибәрде.

Тегесе салкын бер караш белән әле тәрәзәгә, әле стенадагы сызымнарга, әле Юлдашевка карангалап утыра бирде. Сөйләшә торгач, туй ясап йөрү аркасында, хезмәтеннән иртә китү һәм шул сәбәпле эшкә зыян килү кебек хәлләрнең дә булуын чамалап алды Юлдашев. Ул моның өчен тагы аны тозлап-борычлап «сүкте» дә, җил-яңгыр тиюдән курыкмаска кушып, аркасыннан какты.

— Сүз дә булырга мөмкин түгел, әлбәттә, абынмам башкача,— диде Кукушкин.

Ул чыгып китеп озак та тормады, Юлдашев телефон трубкасын алды.

## 10

Тигез юлдан ышаныч белән генә барганда кинәт чокырга төшкән сыманрак булды бу. Төзелештә цементның азаеп килүе турында хәтсез вакытлардан бирле сүзләр йөри иде инде. Көннәрдән бер көнне ул бөтенләй такырланып та куйды. Тәэминатчыларның чапмаган җирләре, шалтыратмаган телефоннары калмады. Әмма аңа карап кына цемент төягән вагоннар күренмәде. Байтак урыннарда эшне туктатып, кешеләрне икенче дәрәҗәдәге вак-төяк эшләргә беркетергә туры килде.

Төнге сменаларда эшләр тукталып калды. Көндезләрен дә элекке кебек мәш килеп эшләүчеләр, бигрәк тә бетон салучылар күренми иде инде.

Бу хәлгә төрле кеше төрлечә бәя бирде. Берәүләр барлык җитмәүчелекне төзелеш җитәкчеләренә таға, икенчеләр илдә төзелешләр күп булганлыктан, цементның җитмәвенә кайтарып калдыралар, өченчеләр берничек тә бәя бирмиләр, андыйларга көн үтсә, шул җиткән.

Төзелештә шундый куркыныч хәл тугач, комсомол прожекторчылары берничә башлыкның кабинет ишекләренә «Тревога!» язулары элеп чыктылар. Анда цемент кайтарту өчен ашыгыч һәм кискен чаралар күрик диелгән иде. Юлдашев кабинеты ишегенә дә мондый язу менеп утырды. Прожекторчылар язуны ябыштырып бетергәч кенә, ул, каядыр барырга ниятләп булса кирәк, кабинетыннан чыкты. Яшьләр китмәгәннәр иде. Юлдашев ишектәге язуны күргәч, иреннәре дерелдәгәндәй бераз тын торды, аннары ризасыз төстә әйтеп салды:

— Бу ни эш тагы? Тавыкны йомырка өйрәтә башладымы? — дип, кулларын ишеккә таба сузды.

Прожекторчылардан Виктор исемле таза озын егет аңа иплэп кенэ йтеп курсэтергэ телэде:

— Бу бер сезнең ишектэ генэ тугел, Зариф Салихович. Без өзеклекне етеру телэгеннэн чыгып шулай эшлибез...

— Өзеклекне шушы кэгазь бетерер дип уйлыйсызмы сез?

— Чарасын курерсез,— диде Виктор, кыю гына итеп.

Юлдашев кесэсеннэн папирос чыгарып кабызды да ниндидер сэер караш белэн прожекторчыларга текэлде. Иң элек Викторга сорау куйды:

— Син кайда эшлисең егет?

— Бетончы да, балта остасы да, кирэк булса монтажчы да.

— Син?

— Мин дэ. Без бергэ эшлибез,— диде Рафис.

— Син?

— Бригадир,— диде Мэдинэ.

— Эш вакытында болай йөрергэ сезгэ кем рөхсэт итте?

— Бетон юк,— дилелэр тегелэр бер авыздан.

Юлдашев аларның эйткэннэрен колагына салмастан, үзенекен итте:

— Башка эш тэ бетмэгэн. Мастерыгыз кем?

Прожекторчылар ык-мык килеп торган арада Юлдашев «Тревога» кэгазен ишектэн кубарып алып ташлады:

— Барыгыз, эшегездэ булыгыз, юкны бушка авыштырып йөрмэгез! Демагоглар сездэн башка да бетмэгэн бу дөньяда...

Яшьлэр телэр-телэмэс кенэ баш конторадан чыктылар. Бер кавым тып-тын гына атладылар алар. Проммэйданга якынлашарак:

— Үзе шундый зур урындагы кеше, үзе шундый тупас,— диде Мэдинэ.

— Җене котырган бэндэ,— дип өстэде Виктор.

Рафис, бер сүз дэ дэшмичэ, салмак кына атлап бара бирде. Аннары ул кинэт борылып китте. Болай кая юл тотуын сорагач, тыенкы гына бер төстэ: «Эшем бар»,— диде.

Кызык кына бу тормыш дигэнең... Эле кайчан гына Рафисның башында бөтенлэй башка уйлар, башка исэплэр иде. Хэзер?

Күк бите болытсыз бик сирэк торган кебек, кеше күңеле, кеше йөрэге дэ уйсыз һэм сагышсыз сирэк була торгандыр. Башта Гөлзадэ өчен күпме йөрэге теленде аның. Булмаса булмый икэн, барыбер кызны үзенэ карата алмады. Эле анысы бер хэл иде. Эллэ кайларга китеп югалып, кешелэр арасында нинди сүзлэр кубарып, мең утларга салды ул Рафисны. Ул чагында кая гына чакырып, кемнэр генэ куркытмады, нилэр дип кенэ янамадылар аңа. Кыз суга-фэлэнгэ батмаганмы, дип никадэр вакыт елга буйларында каранып йөрде.

Моннан соң инде ул бер кызга да бэйлэнмэс, сыланырга йөрмэс. Эле ул яшь. Экренлэп каян булса да аны яраткан кыз да килеп чыкмый калмас. Аның да бэхет кояшы ачылыр. Болай бит эле тегесенэ, эле монсына җан атып йөрү аның үз дэрэҗэсен генэ төшерэ. Аннары аңа да, бер җырдагы шикелле, авторитет эзлэп чабып йөрергэ туры килмэгэе...

Бары тик Гөлзадэ кайтып, яңадан үз эшенэ кергэч кенэ Рафисның күңеле урынына утырды. Рафис мөмкин кадэр Гөлзадэгэ күренмэскэ, аннан читтэрэк йөрергэ тырышты. Үкенеч һэм оялу, ул гына да түгел, гарьлэнү тойгылары аның юлын биклэде. Җитмэсэ бит эле, комсомол сызыгы буенча да шелтэ чэпэп куйдылар. Инде тормышны яңа баштан башлап җибэрим дисэ, тагы каршылык, тагы кыенлык... Кинэт ул Мэдинэ турында уйлап алды. Матурлык ягыннан Гөлзадэдэн кайтышрак сыман, ягымлылык ягы шэп булырга тиеш аның. Вакытында аңа да гашыйк булган иде ул. Тик моннан хикмэт кенэ чыкмады. Шулай булса да эллэ ничегрэк аның карашы.

...Эллэ нигэ бер караса да, бөтен йөрэгеңне көйдереп ала, нигэ алай карый ул?

Рафис ике катлы ак йортка яңадан керде. Партком секретареның кабинеты беренче катта иде. Сабиров ишекне шар ачып куйган да кемнәрбеләндер гәпләшеп утыра. Рафис кыяр-кыймас кына ишек каршында тукталып калды, гәпләшүнең тиз генә бетмәячәген уена китереп, арыбашка барды, стена газетасын караштырды. Аннары тагы, бу кая да булса китеп бармасын дигән кебек, салмак кына адымнар белән секретарь бүлмәсе янына килеп туктады. Сәгатенә күз салды. Инде кетәргәме яисә китеп барыргамы, дип торганда, Сабиров аны үзе чакырып алды:

— Рафис, нәрсә анда торасың? Кер. Утыр.

Озакламый кешеләр төрлесе төрле җиргә таралышып беттеләр. Икәүдән икәү генә калгач, Солтан Сабиров егетне өстәлгә якынрак килеп утырырга чакырды. Кирәк кайчан гына булмасын, кешеләр белән сөйләшкәндә Сабировның күзләренә сүнми торган нурлар чыга сыман, Рафис аңа карап-карап куйды.

— Хәлләр ничек, Рафис? — дип сорады секретарь.

— Үзегез беләсез, Солтан абый.

— Бетон юкмы?

— Әйе, юк...

— Тиздән булыр.

— Чын сүзме?

— Чын! Андрей Акимовичтан телеграмма килде.— Сабиров шул цемент турыннан төзелеш башлыгының йөрмәгән җире, кермәгән министрлыгы калмавын әйтте. Никитин комсомол Үзәк Комитетында да булган, мәсьәләнең уңай якка хәл кылынуына ирешкән.

Рафисның чырае ачылып ук китте. Инде ул «Тревога» турында онытада башлаган иде. Ләкин күңелдәге кимсенү хисе яңадан баш калкытты да Юлдашевның күрсәткән шул тупаслыгы турында әйтмичә түзмәде. Сабиров аны дикъкать белән тыңлаган сыман күренсә дә, шунда кинәт кенә өзеп бер сүз әйтмәде, Рафиска тагы күңелсез булып китте.

— Хәзер тәнәфес вакыты, бәлки ашыгасыздыр,— диде ул секретарьга.

— Юк, ашыкмыйм.

Бу егетнең бер вакытта да партком бусагасын атлап кергәне юк иде. Билгеле, булган күңелсезлекләрдән соң, Рафисның комсомол сызыгы буенча каты шелтә алуын Сабиров белә иде инде. Шелтә биргәнче кирәгеннән артык ваемсыз күренгән егетнең шушылай янып-көеп йөрүе чыннан да күңелле күренеш иде. Ихтимал, партком секретареның тулай торакларда булуы һәм аннан соң тиешле кешеләрнең һәммәсен дә йокыдан уятуы да эзсез калмагандыр. Солтан, шундыйрак исәп йөрткән хәлдә, Рафис белән сөйләшүен дәвам иттерде:

— Укулар ничек бара соң?

— Бармый бер ничек тә, килеп терәлде.

— Нишләп?

— Ташлыйм. Миннән барыбер бернинди дә хикмәт чыкмас.

— Юкка кәҗәләнү бу. Кемне гаҗәпләндермәкче буласың?

Рафис кайтарып әйтергә сүз тапмады.

— Мин синең канатларың кутәрелә дип торам. Баксаң, менә ничек икән. Бу турыда сүз дә булырга мөмкин түгел: укуыңны ташламыйсың, килештекме? Әллә уку өчен тиешле шартлар җитмиме?

Рафис дәшмәде, башын түбән салган килеш, моңсу гына карап утыра бирде. Дөрес, укуны ташлау турында әле аның төпле уе юк, тик күңеленең кай почмагындадыр андый уй баш калкыта гына башлаган иде. Менә әллә ничек кенә, көтмәгәндә кулдан төшкән әйбер кебек, теленнән сүз ычкынды да китте бит. Тот аны, хәзер!

Сабиров аның зачетлары ни хәлдәрәк торганын һәм консультацияләргә бару мөмкинлеге ничек икәнен һәммәсен дә сораштырды. Рафис тиздән имтиһаннәргә барырга тиеш, әмма барасы килми икән. Күптәннән

ирле китап-дәреслекләргә күз төшерми икән. Сабиров, егетнең башын-
дагы юк-бар уйларны кире кайтару турында күңеленә ныклы уй берке-
теп, бу хакта аның прорабы белән дә сөйләшергә булды. Мәгәр укуны
ташлау турында кинәт кенә сүз башлаган Рафис, шундый ук көтелмәгән-
нәрәк, бу исәбеннән баш тартуын да әйтмичә булдыра алмады:

— Рәхмәт яхшы киңәшегезгә, Солтан абый. Артталыкны ничек тә бетерермен.

— Юләр син,— дип дәвам итте Солтан.— Янадан өч, күп булса дүрт елдан инженер буласың. Сәләтең бар. Разве шуны кулдан ычкындырырга ярый?

— Дөрес,— дип аның белән ризалашты Рафис.

— Тормыш шартларың ничек? — дип кабатлап сорады секретарь.

— Зарлана алмыйм. Ике кешелек бүлмә...

— Аяклары карават астыннан күренеп торган теге егет белән бергә торасыңмы әле?

— Ул бер урында озак кунакларга яратмый икән. Әллә кайчан эзен суытты инде. Енисей буйларыннан Карчыгага хаты да килеп төште. Чакырып яза.

Сабиров тулай торакта беренче мәртәбә булуын искә төшереп булса кирәк, көлемсерәп куйды. Әңгәмә күңелле генә үз юлыннан акты.

— Синең янга кайсы күчте?

— Виктор.

— Алып батырмы?

— Әйе.

— Тегесе кебек, бу инде сине ярамаган юлга өстерәми торгандыр, шәт?

— Аныңы Виктор белән килешеп була. Үзенең гәүдәсе тау хәтле булса да, аның барлыгы да сизелми. Кич булдымы, үзешчәннәр түгәрәгенә китеп югала. Ул хәтәр шәп җырлый бит. Тавышы бар чуртның...

Тулай торакларда эшнең рәтләнеп китүен, тәртипнең әйбәтләнә баруын Солтан белә, һәркайчан күзәтеп тора иде. Әле күптән түгел генә төрле-төрле чүп җыеп яткан җирне тигезләп, егетләрнең спорт мәйданы ясаулары да бик ошады аңа. Хәтта бер-ике тапкыр ул үзе дә анда туп чөеп уйнады. Бу үзгәреш тышта гына булмыйча, бинаның эчендә дә сизелерлек яңалыклар туды. Шулар хакында уй йөрткән чагында, Рафис аның ышанычын ныгытып сөйләп бирде:

— Хәзер инде участоклардан да кешеләр килә. Сез килеп буран куптарганнан соң безнең дә дөньяда барлыкны белделәр. Карта сугучыларны тараттылар.

— Сезнең бүлмәдә дә үзгәрешләр бардыр инде? — дип сорады Сабиров.

Рафис ачылып китте, чырае сөйләгән саен яктыра барды:

— Билгеле. Теге вакытта сез искәрткәннәрне искә алдык без. Шәрә хатын рәсемен дә алырга туры килде. Тәрәзә пәрдәләре өр-яңа, урын-җирләр беренче разряд гостиницадагы кебек дисәң дә ярый. Комендант-мазарлар да эш сәгатьләрен үзгәрттеләр.

— Ничек, милиция кешеләре һаман да еш булаламы?

— Хәзер алар да сирәгрәк килә башлады. Безнең торакта аларга эш азаеп бара дигән кебек.

Инде китәргә ниятләп торганда Сабиров төсенә житдилек чыгарып әйтте:

— Ә баш инженер кабинеты ишегенә «Тревога» язуын яңадан элеп куегыз. Ул эштән чигенергә ярамый.

— Тагы алып ташласа,— дип сагая калды Рафис.

Сабиров аңа текәлеп карады.

— Алмас!

Иртәгесен эшкә килгәндә Рафис, ниндидер сылтау табып, баш конторага сугылып чыкты. Чыннан да «Тревога» язуы, ул нәкъ кичтән ябыштырганча, ишектә эленеп тора иде.

## 11

Ай ахырлары якынлашып килә иде. Бу көннәрдә Мәскәүдә булган Никитин телеграмма артыннан телеграмма җибәреп кенә торды. Ул да булмады, көннәрдән бер көнне цемент төялгән авыр вагоннар төзелешкә килеп төште. Шулай итеп, ике атнадан бирле өзеклек булып торганнан соң, эшләр тагы үз җаена кайтты, үз сукмагына басты. Проммәйданда эш җайлана барды.

Васил төп корпус корылмаларына килгәндә төш авышкан, алай да кояш миләрне кайнатырлык бер рәхимсезлек белән кыздыра иде. Ул юка чалбардан, кыска җиңле күлмәктән генә булса да, бу киемнәр белән дә эссе кебек иде. Ул күбектәй җиңел эшләпәсен бер кулына тотты, бер башына киде. Алай да эсселектән котыла алмады. Әмма кешеләр арасына килгәч, барысын да онытканшикелле, тынычланып калды. Чөнки биредәге җанлылык, күтәренкелек аның да күңел тәрәзәләренә куанычлы хәбәр сөйләп какты. Мәдинәләр бригадасына нигәдер тукталып тормыйча, башкалар янына үтте. Ләкин ничек кенә булмасын, ул Мәдинәнең кара кашларын чөеп, ирен читләренә елмаю сызыклары чыгарып аңа карап калуын тиз генә оныта алмады. Ә Гөлзадә... Ул Василга нурлы күз карашларын бер генә сирпеп алды да яңадан бетон тыгызларга тотынды. Аның карашы күктә атылган йолдызны хәтерләткәндәй якты иде. Ул гына да түгел, Гөлзадә кай ягы беләндер карлыгачны искә төшерә кебек... Бер үк вакытта Васил Нурзиләне дә күз алдына китерде. Кызык кына, бу башка ниләр генә керми дә, кеше ниләр турында гына уйламый йөртми...

Бригадир Фиргали Гатинны күргә, Васил тукталып калды. Бу өлкән яшьләрдәге кеше кай ягы беләндер көрәшчене хәтерләтә, кай ягы беләндер элекке китапларда тасвирлап язылган грузчикларга охшый. Аның камыт аяклары белән җиргә басып йөрүендә үзенә генә хас бер мәгънә бар сыман. Җитмәсә бүтәннәрдән үзенең шадралыгы белән дә аерылып торган бу кеше сүзнең җаен белеп кенә, тәмле итеп кенә сөйләшергә ярата.

— Өй тулы бала, эшләр алга бара, дигәндәй, хәзер яхшы ук тернәкләндек, Васил туган.

Васил шундук бу көндәм бригадирның төзү материалларын бик саклап эш итүен дә сизенде. Бетон салгач, арматураларның тышлама такталарын саклык белән генә алып, икенчеләренә куллануларыда бик ошады аңа. Күп кешеле бу зур бригаданың эше һәм колачы да гайрәтле иде. Васил бригадирга карап әйтә куйды:

— Беләсезме, Фиргали абзый, нәрсә, сезнең бригададан дүрт-биш кешене малярлык-буяучылык һөнәренә өйрәтергә кирәк булыр.

Фиргали абзый башын кашып алды:

— Кемне бирербез икән соң?

— Кешеләр белән сөйләшегез, уртак тел табарсыз. Аларны иң элек кыска сроклы курсларга йөртергә туры килер.

— Эштән соңмы?

— Әлбәттә.

Шул чагында, каяндыр чокырдан калкып чыккан шикелле, элеп киптерелгән кебек ябык гәүдәле, озынча йөзле озын куллы берәү боларга таба якынрак килде, Васил белән бригадирның икесенә берьюлы сорау куйды:

— Нәрсә, сезгә малярлар кирәкме әллә? — Аннары ул, берсенең дә җавап кайтарырга ашыкмавын чамалап булса кирәк, үзе тел какты:—

Кирәк булса, аның инде миннән дә остасын таба алмассыз. Әллә ничә ел маляр булып эшләдем...

Ул сүздән туктагач, Васил аңа тагы бер кат карап алды. Бугаз тирәсе өзлексез йөреп торган бу чандыр кешене беренче мәртәбә Акъярда күргән иде бит ул. Шундук аның күз алдына бер якта кыйшайган тарантас, малай һәм әле каршында хәзер басып торган кеше килеп баскандай булды. Аның мәзәк җыры хәтерендә яңарды. «Колхоз диңгез, без корабль, дөмбердәтәбез генә...» Васил ирексездән көлеп җибәргәнен дә сизми калды. Сүзенә җавап биргәнче, ул аның кайчан, ничек төзелешкә килеп урнашуы турында уй йөртте. «Кара син аны, кай арада колхоздан ычкынган да, кай арада монда килгән? Шомарган кеше булырга тиеш. Руслар мондый кешене: «Тертый калач», диләр бугай әле». Васил Солтан Сабиров сөйләве буенча аның фамилиясен дә хәтеренә төшерде:

— Ялгышмасам, Фарук Фарукшин бит әле сез?

— Әйе. Хәтерегез бик яхшы икән, начальник иптәш.

Васил аны ишетмәгәндәй үз соравын куйды:

— Сез ничек әле биредә, күптәнме?

— Бер тапкыр аванс алдым инде. Получка алуны көтеп йөрим...

— Шуннан?

— Шуннанмы? Дәлше дә эшләргә исәп.

Васил колхозда эшче көчләр җитмәү турында председатель Нәримановның сүзләрен исенә төшерде:

— Ә сезне ничек җибәрделәр соң?

— Колхозда яшьләр, и аннан китереп, механизаторлар кадерле. Минем кебек чалбар балакларыннан картлык тарта башлаганнар әллә нинди бәяле түгел хәзер. Пажалысты, дүрт ягың кыйбла...

— Төзелешкә бигрәк тә яшьләр кирәк, картлар монда әллә ни кыра алмый,— дип каршы төште Васил.

Фарукның бугаз төере әле аска, әле өскә йөгерә башлады. Ул ни әйтергә белмичә беркадәр уйланып торды да кинәт тел тибрәтте:

— Монда хикмәт яшьлектә-картлыкта түгел, монда һөнәр кирәк. Ә ул яктан минем эш во! — Ул елмаеп баш бармагын күрсәтте.

— Димәк, сез төзүче?

— Мин тотмаган эш, мин белмәгән һөнәр аз булыр бу фани дөньяда, Васил туган. Мин әле шушы узган сугыштан соң гына Урал якларында биш-алты ел тәгәрәтеп кайттым. И булмаган төзелеш калмады анда...— Фарук серле генә елмайгач, тагы ялгап алып китте:— Сез сөйләшеп торганда малярлар кирәген ишеттем. Ул эшкә миннән дә останы,— мактанып әйтүдән түгел,— таба алырсыз микән?

Васил аның тел төбен тартып карады. Чыннан да ул буяу эшен белә, бу турыда яхшы ук хәбәрдар икән. Барыннан да элек, Васил бу кешенең колхоздан ни өчен китүе кызыксындыра иде. Идарәдә хисапчы булып эшләп тә кинәт кенә ник ул читкә тайпылып калган?

— Авылны нигә ташладыгыз иттегез соң?

Фарукның бугаз төере тагы йөри башлады:

— Шулай туры килде, ни...

— Алай да?

— Нигә дип әйтеп әйтсәгез, сездән яшереп булмый инде аны. Мин бит хисапчы да, бер үк вакытта кассир да булып эшләдем. Районга банкка барган саен акча алу куанычыннан азрак тамак чылатмыйча булмый бит инде, үзегез беләсез...

— Тамак майлау анысы мәҗбүри түгел. Ансыз да була,— дип каршы төште Васил.

— Юк, булмый икән шул,— дип дәвам итте тегe.— Имеш, шул хәтле акча кулыңда булсын да, ничек инде ул тамак төбе кычытмасын? Андый чакта күңелгә шайтан оялый бит... Ярый, кызган баш белән кайтам мин. Кайткан саен иптәш Нәриманов тирги мине, почем зря сүгә: «Бу нинди

туктый белмәү, бу нинди аракы базына чуму, значится...» Ярый, тиргәве инде аның уза да китә. Аннан кабырга сынмый. Ә менә түләү? Кайткан саен өскә чыга минем. Шул «тамак чылаткан» өчен ахырында сыерны сатып түләргә туры килде. Монсында инде тиргәп кенә калдырмадылар. Арт якка ләп!

## 12

Урак өсте житәсен белгән шикелле, җәйге кайнар җилләр болытларны таратып йөрделәр. Ләкин кинәт кенә җиңә алмадылар. Болытлар бер яктан таралса, икенче яктан куера бардылар. Ниһаять, яшенле яңгыр коеп үтте. Төзүчеләр шул көнне эштән соң шеф колхозга өмәгә барырга тиеш булсалар да, коеп яңгыр яугач, бу нияттән баш тартып торырга туры килде. Кычкырып, куе болытларны аралап, балкып кояш чыкты һәм шул ук вакытта көнчыгыш якта үзенең аллы-зәңгәрле төсләре белән дөньяны, бөтен әтрафны нурга төреп, салават күпере калыкты. Һәркемнең карашын һәм уйларын үзенә тарткан бу моңсу матурлык әйтерсең лә күктәге олуг бер бәйрәм билгесе иде. Ләкин ул озак балкып тора алмады, әлеге дә баягы җәйге тынгысыз шаян җил, болытларны куып йөри-йөри, салават күперенең дә төсен тоныкландыра барды һәм бераздан инде ул бөтенләй уңып та бетте.

Эх, бу җәйге көн! Эх, бу җәйге кояш! Җир гүя әле генә су коеныпчыккан яшь егет сыман сафланып калу белән бергә, җил тастымал булып аның аркасын, бөтен тәнен сөртте. Җир тиз кипшенде һәм иркен сулыш алып, үзенең гаҗәеп күп, гаҗәеп бай үсемлекләре белән кешеләргә бәхетле көннәр вәгъдә иткәндәй балкып китте.

Иртәгесен көн тел белән әйтеп бетермәслек матур иде инде. Чык кибүгә, Акъярның борчак басуларында кызу эш башланды. Борчак чабу машиналары аерым участокларда эшли, аларга ярдәмгә чыккан йөзләгән кеше чалгылар белән борчак чабарга керештеләр. Борчаклар уңган, бу — туземнәрнең калынлыгыннан ук күренеп тора. Мондый куе һәм биек булып үскән борчакны чабу җиңел түгел. Әнә бригадир Фиргали абыйлары, юл ярып барган шикелле, җиргә ныклы адымнар белән баскан хәлдә, чалгы сабыннан кысып тоткан да гайрәтле селтәнеп алдан бара. Аның артыннан бер-бер артлы Виктор (Алып батыр), Рафис, Карчыга, Игнат, Зиннур, аның хатыны Хәмидә, аннан Мәдинә, Лизалар борчак чабалар. Басуда яшькелт төстәге калын дулкыннар артканнан арта бара. Кешеләр кайнап торган кырдан карашны аласы килми. Борчак җире буеннан гына зифа таллар, шомыртлыклар арасыннан чыңчынлап ефәк тасманы хәтерләткән Тын елга сузыла. Бүген аеруча матур һәм ямьле булып бизәнгән күк битеннән кояш чын күңеленнән рәхимле елмая шикелле. Аның кыздыруы, дөресрәге, яндыруы кешеләрне артык борчымый. Чөнки аларның бик күбесе шушы кояш, шушы җил, шушы зәңгәр күк астында эшли-эшли күптән чыныкканнар, тәннәре бронза төсенә кергән. Кайбер ялкаурак адәмнәр тәмәке көйрәтеп алырга ният тотсалар да, түзәргә дучарлар. Чөнки син туктасаң, синнән арттагылар да тукталып калачак. Телеңне тешләп булса да түзәргә туры килә. Иң башлап юл салучы Фиргали абыйлары, бүтәннәргә караганда өлкән яшьтәге кеше, мәгәр буыннары нык, йөрәге таза, күрәсең, эһ тә итми, бара да бара. Ара-тирә чалгысын янап ала да тагы да әлдерә генә. Кешеләр арасында кулларына беренче мәртәбә чалгы тотучылар күбрәк бугай. Андыйларның артларында да шактый «кәҗә сакаллары» утырып кала. Әмма эш барышында кешеләр берсеннән-берсе күреп өйрәнәләр һәм чалгыларны ыграк тоталар, туземнәре дә тигезрәк була.

Василның Акъярга икенче генә килүе иде әле. Ул һәммәсен дә бик тиз искәрде: яңа биналар, яңа каралты-куралар торгызылмый, искеләренә дә ремонт ясалмый, яңа салына башлаган өйләрнең ярты юлда

укталып калганнары да бар иде. Һәркем күчену мәшәкатьләре алдында эра, бу бер үк вакытта тынгысыз да һәм күңелсез дә кебек. Чөнки бер ялэнгэн жирдэн кемнең уйсыз-исэпсез, моңсыз-сагышсыз күченеп итүе мөмкин...

Акъярдан ерак түгел, Солтан Сабиров тәкъдим иткәнчә, тирә-яктагы ечкенэ авылларны берләштереп, яңа поселок төзүгә дә керешкәнәр иде.

Васил яшелрәк берничә кузак өзеп алды да шуларны тәмләп ашыйшый сорау куйды:

— Кара, бу партком секретаре нилэр уйлап йөргән икән!

Наримановның чырае тагы да яктырак ачылып китте:

— Башы йомры аның, безнең авылдашның. Мин үзем, мәсәлән, сездән ишереп тора алмыйм, баштарак икеләнгән идем. Аннан иптәшләр минем шанычымны ныгыттылар. Югарыда да Солтан тәкъдиме бик хуплап каршы алынды.

— Чыннан да, иптәш Нариманов, киләчәктә авыллар бу килеш калмаслар бит. Минемчә, алар кечкенәрәк шәһәр төсен алырлар.

— Әйе,— диде Нариманов сузыбрак.— Тормыш шуңа таба бара. Тик эллар гына тыныч булсын. Тыныч вакытта яхшы тормыш өчен сугыш алып бару — ул үзе бер бәхет...

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә юлга чыктылар һәм көтеп торган председатель машинасына утырып, яңа участокларга киттеләр.

Төшке аш вакытында һәммәсе дә Тын елга буендагы матур аланлыкка жыелды. Кешеләр төркем-төркем булып куак төпләренә, яр буйларындагы ефәктәй үлән өсләренә урнаштылар. Иртәдән бирле күренмәгән, Яңа бүләк бригадаларында йөргән Солтан да көндезге аш вакытында башкалар белән бергә аланлыкка килде.

— Анда безнең егетләр куырдылар гына, төштән соң чабып бетерергә сүз куештылар,— диде.

— Бик шәп, бик шәп! — дип хуплады Нариманов.

Васил үз тирәсендә бик күп танышларны, аның кул астында эшләүче кешеләрне күрде, куанычы үсеп китте. Менә бер вакыт савыт-саба, коштабак-кашыклар чыңы таралды. Телемләп киселгән бодай икмәкләре поднослар белән үлән өсләренә куелды. Алъяпкыч бәйләгән хатынкызлар балык таңкаләре кебек өреләре йөзеп йөргән кайнар ашны өмәчеләргә китерә тордылар. Васил аш бүлүче Гөлзадәне күргәч, ничектер үзе дә сизмәстән каушыйрак калды. Шундук сүз катты:

— Мин сезне кызлар арасында күренмәгәч, бәлки килмәгәндер дип уйлаган идем. Менә ничек икән...

Биленә ак алъяпкыч бәйләгән Гөлзадә куе чәчләрен жыеп, башына ак калфак кигән. Гәүдәсе тагы да матурланыбрак киткән сыман, жиргә басып йөрүләре үк күңелле. Васил караган саен кызның бит алмалары кызарып яна барганын сизеп, аннан карашын алды. Гөлзадә әкрен генә әйтте:

— Без барыбыз бергә килдек. Мине аш пешерергә авылдаш апалар үзләре сорап алдылар.

— Ашны оста пешерә белгәнгә күрәдер,— диде Васил.

— Ул тиклесен ашап карагач әйтерсез, Васил абый.— Шулай дип, Гөлзадә тәмле аш исе чыгарып торган казан янынннан китеп барды.

Дүрт-биш кашык аш кабуга ук Василның күңеленә рәхәт булып китте.

— Чыннан да бик тәмле, телеңне йотарлык,— диде ул Наримановка карап.

Тегесе кеткелдәп көлде:

— Безнең Акъяр кызларының куллары тәмле аларның.

Ул көнне төзелештән килүчеләр Акъяр басуларында бик күп эшне әйләндереп салдылар.

Кичкырын, тәмләп яңа бал белән чәй эчкәч, Васил, Солтан, Нәримановлар тын гына сөйләшеп авыл урамнарында йөрделәр. Авылның нәкъ урта бер җирендә, хәзер инде мәктәп бакчасына әйләндерелгән кечкенә мәйданда гражданнар сугышы елларында сәнәклеләр тарафыннан ерткычларча үтерелгән активистлар кабере турына җиткәч, тукталып калдылар.

Өч кеше!

Авылның өч лачыны, якты азат көннәр өчен үзләренең гомерләрен биргән өч кешенең гәүдәсе күмелгән монда. Солтан белән Нәриманов, өлкән яшьтәге агайларның сөйләве буенча, бу кабердә кемнәр ятканын беләләр иде, Нәриманов авыр сулап куйды, Василга революция юлында башларын салган, гомерләрен биргән кызыл каһарманнар турында сөйләп күрсәтте.

— Алар өч кеше,— дип башлап китте ул.— Шәнгәрәй Яхин дигәне ул елларда авыл Советы председателе булып эшләгән. Икенчесе комсомол Әхтәри Мотыйгуллин, тагы берсе Леонид Коршунов. Анысы безнең авылда озак еллар тимерче булып эшләгән. Хәзер дә аны авыл халкы Ләвәнтәй дип телгә ала. Аның калкулыкта кечкенә генә алачыгы булган. Шул турыдан аз гына сулы чокыр үтә. Анысын авыл халкы Ләвәнтәй чокыры дип йөртә.

Нәриманов, сәнәклеләр фетнәсе турында тагы даниләрдер әйтеп, иң элек Солтанга, аннары Василга карады:

— Каралты-кураларны, өйләрне күчербез инде анысы, сүз дә юк. Ә туганнар кабере су астында калырмыни? Бер дә калдырасы килми югыйсә. Ул гомергә йөрәкне тырнап торыр.

Чыннан да нишләргә? Бу сорауга шунда гына Васил да, Солтан да җавап таба алмадылар. Әмма ничек кенә булмасын, Нәримановның борчылуы бик тә урынлы иде. Билгеле, тиешле оешмалар белән киңәшеп туганнар каберен күчерү кирәклеге аңлашыла иде кебек. Васил кайдадыр су баскан урында зиратны өстән бетонлап калдыру турында ишеткәнен әйтте.

— Бу бит гади зират түгел, аннан китереп кешеләр дә бик аз,— дип җитди төстә әйтте Нәриманов.

— Мин тәкъдим итмим, сүз җаенда әйтүем генә,— диде Васил.

Солтан башын кашып алды:

— Бу безнең өчен бик кадерле истәлек! — Аннары тукталып калды, тагы өстәде:— Аларның инде табутлары да череп беткәндер.

— Анысы яңа табутлар ясату әллә ни түгел,— диде Нәриманов...

## 13

Табигать әкренләп көзгә таба борыла башлады. Инде хәзер көннәрнең кыскаруы сизелә, кич-иртә шактый суытып та җибәрә, томаннар да төшкәли. Бер ягы белән авылга, икенче ягы белән шәһәргә охшаган Яңа Наратлыда яшь әтәчләр тавышы ишетелә. Кояш та җәйге көннәрдәгегә караганда иртәрәк байый. Менә яңа уку елына, соңгы бер айда тәүлек буе эш оештырып, өч катлы яңа мәктәп бинасы да житештерделәр, әллә кайлардан күренеп торган бу яңа бина беренче караштa ук күз явын алырлык. Тик менә...

Кичке чәйдән соң Никитин, залдагы йомшак диванга ятып, беркадәр ял итәргә булды. Кулына газета алды. Гадәттә ул шулай азрак укып ята һәм күңеле тыныч булганда черем итеп тә ала торган иде. Бүген аның күзләре йомылмады. Йөрәген әллә нинди генә корт тырный кебек иде. Ул көндез Юлдашев белән телгә килүен исенә төшерде. Бу хәл аның өстәленә төзелеш мәгълүматлары китереп куйгач булды. Мәгълүматларны игътибар белән карый башласа, аның исе китте. Бу ничек килеп чыга соң әле? Бер атнага якын төзелештә цемент булмый торды. Кешеләр

кенче дәрәжәдәге вак-төяк эшләрдә йөрделәр. Ә план, айлык задание дә гел... йөз процентка үтәлгән. Ул Юлдашевны чакыртты, план бүлеге начальнигын да дәшеп китертте. Күзгә күз карашып, бәхәсләшә, тарткалаша башладылар. Тегеләр икесе бер сүздә иделәр. Һаман бер җалык башын чәйнәгәндәй, тәкърарлый тордылар. «Шулай, Андрей Акимович, корректив кертергә туры килде. Мәсьәлә Главка белән киләшенгән, беркем бер сүз әйтерлек түгел...» — диделәр. Никитин алар белән ризалашырга теләмәде, үзенекен итте. «Ничек инде ул алай, болай үтү эшләнмәгән эшне башкарылган итеп күрсәтү була ич? Бу бит дәүләтнең кесәсенә керү дигән сүз!..» — Тегеләр үз фикерләреннән кайтырга исәп тотмадылар. Юлдашев үзенчә каерды: «Бер дә алай түгел, бер кесәдәге акчаны икенче кесәгә салу гына була ул, аннан беркемгә дә зарар юк».

Никитин, беркадәр кызыбрак киткәнен дә сизмәстән, айлык планны башта ничек булган шулай калдырырга кушты. Баш инженер белән план бүлеге начальнигы аның әйткәннәре белән ризалашмасалар да, уйлашырга булдылар.

Инде керфекләр йомыла дигәндә, Никитинның хәтеренә шул авыр сөйләшү калкып чыгып, аның күңел тынычлыгын җибәрә торды.

Роза Павловна җыйнак кына язу өстәле артында, зәңгәрсу абажурлы лампа каршында укучыларның дәфтәрләрен тикшерә. Ул гел шулай инде, әллә ничә ел шулай. Ичмасам, башын да күтәреп карамый. Өлкән яшьләрдәге, ләкин яшь хатыннарча җинел гәүдәле, якты зәңгәр күзләрендә һаман да яшьлек нурлары китмәгән Роза Павловна менә ничә ел инде ире кая күченсә, аның белән бергә йөри. Аларның бергә-бергә тормыш көтүләренә күп еллар үтте инде. Роза Павловна кая барса да үзенең яраткан эшен — укытучылыкны ташламады. Шул дәфтәрләр белән кайнашып утыруына кайчакта Андрей Акимович ачуланып та куя иде. Бу юлы да ул берничә мәртәбә аңа сүз кушарга омтылып карады, тик иреннәре генә ачылмады. Аннары ул буш вакытларында уку-язу белән шөгыльләнә торган түр яктагы кечкенә бүлмәгә чыкты. Өстәлендә торган җыйнак кына утыртмалы рам эчендәге фотога күз салды. Рита! Аларның уртак бәхете, бердәнбер кызлары. Аның күз карашлары нинди саф, нинди балаларча, нинди эчкерсез. Кыз әнисенә шул хәтле охшаган, шул хәтле. Эх, бу еллар... Әмма кыз өйдә, аларның үз яннарында булмагач, нидер җитми, нигәдер аннан башка ямансу. Кызлары үз канат асларында вакытта Андрей Акимовичның күңелендә бер дә мондый тойгылар калыкмый торган иде. Телевизорны тоташтырса? Юк, ярамый. Розаның шөгылен, дөресрәге — кәефен бозып куюю ихтималы бар. Андрей Акимович берничә минут өстәл артында пошынып утырды. Аннары барыбер түземе җитмәде, күрше бүлмәгә чыкты. Бу юлы инде хатынына сүз кушты.

— Шулай итеп, икәү генә калдык, диген, Розочка?

— Нишлисең, тормыш,— диде Роза Павловна. Үзе алдындагы дәфтәрне өстәлнең почмагындагы өемгә куйды да урындыгын иренә таба борыбрак утырды. Чәчләрен рәтләде.

— Баланы гомер буе канат астында торгызып булмый. Югыйсә миңа да бик күңелсез аннан башка. Нишлисең, булган хәл белән килешергә туры килә.

Андрей Акимович хатынының кечкенә йомшак кулларыннан тотып иркәләде.

— Әйдә, кеше булсын, аның тормышы алда,— диде. Аннары бераз тын калып торгач, янә дәвам итте:— Әйе, Розочка, узып киткәндер инде безнең гомерләрнең күбесе... Ә Рита кебекләрнең тормышлары башланып кына килә. Аларга яшисе дә яшисе. Ә безнең заманда һөнәрсез яшәү — кыен.

— Биш ел...

4*

— Узар. Ярый әле институтка керә алды. Эш белән, шөгыль белән вакыт сизелми дә үтә ул. Мисалга үзебезне генә алып карыйк...

Роза Павловна кызларының педагог булуын теләгән иде. Ләкин Рита бу фикер белән кушылмады. Әтисе ягына каерды. Һәм төзүче инженерлар институтына керде. Дөньяның бөтен тәмен, бөтен ләззәтен бары тик мәктәптә, балалар арасында гына дип, чын күңеленнән ышанган Роза Павловна, үз фикереннән кайтмаса да, кызының юлына аркылы төшмәде. Әйдә, үзе теләгән икән, шулай итсен, диде. Мәгәр әле һаман да аның күңеле ныклап утырып җитмәгән иде.

— Белмим, тик минем сүзне тыңламавына соңыннан үкенмәс микән?

— Үкенмәс. Төзүче профессиясеннән дә шәп һөнәр, белмим, юктыр,— дип, үзенекен куәтләде Андрей Акимович.

Роза Павловна йорт эшләрен караштырып йөрде дә иренә ниндидер сорау беләндер мөрәҗәгать итте. Тегесе ишетмәде булса кирәк, кайтарып сүз катмады. Хатыны икенче мәртәбә кабатлап әйткәч кенә ул аңа җавап кайтарды. Роза Павловна иренә игътибар белән рәк карады һәм аның төсендә ниндидер күңелсезлек барын чамалап алды. Ул гына да түгел, берәр нәрсәгә кәефе кырылса, иренең сул күз кабагы тарта торган гадәте дә бар иде. Роза Павловна бу хәлне хәзер дә күреп алды.

— Әтисе, әллә эштә берәр күңелсезлек булдымы?

— Юк, булмады.

— Нигә соң үзеңә урын тапмагандай йөрисең?

— Болай гына. Алай зур күңелсезлекләр юк әлегә.

Хатыны кайтарып сүз әйтмәде. Әйдә, әллә ни юктыр әле, булса үзе үк әйтер иде дип уйлады.

Өйдә тын, тик стена сәгатенең өзлексез келт-келт итеп йөргәне генә ишетелә.

Роза Павловна моннан берничә вакытлар элек Юлдашевларның яңа квартирга күчәргә җыенганнарын ишеткән иде. Кешеләр арасында шул уңайдан күңелсез генә сүзләр дә таралып өлгергән һәм бу хакта аңа да ишетелгән иде. Әмма ничектер җае килмәде, аннан да бигрәк, вак гайбәт сүзе сыман тоелып, бу турыда иренә әйтергә кыюсынмады. Бу юлы инде ул кычыткан телен тыеп кала алмады:

— Юлдашевлар яңа квартирга күчтеләрме әллә?

— Бер дә ишеткәнем юк.

— Син бит барысын да белергә тиеш.

— Бәлки шулайдыр да. Ләкин...— Андрей Акимович башлаганын әйтеп бетерми тукталып калгач, хатыны янә ялгап җибәрде:

— Күчәчәк квартирларын әллә ничә кат буяганнар, һаман ошамый ди аларга. Әллә инде алтын-көмеш бизәкләр кирәк микән югыйсә?

— Сыйфат ягына басым ясыйлар, күрәсең.

— Сыйфат кына ди синә? Бу — просто каприз. Алай гына да түгел, мещанлык. Имеш, башкаларга яраган аларга ярамый...

— Шулай ук булыр микән, Розочка?

— Син һәрвакыт диярлек минем сүзне уенга алырга яратасың. Үзләрен әллә кемгә куеп, борыннарын чөеп йөрүче шуның ише кешеләрне җенем сөйми минем.

Андрей Акимович хатынының кыза баруын чамалап сабыр гына әйтә куйды:

— Әйе, әнисе, сыйфат ягыннан аксыйбыз әле без. Монда да шундый бер хәл бардыр, бәлки.

— Белмим, сыйфат кына микән? Инде аларның күчәчәк квартирларын дүртме-бишме мәртәбә буяп чыкканнар, һаман ошамый ди үзләренә.

— Арттыралар булыр. Кай чагында, кешеләрне үзең беләсең, бергә икене кушып сөйлиләр.

— Юк, әтисе, бу урында мин синең белән килешә алмыйм.

— Алайса пәркаисыоыз үз фикерендә кала.
— Мин калам. Әмма сиңа үз фикереннән кайтырга туры килмәсен...
Шуннан артык бәхәскә кереп китмәделәр, туктап калдылар. Алай да у мәсьәлә белән Андрей Акимович кызыксынырга булды.

Юлдашев белән алар арасында теге-бу мәсьәлә унае белән килешеп итмәү әледән-әле чыгып тора иде. Ул, төзелеш башлыгы буларак, Олдашевның эшне төгәл график белән алып барырга тырышуын, төрле рофессия эшчеләре хәзерләү өчен курслар ачып, күзәтеп баруын һәм ыйфат өчен кискен таләпләр куюын бик ошата. Юлдашевның үз-үзен отышында кайбер килеп җитмәгән яклар бар икән, алар әле бер хәл. ның үз кул астындагы кешеләр белән тупас мөнәсәбәттә булуы, урын-ызга яки һич кирәксезгә кычкырынуы Никитинга бер дә ошамый иде. 'л аның мондый якларына басым ясабрак торырга исәп йөртте.

Вакыт шактый соң иде инде. Андрей Акимович өстенә киенде, Роза Павловнага ләм-мим сүз әйтмичә, ишеккә юнәлде. Бу хәлгә гаҗәпләнә алган хатыны тавыш бирде:
— Болай кая баруың әле бу синең?
— Гафу ит, мин кая барасымны әйтмәдеммени әле? Шулай бугай шул. Бераз йөреп керим әле, бәлки төзелешкә дә сугылырмын.
Роза Павловна:
— Дөньяңны онытып бик озак йөрмә,— дип кисәтеп калды.

Урам тын, йөрүчеләр аз. Каяндыр аскы урамнар ягыннан җыр-гармун авышлары ишетелеп-ишетелеп куя. Татар көйләренең үзалдына моңлы икәнен чамалап алды ул. Бу төзелешкә килгәннән бирле аңа татар көй-ләрен хәтсез генә ишетергә туры килә инде. Баштарак көйләрнең күбесе олакка ят сыманрак ишетелсә дә, бара-тора күнекте. Иске көйләрдән дә, яңа көйләрдән дә аңа ошаганнары байтак кына. Аларның кайберлә-рен ул бигрәк тә бирелеп тыңлый. Күрәсең, рус халык көйләре белән аларның ниндидер уртаклыгы бар иде шикелле. Никитин партком секре-таре белән берничә тапкыр авылларда булды. Шул чакта кичен урам-нардан моңлы гына көйләргә гармун уйнап үтүчеләрне очратты. Күрәсең, кичен гармун уйнап йөрү гадәте авыл яшьләренә ияреп монда да килгән. Әлеге дә баягы шул гармун тавышларын ишетүгә ул адымнарын әкре-найтте. Әх, менә сүзләрен беләсе иде, дип уйлады.

Күк битендә йолдызлар чекерәеп яналар. Болытлар сирәк-мирәк кенә. Булганнары да алама, ертык һәм ниндидер килбәтсезләр иде. Төн караңгылыгын җиңәргә теләгән кебек, тирә-якны чолгап алган төзелеш корылмаларында утлар балкуы ничектер күңелгә бер төрле куаныч сала һәм кай ягы беләндер шәһәр читен хәтерләтә. Салкынча җил аның пальто чабуларын күтәрә, аннары шул ук шаян җил үзенең салкынча кулы белән битләрен сыпыра, якалардан килеп кытыклый. Бу узган җәйнең нәтиҗәле икәнен күзаллап барды ул — проммәйданда алып барылган зур һәм гаять җаваплы төзелештән тыш, ни хәтле торак йортлар салын-ды, ни хәтле асфальт юллар түшәлде. Хәзер урамнан барулары ук күңелле. Зур шәһәр буйлап атлыйсыңмыни! Поселокның күпчелек урам-нары төзек хәлгә китерелгән диярлек. Электр баганаларында балкып утлар яна. Мондый урамнарда явым-төшем вакытларында тездән сазга батып интегүләр һәммәсе дә артка чигенә. Тик менә халыкны культурага өйрәтеп житкереп кенә булмый. Явым-төшем булдымы — юллар һәм тротуарлар куе саз белән каплана. Бу яктагы кара туфрак көчле яңгыр-лар вакытында куе дегет боламыгына әйләнә дә кала. Нигә тротуарлар-дан гына йөрмәскә, нигә аяк астына карап атламаска? Әлегә яшеллек бик загыйфь, бик төссез икән шул. Җитмәсә кәҗәләр... Никитин үзәк урамда үзләрен чын хуҗа санап йөргән әллә ничә кәҗә күрде. Ул аларны таш-балчык кисәкләре атып куып җибәрде. Яшь агачларның аерым тәме бармы икән бу комсызларга? Бу аның эчен бик пошырды. «Нәрсә карый Гәрәев?» — дип уйлады башлык.

Юан вахтер хатын гадәтенчә үз урынында иде. Төзелеш башлыгының килеп керүенә ул беркадәр гаҗәпләнә калды. «Әллә югыйсә саташканмы, монда ни калган аңа?» — дип уйлады. Никитинның соравына каршы каушаганрак хәлдә, ачык чырай белән җавап кайтарды һәм Васил торган бүлмәне күрсәтте. Андрей Акимович килеп кергәндә Васил нинди дер китап укып утыра иде. Сабыр гына исәнләшкәч, Никитин Васил каршына, озынча өстәл артына килеп утырды. Бүлмәне күзләре белән сөзеп чыкты — бер дә җанга-күңелгә ошашлы түгел, чиста булса да, шәрә һәм күңелсез иде. Ул, үзе дә сизмәстән, эче пошкандагыча уң кулының бармакларын өстәлдә биеткәләп утырды да салмак кына шулай башлады:

— Менә кайда тора икән безнең Васил Закирович. Монда бит бик тынгысыз урын. Әллә мин әйтәм... Ул башлаганын әйтеп бетермәде һәм бармакларын уйнатудан туктамады.

Васил, уртача калынлыктагы китапның укыла торган битен бөкләп ябып куйгач, тынлыкны бозды:

— Мин инде, турысын гына әйткәндә, шау-шудан тынычлык табам кебек. Берсен дә сизмим, күнегелгән ул тиклесенә.— Васил да бүлмәгә күз йөртеп чыкты.— Монда торырга була, Андрей Акимович, яңгыр үтми, җил керми, һәрвакыт салкынча, форточка ачып маташасы юк дигәндәй...

Никитин, бармакларын уйнатудан туктатып, көлемсерәде дә үзенең калын тавышы белән дәвам итте:

— Бәхәсләшмим, торырга була. Тик шулай да уңайсызлыклар тулып ята.— Ул аз гына вакытка сүзеннән бүленеп торды. Василдан карашын алмыйча, ялгап җибәрде:— Күптәннән сорарга йөрим, ничектер туры килми, сезнең семья мәсьәләсе ничегрәк?

Бу сорауны ишеткәч, Васил нигәдер кызарынып китте. Тавышына чыккан калтырауны яшерергә тырышып әйтте:

— Семьялы кеше мин. Бер балабыз бар. Тик...

Ул тукталып калгач, Никитин шаярткан тондарак шундый сүз катты:

— Бәлки аның монда киләсе килми торгандыр? Андый хәлләр дә була тормышта...

— Ничек әйтим? Әлегә шулайрак шул, Андрей Акимович.

Никитин аскы иренен тешләп, кашларын сындырды һәм тагын да бармакларын уйнаткалап алды:

— Ни хәтле кешегә квартир бирдек! Сезне һаман читләтеп үтәбез кебек. Үзегез сорамыйсыз.

— Шулайрак шул.

— Сезгә нәрсә ул хәтле баш ватып торырга? Квартир аласы да семьягызга телеграмма сугасы. Аннары үзеннән-үзе эш юлга салыныр, минемчә.

— Киңәшегез өчен рәхмәт! Уйлап карармын,— диде Васил.

— Ничек? Аннары болай килешеп тә бетми бит. Үзең төзүче, үзеннең торырга рәтле урының юк. Бу инде, сапожник без сапог, дигән кебегрәк була түгелме? Менә шулай, Васил Закирович.

Никитин төзелеш хәлләренә кайтып төште. Тиздән яңа гостиница бинасы салырга керешергә тиешләр иде. Дүрт катлы бу йортның сызмалары һәр икесенә таныш. Ул турыда да сүз алыштылар. Ничектер Никитинга бүлмәдә һава җитми сыман тоелды. Озакламый алар урамга чыктылар да байтак кына сөйләшеп йөрделәр. Никитинның Василга әйтәсе башка сүзләре, башка фикерләре дә бар икән.

— Әйдәгез, төзелештән урап кайтыйк әле, — диде Никитин. Васил каршы килмәде. Проммәйдан ягындагы утлар алар барган саен яктырак җемелди, гүя үзләренә чакыралар иде.

## 14

Киңәшмә бик шау-шулы узды.

Һәр җитәкчегә үз гөнаһсына, аның эшенә карап каты-каты сүзләр йтелде. Башкаларны телгә алганда кай ара көлемсерәп, кай ара: Элəктеме, ничек итеп эшләргә кирәген белеп җиткермисез шул»,— дип, ашлыкның акыллы сүзләренә тирәнтен гаҗәпкә калып утырган Вазих Зафич Гәрәев, үз фамилиясе телгә алынгач, тыныч утыра алмыйча, ıныңдагы берәүне чак-чак кына урындыгыннан екмый калды. Тегесе агаеп мона карады. Гәрәев аны сизмәде. Башлыкның сүзләре аны өтеп ылгандай булды. Ничек ди бит әле: «Гәрәев күп очракта эшне үз агыына куя. Гамьсезлек белән ярыйсы ук нык авырый башлады». Әле бу иклесе бер хәл иде. Никитин стаканнан аз гына су эчкәч, тагын ялгап җибәрде. Монысында инде Гәрәев, артына кемдер инә кадагандай, урыыннан сикереп үк торды, янә утырды. «Поселокта фактический кәҗәләр хуҗа. Гәрәев аларның урынбасары гына. Ул үзен кәҗәләр сөзәр дип курка торгандыр, югыйсә бу хәтле салкын канлылык күрсәтмәс иде»,— дигәч, кешеләр дәррәү күтәрелеп көлештеләр. Бу юлы инде Гәрәев түзеп кала алмады, җәһәт кенә урыныннан кузгалды да сорады:

— Нишләргә соң кәҗәләр белән?

— Ул тиклесен сездән сорарга кирәк,— диде Никитин. Гәрәев күзләрен челт-челт йомгалап һәм авызын бер йомып, бер ачып, тирән-тирән сулап утыра бирде. Никитин, торак коммуналь хуҗалыгы эшчеләрен яшь агачларны саклап үстерүдә төп җаваплы кешеләр дип санап, алар адресына үткен-үткен сүзләр әйтүдән тиз генә туктамады. Урамда корткычлык эшләп йөрүче кәҗәләрнең ияләрен табарга, алардан күрелгән зыянны түләтергә, ияләре табылмаганда, хәтта заготскотка тапшырырга кирәк икәнен дә әйтеп күрсәтте.

Киңәшмәдән соң, Никитинны төрле йомышлар белән сырып алучылар арасында Гәрәев тә бар иде. Ләкин аның өчен мәсьәлә ачык булганга, ул бер мизгел ык-мык килеп торды да, аннары бу турыда сүзне куертмыйча, үз юлына атлады. Гәрәев кабалана-кабалана конторага кайтып кергәч, иң башлап телефон трубкасын алды. Аны чакырды, моны чакырды, тегесен пешерде, монысын әрләде. Ниһаять, аның тавышы да нормальлыгын югалтып, «яшелләнеп» китте. Тагы да ярты сәгатьләр үтүгә инде Гәрәев кабинетында кайнар, зәһәр сүзләр яңгыраган тагы бер киңәшмә бара иде.

— Иптәшләр! Кәҗәләргә һәм кәҗә тәкәләренә карата килешүчәнлек күрсәтеп яшәү заманнары узды,— дип башлады ул.— Безнең өчен иң куркыныч дошман бүгенгесе көндә кәҗәләр һәм кәҗә тәкәләре. Рас шулай икән, кәҗәләргә пощады булырга тиеш түгел. Безнең алда ике юл — я без кәҗәләрне җиңәбез, я безнең алар өчен үз тиреләребезне туныйлар. Ачыграк итеп әйткәндә, за развал работы безне эштән куалар... Башкача булырга да мөмкин түгел...— Ул Никитин сүзләрен кабатлап күрсәтте. Хезмәткәрләрдән берсе дә аңа каршы чыкмады. Урамнарны әледән-әле күзәтеп торырга һәм очраган кәҗәләрне тотып ябарга булдылар.

Гәрәев, начальник буларак, коллектив аның сүзләрен хуп күрүгә бик кәефе килеп, йөзенә елмаю сызыклары чыккан хәлдә, киңәшмәне ябарга ниятләп торганда гына, ишек катындагы урындыкларның берсен шыгырдатып утырган юан вахтер хатын сорау куйды:

— Барысын да бик шәп итеп энәсеннән җебенәчә аңлатты безгә Гәрәев. Минем үземнең дә кәҗәне җенем сөйми. Кәҗә безнең татарның чучкасы инде ул. Анысы хак. Итем хәрам булсын дип, урлап ашый ди бит ул. Тик сүзне әйтү ансат дигәндәй, ябар урын юк бит ул анадан сакаллы булган нәстәләрне. Кая ябарга аларны, шуны әйт син, Вазих Вафич!

Мондый сорауның нигә кирәге булды тагы? дигән кебек, Гәраев кулларын җәеп җибәрде. Чыннан да бернинди дә каралты-мазарлары юк бит. Гәраев бу сорауга тиз генә өзеп җавап кайтара алмады. Ул, уйлагандай, үзенең шома башын тотып утырды утырды да кинәт төсенә яктылык чыкты.

— Таптым! Беләсезме, нишләргә?

Дистәләгән күзләр Гәраевкә текәлделәр.

— Кая ябарга?

— Бәлки бигүк килешеп тә бетмәс. Ну әлегә безнең башкача чара юк. Әлегә, ачыграгы бүгенгә, кәҗәләрне контора коридорына ябып торырбыз. Ә иртәгәсен...

Гәраев башлаганын әйтеп бетерә алмады, берсе икенчесеннән узды-рып тавышлар ишетелде:

— Ул хәтле килешмәгәнне,— диде кайсыдыр.

— Контораны абзарга әйләндермәскә кирәк,— диде берсе.

— Кәҗә «чикләвеге» генә җыясым калган икән башымны хур итеп, ул гына җитмәгән икән,— диде җыештыручы хатын.

Гәраев гадәтенчә кулларын болгап, тавышын күтәребрәк, өзелгән сүзен ялгап җибәрде:

— Ачуланып кушмадыңмы — һәрвакыт шулай каршы ишетәсен инде аны. Кабатлап тормыйм: мин ничек әйттем, шулай үтисез. Командирның приказын тикшермиләр. Булдымы?!

Төнен Гәраевнең йокысы йокы булмады, мең бәләләр белән саташып чыкты. Аны шул әлеге дә баягы ләгънәт төшкере кәҗәләр һәр адым саен очрап интектерделәр. Эшкә килгәндә контора ишек төбенә мөгезләрен-нән бау белән бәйләп куелган өч кәҗә чалынды аның күзенә.

— Ә, килеп эләктегезме, җир корткычлар! — дип үтте ул аларга бармак янап. Гәраев кабинетына җыештыручы хатын килеп керде. Аның кашлары җимерек, чырае кырыс иде.

— Беренчесе дә, соңгысы да шушы булсын,— диде җыештыручы хатын.

— Нәрсә булган!

— Кәҗәләр коридорны җимереп бетерделәр. Кергәндә күргәнсеңдер.

— Миңа калса һәммәсе дә үз урынында кебек.

— Бер дә алай түгел, Вазих Вафич.

Гәраев коридорга чыкты. Берничә урыныннан стена штукатуркасы-ның кубып төшкән булуын күрде.

— Ничава, ремонт ясаучыларыбыз бар, рәтләрләр.

Җыештыручы хатын иңбашларын сикертте:

— Җыя-себерә кара тирләргә баттым, бар икән, ходаем. Аптырагач тышка чыгарып бәйләп куйдым. Хәзер җыештырып алгач та сезгә күрен-ми. Бу тәүфыйксызлар стена газетасын да ашап бетергәннәр, тагы квар-тир хакын озак түләмәгән кешеләрнең исемлекләрен дә йотканнар. Ул бухгалтерның тузынуын күрсәң ие. Хәзер мин кайтып китәм. Кәҗәләрне кая куясыз?

Җыештыручы хатынның сүзләрен ишетмәгәндәй, Гәраев үз уйларын әйтте.

— Нигә кәҗәләр бик аз, кичтән күбрәк иде бит.

— Яртысы бауларын өзеп качтылар. Боларын кайда тотарга бел-гән юк.

— Урын табылыр,— диде Гәраев.

Абзар ясауны коры тоттылар, кичкә таба такталардан оештырып ясалган каралты әзер иде инде. Барлык «бандит» кәҗәләрне урамнан тотып, шунда яба башладылар Бер көн үтте, ике көн үтте... Ниһаять, өченче көнне генә кемнәрдәндер ишетеп, берничә хуҗа килде. Алар үзләренең кәҗәләрен шундук таныдылар. Китте тартыш, китте ызгыш...

үзеп кенә тор! Ничек кенә булмасын, кәҗәләрен карамаган кешеләргә шмы-күпме штраф түләтергә туры килде. Әмма күп хуҗалар килмәдеәр. Берничә көн буе ач торып, эчләре эчкә ябышкан кәҗәләр дөньяарын бетереп, разбой салып кычкырырга тотындылар. Каралты контора ләп янәшә генә булганлыктан, бухгалтериядә дә эшнең рәте китте. атур-матур киенгән хатын-кызлар һәм башка хезмәткәрләр кәҗә вышын ишетмәс өчен колакларын томалап утыра башладылар.

Ниһаять, хуҗасыз кәҗәләрне поселок читенә куып чыгара торган лдылар. Гәрәевнең кәҗәләргә каршы рәхимсез көрәш ачуы турындагы бәрләр капкадан капкага, ишектән ишеккә таралды. Урамнарда каһәр шкән агач корткычлар күренми башлагач, коммуналь хуҗалык хезәткәрләренә җиңелрәк булып китте. Гәрәевкә калса, ул үзен биш-алты га яшәргән кебек хис кыла башлады. Ул бик тырышып-тырмашып аткан абзар да күбесенчә буш тора иде инде. Әмма эш аның белән нә бетмәгән икән шул әле...

Бер көнне Гәрәев көндезге аштан соң конторага килгәндә башмак-шадан аз гына кайтыш бик зур кара кәҗәнең быел көзен генә утыртән яшь юкәләрне кимереп йөрүен күрде. Аның күзләре маңгаена сикәп менделәр кебек. Иелеп таш алыйм дисә, үзе егылып китте. Өйдә бик к ашалган, ахры, таш алып кәҗә куып йөргәндә бик хәтәр саруы кайрга тотынмасынмы! Ул мур кыргырын ничә тапкыр куды, кәҗә исә ман саен артыннан төшеп, янә агачларны кимерергә җитешә иде. рләгән-пешкән, бик яман ачуы кабарган Гәрәев түземен саклап кала мады. Хуҗалык дворына барып ике эшчене ияртте дә теге тәүфыйкз хайван янына килде. Теге кара кәҗә яшь агачлардан ерак түгел нә алгы аякларын сузып күшәп ята иде. Гәрәев эшчеләргә кәҗә кимерн агачларны күрсәтте. Артык баш ватып тормастан, кәҗәне тотып дылар да мөгезеннән сөйрәп конторага таба киттеләр. Гәрәев кабинена йөгереп керде. Аның каны шул хәтле кызган, ачуы ташып чыккан, ы бирәү дә тыеп калырлык түгел иде инде. Ул җәһәт кенә телефон убкасын алды. Ни хәтле тырышса, ни хәтле җан тирләрен чыгарагара кычкырса да, заготскот конторасын ала алмады. Аннары беркар үзе исәп итеп торды да ашханәгә шалтыратты:

— Сезгә ит кирәкме?

— Кирәк,— диде тавышына карап ирме, хатын-кызны икәнен аерып улмаслык бирәү.

— Булды алайса, килештек! — диде тантаналы тавыш белән Гәрәев. Ул контордан йөгерә-атлый чыкканда, ике кеше күзләренә сораулы араш чыгарган хәлдә, баскыч төбендә көтеп торалар иде.

— Киттек! — диде Гәрәев һәм үзе алдан атлады. Утыртма коймә ләп әйләндереп алынган ишек алдына кергәч, Гәрәев кешеләргә бау м үткен пычак алып килергә кушты. Мичче белән балта остасы бу аләресен, күз ачып йомганчы дигәндәй, бик тиз башкардылар. Әмма әйләнеп ташланган кәҗәне суярга кушкач, берсе дә риза булмады. шта ык-мык килеп, әле Гәрәевкә, әле бер-берсенә карап аптырап торлар. Аннары баш тарттылар. Гәрәевнең ярым боеру тонында әйтүенә ә буйсынмадылар. Начальник һаман кыстады, мәгәр тегеләрнең җаваында өмет күренмәде.

— Мин булдыра алмыйм, куркам,— диде озын какча кеше — балта стасы.

— Кесәм кычытып тормый, соңыннан түләргә туры килмәгәе,— диде ызыл борынлысы — мичче.

— Кара кәҗә харап иткән агачларны күрдегез, сезгә шул нигез түмени? — дип башлаганына куәт биреп карады Гәрәев. Алай да аның үзләрен тыңлаучы булмагач, кәкре каенга килеп терәлгәндәй, сүзсез орды да катгый итеп әйтте:

— Барысын да мин үз өстемә алам, сезне белүче юк. Булдымы?

Шулай тарткалаша, сүз көрәштерә торгач, мичче белән балта остасы башкача каршылык күрсәтмәделәр, кызыл борынлысы, бисмилласын әйтеп, зур үткен пычакны кулына алды.

Кара кәҗәнең эшен тиз тоттылар, береэдән аның түшкәсе ашханә ишек алдында иде инде. Гәрәев ук кебек атылып, ашханәгә кереп киткәч, мичче белән балта остасы Агылый белән Тагылый шикелләрәк бер хәлдә калдылар. Алар биш-алты тапкыр папирос көйрәтергә дә житеште. Гәрәев һаман чыкмады да чыкмады. Инде бу тиклесен булдыргач, начальникның итне тапшырачагына һәр икесе ышаналар иде. Ахырында аларның иң элек берсе, аннары икенчесе китеп барды. Ә Гәрәев һаман күренмәде. Кухня һәм ашханә тирәсендәгеләр үз эшләре белән мәшгуль иде. Ишек алдындагы бер почмакта иске ватык арбага куелган кара кәҗә ите турында берсе дә уйламады. Гәрәев ашханәдә юанганда, кайсыдыр ишек алдының кечкенә капкасын ачык калдырган иде. Ит исе, кан исе шул тирәдә йөрүче Сарбайның борынын кытыклады. Сагаеп кына ватык арба тирәсенә килде. Озакламый кара кәҗә ите янына бер кара көчек тә килеп житте.

Ашханә конторасында Гәрәевнен башы катып бетте. Аның белән телефоннан сөйләшкәндә: «Ит кирәкме?» — дигәч, «кирәк» дигән сүзнең иясен таба алмады ул. Шунлыктан иң элек мөдир белән уртак тел таба алмыйча иза чикте. Инде мөдирне иплэп-юамалап ризалатса, бухгалтерның муенын бөгә алмады. Анысы кирәгеннән артык законный кеше булып чыкты. Ничек накладной язсын да ничек рәсмиләштерсен, клэймэ кая, теге-бу... Гәрәев бер өстәлдән икенче өстәлгә йөри-йөри тәмам хәлдән тайды. Аның тырышлыгы бөтенләй бушка китмәде, ахырында иң элек итне карарга, аннан мәсьәләне ничегрәк хәл кылырга икәнен уртага салып, киңәшергә булдылар. Шул ният белән дүрт-биш кеше ишек алдына чыкты. Ташландык арба янына килеп житсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр: бер сары һәм бер кара эт тырышып-тырышып, ырлаша-сугыша кәҗә итен ашап яталар иде. Алар инде шул хәтле итнең тәмен тоеп өлгергәннәр, арба янына кешеләр килгәнен дә сизмәгәндәй, түшкәне ботарлаудан аерылмадылар. Бары тик Гәрәев ватык арбаның бер'тәртәсен каерып алып Сарбайның жилкәсенә тондыргач кына чинашасикерә китеп бардылар. Бу хәлне күргән ашханә кешеләре, ит турында яңадан ләм-мим сөйләшмичә, борылып киттеләр. Гәрәев ялгызы катып калды. «Итнең бәясе кәҗә хуҗасына штраф түләргә житәр», дип уйлаган иде ул башта. Менә хәзер көймәсе комга терәлде. Ничек болай кәмит булып бетте әле бу? Гәрәев хәзер каш ясыйм дип күз чыгару кебегрәк хикмәт эшләп куйганын төшенә, ләкин соң иде инде.

Халык арасында Гәрәев мажаралары турында төрле көлке сүзләр кайбер өстәмәләр, койрык тагулар белән бик тиз арада таралып та өлгерде. Кайберәүләр аны күрү белән пырых итеп көлеп куя, кайберәүләр әче тешләп ни дә булса ирештерәләр. Аның турында сөйләнгән сүзләр үзенә дә ишетелә, ләкин мондый чакларда ул югалып калучылардан түгел иде.

— Ни булса булды, ә менә кәҗәләр урамнарда күренмиме? Күренми! — дип, үзенең кылган әлеге эшен акларга юл таба иде. Тик менә кар катыш яңгыр явып торган чытык йөзле көзге көннәрнең берсендә үзен судка чакырып кәгазь килгәч кенә Гәрәевнең кәефе чын-чынлап бозылды. Аңа үзе суйдырткан кара кәҗә хакын үз кесәсеннән түләргә туры килде.

Кәҗә вакыйгасы менә шулай булып бетте. Тик бетте дигәч тә әле ул сүнеп житмәгән ут кебек пыскудан туктамады. Гәрәевне төзелеш башлыгы кабинетына чакыртып, әлеге хәл турында энәсеннән җебенәчә сөйләттеләр һәм авыз ерып көлеп кенә калмадылар, нык кына кисәтү ясадылар. Гәрәевкә башын кашудан бүтән чара калмады.

Гәраев, гадәтенең турылыгы дуга кебегрәк булу аркасындадыр инде, гр чоңгылдап чыгуга икенчесенә төште. Аннары бит аның эше дә шуайрак. Аның сак колаклары күпне ишетә иде шул...

...Ул көнне Солтан эштән бик нык соңга калып кайтты. Мондый соңга алуларның эш, җыелыш, партком утырышы белән бәйле булганын аның атыны белә һәм эчтән борчылса да, тыштан бер төрле ризасызлык сизәрми иде. Мәгәр бер көнне, бәлки башка сәбәпләр дә булыптыр, ул ңга калып кайткан иренә телле-тешле сүзләр ишеттерә башлады. Кеше шикелле, бер рәтләп киногa барган юк, концерт караган юк. Кайан бетәр бу синең җыелышларың?» — дип тотынды ул.

Солтан һәркайчандагыча монда да салкын канлылык күрсәтте.

— Бераз бушаныйк. Аннары һәркайсы тәртипкә керер, хәзер төзештә, Никитин әйткәндәй, урак өсте чаклары...

Хатын аның сүзләре белән килешмәде, килешергә дә уйламады, һаман зенекен итте:

— Синең шул инде, киңәшмәләрдә утыра-утыра чалбар төбең шомаып беткән... Әйтерсең лә һәркайсында синә катнашу мәҗбүри...

Солтан хатынының ярсуына каршы тыйнак һәм дәлилле җавап кайару белән чикләнде. Моны бик яхшы аңлаган хатын икенче яктан кителеп суктырды:

— Өйдә бер рәтле мебель булса икән! Кеше килсә кызарып бетәм. Бүтәннәр ничектер рәтен таба...

— Әкренләп безнеке дә булыр. Һәммәсен дә берьюлы гына юнәтеп булмый ич,— диде Солтан.

— Син шул гомер буена үз күләгәңнән үзең куркып йөрисең инде. Синең урында берәү булса...

Солтан сабырлыгын югалтмаса да, монысында инде ул хәтле салкын канлы булып кала алмады, кашлары дугаланып җимерелде:

— Син ни әйтергә телисең? Миңа бит бушлай мебель бирүче юк.

— Бүтәннәр рәтен табалар.

— Кемнәр? — Солтан, тавышының күтәрелә баруын сизмәстән, кыыс төстә шулай сорады. Хатын җавап бирмәде һәм ул тагы гадәти тынычлык белән сөйли башлады. Аннары озакламый аларның бәхәсләре сүнеп тә калды.

Ул кичне урамнар әйтеп бетермәслек былчырак, асфальт өсләренә юри түшәлгән төсле бер илле балчык яткан иде. Берничә көн буе тоташ сибәләп торган көзге яңгырлар шулай урамнарның рәтен җибәргән иде. Гәраев килеп кергәндә Солтаннар кичке чәй янынннан әле кузгалып кына киткәннәр иде. Солтан аңа урын тәкъдим итте. Күн итеген өй алдына салып кергән Гәраев, кечкенә чепи күзләрен елтыратып, бертуктаусыз сөйләнә бирде:

— Борчыганым өчен гафу итәрсез инде, Солтан Сабирович. Туктале, мин әйтәм, ничегрәк торалар икән, белеп чыгыйм дим. Үзегез беләсез, һәр квартир хуҗасы турында кайгырту безнең бурыч...

— Илтифатыгызга рәхмәт,— диде Солтан.

Гәраев иң элек тышта аяк асты былчырак, әшәке булуын искә алды. Үз эшенең авырлыгыннан да зарланырга житеште:

— Безгә мондый явымнардан соң бигрәк тә кыен була. Ни өчен дигәндә, бик күп түбәләрдән су үтә. Яңгырдан соң, гөмбә җыярга барасы урында, кешеләр көтү-көтү минем янга киләләр. Кайчагында, бер дә арттырып әйтү түгел, егермеләп кеше җыела.

— Коры чакта түбәләрне ремонтлап куясыздыр бит?

— Куябыз, Солтан Сабирович, куябыз. Телевизор антенналары куеп тишеп бетерәләр түбәләрне. Алар тишә, син гаепле...

— Андыйларның үзләрен ремонт ясарга мәҗбүр итәргә кирәк, алай булмаганда алар хисабына...

— Бик ишәя башлады бу телевизорлар да. Йорт түбәләрендә урман бит, урман, валлаһи. Сез үзләре хисабына дисез. Каян барын да күреп бетерәсен. Мин бер үзем, ә алар?

— Коллектив бер сездән генә тормый ич, башкалар да бар,— дип каршы төште Солтан.

Гәрәев, анын сүзләрен ишетмәгәндәй, кулын селтәде:

— Сознательность ягы бик аксый халыкта, хикмәт шунда, минемчә. «Үзем тапкан мал түгел, әткәй тапкан җәл түгел», кебек килеп чыга.

— Ул тиклесенә дә күз йомып булмый, халык чуар,— диде Солтан.

Гәрәев, ничек җылытуларын белү өчендер инде, батареяларны капшап карады, стена, түшәмнәргә күз йөртеп чыкты. Аннары көннең һаваларның ачылмавыннан тагы бер кат зарланып алды.

— Пычракны ишек алдына ташыйбыз аяк белән,— дип сүз кушты Солтан. Гәрәев аңа мәгънәле генә карап алды. Ул, күзләрендәге елтырауны тагын да арттыра төшеп, дәвам итте:

— Сезнең диван да искерә төшкән димәсәм,— ул, үз сүзенә үзе уңайсызлангандай, кашларын сикертеп куйды.— Урындыклар да яңартуны сорый түгелме? Хәзер бит барысы да яңара дигәндәй. Бер үк кресло, мәсәлән, кирәк булса караватта була ала, диванга да әйләнә. Шундый йомры безнең заман кешесенең башы. Әллә, мин әйтәм...

— Әллә кибеткә яңа мебельләр кайтканмы? — дип сорады Солтан.

— Юк. Кайтса да аны арт яктан шудырып бетерәләр. Алай да безнең тулай тораклар өлешсез калмый...

Мебель турында сүз чыккач, моңарчы ирләрнен гәпләшүенә колак салмаган Солтанның хатыны да, камырлы кулларын алъяпкычка сөртәсөртә, кухня ягыннан килеп чыкты. Әле Солтанга, әле Гәрәевкә күзләрен йөртеп, мәгәр нидер әйтергә теләгән сыман, иреннәрен кыймылдатырга кереште. Шул арада Гәрәев әйтеп ташлады:

— Сезгә мебель кирәк икән дип тә ишеткән идем.

Хәзерге уйларына бик тап килгән бу сүзләрне ишеткәч, Солтанның хатыны да сүзгә катнашты:

— Кирәк, кирәк булмаган кая ул...

— Мин сезгә үзебезнең складтан мебель дә, келәм кебек әйберләр дә бирә алам. Анда яттылар ни, монда тордылар ни — барыбер.

Солтан, бөтенләй аптырап калган шикелле, кулларын җәеп җибәрде. Ул тулай торакларда йөргәндә урындык һәм диваннарның булмаләрда бик аз булганлыгын хәтеренә төшерде. Гадәти сабырлык белән әйтте:

— Сез инде күбрәк тулай тораклар турында кайгыртыгыз, Вазих Вафич. Инвентарьны аерым кешеләргә таратсагыз, җыеп ала алмыйча иза чигәрсез. Яшьләр турында кайгыртырга кирәк күбрәк.

— Кайгыртабыз инде, кайгыртмаган кая,— дип, үзенең аяк башларына карады Гәрәев.

Иренең тел төбеннән ни әйтергә теләгәнен ярты сүздән үк төшенә торган тыйнак һәм чибәр хатын Гәрәевкә таба бер салкын караш ташлап алды да янә кухня ягына чыгып китте.

Гәрәевнең башында бүтән төрле планнары да бар иде. Ул капкадан кергәндә партком секретаренең яшелчә тозлау турларыннан эшләре ничек икән, мичкә-фәлән кирәк түгелме икән, дип тә фикер йөрткән иде. Ләкин, секретарьның үзен кергәннән артык тыйнак тотуын чамалап, алары турында сүз кузгатуны кирәкле санамады. Бәлки, аның үзенә әйтмичә генә хатыны белән сөйләшсә, артыграк булачагын башыннан кичерде.

Гәрәев чыгып киткәч, Солтан төрле йорт җиһазлары турында әле күптән түгел хатыны белән икесе арасындагы бәхәсле сөйләшүне исен-

өшерде. Күрәсең, аның хатыны бу турыда тагы кемгә булса да зарланып сөйләгәндер. Авыздан ычкынган сүзне кулдан ычкынган кош дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул. Солтан бу тиклесен дә үз эченә йотып калды.

Икенче көнне хезмәтеннән кайтуына Солтан баскыч төбенә куелган зур гына тимер кыргыч күреп гаҗәпкә калды. Ул шундый уңайлы ясалган: ике кулың белән калын тимер саптан тотасың да киң калаклы тимер кыргычка аякларыңны ышкып былчыракларны кырып төшерәсең. Күрәсең, җиргә тирән кагып куелган, нык тора. Солтан, монысының да берәр хикмәте юкмы икән дигән кебек, башын селкеп елмайды. Иртәгесен коммуналь хуҗалык конторасы янынннан юри җәяүләп үтте. Анда баскыч төбендәге элек торган зур тимер кыргыч күренми, йомыш-юл белән килгән кешеләр баскыч киртәләренә аякларын сылап, ишек төбендә тәмам газлык хасил булган иде. Солтан тагы да башын селкеп куйды.

Озакламый тулай торакларда комиссия рейды үткәрелде. Складта чунап яткан мебельләрнең дә байтагы тораклардагы төрле бүлмәләргә күчте. Контора янындагы тимер кыргыч та яңадан үз урынына кайтып утырды. Гәрәев башта: «Бар икән кадерне белмәгән кеше. Бирәү булса...» — дип уйлады. Аннары инде партбюро утырышына чакыртып кискен телдә аның үзе белән сөйләшү булгач һәм кисәтү алгач, моңа хәтле йөз суы түгүнең яки кызаруның ни икәнен белмәгән Гәрәевкә бурлат кебек кызарырга, уңайсызланырга туры килде.

*Дәвамы бар.*

Салих Баттал


# ЧИРМЕШӘН ЯКЛАРЫНДА

ШИГЪРИ РОМАН[1]

## АЛТЫНЧЫ КИСӘК

### I

Качты аклар Казаннардан,
Чистайдан, авыллардан...—
безнең большевикларыбыз
куптарган давыллардан.

Тагын яраларын ялап,
кире килмәсеннәр,— дип,—
хезмәт халкы муенына
элмәк элмәсеннәр,— дип,—

бетсен,— дип,— иске дөньяның
йогышлы микроблары,
чыга җырлап урамнарга
Кызыл яу никрутлары.

Сагышлы ата-аналар,
кодалар, кодачалар...
Һәммәсе дә якыннарын
сугышка озаталар.

Аерылышыр чаклар җитте,
йөрәкләр ачык хәзер.
Бикле йөрәклеләрнең дә
җырлары ачкыч хәзер.

«Агыйделдән пароход килә,
төятер идем кершән,
кара күзләреңә карап
сөйләшер идем күрсәм...»

Гармун калайлары белән
күзләрне чагылдырып,
Сәлим чыкты чакыргач ук,
тормады ялындырып.

Төркем дә ишәя бара,
җыр да көчәя бара,
күкрәтеп уза авылны
әрәмәлеккә таба.

### II

Һәм чыга урамга кызлар
аклы киемнәр белән.
Бизәлә гүя урамнар
аллар да гөлләр белән.

Ахирәтем, адашым,— дип,
бер-берен чакырышып,
кызарынган күзләренә
карашмаска тырышып,

---

[1] Дәвамы. Романның баш өлешләре «Казан утлары»ның 1965 ел 10нчы санынд
һәм 1966 ел 3, 4, 5 — саннарында басылды.

Автор бу романда татар халкының революциягә килүен волость күләмендәг
вакыйгаларга сыйдырып күз алдына китерә.

Романның бу өлешендә Хәрби коммунизмнан НЭПка күчү чоры өч каһарман —
Сәлим, Садыйк, Алмалар аша сурәтләнә.

энеләрен чишендереп,
юк җирләрне бар итеп,
эрәмәгә җыеналар.
эшләрен сылтау итеп.

Җирләре табылмаганы
«ярма юарга» ди-ди,
ярмасы да булмаганы
«казлар куарга» ди-ди,

чулпыларын чылтыратып,
кыстырып кулмәкләрен,
изүләренә яшереп
хатларын, бүләкләрен,

эрәмәгә юнәләләр.
Аларның арасында
Садыйк белән күрешергә
Алма да бара шунда.

Садыйкның да кем икәнен
әйтим, кирәк булса дип:
данлы Мәгъзия апаның
кече улы ул Садыйк.

Шул Садыйк бит җыр башлады
«кершән тәятергә» дип,
димәк, Алманы чакырды
«күреп сөйләшергә» дип!

Алманың кер дип алганы —
чигелгән күлмәк иде;
Садыйкның күлмәге ертык —
ул моны күргән иде.
Күлмәк астында кәрәзле
балы — бер чүлмәк иде...

III

Тукталды килеп егетләр
эрәмәнең түренә:
тау битендә тигез мәйдан —
бар тирә-як күренә.

Китте бию... Чаткы чәчри
Садыйк итекләреннән,—
табан астына ташланган
тәмәке төпләреннән.

«Алма!»— диделәр... Бу исем
мәйдан эченә кереп
тетрәтте егет күңелен
биегән җирә кебек.

Һәм ритмны бозды бугай
аз гына гармунчы да...
Туктый да Садыйк биюдән,
түгәрәктән үк чыга.

Юнәлә ул су буена —
«Алмалы» тал төбенә.
Асыл ярга якынайгач,
җыр кила күңеленә:
«Башындагы яулыгын ул
роза-гөлгә япкандыр,
тумагандыр анадан ул,—
чәчәк булып аткандыр...»

Гүя каршына күкләрдән
фәрештә инде менә!

IV

Рәтләп сүз сөйли алмыйлар
бер сәгать инде менә!

Һәм аларның хисен, уен
берәм-берәм һәрберсен
җырга салып әйтеп бирә
тау битендәге төркем:

«Нигә телләр тотлыгалар
Озату чакларында,
нинди авыр уйлар икән
иелгән башларында?..»

«Нигә таулар мендем икән
бер татлы тамыр өчен;
нигә ярлар сөйдем икән
тилмереп калыр өчен...»

«Тау битендә алмагачлар,
алмалары пешәрләр;
Алма кебек матур ярлар
исебезгә төшәрләр...»

«Әрмиядә йөргәндә дә
хат яз, бәгърем, онытма;
йөрәгемдә гөл үстердең,
суын да сип, корытма!»

«Шәлем ап-ак, шәлем ап-ак,
кулъяулыгым да ап-ак;
көтәрмен, дип бер кат әйткәч,
ник әйттерәсең кат-кат?!»

«Ситса күлмәкләр килешә
якасын кыек уйгач;
кайтырсың әле куйныма
дошманны кыйнап туйгач!»

«И, җаныем, тәнлә килсәң,
ки кара бишмәтеңне;
аздырдың, юлдан яздырдың —
теләсәң нишләт инде!»

...Кайсы наян кыз җырлады
кара бишмәтне көйләп? —
Алма шуны тыңлады да
җылый башлады кинәт.

— Аһ,— диде,— булсачы хакым
сезгә шулай җырларга!
Чыгып адаштым шул инде
сез белмәгән юлларга...

Аптырады егет: нигә
өзгәләнә яшь күңел?
— Әткәең искә төштеме?
— Аңарга гына түгел...

Һәм яшенә буыла-буыла
сөйләп бирде: бер малне —
маскарадлы төндә Сәлим
аңар куна кергәнне.

Чирканды кыздан күңеле,
артка чигенде егет,
йөрәк арасына боздан
койма койдылар кебек.

Китте ул төркем ягына
ачуыннан буылып.
Үтте ул Сәлим яныннан
басып сытардай булып.

Сизде: Сәлимне кыйнаса
ул ялгызы калачак;
бөтен төркем гармунчыны —
Сәлимне яклаячак.

Барыбер сугышыр иде... тик
көндез күтәрми кулын —
күрсәтәсе килми чөнки
култык асты ертыгын;

Бигрәк тә — йөз чөергәч
Алмадан, бүләгеннән;
балларыннан һәм чигешле
ер-яңа кулмәгеннән!

Тау битендә калды төркем.
Алда — татулык әле.
Ял итә Сәлим, гармунын
янына куеп әле.

Тау башында бүрәнә бар —
калынлыгы бер колач.
Кисәннән соң йөз ел ятып
җиргә сеңгән яртылаш.

Узды да шуның артына
Садыйк та җиргә сеңеп
ятты, гарьләнгән җанына
урын эзләгән кебек.

Кинәт кузәләр — бүрәнә
акрынлап кузгала,
Сәлим өстенә тәгәри,
барышы кызулана.

«Һәй!» дә «һәй!» дип кычкырулар
һәм кисәтүләр катыш
тайпылды Сәлим. Гармуннан
калды «чырк!» иткән тавыш...

Югартын — йонлаган булып
ятучы Садыйк тора,
кузен уып, төшен сөйли,
сабан туен кыстыра —

бүрәнә кебек батырны
күтәреп бәргәнлеген,—
аңлата ул бүрәнәне
юри этәргәнлеген.

Ачу курсәтергә базмый
сытык гармун иясе:
андый пүчтәк нәрсәләргә
төкерә ул, янәсе...

Сәлим сер бирмәде хәтта
Садыйк үзе килгәч тә.
Кайтып китте, Садыйк аңар
«кайтабызмы?» дигәч тә.

V

«Кайтабыз!» — дип әрәмәдән
алып киткәннән бирле
Сәлимне калдырмый, Садыйк
Үзенә алып керде.

Бергә кунды. Иртәгесен
китәргә вакыт җиткәч,
комитетка алып барды
һәм әйтте: — Антон иптәш!

Малай җитәрлек эшләде
баена ялчы булып.
Инде безгә хезмәт итсен —
барсын олаучы булып!

Олаучыны интектерде
нәкъ пристаньга кадәр:
— Сине кайтарып җибәрәм
миңа сөйләсәң әгәр, —

Ничек булды әлеге эш?
Кайсы ай иде? Әйдә,
я, шуннан соң нишләдегез?
Сөйләп бир бәйнә-бәйнә!

...Пешкән, җитешкән пәһлеван
үчен ала йөдәтеп —
тәне-җаны җитлекмәгән
малай серен сөйләтеп...

Тик артты гына үзенең
Алма өчен сызлавы,—
бәлки «Садыйгым» дип, чынлап
яратадыр ул аны?!

Дөресен үзе әйткән өчен
кызны этләү файдасыз.
Ни булса да ат урлангач
абзар бикләү — мәгънәсез.

Ә карак кем? Шул малаймы! —
муены — нечкә генә.
Тифтән соңгы чәчсез башын
күтәрә көчкә генә...

Басты егетне ирләрчә
яшерен, кырыс кызгану,
ярлыларга уртак саран
бәхет өчен сызлану.

Барып төшкәч, Сәлим өйгә
арбаны боргач кына,
Садыйк үзенең хисләрен
сиздерде җырлап кына:

«Җаныкаем очыраса
сәлам тапшыр, сораса;
тап хәтерен, юат күңелен,
сөрт күз яшен, еласа...»

## VI

Әрәмәдә калган Алма
тирәли таллар иде.
Шундый кыен ялгызлыкка
ташланып калган иде!

Батып үлмәкче дә булды
хурлык ачы булганга,—
ул нияттән кире кайтты
су бик якын булганга.

Өйгә кайтып газапланды
бер тәүлек бер ялгызы.
Ник булмаган ул авылның
башка кызлардай кызы!

«Кемгә тансык минем кайгым...
Серемне кемгә сөйлим!..» —
Шулай уф орып йөргәндә
Кайтты олаучы Сәлим.

Алма аңар нәфрәт белән
карады кырын гына.
Тәгәллап җырлады Сәлим
Садыйкның җырын гына:

«Алмакаем очыраса,
сәлам диген, сораса,
тап хәтерен, юат күңелен,
сөрт күз яшен, еласа...»

Балкыды кыз! Тапты җырның
һәр сүзеннән мең мәгънә!
Әйтте ул, Сәлим подвалга
ат тугарып кергәндә:

— Әрәмәдә күлмәгем бар,
Сәлим, шуны барып ал,
барын сиңа һибә кылам —
чүлмәге бар, балы бар...

Сәлим үз эшләре белән
узышып, балга бара;
Кызыл Армиядә Садыйк
сугышып алга бара.

## ҖИДЕНЧЕ КИСӘК

### I

«Хатлар язарга утырсам,
җырлар өстим юл сызып.
Йокыларымнан уянам
күрешергә кул сузып».

«Чигеш чигәм сөлгемә —
өлгеләрем — гөл генә.
Садыйккаем, син — улкаем,
Күңелемдә син генә».

«Сельсовет түбәләрендә
кызыл байрак җилферди.
Тәрәз ачып сәлам көтәм —
сәлам түгел, җил керми».

«Сугышларда йөргән чакта
кыю тот атларыңны.
Уң битемә куеп ятыйм —
җибәрче хатларыңны!»

«Алтын да булыр идем,
көмеш тә булыр идем;
сугышта сине саклаган
фирештә булыр идем...»

Мәгъзия яздыра хатны
улына — Садыйгына.
Алма яза. Ә каләме
сайрый да сайрый гына...

Йорде солдатлы өйләрнең
хат язып һәммәсенә, —
өметләнде: «Чакырмасмы
Садыйкның әнкәсе дә...»

Һәм чакырылды, ниһаять —
иреште максатына.
Садыйк уен беләчәк ул
аңар хат язса гына.

Елмая Алма. Хатка ул
карый могҗиза итеп:
«Улым» дип яза Садыйкка —
үзен Мәгъзия итеп!

Һәм Мәгъзиядән яшереп,
чәченнән бантик алып,
хатка мондый юллар өсти
аны конвертка салып:

«Алсу лента хатка салам —
када ат ялларыңа,
сугышларга кергән чакта
хәл өрсен җаннарыңа...»

Хисләрен тыеп, ниһаять,
итте дә хатны тәмам,
өстәп куйды: «Язучыдан
укучыга күп сәлам!»

Мәгъзия аңа «кул ялы»
бирмәкче көчләп-көчләп.
Алмады Алма. Бары тик
җыр гына язды өстәп:

«Кызыл яулар җиңеп чыкты
Идел буе крайда;
Буденныйдан сорап кара —
җибәрмәсме бер айга?..»

Очып кына барыр идем
армия сафларына;
былбыл булып кунар идем
кылычы сапларына.

Таһир-Зөһрә кыйссаларын
укып чыгам төнлә дә;
Таһир белән Зөһрә кене
килеп җитте безгә дә.

Әрәмәгә барып түгәм
йөрәгемнең ялкынын;
үзем белән алыр идем
без очрашкан тал төбен...»

...Шомлы кара бишмәт килдә
Алма кузалларына;
Кире сикерде уйлары
Әрәмә талларына:

«Таллар куе, таллар куе —
кошлар үтәрлек түгел.
Җырлап түгел, сөйләшеп тә
сүзем бетәрлек түгел...

Алсу яулык япсам гына
алсулана чыраем;
алсу йөзләрем саргайды —
тагын күпме чыдаем!..»

Шунда Алма уйга калып,
торды карап көзгегә —
аз гына да саргаймаган,
балкып торган йөзенә.

Юк, саргаеп булмый икән,
симез ит кенә чәйнәп.
Ә бит сугыша белү кук,
сөя белү дә сәнгать.

## II

Ил хәлләре белән таныш:
мөмкинлек зур Алмада
газеталар укырга да,
карталар карарга да.

Җиңү яулап алган саен
Буденный гаскәрләре,
яңа җырлар яулап ала
Алманың дәфтәрләрен:

«Җырлар язам, җырлар язам —
карам тесләре бишни.
Башларым әйләнеп китә,
йөрәгем әллә нишли...

## III

Үз җырларына Алманың
җитди мөнәсәбәте:
«Саргайдым» дип яза, димак,
шуны тели сәнгате.

Һәм ул тәүлеккә бер ашап,
ябыгып һәм суырылып,
Чистайларга барып кайтты
карточкага сугылып.

Һәм карады: туры килә
рәсме дә җырларына.
Һәм үзеннән дә Садыйкка
хат салды шунда гына.

IV

Очлы шлем, кызыл йолдыз
буденныйчы башында.
Үз бурычын үзе үти
Үз власте каршында.

Авылында җилферди байрак —
ука белән чигелгән:
«Берләшегез, бөтендөнья
юксыллары!» — диелгән.

Әй, Антанта! Син уйлама
Совет илен бозарга,
Кызыл гаскәр шундый бәрер —
әйләнерсең тузанга!

Һәм Садыйк та җырлый-җырлый
бар киртәләрне кичәр:
«...Ведь с нами Ворошилов —
первый красный офицер!»[1]

Менә яулап алды алар
Кырым калаларын да.
Хат язды Садыйк ял иткән
минут араларында:

«Сез җибәргән алсу ефәк
акбүз атым ялында.
Безгә дошман каршы чыкса
сабак алыр тагын да...

Әникәем, исемнәрең —
кылыч каешларымда;
шуны ятлап сугышамын
кояш баешларында.

...Буденовка шлемымны
башларымнан саламын;
кошлар очып үткән саен
сәлам әйтеп каламын.

Шинель кигән җирдә калды
шул кара бишмәткәем;
мине сәям, дип, үзеңне
алдама, иптәшкәем!»

V

Мәгъзия дәшеп китерде
хат укырга Алманы.
Соңгы җыр кемгә кагыла —
Алма моны аңлады.

Тик эчтән укыды бусын
һәм алла нишләп калды.
Шинель гүя киелеп китте,—
тилмереп бишмәт калды...

Өенә кайтканда аңар
котырып бәйләнде эт...
Юк, эт түгел, куган саен
шулай ябыша өмет.

Тик язмыш аңа күсәген
шундый тондырды кинәт,—
калды Алма йөрәгенә
өмет ватыгын төяп.

## СИГЕЗЕНЧЕ КИСӘК

I

Мең тугыз йөз егерме бер.
Язның епшек карында
кайтты Садыйк. Ачлык елны.
Мартның ахырларында.

Һәм шунысы күмеп куйды
Алманы сагыш белән:
Кырымның бер матур кызы
кайтты бит Садыйк белән!

Садыйкның әти-әнисе
гүргә керделәр кинәт...
Яшь килен рәхәтен күрү
насыйп булмаган, димәк.

Яшьләр ярма алып кайткан.
Ата-ана бергәләп
ач килеш шуны, чи килеш
ашап, булдылар һәлак...

II

Алма хәле — җырдагыча:
бай кызлары — бай кебек,
безнең михнәт арбасына
өйрәнмәгән тай кебек.

Ләкин мәхәббәт тәртәсе
аны да илаштерә.
Үлем тиңләштергән кебек,
сөю да тиңләштерә.

Зираттан кайта Садыйк
алар турыннан узып.
Мандолинын ала Алма,
җырлап җибәрә сызып:

[1] «Буденный маршы» җырының юллары. С. Б.

«Әлли-бәлли итәр идем
тирбәтүчеләр булса;
ияреп үк китәр идем,
иятрүчеләр булса...»

Юк, теләми иярергә,
уза, карамый Садыйк.
Садыйк кынамы,— яшьлеге,
мәхәббәте уза бит!

Садыйк уза. Гүя саңрау.
Тойгыларыннан шашып,
мәхәббәте белән Алма
җырлый гүя хушлашып.

«Гомер юлы — карурман ул, —
атың өркәк булмасын;
каберең уртак булса булсын —
ярың уртак булмасын...»

Тик кыймылдый биртек өмет.
Нинди каты суксаң да,
Антантадан ныграк икән —
әверелми тузанга:

Кыз алып кайткан булса соң,
ул түгелдер бәлки яр,
комиссардыр, санитардыр,
азмы хәзер шундыйлар!

Төшләренда сулар алды
һәм төшерде чиләген...
Һәм саташып, әнисенә
ычкындырды серләрен...

Сахраларда ялгыз калды
коры чүлгә яшь түгеп.
Иртә белән әнкәсеннән
ишетте мондый үгет:

«...Кара көн биргән язмышың
якты көн бирмәсмени,
кызым, сине соң шуңардан
башкалар сөймәсмени!

«Көянтә йолдыз» дилар дә,
чиләк асып булмый бит;
син гашыйк булган һәр кеше
сиңа гашыйк булмый бит.

Яңа бакчалар да сиңа
капкалар ачар әле;
иске ярның мәхәббәтен
яңа яр басар әле!»

Күпме генә үгетләмә —
сизелә бит анага;
бер чара кирәк. Югыйсә
әйләнер диванага...

Мәҗлес үткәрергә кирәк...
Садыйк та килсен өчен
үткәрергә берсекенгә
Мәгъзияләрнең «өчен».[1]

Аш-су булыр, дога булыр
мәҗлес керешләрендә.
Ә яшьләргә — күңел ачу —
соңгы өлешләрендә.

Гәнаһмыни шундый чакта
яшьләргә җырлар, моңнар.
Үзе мандолинын чиертер,
Сәлим — гармунын уйнар...

### III

Башланды яшьләр мәҗлесе.
Юл ачты күмәк дуэт:
егетләр хоры каршында —
кызлардан торган букет.

Кушыла гармунга җырлар.
Иркәлиләр, чәнчәләр,
ары да бире очалар,
гүя уклар, чачкәләр...

Сөйгәненә чәнчә бер кыз,—
исемнәре — Сәкинә:
— Авылда бер мин генә дип,
Йөрдең бит кичә генә!

(Бу җыр белән әйтә бит ул
Садыйкларның кайтуын —
«бердәнбер»ләрнең бүгеннән
нинди хисләр татуын.)

Кемнедер кисәтә бер кыз —
исемнәре — Хатимә:
— үз ярың кешегә бирмә,
кеше ярына тимә!

Кушыла керәшен кызы —
исемнәре — Верочка:
— Берсен башлап, берсен ташлау —
бу нинди привычка!

---

[1] Ачлык елны хәлле Нәфисә Мәгъзиянең һәм иренең «өчен» үткәрә икән, Садыйкны шунда килүдән баш тартмаячагын ул белә, әлбәттә. С. Б.

Салмак кына жырлый егет —
кушаматы — «Ташбака»:
— Иске ипигә мәхәббәт
яңа ярны ташлата...

Хисен гарыз кыла бер кыз,
исеме дә — Гариза;
жырлый: «Үз кулларың белән
суга салсаң да риза!»

Жырлый алмый калды бер кыз —
исемнәре Маһинур;
ике бите — пешкән алма,
иреннәре — помидор.

Аны бүлде мандолина.
Кем бу жырлый? Алма бит:
— Нәрсә карый Кызыл гаскәр,
һөжүм итми алга?! — дип.

Ә Садыйкның җавабында —
ирония, горурлык:
— Сезнең зифа буегызга
карап кына торырлык.

Һәм чарпыша башладылар
шәфкатьсез, чигенүсез.
Кайсы жырны кем жырлаган —
төшенерсез үзегез:

— Күз карашларыгыз серле,
серләр ачык булсачы!
Серле карашларыгызга
жырлар ачкыч булсачы!

— Йөрәгебез йозак түгел,
ачүләр озак түгел —
кырымнардан тамырланып
анда чәчәк атты гөл.

Минә гелем — гомерлегем,
күрәсездер сез аны!
— Тугыз булсын, уныньчысы
без булырбыз, ризамы?

Карт солтаннар диста-диста
жариялар тотканны
шул хокуктан мәхрүмме
егетләрнең солтаны!

— И дускаем, бирсәгез дә
бер гелемне ун итеп,
берсен генә кадерләрмен
тугызын да юк итеп!

Сезнең күз алларыгызда —
солтан гына, хан гына,
безнең теләк — ашыгызга
булмыйк таракан гына!

Безнең төшләргә дә керми
бай Хәмит тә Бай-Әхмәт...
Олы башны кече итеп
дәшүегезгә рәхмәт!

Шуннан Садыйк: «Әйдә!»,— диде,
карап Кырым геленә, —
рәхәтләндек (бу «ял иттек»
дию Кырым телендә).

Алма өстенә гүяки
коелды кара корым:
шулай укмы бу өмет тә
бетте башламас борын!..

Таралалар бит кунаклар!
Алма да бетә, шиңә...
— Хушыгыз! — дигәнгә «хуш!» ди,
баш исәләр — баш ия.

Булгалый бит җәй кенендә:
яшен яшьнәп үтә дә,
күкрәүләр тынды дигәндә
ул шатырдый түбәдә.

Алманың да түбәсеннән
күкләр күкрәгән кебек,
күкрәгеннән күкрәп чыккан
жыры яңрады килеп:

«Сандугачым, сайрый-сайрый
гелләргә күмел инде;
күңелкәем, сүрел инде, —
ул сиңа түгел инде...»

*Дәвамы бар.*

# *АФЗАЛ ШАМОВКА 70 ЯШЬ*

— Теләүчеләр ике адым алга!

Сафка тезелеп торучы хәрбиләр арасыннан сары күн кепкасын латыш укчыларына охшатып кырын салган, кара бөдрә чәчләре кепка астыннан ташып чыккан унтугыз яшәр таза, чибәр курсант ике адым алга атлады.



Кызыл командирлар әзерли торган хәрби курста уку әле тәмамланмаган, укып бетерергә теләсәң, кала да аласың, әмма Польша фронтына сугышчылар кирәк.

Моннан унтугыз ел элек Шиһабетдиннәр гаиләсендә Афзалетдин исемле малай дөньяга килгән булса, шушы минутта, ике адымны атлаган чакта инде Афзал Шамов, ягъни гражданин Шамов барлыкка килде. Кайбер курсантларга караганда, ике адым алданрак йөрү — үзенә күрә зур батырлык иде. Хәер, моңа кадәр дә ул батырлар рәтендә йөреп баккан иде инде. «Син гайрәтлерәк» дип, аны 1918 елны ук, заманының электә иң кара авылына, ат караклары, бандитлары белән дан тоткан авылга (авылның исемен әйтмибез, бүген ул авылда чын совет кешеләре яши) укытучы итеп билгеләделәр. Кесәдән «сабын гына күрсәтеп йөрү өчен» наган бирделәр, ә батырлык үзенеке, батырлыкны кесәдән генә күрсәтеп йөреп булмый, ул бара торган юлының хак юл икәнлегенә ышанган кешенең күңел түрендә... Авылның алдынгырак кешеләре килеп-килеп әйтәләр: «Саграк йөр, Афзалетдин энем, дошманнар үзеңне нитеп куймагайлары...»

Кесәгә патронсыз наган тыгып, дошман мыжлаган авылда 1918 елда балалар укытып, спектакльләр уйнап йөрү шулай ук батырлык иде.

Аның тормышында батырлыклар күп булды. Ул Врангельгә каршы сугышты, Махнога каршы сугышты. Атлы разведчик иде Афзал абыегыз. Барлык разведчиклар кебек, ул да дошман солдатларын плен алды. Алга йөгереп әйтим, әле бу сугышта да ул җиде фрицны плен алган кеше. Гәрчә сугышып алган булса да, бу хакта ул үзе көлдереп сөйли, янәсе, кая барырга белми йөргән немец солдатлары иде алар, кул күтәреп: «Әсир итә күр безне» дип, килеп чыктылар. Хәтта шулай булганда да, үзләре теләп бирелгәндә дә, җиде дошман арасында, ялан кырда бер үзең калу — шулай ук йөрәкле кеше эше. Афзалның янә бер батырлыгын әйтәсем килә... Әйтим дә шуның белән батырлык турындагыларын бетереп торыйм.

Чигенебрәк башлыйк: мин инде Афзал Шамов белән кырык еллап таныш, гел диярлек бергә, янәшә, тик сугышта гына икебез ике фронтта булдык. Әгәр анда да бергә булган булсак, җиде фрицның дүртесен ул, мәгаен, миңа биргән булыр иде, чөнки Афзалга юмартлык хас.

Утызынчы еллар иде. Яңарак танышкан вакыт. Мин йомыш белән аның янына нәшриятка килдем. Төшке аш вакыты, ашыйсы килә, Афзал әйтә: мин сиңа бер талонымны бирәм, әйдә ашап чыгыйк, ди. Утызынчы елларда, талоннар һәм ордерлар хөкем сөргән заманда, үз талоныңны иптәшеңә бирү — шулай ук үзенә бер батырлык иде, чөнки талонсыз син икенче көнне инде төшке ашны ашый алмыйсың дигән сүз.

Афзал Шамовны без күп кенә матур хикәяләр авторы итеп беләбез. Ул романтик та, реалист та — икесе бергә. «Рәүфә» — элегрәк язган повестьларыннан иң әйбәте, миңа калса, заманының классик әсәре,— саф реалист тарафыннан язылган, ә гражданнар сугышы вакытларыннан алып язылган хикәяләрендә Афзал романтик, ул хикәяләр кызу романтизм буяулары белән сугарылганнар: тегесеннән дә, бусыннан да заманның кайнар сулышы, саф рухы бәркелеп тора. Аның кешеләре зур идея кешеләре, тугры күңелле, ак күңелле, олы җанлы кешеләр. Мин әйтер идем, алар күпмедер дәрәҗәдә Афзалның, дөресрәге, яшь Афзалның, үзенә охшап торалар. Язучы үзенең геройларына үз җанын, үз бәгырен өзеп салган, үзенең саф рухы белән аларны баеткан.

Соңгы елларда ул безнең вакытсыз «үлгән» классикларыбызны тергезү юлында ул хезмәт куйды. Галимҗан абзый Ибраһимов хакында истәлекләр җыеп, аларны вдакциялап дөньяга чыгарды. Җәмәгать эшеннән ул бервакытта да баш тарта бел-и, ничәмә-ничә комиссиядә әгъза, музей советларында әгъза, әдәби музеебызны ештыруда зур активлык белән катнашты. Язучылар союзы идарәсендә член. Күп ллар «Казан утлары» редколлегиясендә эшләп килде. Редакторлык итте. Язучылар оюзы идарәсе председателе булды. Менә инде ул ун елдан бирле СССР әдәби фон-ының Татарстан бүлеге идарәсе председателе.

Шуны да әйтергә кирәк, эшләгәндә ул, миннән киткәнче, иясенә җиткәнче, дип шли белми, җиренә җиткереп эшли. Мин үзем дә заманында аңардан (үзенә сиздер-и генә) аккуратлыкка өйрәнгән кеше. Ул инде сүз биргән икән, сүзендә тора белә!ик әйбәт сыйфат бу, күпләребезгә җитми торган әгъла сыйфат.

Тагын бер ягын әйтми китә алмыйм: кырык ел эчендә мин аның авызыннан бер енә тапкыр да зарлану сүзе ишеткәнем юк. Афзалның бик кыен хәлләргә калган ллары булды, зарланырга теләсә зарланырлык бар иде, ләкин ләм-мим зар ишеткә-нем булмады.

Инде җитмешкә җитте, чәчләре агарды (кая китте сары кепка астыннан ташып ыккан кара бөдрәләр!), биргән сәламне җыеп кына йөрерлеге бар. Ә ул әле һаман да — яшенә булсын, картына булсын — башлап торып үзе сәлам бирә, хәл-әхвәлен со-раша, авырган иптәшләренең өйләренә бара.

Кеше хәленә керә белү, кирәк вакытта ярдәм кулын сузу — тагын бер матур сыйфат, тагын бер күңел байлыгы.

Афзал дуска, әйбәт язучыга, кеше булган кешегә озын гомерләр телик.

**ИБРАҺИМ ГАЗИ.**

## Афзал Шамов

# МӘХӘББӘТ ТРАГЕДИЯСЕ[1]

### I



Төн.

Өй эче караңгы.

Иптәшләр йоклыйлар,— идәнгә, салам өстенә тезелешеп ятканнар. Гадәтенчә, тиз генә йоклап китә алмыйча, ара-тирә уфылдап, әле бер якка, әле икенче якка әйләнгәләп яткан Никитич та бер көйгә салмак кына гырылдарга керешге. Димәк, ул да йокыга китте. Тик мин генә йоклый алмыйм. Шинелемне башымнан ук бөркәнеп, күзләремне йомам, бөтен мускулларымны йомшартам, башымдагы уйларны куам, бернәрсә турында да уйламаска тырышам. Шулай да күземә йокы керми...

Аптырагач, санарга керешәм. Йөзгә, ике йөзгә, өч йөзгә кадәр са-ныйм... Файдасы юк. Киресенчә, санау аркасында булса кирәк, йокым бөтенләй кача.

Элек, йоклый алмаган төннәрдә мин, башымдагы барлык уйларым-ны куып, мускулларымны бөтенләй бушатып, үземә йокларга куша идем дә бик тиз, дөньядагы бөтен нәрсәне — кайгыларымны, шатлык-ларымны онытып, изрәп йоклап китә идем. Иң ахыр чиктә, үз-үземне

[1] Повестьтан өзек.

йокларга мәҗбүр итә алмаган чакларда гына күңелемнән санарга керешә идем. Беркайчан да дип әйтерлек болай азапланмый идем. Әбүген, сыналган чараларның барысын куллансам да, күземә йокы керми. Ничек керсен? Күңелем тыныч түгел. Көндезге вакыйганы оныта алмыйм. Үзем саныйм, ә үземнең күз алдымда чәчләре тузган, авызборыны кара канга баткан, йөзендә, бөтен торышында куркудан, әрнүдән башка бернәрсә дә калмаган мескен хатын шәүләсе басып тора. Мин аны куарга, аның турында уйламаска тырышам, бөтен игътибарымны йомып күз алдымдагы караңгы бушлыкка юнәлтәм. Ләкин никадәр генә онытырга, йоклап китәргә тырышсам да, әлеге хатын шәүләсе каяндыр килеп чыга да уйларга, уйланырга мәҗбүр итә. Ахыр чиктә, йоклый алмаячагымны төшенеп, күзләремне ачам.

Өй эче караңгы. Лампа күптән сүнгән. Тик мич куышында гына, тычкан күзе төсле җемелдәп, бакавыз янып тора. Ул — безнең «мәңгелек» ут чыганагы. Әкрен генә, сүнәр-сүнмәс булып, төн-көн яна. Без мич якканда, лампаларны кабызганда, тәмәке тартканда шуннан ут алабыз. Кайчакларда тирә-күршеләр дә кереп, шуннан ут алып чыгалар. Алар гына түгел, хәтта станциягә еш килеп йөрүче юлчылар да бездә сүнмәс ут барлыгын белеп бетергәннәр,— узып барышлый, атларын туктатып, йөгереп керәләр дә, рөхсәт сорап, мич куышына таба юнәләләр, тәмәкеләрен кабызалар... Шуның өчен генә керәләрме икән алар? Юк, аның өчен генә түгел шикелле. Чөнки кайберләре, тәмәкеләрен кабызгач, бераз таптанып басып торалар, чыгып китәргә ашыкмыйлар, сиңа дустанә карап, дөнья хәлләрен сорашалар. Барыннан да бигрәк, фронт хәлләре кызыксындыра аларны: эшләр ничек икән анда? Колчак чигенәме икән, юкмы икән? Әллә киләме? Ничек соң, ул ләгыйннең муенын борып салырлык куәт бармы бездә? Бик зур көч белән килә дип сөйлиләр бит аны. Имеш, аңа ундүрт ил булыша икән. Дөресме бу, әллә түгелме? Ай, бу сугышлар, сугышлар! Кайчан бетәр дә кайчан рәхәтләнеп, тынычланып гомер итә башларбыз икән! Бик туйдырды бит инде...

Кыскасы, без шул сүнәр-сүнмәс булып пыскып янган бакавыз белән кешеләргә ут, яктылык өләшәбез. Әгәр шуның белән бергә аларга күңел яктылыгы, күңел нуры да өләшсәң, нинди яхшы булыр иде! Кем белә, шулай эшләп булса, бәлки, мин дә бүген төнне болай йокысыз үткәрмәс идем.

Өйгә — идәнгә, каршыдагы стенага бәсле тәрәзәләр аша кар шәүләсе төшкән. Көчсез шәүлә, сүрән шәүлә. Шулай да стенадагы кайбер әйберләрне, чөйләргә элгән биштәрле капчыкларны, патронташларны, почмакка сөялгән винтовкаларны бераз шәйләп була. Мин борчулы уйларымны икенче нәрсәгә юнәлтер өчен шул стенага төбәп карыйм, үз винтовкамны табарга тырышам. Минеке кайсы икән?.. Ләкин шәүлә шулкадәр сүрән, винтовкаларны берсеннән берсен аерып булмый, барысы бергә укмашып, кара күләгәләр булып күренәләр.

Тышта җил. Январь җиле. Ул ара-тирә саңгырау гына сызгырып, ачуланып, стеналарга, тәрәзәләргә килеп бәрелә, тәрәзә капкачларын шыгырдата, өйгә, җылыга, керергә теләгәндәй, еламсырап ыңгыраша, нечкә генә сызгыра... Шулай бераз азаплангач, морҗаны, стеналарны, тәрәзәләрне капшап карагач, өйгә керә алмаслыгына, аның ныклыгына, тәзлегенә ышанып, сызгыра-сызгыра, каядыр китеп югала. Дөнья бераз тынып тора. Мин, шул тынлыктан файдаланып, тышка, станциягына колак салам. Аннан тавыш-фәлән ишетелми,— вагоннар дөбердәми, паровозлар кычкырмый. Димәк, поездлар юк...

Секундларымы, минутларымы уза, җил яңадан әйләнеп кайта, яңадан өй тирәсендә йөри, капшана, сызгыра, җылыга керергә юл эзли, ыңгыраша...

Иптәшләр, тирән-тирән сулап, кайберләре акрын гына, өй тынлыгын бозмаслык кына гырлап, ара-тирә, әллә нигә бер дигәндәй, төш аралаш саташкалап алып, бернигә игътибар итмичә, көчәйгәннән-көчәя барган җилнең сузып сызгыруын, тәрәзәләргә килеп бәрелүен сизмичә, ишетмичә изрәп йоклыйлар. Арыганнар.

Арымаслыкмы соң! Идәндә йоклап ятучы иптәшләремнең бер өлеше узган тәүлекне каравылда тордылар,— ашлык амбарларын саклады-лар, төнне йокысыз үткәрделәр, көндезләрен дә, постта тормаган сәгатьләрдә тик утырмадылар, безнең янга килеп, кулларына балта, пычкы алдылар, безнең белән бергә амбарларны төзәтештеләр, ачык тишекләрне ямадылар, идән түшәштеләр... Кыскасы, аларга эш житәрлек булды. Шуңа күрә хәзер рәхәтләнеп, изрәп йоклыйлар.

Тик мин генә йоклый алмыйм. Көндезге вакыйгалар берәм-берәм күз алдыннан үтәләр...

...Бүген иртә белән продотряд командиры мине Иске Артышка җибәрде. Аңа волостька барыр өчен ат кирәк иде. Иген амбарындагы эшемне ташлап, авылга йөгердем.

Авыл ерак түгел. Станциядән чакрым-чакрым ярым чамасында, узәнлектә җәелеп ята. Мин кайчакларда, станция кырыендагы амбарларда эшләгәндә яисә каравыл торганда, шул авылга, аның ап-ак кар белән капланган вак-вак өйләренә, каралтыларына, бакчаларына, ындырларына карап торырга яратам.

Нигәдер ул миңа кичке сәгатьләрдә, бигрәк тә кызарып кояш баеган чакларда аеруча матур, моңлы һәм серле булып күренә. Шундый минутларда аның кояшка караган, станциядән чак күренеп торган тәрәзәләре кинәт, алтын нурларга манчылып, кабынып, җанланып китәләр, ут алгандай алсуланып янарга керешәләр, бөтен авылны — ак шакмаклардай сибелеп яткан вак-вак өйләрне, каралтыларны, бакчаларны, хәтта бөтен тирә-юньне сихерле нурга чумдыралар. Мин, табигатьнең матурлыгына, байлыгына, салам башлы авылны да әкияттәгедәй бизәвенә хәйран калып, сокланып, үз-үземне онытып, карап торам. Бу минутларда минем шул авылга барасым, тәрәзәләре нурланып, янып торган өйләргә керәсем, андагы кешеләрне күрәсем, алар белән сөйләшәсем килә. Алар миңа шат күңелле, ачык чырайлы, яхшы ниятле кешеләр булып тоелалар. Ләкин тәрәзәләргә төшкән, аларны балкыткан, матурлаган нурлар озак тормый: кояш, кып-кызыл утлы шарга әверелеп, зурайганнан-зурая барып, тау артына кереп чума, үзе белән бергә авыл өстендәге сихерле нурларны да алып китә. Өйләр, каралтылар, бакчалар яңадан боегып, мескенләнеп калалар, кичке моңсу сөремгә төренеп, караңгылык эченә чумганнан-чумалар.

Минутлар уза. Авылда беренче утлар кабына. Алар да бакавызлар булсалар кирәк,— тычкан күзләредәй җемелдәп кенә күренәләр. Шулай да очсыз-кырыйсыз ак җәймә өстендә яткан карасу шәүләләрне яңадан тергезәләр, бизиләр, серләндерәләр...

Шул авылда, Хәйрулла исемле кешедә, безнең өчен һәрвакыт бер ат әзер тора. Без аны теләсә кайвакыт, теләсә кая барырга, көндез дә, төнлә дә чакырта алабыз. Авыл Советы аның бер атын безгә бердә, төнлә дә чакырта алабыз. Авыл Советы аның бер атын безгә беркеткән. Шуның өчен ул Хәйрулла абзыйны башка йомышлар белән олауга йөртми, шулай ук аны авыл өстенә төшкән төрле эшләр белән дә борчымый, хәтта узган-барган кешеләрне дә аңа кунарга кертми.

Атның кирәклеге алдан билгеле чакларда без аңа бу турыда бер көн элек яисә, иң кимендә, берничә сәгать элегрәк әйтеп куябыз. Ул, чыпталары бераз кыршыла-туза төшкән артлы чаңгасына бурлы алашасын җигеп, астына печәнен, солысын салып, без билгеләгән сәгатьтә капка төбенә яки ашлык амбарлары янына килеп туктый да, чыбыркысын кулына тоткан килеш, утырып китүебезне сабырлык белән көтеп тора.

Бу юлы аңа алдан әйтеп куймаган идек, чөнки атның кирәклеге әле генә билгеле булды. Шуңа күрә мин аны алып килергә барам. Ат белән үзе киләме, улы киләме,— безнең өчен барыбер. Тик җигелгән аты гына булсын. Без инде күнеккән. Өендә ирләрдән берәү дә булмаса, атын үзебез җигеп чыгып китәбез, әйләнеп кайткач, туарып, сараена кертеп бәйлибез, чанасын, сбруйларын тиешле урыннарына куябыз.

Командир миңа ашыгырга кушты.

Кайчакларда мин, ат алып кайтырга кирәк булганда, станциягә ашлык китергән янсә башка берәр йомыш белән килгән олаучылар арасыннан Иске Артышка таба кайтучыларның берәрсен эзләп табам да шуңа утырып китәм.

Нигә яшерергә,— юл уңае булмаса да, олау таба алам мин. Кешеләр карышмыйлар, яхшылап үтенсәң, тиешле кылларын тарта белсәң, дилбегәләрен кулларына алалар да барасы җиреңә ялт иттереп илтеп куялар.

Бүген исә, үч иткәндәй, амбарлар янында да, станциядә дә олаулар булмады. Шуңа күрә мин станциядән ярым йөгереп, ярым атлап, ашыгып чыгып киттем, әмма озак бармадым, бәхеткә каршы, артымнан бер атлы куып җитте. Бераз юл кырыена чыгып, тиздән карга батып аңа юл бирдем дә, яныма килеп җиткәч, утырырга рөхсәт сорап, чанасына аудым.

Юлчым утыз биш-кырык яшьләрдәге зур, таза гәүдәле, табак битле шадра бер кеше булып чыкты. Иске Артышныкы икән. Алашасын кызурак атлатуын үтендем. Карышмады. Калын иреннәрен бөтереп, чеңгереп җибәрде, дилбегәсен тартты, сукмаса да, кулындагы чыбыркысын бер-ике тапкыр һавада селкеп алды. Туры алаша кыстатып тормады, чыбыркы күрсәтмәсәң дә, тыңлыйм бит, чабам бит, дигәндәй, башын селки-селки, тау астына таба күңелле генә юыртып китте, юл буендагы салам маяклар тизрәк һәм кызурак артта кала башладылар.

Берничә минуттан инде без Иске Артыш урамында идек.

Кичләрдә, айлы-йолдызлы төннәрдә ерактан караганда, һәрвакыт серле, моңсу булып тоелган, мине төрле уйларга чумдырган, бала чакларымны, яшүсмер елларымны хәтерләткән, үзенә чакырган, кызыктырган авыл урамына барып керү белән үк серлелеген югалтты, миңа Иске Артыш таныш булып калды. Шул ук йортлар, шул ук тәрәзәләр, шул ук капкалар. Урамга, юл буена түгелгән салам көлләре дә, хәтта капка асларыннан яшен тизлегедәй атылып чыгып, артыбыздан гайрәтләнеп өреп калучы этләр дә таныш...

Авыл серлелеген югалтты, әмма моңсулыгы калды. Түбәләрендәге авыр кар катлауларын күтәрә алмагандай, беркадәр җиргә сеңеп, тәбәнәкләнеп калган өйләр, каралтылар, бәсләнгән, сукырайган вак-вак тәрәзәләр, капка төпләрендәге ялангач өянкеләр — барысы да, барысы да моңсу.

Этләрнең артыбыздан һаулап йөгерүләренә, кайберләренең алга атылып чыгып, ат авызына ташланырга маташуларына карамастан, алашабыз, бернәрсәгә игътибар итмичә, башын селки-селки, үз көенә йөгерүендә дәвам итте. Шулай да без Хәйрулла абзыйларга тиз генә барып җитә алмадык. Урта урамга барып кергәч, күп тә китмәдек, бер капка төбеннән ике малай, һич көтмәгәндә каршыбызга йөгереп чыгып, юлга аркылы бастылар да, нәрсәдер кычкыра-кычкыра, туктавыбызны үтенеп, кулларын бутарга тотындылар. Үзләре кычкыралар, үзләре куллары белән урыс капкалы, калай башлы йортка таба төртеп күрсәтәләр. Анда нәрсәдер булган, күрәсең. Нәрсә булган? Нигә анда таба күрсәтәләр?

Олаучым, дилбегәсен тартып, алашасын туктатты. Унбер-унике яшьләрдәге, иске, ямаулы бишмәтле әлеге ике малай, яныбызга ук килеп,

ашыгып-кабаланып, бер-берсенен сүзен бүлә-бүлә, безне ник туктатуларын аңлатырга керештеләр:

— Гайнетдин абзый...— диделәр алар олаучыма.— Гайнетдин абзый... Кәлим абый Фаизә апаны куып йөри...

— Аркалык белән куып йөри...

— Тотса, үтерә ул аны...

Чыннан да, нәрсәдер булган, малайларның йөзләренә курку чыккан, күзләре акайган, сулулары капкан. Шул кадәр каушаганнар, хәтта нәрсә әйткәннәрен дә яхшылап аңлап булмый. Олаучым да аңлап бетермәде, кайтарып сорады:

— Рәтләбрәк әйтегез, маңкалар! Кемне куып йөри?

— Кемне булсын, Фаизә апаны!

— Нигә куып йөри соң ул аны?

— Нигә булсын, кыйнарга!

— Тотса — үтерә ул аны...

Бу авыл кешеләрен белеп бетерми идем әле мин. Кем ул Кәлим? Кемне куып йөри? Нигә куып йөри? Фаизә дигәне кем?

Шуларга җавап эзләп олаучыма карадым, ә ул, бер дә исе китмичә, салкын гына авызын ерды:

— Һе, куып йөрсә соң! Үз хатыны ич! — Һәм ул, кузгалып китәргә теләп, дилбегәсен иплән тотты.

Малайлар, аның бу хәрәкәтен күреп, үрәчәгә ябыштылар, ялына башладылар:

— Гайнетдин абзый, кер инде, зинһар!.. Кыйнарга ирек бирмә...

— Булмаса, абый җаным, син кер,— диде берсе миңа.— Кыйнатма... Абый җаным!.. Ул аны болай да гелән кыйный...

Мин бер фикергә килергә өлгермәдем, олаучым, кулындагы сумалалы чыбыркысын күрсәтеп, бик ачуланып, малайларга акырып салды.

— Китегез, маңкалар! Шуның өчен туктаталармыни! Керермен менә, чыбыркы белән берәрне тамызсам! — диде һәм, чөңгереп җибәреп, атына шундый каты сыдырды, башын иеп, тынып калган мескен туры алаша, урыныннан кинәт кузгалып, сикереп чабып китте. Балалар чак кына читкә тайпылып өлгерделәр.

Малайлар инде артта калган булсалар да, олаучым аларны орышуында дәвам итте:

— Менә бит юньсезләрне! Туктаткан булалар. Имеш, кер, кыйнарга ирек бирмә. Ир белән хатын арасына кер... Кереп кара син алар арасына. Ник кергәнеңә гомер буе үкенерсең...— Шул сүзләрне әйтә-әйтә, ул миңа борылып карады, яклавымны, фикере белән килешүемне көтте булса кирәк.

Мин исә, аның фикере белән килешергә җыенмый идем, шулай да күңелемдә ачык бер карар юк иде әле: туктаргамы, юкмы? Туктасаң, вакыт уза. Командир тизрәк әйләнеп кайтырга кушты. Туктамасаң, ничектер яхшы түгел, күңелгә авыр. Кем белә, анда чыннан да берәр хәвефле эш бардыр. Нигә куып йөри ул аны? Нигә аркалык белән?..

Олаучым һаман мыгырдана, бер үк сүзне кабатлый иде:

— Ир белән хатын арасына кереп кара син...

— Шулай да атыңны туктат әле,— дидем мин аңа.— Чыннан да, нәрсә бар икән анда? Болай гына узып китү яхшы түгел.

— Нәрсә булсын! Ишеттең ич: куып йөри, диләр. Әллә ирләрнең хатыннарын куып йөргәнен күргәнең юкмы? Һай, син дә дөньяда яшисең!.. Хи, хи-хи-хи!..

Ул, шулай хихылдап көлеп, карасу кысык күзләре белән миңа шундый мыскыллап карады, аның мине кешегә санамавы, санаса да, иң кимендә, күктән төшкән ангыра, дивана бәндә итеп уйлавы сизелеп тора иде. Кем белә, бәлки, аның мыскыллап каравы да булмагандыр, табигый күз карашы шулайдыр, әмма бу минутта ул миңа ничектер каты

мыскыллау булып тоелды, йөрәгемне әрнетеп, чеметеп алды һәм мин шул мыскыллы караш астында ачык бер фикергә килдем, борылып, әлеге йорт янына кире кайтырга, андагы вакыйга белән танышырга, әгәр кирәк булса, араларына керергә, аерырга, кыйнауны, сугышуны булдырмаска карар бирдем. Болай гына узып китә алмыйм. Хакым юк! Вөҗданым кушмый.

— Ирләрнең хатыннарын куып йөрүләрен күргәнем барын бар да,— дидем мин олаучыга,— шулай да атыңны бор әле. Кире барыйк. Кыйнамыйммы икән?

— Кыйнаса соң,— диде ул һәм, сүземә игътибар итмичә, атын кууында дәвам итте, сукмаса да, чыбыркысын берничә тапкыр һавада болгап алды.— Кыйнаса соң, безнең ни эшебез бар анда!.. Үз хатыны... Һай, малкай, әйдә әле!..

Бу кешенең көтелмәгән тискәрелеге, дорфалыгы, сүземә колак салмавы, хәтта алай гына да түгел, ә, киресенчә, миңа мыскыллап каравы, барыннан да бигрәк, «кыйнаса соң» дип, түбән җанлануы һәм мине үзенең фикердәше итәргә маташуы кинәт ачуымны китерде. Кем дип белә ул мине? Нигә ул миңа үз фикерен, үзенең түбән карашын, кыргыйлыгын көчләп такмакчы һәм мине шуңа буйсындырмакчы була? Мине дә әллә ул, үзе кебек, шундый хәлләр, вакыйгалар яныннан тыныч кына узып китәр дип уйлыймы? Юк, узмый торыйк әле!

Шундый уйларга бирелеп һәм ачуланып, табак битнең кулыннан дилбегәсен тартып алдым да атын текә генә кире бордым.

Олаучым моны көтмәгән иде булса кирәк. Башта ул бераз аптырап калды, карасу кысык күзләре белән миңа гаҗәпләнеп карады, аннары, аңына килеп, дилбегәне тартып алырга теләде һәм мине терсәге белән тупас кына бер читкә этте. Дилбегәне каты йомарлап тоткан идем, алырга ирек бирмәдем.

— Чү, нишләвең бу?! Кая барасың? — диде ул миңа, һаман да әле дилбегәсен тартып алырга теләп.

— Кая булсын, әлеге кешеләргә,— дидем мин аңа салкын гына.— Барыйк. Күрик. Бәлки, чыннан да, аерырга кирәктер.

Мин тупас җавап ишеттем:

— Кирәк икән, төш тә кит! Үзең генә бар! Нигә атны борасың?!. Үз атыңмыни!..

Җавап бирмәдем. Кулымнан дилбегәне ычкындырмыйча, олаучыга терсәгем белән каты гына төрттем дә атны юлга чыгардым. Башта шактый чәбәләнеп каршы торган агай, минем үз сүземнән кайтмаслыгымны сизеп булса кирәк, бераз йомшара төште:

— Кара әле, иптәш, син мине бу эшкә бутама әле,— диде ул һәм нигәдер тагын кеткелдәп көлеп җибәрде.— Ир белән хатын арасына керү, бәлки, сиңа тансыктыр ул. Тансык булса, үзең генә бар. Ә мине бутама...

Капка төбенә барып җиткәч, аңа шактый кырыс тавыш белән әйттем:

— Төш! Әйдә, керәбез. Нәрсә бар икән анда?

Олаучым, бер сүз дә әйтмичә, чанадан теләр-теләмәс кенә төште. Ул арада әлеге ике малай, капка ярыгыннан ишек алдына бик кызыксынып карап торуларын ташлап, яңадан безнең янга йөгереп килде. Тагын алар:

— Кыйный!.. Үтерә!..— дигән сүзләрен кабатладылар.

Мин ишек алдына керергә ашыктым. Чыбыркысын тотып, артымнан ияреп килгән Гайнетдин абзыйның, пошынып, ялварып:

— Кара әле, энекәш, ташла, зинһар, эт белән эт булма...— дигән сүзләренә колак салмадым.

## II

Ишек алдына без каяндыр килеп чыккан аксак бер карт һәм кызыксынып артыбыздан ияргән өч-дүрт малай белән барып кердек. Анда, көннең шактый салкын булуына карамастан, өстендәге каешланып беткән кыска сары тунын төймәләмәгән, озын буйлы, такыр башлы, кәләтүшле бер кеше лапас астында каеш аркалык белән хатынын кыйный һәм суккан саен, бик эшәке сүгенеп:

— Икенче бармассыңмы?!. Икенче бармассыңмы?! — дип гыжлап кабатлый иде.

Күлмәкчән һәм оекчан гына чыккан хатын, куллары белән башын-күзен каплаган, җирдә сибелеп яткан саламга чүгәләгән дә аркалык сызгырып килеп төшкән саен, бөтен гәүдәсе белән җыерылып, калтырап, ыңгырашып җибәрә һәм, тавышын чыгармаска, читләргә ишеттермәскә тырышып, эченнән елый, үкси.

Мин капкадан керү белән үк:

— Ник кыйныйсың аны?!. Ничек оят түгел сиңа!..— дип, бик ачуланып кычкырып, алар янына йөгереп бардым да кыйнаучының кулыннан аркалыгын тартып алдым, такыр башның үзен бер читкә этеп җибәрдем.— Оятсыз, нишләвең бу синең!.. Әллә үтермәкче буласыңмы?!.

Такыр баш бу хәлне, нindидер чит кешенең ишек алдына килеп керүен, кулыннан аркалыгын тартып алып, үзен бик каты бер читкә этеп җибәрелүен һәм, җитмәсә, аркалыкны селки-селки, аңа ачуланып кычкыруын көтмәгән иде булса кирәк. Башта ул, аптырап, каушап калды: «Тукта әле, кем син? Монда, минем ишек алдында ни эшең бар синең?» — дигәндәй, төссез акай күзләре белән миңа текәлде. Хатын да сискәнеп китте, ялангач башын күтәреп, куркып, безгә таба борылып карады. Аның чәчләре тузган, авыз-борыны канаган, зур булып ачылган яшьле күзләрендә чамасыз әрнүдән, куркудан, ялварудан башка бер нәрсә дә юк иде. Шунда ук ул, ишек алдындагы кешеләрнең нигә килүләрен төшенеп, оялып, куллары белән яңадан башын-күзен каплады, аннары, аңына килеп булса кирәк, безгә йөзен күрсәтмичә генә борылып, җирдә аунап яткан яулыгына сузылды, аны капшаланып табып, тиз генә башына салды, урыныннан сикереп торды, әллә оятыннан, әллә инде сызлануыннан, әрнүеннән бөгелә төшеп, өйгә таба йөгерде. Мин аның кызларча нечкә буйлы, озын кара толымлы һәм, иренә караганда, шактый яшь икәнен күреп алдым. Шуның белән бергә күлмәгенең аркасы берничә җирдән ертылганлыгы да күземә чалынып китте. Я хода, шундый ерткычларча кыйнау булыр икән дөньяда! Ничектер, ачудан, нәфрәтемнән йөрәгем өзелеп төшкәндәй булды, акай күз өстенә ташланудан үземне чак тыеп калдым.

Хатын кереп киткәннән соң, без утыз биш яшьләр тирәсендәге, кыска саргылт сакаллы, тычкан койрыгыдай нечкә мыеклы, озын буйлы, төссез акай күзле кеше белән кара-каршы калдык. Акай күзнең ачуыннан сул яңагы нервланып сикерә, шуңа булса кирәк, авыз кырые кыйшаеп-кыйшаеп китә иде.

Каушап калуы озак дәвам итмәде. Мондый бәрелешләргә күнеккән булса кирәк,— үзен тиз кулга алды, шинелемә, аягымдагы табан салган киез итеккә һәм кыршылып беткән колакчын бүрегемә күз төшереп алгач, минем әллә кем түгел икәнемне күреп, кинәт гайрәтләнеп кычкырырга, бик эшәке сүгенергә тотынды:

— Ни дип кердең әле син минем ишек алдына?!. Ни кирәк сиңа?! Может син мине үтерергә, таларга кергәнсең.

Аннары ул, аксак карт белән малайларга карап, акырып салды:

— Сезгә ни кирәк монда?! Үкчәгезне күтәрегез! Югыйсә, барыгызны да буып үтерәм!

Аның карашынча, ул гаепле түгел, ә без гаепле идек.

Мин, артык кызып китүдән үземне тыярга тырышып, мөмкин кадәр салкын кан белән аңа:

— Бик акырма,— дидем,— бугазың ярылыр.

Ул, шуны гына көткән шикелле:

— Шулаймыни әле, бугазым ярылырмы?! — дип гыжлап кычкырып, кинәт артка сикерде, ат сарае янында сөялеп торган өч җәпле тимер сәнәген күз ачып-йомганчы кулына алды. Аны штыклы винтовка шикелле итеп тотып, каршыма килеп басты да, һаман әшәке сүгенүендә дәвам итеп, тагын да катырак акыра башлады: — Карап карыйк, кемнең бугазы ярылыр икән!.. Сез әле мине көпә-көндез таларга, суярга кердегезме?! Хәзер барыгызның да эчәгеләрен актарып чыгарам! Моның өчен суд юк миңа!..

Аның сул яңагы һаман да нервланып сикерә, ә яшькелт күзләре атылып чыгарлык булып акайган иде.

Башта, аның көтмәгәндә сәнәккә ташлануын күргәч, үзем дә сизмичә, сискәнеп киттем, шулай да урынымнан кузгалмадым, такыр баш сәнәген тоткан килеш миңа таба борылганчы, үземне кулга алып, акылымны, тәнемдәге бар көчемне бер ноктага туплап өлгердем. Ул миңа таба тимер сәнәген сузып килгәндә, мин инде, кулларымны йодрыклап, тешләремне чатырдатып кысып, күзләремне аның хәрәкәтеннән бер секундка да алмыйча, һөҗүмен кире кайтарырга, өстенә ташланырга әзер идем, мускулларым соңгы чиккә кадәр тартылган, бер йомгакка тупланган иде. Аларның ни дәрәҗәдә тартылуын, туплануын, ычкынырга, кинәт атылып китәргә әзер булган пружинадай торуын мин бары соңыннан, тәнемнең барлык җире сызлавыннан гына аңладым.

Бу кеше авылда үзенең усаллыгы, хулиганлыгы белән дан казанган булса кирәк. Аның сәнәк алуын күрү белән үк малайлар, өркетелгән чыпчыклардай, куркуларыннан кычкырып җибәреп, чәрелдәшеп, капкага таба атылдылар. Аксак карт та бик тиз күздән югалды. Тик бераздан гына аның капка төбеннән, бик куркып, ярым чыелдап, ярым безелдәп кычкырган тавышы ишетелде:

— Нишләвең бу синең, Кәлимулла!.. Акылыңа кил!.. Рибалбирлы кеше бит ул! Камисар! Әллә тагын башыңны себер җибәрмәкче буласыңмы?!

Хәлем ансаттан түгел иде. Шулай да мин урынымда басып торуда дәвам иттем. Хәзер бу хулиганга нинди дә булса сүз әйтүнең, акыруның, кычкыруның, хәтта үгетләүнең дә файдасы юк. Сүгенеп бетерүен, кызуы бераз басылуын көтәргә кирәк. Аннары шунысы да бар: бу кеше сәнәген тоткан килеш кар өстендә, январь суыгында, күлмәк изүен чишеп җибәреп, такыр башын чак каплаган, майланып, каешланып беткән кәләпүштән озак басып тора алачак түгел, туңачак, салкын аңа, аның әрекмән колакларына, бритва белән кырдырып алдырган, ялтырап, күгәреп торган башына шифалы тәэсир итәчәк.

Күпмедер вакыт без шулай, бер-беребезгә текәп карашып һәм бер-беребезне чәйнәп ташларлык булып, икебез дә урыныбыздан кузгалмыйча басып тордык. Аның кулында тирескә буялып, пычранып беткән өч җәпле тимер сәнәк. Минем бер кулым буш, икенче кулымда әлеге каһәр төшкән аркалык. Мин аны, өзәрлек дәрәҗәдә кысып, кулыма йомарлап тотканмын. Икебезнең дә ачуыбыз кабарган. Ул мине кадап, чәйнәп үтерергә, эчәгеләремне актарып чыгарырга әзер. Мин дә бу минутта аның икмәк шүрлеген җимерер өчен әллә ни бирер идем.

— Ташла сәнәгеңне! Миндә аннан да көчлерәк әйбер бар,— дидем мин аңа коры гына һәм уң кулым белән кесәмә шапылдатып сугып алдым. Дөресен әйтим, кесәмдә тәмәке янчыгыннан башка бернәрсә дә юк иде.

Күпмедер вакыт үтте — секундлармы, минутлармы,— анысын әйтә алмыйм, әмма миңа бу бик озак тоелды. Ниһаять, Кәлим түзмәде, уры-

ымнан кузгалмавымны, курыкмавымны, киресенчә, бик ачулы карап, басып торуымны күреп, тагын бер тапкыр бик әшәке сүгенде дә кулындагы сәнәген бер кырыйга ыргытты, салкынны тоеп булса кирәк, күлмәк өзүен төймәләде, майланып, каешланып беткән кәләпүшен басыбрак киде, колакларын тиз генә уып алды. Мин дә аркалыкны бер читкә ыргыттым.

Тынып калудан файдаланып, бер нәрсәне хәл итәргә тырыштым: «Нишләтергә моны? Тотып, авыл Советына алып барыргамы? Әллә соңыннан чакыртыргамы?»

Ачуым бик кабарган иде. Чөнки мин хатын-кызларны җәберләүче, кыйнаучы, хурлаучы, аларның намусларына тукынучыларны берничек тә гафу итә алмыйм.

Хәзер үз-үземә гаҗәпләнәм. Мин аның өстенә ничек ташланмадым да, бугазыннан алып, җиргә бәтереп салып, авыз-борынын ничек җимермәдем икән?..

Дөресен әйтим, аңа каршы кул күтәрмәвемә бик шатланам. Әгәр якасына ябышкан булсам, сугышудан, кызылармеец дигән дәрәҗәмне төшерүдән башка бернәрсә дә булмас иде.

Аннары кем белә, өч җәпле тимер сәнәкне кулына алып өлгергән кешегә ябышу нинди нәтиҗә бирер иде? Якын тирәдә миңа ярдәмгә килерлек берәү дә юк. Аксак карт сәнәкне күрү белән үк чыгып тайды. Балалар да күздән югалдылар. Хәер, аларның булулары белән булмаулары арасында аерма юк. Олаучым да күренми. Әллә кергән, әллә инде ул да шылган. Кыскасы, тимер сәнәкле акай күз алдында бер үзем басып калдым. Аннары шунысы да бар: мондый мәсьәләне түбәләшеп хәл итү бик зур ахмаклык булыр иде.

Шулай да, кемне булса да ярдәмгә чакырырга теләп, артыма борылып карадым. Ишек алдында безнең икебездән башка берәү дә юк. Дөрес, әлеге какча гәүдәле аксак карт белән малайлар, аннары тагын ниндидер бер-ике кеше, кечкенә капкадан башларын тыгып, бу җәнҗалның нәрсә белән бетүен көтеп, бик кызыксынып карап торалар. Аларны чакырудан файда юк. Акай күз аларга тагын бер акырса, алар үкчәләрен күтәрергә әзер торалар. Хәтта кечкенә капканы да бөтенләй ачмаганнар, ә ябарга әзер булып, урам яктан башларын гына тыкканнар. Димәк, бу йөгәнсез хулиганга мин бер үзем каршы торырга тиеш.

Кычкырышып, акырышып торуның файдасы юклыгын белгәнлектән, мин, аның чәпчүен басарга теләп, сорау бирдем:

— Ник кыйныйсың син аны? Нинди хакың бар синең?

Такыр баш, каты сүгенеп, бик дорфа җавап кайтарды:

— Кыйнаса, синең ни эшең бар?! Үз хатыным! Синең хатының түгел.

— Беләсеңме син, юкмы, контр, үз хатының булса да, кыйнарга ярамый. Революция хәзер. Хөррият!

Мин тагын да әшәкерәк җавап ишеттем:

— Рибалутсия булмагае, чорт булсын! Үз хатынымны мин теләсә нишләтә алам. Теләсәм — кыйныйм, теләсәм — кочып ятам. Берәүдән дә сорап тормыйм. Үз хатыным! Никахлы хатын!

— Барыбер хакың юк. Рәтле кеше этен дә кыйнамый.

— Хакым бармы, юкмы,— аны синнән сорамыйм. Анда синең эшең юк. Син үз хатыныңны кара, әгәр булса. Хәер, синең кебек галахның каян килеп хатыны булсын! — диде ул һәм көләсе килмәсә дә, көчәнеп, шаркылдап көлеп җибәрде. Өркетелгән кешеләр алдында аның миңе мөмкин чаклы хурлыйсы, изәсе, мыскыллыйсы, шуның белән үзен бернәрсәдән дә курыкмый торган кеше итеп күрсәтәсе килә иде булса кирәк. Чөнки ул минем белән бәхәсләшкәндә, сүзем, батырлыгым башкаларга ничек тәэсир итә икән дигән төс белән капка төбендәге кешеләргә берничә мәртәбә карап алды.

— Шулай да, әшәке җан, әйт әле, ник кыйныйсың аны? Ни гаебе бар аның?

Ул җавап бирми торды, нигәдер сәнәккә күзен төшереп алды, ләкин урыныннан кузгалмады.

— Ник кыйныйсың? — дип кабатладым мин.

Ниһаять, ул үкереп салды:

— Анда синең эшең юк! Бар, яхшы чакта үкчәңне ялтырат!

Мин бу кеше белән монда, аның ишек алдында сөйләшү мөмкин түгел икәнен аңлап, борылып чыгып китүне дөресрәк санадым, шулай да чыгар алдыннан аңа әйттем:

— Бел, контр җан, мин моны болай гына калдырмам. Тикшертермен, хулиганлык итәргә, хатыныңны кыйнарга ирек бирмәбез,— дидем.

Такыр баш, авызын мәсхәрәле кыйшайтып, тагын шаркылдап көлде:

— Бар, бар, тикшерт! Әллә курка дип беләсеңме! Сиңа гына түгел, миңа да рибалутсия хәзер. Хөррият! Теләсә нәрсә эшлим. Миндә беркемнең эше юк.

«Менә җир битне син аны, тамагына пычак кергере, революцияне, ирекне ничек аңлый! Аныңча, революция дигән, азатлык дигән сүз: хулиганлык, кабахәтлек, законсызлык»,— дип уйлап мин, чамасыз нәфрәтләнеп, борылып китеп бардым. Капка төбенә җитәрәк, мин аның, «ертык» шинелемне, өс-башымны, хәтта табан салган итегемне дә телгә алып, русча-татарча сүзләр белән сүгенүен, артымнан эт кебек өреп калуын ишеттем (куркак этләр шулай булалар, кеше ераклашкан саен катырак, гайрәтләнебрәк өрәләр):

— Бөтен илне талавыгыз җитмәгән, инде хәзер ир белән хатын арасына да керә башладыгызмы?! Әллә аларны да сугымга җыймакчы буласызмы? Җыегыз, алыгыз, зинһар! Әллә хатын таба алмам дип уйлыйсызмы? Поты бер тиен аларның хәзер. Бер сызгырсам, уны чыга!..

Минем ишек алдыннан тәмам чыгып баруымны күргәч, ул тагын да катырак, әшәкерәк сүгенергә, Совет властен төрлечә хурларга, мыскылларга керешә: имеш, ул дөньяда бернәрсәдән дә курыкмый, төкерә ул безнең властька, ул үзе власть, үзенә үзе закон... Аннары, имеш, безнең бер дә борын күтәрерлек җиребез юк; кыл өстендә торабыз. Колчак килгәч, барыбызны да асачаклар. Муеннарыбыздан түгел, аякларыбыздан асачаклар...

Кыскасы, аның әшәке җанлылыгын тел белән әйтеп, аңлатып бетерү мөмкин түгел.

Сулуым капты, катып калдым, йөрәгем тибүдән туктады дип торам. Менә каһәр суккан җан! Безнең ашлык җыюыбыз, ач шәһәрләрне, фронтны, Кызыл Армияне икмәкле итәргә, шуның белән революцияне саклап калырга теләвебез турында, Совет власте, аның законнары турында менә нинди әшәке фикердә икән ул! Юк, моны гафу итә алмыйм. Ул минем үземне, өс-башымны теләсә ничек хурласын, мыскылласын, әмма Совет властен, безнең изге эшебезне, максатыбызны хурларга, мыскылларга нинди хакы бар аның!

## III

Урамда, капка төбендә, теге аксак карт белән малайлардан башка тагын берничә кеше басып тора иде. Нигәдер алар мине тын, сәер каршы алдылар. Мине яклап та, Кәлимне яклап та бер сүз әйтмәделәр. Тик малайлар гына миңа бик кызыксынып, күзләрен елтыратып карап торалар иде.

Авыл Советына барып, бу турыда хәбәр итим, тикшерсеннәр, сөйләшсеннәр, берәр чарасын күрсеннәр дип, олаучымны караштыргала-

ым, ләкин аннан жилләр искән. Җанҗалга катышып, карап булмыйм, әласеннән баш-аяк дип качкан булса кирәк.

Чыннан да, шулай булып чыкты. Җыелып торучылардан аның кая итүен сорагач, малайларның берсе, соңыннан килеп кушылганы булса кирәк:

— Абый, ул син кереп киту белән үк чанасына менеп утырды да ан-фәрманга аттырды,— диде.

Мин, әле генә булып алган вакыйга өчен бик борчылып, күңелсезлә-п, Хәйрулла абзыйларга таба киттем. Күңелсезләнмәслекме соң! ызылармеең башым белән шул кешене, хулиганны, җирбитне буйсын-ыра алмадым. Хәтта алай гына да түгел, Совет властен мыскыллап, урлап, артымнан бик каты сүгенеп калды. Аннары, барыннан да ңелсезрәге, йөрәкне әрнеткәне шул: капка төбендә өелешеп, безнең өрелешне кызыксынып карап торучы кешеләр арасыннан, мескен тынны яклап, минем янга, миңа ярдәмгә керүче берәү дә булмады. аксаң, алар арасында әлеге аксак карт белән бала-чагалар гына түгел, ипсә тимер өзәрлек агайлар да бар иде. Шуның өстенә тагы олаучым а качкан.

Нәрсә алар, Кәлимнән куркалармы, әллә мине чит күрәләрме? Әллә иде чыннан да мин, ир белән хатын арасына кереп, начарлык эшләдем-е, авылның борынгыдан килгән гадәтен боздыммы,— шулай итеп, апка төбендә басып торучы сакаллы агайларның үз-үзләрен сөю хис-әренә тукындыммы, аларны хурладыммы? Нәрсә булды? Нигә мине әм Фаизәне яклаучылар булмады?..

Юк, начарлык эшләмәдем мин. Бары мескен хатынны гына арала-ым, аны якладым, мәрхәмәтсез кыйналудан, гарипләнүдән коткарып алдым.

Тукта әле: «мескен хатын?» Мескенме икән ул? Ялгышмыйммы икән? Мин бит аны белмим. Бәлки, аның читләргә билгеле булмаган, бары ре генә белә торган нинди дә булса зур гаебе бардыр. Ире аны шуның чен гафу итә алмый торгандыр, шуңа күрә аралары бозылгандыр, авыш чыгадыр...

Юк, мин моның белән килешә алмыйм. Хатынның нинди генә гаебе улмасын,— зурмы ул, кечкенәме, барыбер, иренең кыйнарга хакы юк. Дөньяда тәртип бар, закон бар. Яңа тәртип! Яңа закон!

Яңа закон? Кәгазьгә язылган, гамәлгә кергән, халыкка билгеле бул-ан закон бармы икән соң әле? Андый законны ишеткәнем юк. Ишетмә-ән булсам да, революциянең үз законы бар. Әгәр ул закон бүген әгазьгә язылмаган, халык арасында таратылмаган икән, аның каравы, л Совет власте өчен көрәшүчеләрнең каннарына, күңелләренә, йөрәк-әренә язылган. Мин менә шуннан чыгып, Азатлык, Тигезлек дигән әге законнан чыгып, хәтта аның тирән мәгънәсен, киңлеген, зурлыгын, өеклеген тиешенчә аңлап бетермәсәм дә, бары намусымның, вөжда-ымның кушуы буенча гына мескен хатынны якладым. Ялгышмадым.

Мин, шулай уйлый-уйлый, Хәйрулла абзыйларга баруымда дәвам иттем. Бераздан минем артымнан, кар шыгырдатып, ашыгып килгән аяк авышлары ишетелде. Борылып карасам, әлеге какча гәүдәле, аксак арт белән өч-дүрт малай, тагын ниндидер бер хатын килә. Хатынның стендә бераз искерә төшкән биш билле кара бишмәт, башында ыйнак кына уралып, чуклары салынып торган гади ак шәл, аягында лтан салынган чуар итек. Күрер күзгә нәрсәсе беләндер кешене җәлеп итә торган ягымлы йөзле, озын буйлы, кырык-кырык биш яшьләр тирә-ендәге хатын иде ул.

Аларның мине куып җитәргә теләүләрен сизеп, адымнарымны акры-айттым.

Куып җиттеләр.

Аксак карт, минем белән янәшә бара-бара, үзен акларга теләгәндәй, бераз чыелдавык тавышы белән зарланып сөйли башлады:

— Шулай инде бездә, иптәш кеше, усаллардан куркып, калтырап яшиләр... Әлеге тегә Кәлимне әйтәм. Бөтен авылны куркытып тора ул. Ачуы килсә-нитсә, хәзер өстенә килә, пычагын чыгара. Этнең дә эте... Бик үчле нәрсә...

Бу сүзләрне ишетеп, мин баруымнан туктадым:

— Закон юкмыни аңа? Акылга утыртып булмыймыни аны? — дидем.

— Булган иде дә... кайтардылар шул.

— Нәрсә, төрмәдә идемени?

— Шунда иде. Патша төшкәч кайтты. Хәзер шуның белән мактана. Имеш, аны патша заманында япканнар. Ривалутсия өчен страдать иткән.

— Нигә япканнар иде соң? — дип сорадым мин, кызыксынып.

— Нигә булсын, шул инде, усаллыгы өчен. Сугышып, берәүне кадап үтерде, икенчесен гомергә гарип итеп калдырды. Хәзер дә әле янамаган кешесе юк... Миңа да көн күрсәтмәс әле ул эт нәрсә.

Ак шәлле хатын моңа чаклы сүзгә кушылмаса да, аның бу мәсьәлә белән бик кызыксынганлыгы, миңа нәрсәдер әйтергә теләве, аксак картның сүзләрен яратып бетермәве йөзеннән, күз карашыннан сизелеп тора иде. Нинаять, ул түзмәде, картның соңгы сүзләрен беркадәр үчекләп кабатлап:

— Көн күрсәтмәс, күрсәтмәс,— диде.— Куян йөрәк булсаң, күрсәтмәс шул, Гата абзый!

— Мин куян йөрәкме? — диде аксак карт чәрелдәвек тавыш белән һәм шәлле хатынга ачуланып карап алды. Бу секундта аның чал кергән кара сакалы да, хурланып, тырпаеп куйды кебек.— Мин куян йөрәкме!? — диде ул, кабатлап.— Пычагын чыгарып, бугазыңа терәсә, син дә куян йөрәк булырсың... Хәер, хатыннарга нәрсә аларга... Алар ни сөйләгәннәрен үзләре дә белмиләр...

— Син генә куян йөрәк түгел, Гата абзый,— диде шәлле хатын.— Үпкәләмә, күбегез куян йөрәк. Аннан куркып, калтырап торасыз. Курмәдәнмени, бу иптәшкә дә сәнәк күтәрде ич. Ә иптәш курыкмады, урыныннан да кузгалмады. Кәлим ул куркаклар алдында гына гайрәт чәчә, ә батырлар алдында куяннан да болайрак. Шулай күренә. Әгәр шунда берәрегез бу иптәшкә ярдәмгә кергән булса, аны, бөтереп алып, сәвиткә илтеп була иде бит? Була иде. Белер иде шуннан соң ул... Куркаклар шул сез, куркаклар. Ачуым бер килмәгәе, әйтсәм әйтим инде, ирләр исемен күтәреп, сакал сәлперәйтеп йөргән буласыз шунда... Бүрек киеп түгел, яулык бәйләп йөрергә иде сезгә...

Хатынның зур, акыллы күзләре ачуданмы, әллә куян йөрәкләрдән нәфрәтләнүдәнме, нәрсәдәндер, чаткыланып-чаткыланып китә иде. Бу минутта ул үзенең ир булып, көчле зат булып тумавына үкенә иде шикелле.

Гата абзый бу хатын белән дә ачуланышырга, араны бозарга теләми иде кебек. Ул аңа күзләрен чепелдәтеп, йомгалап карап торды да, үзенең куркаклыгын, иң кирәк вакытта ишек алдыннан ашыгып чыгып китүен һаман да әле акларга теләп:

— Аңа каршы нишли алам мин, Хәбирә килен,— диде.— Беләсең ич син аны. Ул я сәнәк, я балта күтәрә, я пычагын чыгара...

Хатын аның сүзен тыңларга теләмәгән төс белән кулын селтәде.

— Сиңа карата гына әйтмим лә мин аны, Гата абзый. Аллага шөкер, синнән башкалар да җитәрлек иде анда. Әзмәвер кебекләр бар иде. Тик берсе дә иптәшкә ярдәмгә кермәде. Күзләрен акайтып карап торуны гына белделәр. Әйтерсең, кәмит күргәннәр! Тфү, кеше булган кеше,

кирәк икән, утка керер, булышыр... Син дә бит шулар белән авызыңны ачып карап тора идең. Менә нигә ачуым килә минем...

Малайларның берсе, араларыннан кечерәге, картны яклап:

— Хәбирә апа, син күрмәдең, Гата бабай да ишек алдына керде... Кояштыр менә, керде,— диде.

Икенче малай исә, барсына караганда да зуррагы, аның сүзен ярат-мыйча, мыскыллап:

— Керде, керде... Керүмени ул! Сәнәкне күргәч үк чыгып качты ич! — диде.

Хәбирә апа моны күрмәгән иде булса кирәк. Бу турыда ишеткәч, әметсезләнеп, бөтенләй кулын селтәде:

— Әй, барыгыз да бер чыбыктан куылган бәндәләр сез!

Бу апаның ирләрдән тел яшермәве, йөзен капламавы, әйтәсе сүзен курыкмыйча, оялмыйча туп-туры әйтүе ошый иде миңа.

Юлда алар миңа Кәлим турында тәфсилләп сөйләп бирделәр. Шактый холыксыз, нервлы кеше икән ул. Ачуы-фәлән чыкса, бер нәрсә белән дә исәпләшеп тормыйча, кешене төрле әшәке сүзләр белән хурлый, мыскыллый, хәтта сугышырга ук керешә икән. Шуның аркасында хатыннары белән дә тату тора алмаган. Моңа кадәр өч өйләнгән, берсен үзе аерган, ә икенчесе, җәбер-золымга түзә алмыйча, качып киткән. Бусы — Фаизә исемлесе — төрмәдән кайткач өйләнгән хатыны. Башта елдан артык тату торганнар. Халык та, гаҗәпләнеп: «Күрәсезме, Кәлим төрмәдән акылга утырып, төзәлеп кайтты бит, хатыны белән тату тора, тавыш чыгарганы, кычкырышканы ишетелми»,— дип ошатып сөйли башлаган. Тик аның бу уңай сыйфаты озак дәвам итмәгән. Узган көздән бирле Кәлим яңадан элеккеге Кәлим булып әверелгән, яңадан нигәдер еш кына тавыш чыгара, ызгыша башлаган, ә соңгы айларда бөтенләй котырынып, Фаизәне берничә тапкыр бик каты кыйнаган. Теле белән дә бик рәнҗетә икән. Кайчакларда, әшәке сүзләр белән сүгеп, кышкы суыкта ялан күлмәктән генә ишек алдына куып чыгара да сәгатьләр буенча өйгә кертми азаплый икән.

— Нигә рәнҗетә соң ул аны? — дип сорадым мин алардан.

— Кем белә аны,— диде Хәбирә апа.— Аныкын белмәссең, шундый кеше ул. Хәтта кайчакта ник кыйнаганын үзе дә белми торгандыр. Бик холыксыз бәндә. Бөтен нәрсә өчен рәнҗетә: гаебе булса да рәнҗетә, булмаса да рәнҗетә. Хәтта элегрәк аты чыгымлаган өчен дә хатынын кыйный дип көләләр иде аннан. Чыннан да, бер тапкыр шулай булган диләр.

— Аты чыгымлаган өчен кайсы хатынын кыйнаган? Фаизәнеме?

— Юк, аны түгел. Качып киткәнен.

— Фаизәне ул һаман шулай каты кыйныймы икән?

— Белмим,— диде Хәбирә апа.— Бәлки, Гата абзый белә торгандыр. Алар күршеләр диярлек. Араларында бер-ике йорт кына.

Гата абзый ачык җавап бирмәде:

— Кем белә аны,— дип, иңбашларын гына җыерып куйды.

— Бу юлы ник кыйнаган икән ул аны?

Хәбирә апа да, Гата абзый да белми икән, әйтә алмадылар.

Ләкин малайларның берсе, Кәлимнәр күршесе, белә торган булып чыкты. Фаизәне ул хатын-кызлар җыелышына барган өчен кыйный икән. Моннан бер-ике атна элек, шәһәрдән бер кыз килеп, хатын-кызлар җыелышын үткәргән. Иске Артышта бу беренче җыелыш булганга, бик кызыксынып, бөтен авыл хатын-кызы җыелган. Хәтта карчыклар да килгән.

— Нигә, җыелышка барырга ярамыймыни? — дидем мин.— Барса, ни булган?

— Ярый, нигә ярамасын! — диде Хәбирә апа.— Тик менә Кәлимгә генә никтер ярамаган.

Шуннан соң гына мин Кәлимнең: «Икенче бармассыңмы?! Икенче бармассыңмы?!.» — дип, сугенә-сугенә кыйнавының мәгънәсен аңладым. Димәк, җыелышка барган өчен кыйнаган. Шулай да моңа ышанасы килми иде, ничектер башыма сыймый иде бу. Моның башка зуррак сәбәбе юкмы икән?

Мин Кәлимнең кем икәнен белер өчен сорашуымда дәвам иттем:

— Нигә, Фаизә әллә иренә әйтмичә барганмы?

— Кәлим өйдә юк иде ул көнне,— диде карт.

— Кайда иде соң? — дип сорадым мин.

— Кайда иде? — дип, соравымны кайтарып әйтеп куйды Гата абзый. Аннары аңа үзе үк җавап бирде.— Аныкын белмәссең. Ул бүген өйдә, ә иртәгә җирнең теге читендә. Канавал ул. Нәсел-нәсәпләре белән канаваллар. Шуңа күрә күп вакыт өйдә тормый, чит авылларда йөри. Аннары алыш-биреш белән дә шөгыльләнә... Хәер, кешенекен белмәссең, караңгы. Теләсә нишләсен, гөнаһсына керәсем килми.

«Менә кем икән ул Кәлим!.. Менә кем икән!» — дип уйладым мин һәм күнелем бераз җиңеләеп китте. Бу эшкә дөрес катнашканмын икән. Моны болай гына калдырырга ярамый.

Без инде Хәйрулла абзыйлар капкасы төбенә килеп җиткән идек. Миңа ашыгырга, атны тизрәк алып кайтырга кирәк. Шуңа күрә мин Гата абзыйның авыл Советы председателе янына баруын, бу вакыйганы аңа тәфсилләп сөйләп бирүен үтендем.

Картым, бу сүзләрне ишеткәч, бераз кызарып, яшьләнеп торган күзләрен ешрак йомгалый башлады һәм ничектер боегып, мескенләнеп калды.

— Син инде, туганкай, бу эшне миңа кушма,— диде ул беркадәр ялварулы тавыш белән.— Мин карт кеше... Үзең барып әйт.

— Нигә кушмаска?! — дидем мин, аның киреләнүенә гаҗәпләнеп.— Кыйнаганын күрдең ич.

— Күрсәм ни...— диде ул һәм, мескен бүреген маңгаена шудырып төшереп, җилкәсен кашып алды.— Күрсәм ни... Башкалар да күрделәр... Аннары мин рәтләп сөйләп бирә дә алмам...

Картның барырга теләмәве күренеп тора иде, шулай да мин аны кыставымда дәвам иттем, чөнки үзем, никадәр теләсәм дә, хәзер бара алмый идем.

— Син, абзый кеше, киреләнеп маташма,— дидем мин аңа.— Бар да бөтенесен сөйләп бир. Вакытым сыйдырса, сиңа әйтеп тормас идем, үзем барыр идем. Ашыгам. Болай да аның аркасында әллә никадәр вакытым әрәм булды. Командирдан сүз булуы мөмкин.

Безнең белән капка төбенә хәтле килгән Хәбирә апа, кыстауның файдасы юклыгын төшенеп булса кирәк, сүземне бүлдерде:

— Син, энем, аның белән сөйләшеп, вакытыңны әрәм итмә,— диде ул миңа һәм Гата абзыйга тагын бер тапкыр мәсхәрәләп карап алды.— Гата абзый курка ул. Имеш, барып әйтсә-нитсә, Кәлим аны үтерәчәк. Зерә генә сакал йөртә ул. Аны кырып ташласа, яхшырак булыр иде, ир кеше икәнен белмәсләр иде... Үзем барам, энем, персидәтелне күрәм дә әйтәм. Арт сабагын укытсыннар әле бер. Хатын дигәч тә... Хатынны кыйнарга ярамаганны белсен, аңласын. Ә син, Гата абзый, бар, өеңә кайтып кит. Хәкимә апа көтә торгандыр сине...

Гата абзый сүзнең мондый юнәлеш алуын көтмәгән иде булса кирәк. Ул Хәбирә апага карап, нәрсәдер әйтергә чамаласа да, сүзен әйтә алмады, авызын ачкан хәлдә катып калды.

Хатынның сүзе бетмәгән икән әле.

— Алайса, шулай иттек,— диде ул эшлекле генә.— Кич белән килеп чыгам, дисең. Ялгышмасам, энем, син станциядән, отрядтан бугай?

Мин, шулай икәнлеген белдереп, башымны селкедем.

— Фамилияң ничек? Персидәтелгә кем дип әйтим?

Фамилиямне әйттем, анықын да сорадым.

— Гафият Хәбирәсе,— диде ул.— Шулай әйтсән, беләләр. Гафият бирәсе авылда мин генә.

Хәбирә апа, артына күн салган чуар итеге белән хатыннарча житез, ниел атлап, урам уртасыннан, ат юлы буйлап авылның икенче башына ба китте. Авыл Советы шул якта иде. Аның артыннан әлеге малайлар иярде. Алар да бу эшне ахырына кадәр житкерергә телиләр иде булса рәк. Гата абзый исә, чал кергән кыска кара сакалын тырнаштырга-п, бер урында бераз таптангалап басып торганнан соң, зәгыйфь гы белән һәрьюлы ниндидер күзгә күренми торган чокырга баскан ман, уң якка чума-чума, кулындагы таягын атлаган саен селтәп ибәреп, килгән юлы белән кире китеп барды.

Бераздан мин, атымны жигеп чыгып, аны кызулату өчен кулымдагы былыркы белән ара-тирә селтәнгәләп, станциягә таба юл алдым.

## IV

Кич белән, сәгать жиделәрдә, мин авыл Советында идем. Салам шлы, биш тәрәзәле, урта зурлыктагы өй. Маңгаеңны ишек өстенә рмәс өчен, башыңны иеп, бөгелеп керү белән үк борыныңа башта мәке исе, ачы салам исе, аннары ниндидер юеш, тынчу ис килеп бәре-. Жиллэтмиләр булса кирәк. Жиллэтсәләр, тәмәке исе бу кадәр кермәс, сакланмас иде. Мичкә дә аз ягалар, ахры. Тәрәзәләре ике тлы булуына карамастан, өске өлгеләренә кадәр бәсәргән, тенлә тыш-ы карагаңда өй эчендәге уңлы лампа яктысы саргылтсу булып, сизе-әр-сизелмәс кенә елтырый.

Өйнең жиһазы да бик ярлы. Түрдә өстенә бернәрсә дә җәелмәгән, ара түгелеп, пычранып беткән, кырыйлары тиктормас малайларның гкен пәкеләре белән киртләчләнгән, сырланган иске өстәл. Янында ике эындык. Икесе дә артсыз. Стена буйларында, мич янында озын эскә-мияләр. Түшәмгә асылган уңлы лампа. Бер герле, озын телле сәгать. йөнең жиһазы, бөтен байлыгы шуннан гыйбарәт.

Председатель утызга якынлашып барган, урта буйлы, таза гәүдәле, зенә килешеп торган жыйнак кара мыеклы, күрер күзгә сабыр таби-гатьле, Госман исемле өйләнмәгән кеше. Электә, яшь чагында, хәтта алай чагыннан ук диярлек, кулакларда батраклык иткән, авылдашла-ы белән бергә читкә чыгып, шахталарда, прискаларда эшләп йөргән, акыты житкәч, солдатка алынган, беренче империалистик сугышка атнашкан, яраланып, немецларга әсир төшкән. Терелеп, йөри башла-ач, андагы газапларга, җәберләүләргә түзә алмыйча, ике тапкыр ачкан. Берсендә тотып, төрмәгә япканнар, тагын да катырак газапла-аннар. Тик икенче качуында гына, бу юлы инде февраль революциясен-ән соң, үзебезнекеләр ягына чыга алган. Демобилизацияләр башлан-ач, авылга кайтып тормаган, яңа төзелеп килгән Кызыл Армиягә үзе еләп язылган. Үзган жәй Көнчыгыш фронтта, акларга каршы сугыш-ларда тагын яраланган.

Бераз хәл жыю, көч алу өчен, дөресрәге, яралары төзәлеп беткәнче ип, хәрби госпитальдән аны берничә айга авылга кайтарганнар. Бирел-ән мөмкинлектән файдаланып, бераз авылда торырмын, көч туплармын, уганнарымны, якыннарымны күрермен, әни карчыкка булышырмын, орт тирәсе дә инде бик искергән, жимерелгәндер, бурәнә, такта кебек ирсәләр табып булса, аны да бераз рәтләрмен дип, бик сагынып, зары-ып кайтып кергән Госман Вәлиев салам башлы жимерек өе тирәсендә, балта, пычкы кебек кораллар тотып, берничә көн актарына да, үзе дә сизмәстән, авылның җәмәгать эшенә башы-аягы белән чума, үз тирәсенә ярлыларны, сугыштан кайткан солдатларны туплап, кулакларга, алар-ның ниярченнәренә каршы көрәш башлап жибәрә. Әйт, шундый чакта,

синең туган авылында авыл советына кулаклар, куштаннар оялаган булса, алар төрле хәйләләр белән яшь Совет властен, синең каны түгелеп алынган властьны алдалап, аның политикасын күрәләтә бозып ятсалар, байгуралары төрле салымнардан, контрибуцияләрдән котка- рып килсәләр, авыл өстенә төшкән йөкләмәләрнең иң авыр өлешен, үзләренә түгел, ә урта хәлле крестьяннар җилкәсенә, хәтта кайбер очракларда ярлылар җилкәсенә дә салсалар, канлы сугыштан яраланып кайткан егетнең, большевикның йөрәге ничек түзсен, туган авылындагы мондый хәлләргә ничек риза булып торсын, көннәрен бары үзенең салам башлы куышы, туган-тумачалары тирәсендә генә ничек үткәрсен, наму- сы моны ничек күтәрсен!

Күптән түгел генә, без бу авылга килер алдыннан бер-ике атна элек, урта хәллеләр, ярлылар авыл советын яңадан сайларга кирәк табалар. Сайлыйлар. Сайлау зур талаш, кычкырыш, ызгыш белән үтә, хәтта кай- берәүләр, сүзгә килеп, якалашып, түбәләшеп тә алалар. Госманны үзе теләмәсә дә, кыстап, үтенеп, дөресрәге, көчләп диярлек авыл Советы председателе итеп сайлап куялар.

Госман Вәлиев хәзер шул йөкне тартып алып бара. Авыр йөк. Мона чаклы беркайчан да алып барырга, сөйрәргә туры килмәгән йөк.

Кайчакларда мин Госман Вәлиевкә читтән, беркадәр ерактан карап торырга яратам. Үзенә сиздерми генә ерактан күзәткәндә, кешеләр мина табигыйрак, ачыграк күренәләр. Мин аларның үзләренә генә хас харак- терларын, гадәтләрен, кыланышларын тотып алам, уңай якларны һәм кимчелекләрне тулырак күрәм.

Ул һәрвакыт диярлек солдатларча төз, пөхтә йөри. Дөресрәге, төз йөрергә ярата. Шулай да кайчакларда уң аягының яралы икәне, анысы белән бераз аксый төшүе, вакыт-вакыт уңайсыз, хәтта кыюсыз атлавы сизелә.

Кием-салымы тыйнак. Өстендә, гәрчә бераз туза төшкән булса да, гәүдәсенә ятып торган соры шинель, башында папахага охшатып тегел- гән, чак кына кыңгыр салынган ак куян бүрек, аягында өйдә баскан кара киез итек. Билен солдат каешы белән кысып буган. Сакал-мыегы пөхтәләп кырган. Шуны да әйтергә кирәк, авыл шартлары таләп итүгә карaганда, ул аны ешрак кыра шикелле. Мин әле аны бер тапкыр да сакал-мыек баскан, чәчләре тузган хәлдә күргәнем юк.

Авылның буй җиткән кызлары, аеруча яшьли тол калган солдатка- лар аңа кызыгып, сокланып карый торганнардыр дип уйлыйм. Кем белә, бәлки, алар, аның килешле итеп, бүреген бераз кыңгыр салып, матур, сылу гәүдәсен төз тотып, урамнан узып баруын күргәч, тәрәзә пәрдәсе артына посып, мәхәббәтле күз карашлары белән аны еракка кадәр оза- тып калалардыр һәм соңыннан, күңелләрендәге тынгысыз хисләрен баса алмыйча, тирән итеп, я өметсезләнеп көрсенәләрдер. Көрсенүләре бик мөмкин. Чөнки авылдашларының сөйләүләренә караганда, егет авылда бер кызга да күз төшерми, берәүнең дә мәхәббәтле карашын кабул итми, хәтта аларның күңелләрен җилкендерерлек шаярып та сөйләшми икән.

Кызлар, яшь киленчәкләр генә кызыгалармы икән аңа! Әгәр ялгыш- масам, авылдагы кайбер егетләр дә аңа кызыгып, сокланып карыйлар, аның шикелле булырга, үзләрен аның шикелле тотарга тырышалар.

Госман Вәлиевтә кешеләрне кызыктырырлык, аларга йогынты ясарлык менә шундый сыйфатлар бар. Яшермим, кайчакларда мин дә аңа кызыгып караштыргалап алам. Барыннан да бигрәк, мин аның тынычлыгына, сабырлыгына, бер эшне дә уйламыйча эшләмәвенә сок- ланам. Аңа тормыш итүе, гомер юлы буйлап баруы ансаттыр, күңелен- дә әрнүле, борчулы хисләр юктыр,— булса да, ул аларны җинә, үз ихтыярына буйсындыра ала торгандыр дип уйлыйм. Миңа ул шулай тоела.

Мин авыл Советына барып кергәндә, анда Госман Вәлиевтән башка ерәү дә юк иде. Ул өстен-башын салмаган килеш, өстәл янында, бераз эремләнеп янып торган унлы лампа яктысында, алдында яткан нинди-ер саргылт кәгазьне укып утыра иде. Ул миңа салкын гына кулын узды, күреште, утырырга урын күрсәтте.

— Хәзер. Бераз утырып тор,— диде.

Мин винтовкамны яныма сөядем дә стена буендагы эскәмиягә утыр-ым. Госман күзләрен яңадан әлеге кәгазьгә текәде. Бу кәгазь соңгы акытларда авыл советларына төрле җирләрдән килгәләп торган, рттырыбрак әйтсәк, язгы ябалак кардай коелып торган хитапнамәләр-ен, рәсми циркулярларның берсе булса кирәк. Кәгазь юклыктан, күрә-ең, хәзер хитапнамәләр, өндәмәләр, газеталар — барысы да тотсаң ртылырга, уалырга торган шундый сары кәгазьгә басылалар.

Мин аның нинди язу икәнен сорашып тормадым, укып бетерүен ыныч кына көтәргә булдым. Берничә минут вакыт узды, стенага элен-эн, бер герле һәм аңа булышчы итеп тагылган сынык дагалы сәгатьнең ур стрелкасы, талпына-талпына, бер урыннан икенче урынга күчүендә, йләнә-тирәли сәяхәтендә дәвам итте. Инде кәгазьне укып бетерергә ирәк иде... Игътибар беләнрәк карасам, Госман алдындагы кәгазьне кымый, ә бары, аңа күзләрен текәп, укыгандай булып, нәрсә турында-ыр уйланып утыра. Нәрсә булган аңа? Йөзе нигә бу кадәр уйчан? Кашлары җыерылган, күзләре моңсу, хәтта әрнүле диярлек, яңаклары а бераз агарып, нурсызланып калган. Авыраймы икән әллә? Төзәлеп китмәгән яралары кузгалганмы яисә эшендә берәр күңелсезлек бармы, шуңа борчылып, пошынып утырамы?

Аны беркайчан да мондый күңелсез, кашлары җыерылган, йөзе улган хәлдә күргәнем юк иде. Шуңа гаҗәпләнеп, эндәшергә кыймыйча, бераз тын утырдым. Ахырда түзмәдем, сорадым:

— Кәефең юкмы әллә? Бик күңелсез утырасың.

Ул мине хәзер генә күргәндәй күтәрелеп карады, кулындагы кәгазен бер читкә куйды, кәефенең начар түгеллеген белдереп, башын чайкады:

— Зарланырлык нәрсә юк.

«Нәрсәдер бар, яшерә, әйтергә теләми. Авырый торгандыр»,— дип уйладым мин һәм аны өстәмә сораулар белән борчымаска булдым, бу салкын кичтә мине монда, авылга килергә мәҗбүр иткән мәсьәләгә күчтем:

— Кәлимне чакырттыңмы?

— Юк.

— Әллә сиңа бүген иртә белән Гафият Хәбирәсе бернәрсә дә әйт-мәдеме?

Госман, җавап бирергә ашыкмыйча, бераз уйланып торды, бармак-лары белән өстәлне җиңелчә шакылдатып алды.

— Әйтүен әйтте дә, шулай да чакыртырга кирәк тапмадым.

— Ник? — дидем мин, сәбәбен белергә теләп.

— Безнең эшме икән соң ул?

Дөресен әйтим, аңардан мин мондый сүзне көтмәгән идем. Ул, председатель булып күптән түгел генә эшли башлавына карамастан, мондый җаваплы эшләрне авыл Советында карарга, тикшерергә кирәк-леген белә торгандыр дип уйлый идем. Шуңа күрә, ирексездән:

— Ә кем эше соң? — дип сорарга мәҗбүр булдым.

Җавап бирмәде. Җавабы юк иде шикелле.

— Кем эше соң? — дип, соравымны кабатлап, мин өстәл янына, аңа габарак күчеп утырдым.— Сезнең эш ул, Госман. Авыл советы эше.

— Авыл советы эше?

— Ә син кемнеке дип уйлаган идең?

— Безнең аннан башка да эшебез бик күп. Муеннан,— диде ул һәм.

миңа аңлаешлырак булсын өчен, кулы белән муенын аркылы сызып күрсәтте: — Менә моннан. Әле тегесе, әле бусы...

Госман белән мин күптән түгел генә, отрядыбыз бу станциягә күчеп килгәч, мине кайбер эшләрне үтәр өчен Иске Артышка билгеләгәннән соң гына таныштым. Шул көннән башлап миңа аның белән беренче тапкыр очрашырга, өстемә йөкләнгән эшләр турында сөйләшергә, артык ашлыкларны дәүләткә тапшырырга тиешле кешеләрнең исемлекләрен тикшерергә һәм бу эшне тизрәк тәмамлау өчен авыл советы белән бергә кайбер чаралар күрергә туры килгәләгәне бар. Шундый очрашулардан соң ул минем күңелдә уңай характерлы кеше тәэсирен калдырган һәм мин аның турында яхшы фикердә идем. Моңа кадәр әле аның мондый тискәрелеген очратканым юк иде. «Кара әле, аның тәртәгә тибә торган гадәте дә бар икән»,— дип уйладым мин һәм аның бу гадәтен моңача күрми, сизми йөрүемә беркадәр гаҗәпләндем. Шуңа күрә мин аның белән, билгеле, аны дөрес, туры юлга бастыру теләгеннән чыгып, җитдирәк сөйләшергә кирәк таптым.

— Эшегез аз түгел. Хәтта бик күп. Шулай да, иптәш Вәлиев,— дидем мин аңа, рәсмирәк булсын өчен фамилиясе белән эндәшеп,— үпкәләмә, авыл Советы эшләрен син бераз таррак итеп күз алдына китермисеңме икән? Әллә син аның эше ашлык җыю, аны дәүләткә тапшыру, авылдагы терлекләрнең санын исәпкә алу, янгын-фәлән чыкмасын дип, җимерек мичләрне, ишелеп барган морҗаларны тикшереп йөрү һәм башка шуның кебекләр белән генә чикләнә дип беләсеңме? Юк, аның белән генә чикләнми ул. Авыл советы кешеләр белән, ягъни алар арасында да эшләргә тиеш. Мин шулай уйлыйм. Бәлки, белеп тә бетерми торганмын, шулай да мин Совет властеның нинди власть икәнен, аның тоткан политикасын халыкка аңлатып бирү, аның законнарын төшендерү эшләре авыл Советының төп вазифаларыннан берсе, хәтта иң мөһиме итеп саныйм. Шулай ук авылда революцион тәртип саклау да аның эше...

Ул, сүземне бүлеп, сүрән генә елмаеп:

— Ир белән хатын арасына керүне дә син революцион тәртипне саклау дип саныйсыңмы? — дип сорады.

Мин аңа, шуны да белмисеңме әле син дигән шикеллерәк итеп, үзе кебек елмаеп карап алдым да:

— Әйе, кайбер очракларда мин аны да шулай саныйм,— дидем.— Пролетариат революциясе кешелек тарихында беренче тапкыр хатын-кызларны ирләр белән тигез хокуклы итте. Аларга тулы хокук бирде. Син ничек уйлыйсың, хатын-кызларның Совет власте тарафыннан бирелгән хокукын без якларга тиешме, юкмы?

— Якларга тиеш, билгеле.

— Берәү хатын-кызларны рәнҗетсә, аларны кешегә санамаса, хурласа, ачыграк итеп әйткәндә, хатынын ерткычларча кыйнаса, җәберләсә, син ничек уйлыйсың, шуның белән ул Совет власте тарафыннан бирелгән бу хокукны бозамы, юкмы?

Госман җавапны көттермәде, сүземнең дөрес икәнен белдереп, башын селкеде дә:

— Әйе, боза,— дип авыз эченнән генә әйтеп куйды.

Мин сөйләвемдә, аңа каршы юнәлдерелгән фикеремне куәтләүдә, җәелдерүдә дәвам иттем:

— Шулай булгач, мин синең позицияне аңлап бетермим, — дидем.— Син телең белән берне әйтәсең: хатын-кызларның Совет власте тарафыннан бирелгән хокукларын якларга кирәк, дисең, ә үзең, бу эшне тормышка ашырырга туры килгәндә, аннан баш тартасың, Кәлим эшен тикшерергә теләмисең. Моны ничек аңларга? Ничектер, бик сәер килеп чыга түгелме соң? Бәлки, син бу мәсьәләнең политик ягын, аның тәрбияви әһәмиятен төшенеп бетерми торгансыңдыр? Син болай туры әйткәнгә

пкаләмә, Вәлиев иптәш. Мин моны үзем өчен әйтмим. Гомуми эшебез чен, Совет власте законнарын гамәлгә кертү, ныгыту өчен, крестьянарны большевиклар байрагы астына тагын да ныграк туплау өчен йтәм. Аннары мин тагын бер нәрсәне әйтергә тиеш. Кәлимнең, ул жирштнең, Совет власте турындагы пычрак сүзләрен мин болай гына калырырга теләмим. Әгәр мин аны шулай гына калдырсам, ул тагын да абахәтләнә төшәчәк,— дидем мин һәм, бу юлы инде ни әйтер икән дип, ның җавабын көтеп калдым.

Ул, уң кулы белән иягенә таянган килеш, күзләрен әлеге сары агазьгә янадан текәп, мин сөйләгәнне тыңлап, уйланып утыра иде. үземнең тәмамлануын һәм аңардан җавап көтүемне төшенеп, ул орчулы, моңсу күзләре белән миңа күтәрелеп карады:

— Мин боларның барысын да беләм, иптәш Шакиров,— диде. Мин ны әле генә фамилиясе белән эндәшкәнгә булса кирәк, ул да миңа амилиям белән эндәште, югыйсә, ул минем белән авылдагыча гади теп, исемемне әйтеп кенә сөйләшә иде.— «Безнең эшме икән соң ул?» игән сүземне мин кире алырга да әзер. Әйтергә теләгән фикеремне иешенчә аңлатып бирә алмадым, күрәсең. Менә нәрсә, дускай, торышта кайчак шундый хәлләр була: бөтенесенә дә тыгылып бетә лмыйсың. Я алай, я болай дигәндәй, мөмкин булмаган чаклар килеп ыга. Бу очракта да шуның кебегрәк: бу юлы аны чакыртмый калу өрес булмасмы икән, дим. Хатын белән ир арасына кереп, эшне тагын а начарлата төшмәбезме? Мин шулай уйлыйм. Бик кабахәт нәрсә ул әлим. Ачу итеп, хатынын тагын да катырак кыйнап, гариплэп ташлаасмы икән?

Аның дәлилендә бераз хаклык булса да, чыннан да, шулай булуы өмкин бит дип, күңелемдә шик туса да, фикере белән килешә алмадым, үзен бүлдем:

— Димәк, тагын кыйнар дип куркып, шулай гына калдырырга кирәк абасың?

Ул, соравымны раслап, башын иде:

— Әйе.

— Әгәр чакыртмасагыз, аңа бер сүз дә әйтмәсәгез, моннан соң ул Фаизәне кыйнамас, рәнҗетмәс дип уйлыйсыңмы?

— Ихтимал, кыйнамас дип уйлым. Гәрчә...

Мин аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәдем, чөнки бу мәсьәләдәге айгак позициясе ошамый иде миңа.

— Тагын да кыйнамаслыгына ышанычың бармы соң? — дип сораым мин аңардан.

— Ышанычым юк. Шулай да, бу мәсьәләне куертмасак, бәлки, без Фаизәне яңа газаплардан коткарып калырбыз дип уйлыйм.

— Ярый, шулай уйла. Анысы синең эш. Ләкин син моның икенче агын уйладыңмы?

— Нинди ягын? — диде ул һәм җавап көтеп миңа текәлде.

— Әгәр сез, ягъни авыл Советы, аны чакыртмыйча, аның бу кабаәтлеге турында бер сүз дә әйтмичә, авыз йомып каласыз икән, ул моннан үзенчә нәтиҗә чыгармасмы? Мине барыбер бернәрсә эшләтә алмыйлар дип уйлап, тагын да явызлана, ерткычлана төшмәсме? Менә шул ягын уйладыңмы син? Кәлимнең нинди кеше икәнен белмим мин, ләкин ул миндә бик начар тәэсир калдырды. Хатынын кыйнавы өчен генә түгел, Совет властена каршы әйткән эшәке сүзләре өчен дә мин аны, авыл Советына чакыртып, бик каты кыздырыр идем. Хәтта япты-рып торуны да яклар идем. Аңа арт сабагын укытырга кирәк, телен дә, кулын да тыйсын. Ничек уйлыйсың?

Госман җавап бирмәде. Аның нишләргә белмәве, күңеленнән бу мәсьәләне хәл итеп бетермәве, ачык бер карарга килмәве сизелеп тора иде.

Хәбирә апа барысын да сөйләмәгәндер дип уйлап, мин аңа үз күзем белән күргән кадәресен бик тәфсилләп сөйләп бирдем.

Госман моны күңеленә шулкадәр авыр алыр дип көтмәгән идем. Мин сөйләгәндә ул бер агарды, бер күгәрде. Кайбер мизгелләрдә аның калтыранып, сискәнеп китүе, йөзен әрнүле чытуы, шул ук вакытта үзен тотарга, кулга алырга, эчке кичерешләрен сиздермәскә тырышуы сүрән лампа яктысында да күренеп тора иде. Ул кулларын йодрыклаган, тешләрен кыскан. Кай минутларда күзләрен тутырып ачып, бик гаҗәпләнеп миңа карап ала, ә кай минутларда, тынып, күзләрен каядыр, билгесез ноктага теки. «Юк, аның әрнүе авыруыннан гына түгел»,— дип уйладым мин. Нәрсәдер бар. Ләкин нәрсә икәнен белә алмый идем.

— Менә шундый хәл булды,— дидем мин, сүземне тәмамлап,— Әллә Хәбирә апа сиңа барысын да сөйләмәгән идеме?

— Сөйләвен сөйләде дә... тик бу кадәр тәфсилле итеп түгел.

— Я, нишлисең, чакырырга, тикшерергә кирәк табасыңмы? Әллә, үзең әйтмешли, шулай гына калдырасыңмы?

Ул бармаклары белән өстәлне тагын барабанлап алды, җавап бирергә ашыкмады.

— Нигә бер сүз дә әйтмисең? — дидем мин аңа, түземсезләнеп.

— Шулай да бераз уйлашып, киңәшеп карыйк әле,— диде ул күңелсез генә.

Мин, аның икеләнүен күреп һәм бу икеләнүнең сәбәбен табарга тырышып:

— Нигә, Кәлим әллә якын туганыңмы? — дип сорадым.— Әллә аны халык алдында хур итәсең килмиме?

Госман ирен кырыйлары белән генә елмайды. Бу аның мине хурлап, мыскыллап елмаюы түгел, ә ниндидер эчке әрнүе иде.

— Әйе, «туганым»,— диде ул.— Әниләребез бер кояшта киндер киптергәннәр. Менә шундый туган ул миңа. Әгәр ул туганым булса, мин аннан ваз кичәр идем, бусагамнан да атлатмас идем аны. Белсәң иде, ул «туганым»ның муенын мин шундый борыр идем.— Һәм ул көтмәгәндә йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты.— Шундый борыр идем, гомергә кәкрәеп калыр иде ул. Изеп ташлар идем мин аны.

Аның көтмәгәндә ачуланып, нервланып кызып китүе, йодрыгы белән өстәлгә шапылдатып сугуы мине шактый гаҗәпләндерде, хәтта аптырашта калдырды, чөнки аны мондый хәлдә беркайчан да күргәнем юк иде. Хәзер инде мин аны тынычландырырга мәҗбүр булдым.

— Изеп ташлауның кирәге юк,— дидем мин аңа.— Шулай да закон кушканча тикшерергә, аны акылга утыртырга, тәртипкә чакырырга кирәк.

— Сүзең дөрес, килешәм. Тикшерергә дигән фикерең белән дә риза. Чыннан да, тикшерергә, хулиганлыгы турында каты итеп әйтергә кирәк. Тик шулай да бу эшкә үзем катнаша алмыйм... Аңла, катнаша алмыйм.

Сәбәбен белергә теләп, беркадәр уйлап җиткермичәрәк сорадым. Дөресе, кирәксез сүзнең авызымнан атылып чыгуын үзем дә сизми калдым.

— Әллә син дә Кәлимнән куркасыңмы? — дидем.— Шуңа катнашасың килмиме?

Бу сүзләрем белән аның ирлек горурлыгына тукындым, ахры. Ул кинәт үзгәреп китте, миңа күзләрен ачулы ялтыратып карап алды, аннары, үзен тотарга, салкын канлылыгын сакларга тырышып, ашыкмый гына җавап бирде:

— Менә нәрсә, Зариф энем, моңа чаклы әле мине куркаклыкта берәүнең дә гаепләгәне юк иде. Гаепләрлек сәбәп тә булмагандыр дип уйлыйм... Кәлимнән курыкмыйм мин. Тузан кадәр дә курыкмыйм. Ләкин син шуны аңла: бу эшкә тыгыласым килми минем. Күңелем тартмый

Мин, гаҗәпләнеп, күзенә туп-туры карап, аның әле генә әйткән сүзен ıбатладым.

— Күнелем тартмый?.. Дөньяда күңел тартмаган эшләр күп. Хәтта ık күп! Шулай да син аны эшләргә мәҗбүр буласың. Дөресе, эшләргә ɪрәк табасың. Сиңа моны вөҗданың куша, гаделлек куша. Әгәр бик 'р сүз дип әйтмәсәң, революция куша. Күңеленне җиңәсең, эшлисең. энки аны эшләү — гомуми эшебез өчен кирәк.

— Боларның барысын да аңлыйм, фикереңә дә кушылам, әмма 'улай да...— диде Госман һәм, тукталып, бераз уйланып торды, мине ıпандырырлык сүзләр эзләде булса кирәк. Ләкин ул андый сүзләрне бә алмады, бары моңача әйткәнен генә кабатлады: — Шулай да бу ɪикә катнаша алмыйм.

— Сәбәбе? — дидем мин.

— Катнашып, эшне бозармын дип куркам.

— Аңламыйм. Ничек инде ул?

— Әйдә, ничек икәнен сорама. Аның кирәге юк сиңа.

«Госман белән Кәлим арасында нәрсәдер бар»,— дип уйладым мин 'нелемнән һәм аны белергә никадәр теләсәм дә, сорарга батырчылык -мәдем. Чөнки ул барыбер әйтмәс иде.

Ниһаять, бер фикергә килдек: бу эшне тикшерер өчен авыл советы ɪында өч кешедән комиссия төзергә булдык. Аңа, әгәр каршы килмәсә, ɪтын-кызлардан Хәбирә апаны кертергә кирәк таптык. Ул миндә генә 'гел, Госманда да яхшы тәэсир калдырган икән.

Без, бер-ике көннән очрашырга булып, урыннарыбыздан тордык. интовкамны алып, иңемә элдем. Урамга чыктык.

Госман өенә кайтып китте, мин станциягә таба борылдым.

Төн караңгы, җылы иде. Җәяүле буран күтәрелергә тора. Күк йөзен- ı бер генә йолдыз да юк. Тик җирдә, ярым кар баскан өйләрнең кай- ɪрләрендә генә, тычкан күзләредәй елтырап, саргылт утлар җемелди. лар да сүнәргә, бетәргә торган сыман калтыраналар, күңелгә сагыш ɪм моңсулык салалар.

Болай да күңелем тынычсыз, борчулы. Госманның, авыл советы ɪедседателенең, алай гына да түгел, коммунистның бу эшне тикшерүгә ɪрыдан-туры катнашырга теләмәве, аны икенче берәүләргә йөкләве, 'улай итеп, бу политик мәсьәләгә тиешенчә әһәмият бирмәве, баштарак сә, хәтта аны шулай гына калдырырга, аның белән бөтенләй шөгыль- ɪнмәскә маташуы мине бик гаҗәпләндерә һәм борчый. Күңелемдә ник?» дигән сорау тора. Аңа җавап таба алмыйм.

## V

Мин, Хәбирә апаны очратып, аңа ничек тә Фаизәне күрергә, хәлен елешергә, сөйләшергә киңәш иткән идем. Күрдеме икән, юкмы икән дип ɪзыксынып, Иске Артышка баргач, аңа сугылып чыгарга булдым.

Тышкы яктан караганда аның өе авылдагы башка өйләрдән бер- әрсә белән дә аерылып тормый кебек. Моңсу тәрәзәләре урамга кара- ан, салам башлы, урта зурлыктагы гадәттәге өй. Ләкин аның ишеген чып, бусагасын атлап керү белән үк бу өйнең авылдагы башка өйләр- ән шактый аерылып торуы монда гадәттәге чисталыкны, пөхтәлекне енә түгел, шуның белән бергә матурлыкны, нәфислекне дә яратучы еше яшәгәнлеген сизәсең.

Зур ак мич белән бүленгән почмакта, авылдагы һәр йорттагыча, ыгысыз бәрәннәр белән бозау булуга карамастан, өй эче пөхтә, чиста. әттә аннан гадәттәге терлек исе дә ул кадәр килми. Идәне бик тыры- ып, пычак белән кырып юылган, сап-сары булып, гәрәбәдәй ялтырап ора.

Тәрәзә өсләренә, аның ян-якларына зур кижеле сөлгеләр эленгән, аларның күпертеп тукылган башлары мул булып сәке такталарына салынып торалар. Түрдә, стенаның буш урыннарында төрле зурлыктагы чигешле җаймәләр.

Бу өйгә беренче тапкыр аяк баскан кеше тәрәзәләрне урап торган зур-зур сөлгеләргә, стенадагы җаймәләргә, чигешләргә, аларның ал, кызыл, яшел, зәңгәр һәм башка шуның кебек төсләрдән гыйбарәт нәкышләренә игътибар итмичә калмый торгандыр дип уйлыйм. Бу чигешләрдә, кеше күнелен җәлеп итеп, аны бер мизгелгә тынып калырга, уйланырга мәҗбүр итә, сокландыра торган нәрсәдер бар. Нәрсә бу? Чигешләрнең матурлыгымы, нәфислегеме, әллә аларның моңача минм очратырга туры килмәгән яңалыгымы, әллә инде озак еллар сугышларда йөреп, каннан, дәһшәттән, мәҗбүри тупас мөнәсәбәтләрдән башка бернәрсә дә күрмәгән, күнеле шактый каткан, кырысланган кешенең матурлыкка, нәфислеккә сусавымы? Шул сусау, тансыгу тормышыбыздагы гади чигешләрне, күп мәртәбәләр күргән, бала чактан ук күнегелгән нәкышләрне дә бизәп, матурлап күрсәтәме? Ничек кенә булмасын, өй эченә атлап кереп, аның стеналарына, тәрәзә өсләренә күз төшерү белән үк бу чигешләр, нәкышләр күңелемне биләделәр.

Барыннан да бигрәк, игътибарымны түрдәге бер чигеш җәлеп итте. Кардай ак тукыма өстенә каяндыр, югарыдан төрле төстәге вак чәчәкләр — күпертеп чигелгән ал, кызыл, яшел, сары чәчәкләр коела. Алар күп. Алар инде җаймә уртасына шактый җыелган, бераз калкып, өелеп торалар, шулай да әле коелу дәвам итә.

Син беләсең, болар кеше кулы белән чигелгән, тынып калган, беркайчан да урыннарыннан кузгалмаячак чәчәкләр. Ләкин алар синә җанлы булып, тере булып, әле хәзер генә гөлләрдән сибелгән нәфис чәчәкләр булып тоелалар. Менә кинәт җил чыгар да, алар, бөтерелеп, һавага күтәрелерләр, бөтен өй эчен тутырырлар кебек...

Бу хатынның кул эше остасы икәнен ишеткән булсам да, аны бу дәрәҗәдә остадыр дип уйламаган идем.

Хәбирә апа мине түргә чакырды, артсыз урындык бирде. Минем әле һаман сөлге-җаймәләрдән күземне алмавымны күреп, сәерсенепме, әллә әдәп саклап, сүз юктан сүз булсын дипме әйтеп куйды:

— Нәрсәсе бардыр аларның. Кайберәүләр шулай кызыксынып карап торалар. Үзем бер дә карарлык нәрсә тапмыйм.

— Кем эшләре соң болар? — дип сорадым мин аңардан.

— Кайберләре үземнеке, кайберләре кызымныкы.

Мин аның кулларына карадым. Куллары мондый нечкә, нәфис эшләрне эшләрлек түгел кебек. Авыр эш эшләп ярылган, тупасланган куллар. Аннары Хәбирә апа мондый нечкә эшләрне башкарырлык яшьтә түгел. Кырыктан узган хатын. Күз төпләре, ияк тирәләре җыерчыкланa төшкән, чәчендә дә әллә ни күп булмаса да, ак бөртекләр бар. Ул бөртекләр, аның җыйнак итеп бәйләгән француз яулыгы читеннән җемелдәп күренеп торалар, аңа өлкәнлек, җитдилек бирәләр.

Хәбирә апа әллә карашымны сизде, әллә болай гына кулларына карап алды һәм беркадәр сагышлы тавыш белән:

— Күптән тукыганым, чиккәнем юк инде,— диде, үзенең тукый, чигә алмавына борчыла иде булса кирәк.— Еллары андый түгел. Дөнья мәшәкатьләре күп. Хәзер кызымны өйрәтәм. Утырсын, өйрәнсен. Һөнәрле кеше хур булмас. Нәрсә әйтсәң дә, һөнәр ипигә-тозга ярап куя.

— Әллә кешегә чигәсезме?

— Гомер буе кешегә чигеп, кешегә тукып яшәдем... Кайберәүләр әйтәләр: кырыктан узгач, нигә күзләреңне бетереп азапланасың, ташла, диләр. Ә минем ташлыйсы килми. Яратам мин бу эшне. Берәр әйбер чиксәм, киндергәме, пылатнагамы кечкенә генә чәчәк төшерсәм, күңелем рәхәтләнеп, күтәрелеп китә. Берничә көн шатланып, яшәреп йө-

им,— диде ул һәм оялчан гына елмайды.— Чыннан әйтәм: тиле сыман атланып йөрим. Һич ялган түгел... Аннары, шуның өстенә, йортны лып барырлык килере дә бар.

— Хәзер ничек соң, китерүчеләр бармы?

— Сирәк шул,— диде хатын.— Китерсәләр, рәхәтләнеп эшләр идем, игәр идем. Заманы нинди бит аның: чигәм дисәң, тамбур җебе, гары-ы, ефәге, тегесе-бусы юк... Әллә кая китеп бетте... Хәзер менә шуларга арап торырга гына калды,— диде ул һәм кулы белән чигешләргә үрсәтте.— Мин аларны һәрвакыт элеп тормыйм. Бәйрәмнәрдә эләм ә, аннары күңелем моңсу чакларда эләм. Шуларны чыгарып элгәч, ичектер, күңелем рәхәтләнеп, күтәрелеп китә, иркенләп сулап җибәрәм, агышларым тарала. Аннары бит аларның, Зариф энем, син белмисен, әркайсының үзенә күрә хатирәсе бар. Шунысы да күңелне әхәтләндерә.

— Хатирәсе бар? — дип кайтарып сорадым мин, кызыксынып. Кыз-арның, сөйгән егетләренә багышлап, аларга бүләк итү өчен кулъяу-ыгы, тәмәке янчыклары кебек нәрсәләр чигүләрен белә идем мин. мма кырыктан узган хатынның, ике бала әнисенең, кемнәргәдер агышлап, нәрсәгәдер хатирә итеп чигүе мине бераз гаҗәпләндерде. оңыннан, ул хатирәләрнең нинди икәнлекләрен белгәннән соң, яшер-им, миңа бераз кызарырга туры килде. Чөнки аның хатирәләре, мин йлаганга караганда, күп мәртәбәләр әһәмиятлерәк, мәгънәлерәк бу-ып чыктылар. Бу хатирәләргә карап, аның кул эшләре белән генә үгел, бәлки аның яшьлек еллары, мәхәббәте, гаилә тарихы, хәтта шат-ыгы, кайгысы белән дә танышырга була икән.

— Менә,— диде ул, түр тәрәзә янагына эленгән зур киҗеле сөлгегә үрсәтеп,— моны мин туебыз истәлеге итеп суккан идем. Күрәсеңме, ер башына «Гафият» дип, икенче башына «Хәбирә» дип чигелгән. лы да куелган.— Тавышы, ниндидер бик кирәкле, әһәмиятле, бер ылы өзелгәндәй, моңсуланып, сагышланып китте. Бу минутта аның арасу күзләре моңайган, тәэсирләнгән, җил, буран белән киселгән наклары бераз алсуланган иде.

«Ирен бик юксына, шуңа моңая»,— дип уйладым мин.

Мин сөлгенең бер очын кулыма алдым, чәчәк төсле итеп бизәп чи-елгән исемнәргә карадым. Матур чигеш. Юк, исем чигешләре генә үгел, сөлгесе дә зур, матур, сокландыргыч. Башларына яшел, кызыл, ары җепләр белән күпертеп, милли орнаментлар төшерелгән. Яшь ызларның оста куллары белән сугылган мондый матур, зур сөлгеләр-е сабан туйларында, кемнеке, нинди чибәрнеке икәнен кычкырып йтеп, тантаналы рәвештә һавада болгый-болгый, халыкка күрсәтәләр, актыйлар, аннары колганың иң югары очына бәйләп, мәйдан уртасы-а күтәрәләр, соңыннан, бәйгедә беренче булып килгән чаптарның үенына асалар яисә көрәшләрдә батыр калган егетнең кулына тотты-алар. Мондый сөлгеләрнең даны чапкын атның яисә батыр егетнең аны белән бергә бөтен тирә-якка тарала, аны киләсе сабан туйларына аклы искә төшереп, мактап сөйлиләр.

Сәкедәге ястык өстенә пәхтә генә ябылып куелган, уртасына чәчәк тып торган алмагач сурәте, ә кырыйларына бер-берләре белән үрелеп скән чәчәкләр төшерелгән япманы улы тугач, аның хатирәсе итеп чик-ән икән.

— Хәзер улыгыз кайда? Сугыштамы?

— Авылда. Яшь әле ул.

— Ничәдә?

— Унҗиде тулды гына. Әллә белмисеңме? Сезнең янга еш бара бит л. Әхтәм исемле.

— Теге, шинельдән, шлемнан йөрүче малаймы әллә?

Хәбирә апа, бераз елмаеп, башын селкеп куйды. Бу аның: «Шул малай инде, шул»,— дигән сүзе иде.

Ул малайны беләм мин. Ошый ул миңа. Миңа гына түгел, барыбызга да ошый.

Мин, аны мактап, бер-ике җылы сүз әйтеп алдым. Мактавым анага ошады булса кирәк, күзләре ялтырап, җанланып китте, тавышындагы сагыш та югала төште.

Хәбирә апа тагын бер япма күрсәтте. Анысы кызының тууына багышланган икән.

Инде, барыннан да бигрәк, түрдәге әлеге чәчәкләр төшерелгән җәймә кызыксындыра иде мине. Аны кемгә багышлаган икән? Нигә ул чәчәкләренең җиңеллеге, өрдеңк исә, очып күтәрелеп китәргә әзер торуы, төсләренең күплеге, җанлылыгы белән башкалардан аерылып тора? Чигүченең бай фантазиясен, кайнар хисен, җанын, рәссамлык талантын исбатлаучы бу җәймә дә Хәбирә апаныкымы, аның бармаклары белән чигелгәнме, әллә бу ярлы өйгә ул, каян булса да читтән кереп, аны шулай нурландырып, матурлап торамы?

Анысы кызының иҗаты икән, ул чиккән икән аны. Бу япманың да берәр хатирәсе, багышлануы бардыр дип уйлап, бу турыда Хәбирә ападан сорамыйча булдыра алмадым. Хәбирә апаның күзләре хәйләле, серле кысыла төште, ирен тирәләре дә бераз җыерылып, калтыранып китте. Эчке елмаюын яшерә алмый иде ул.

— Кем белә аны,— диде ул, серле итеп.— Булуы мөмкин. Егерме белән бара инде. Кыз күңелендә нилəр ятмас...

Төпченеп сорашып тормадым, күз явын алырлык бу чәчәкләрнең мәхәббәткә багышлануы болай да сизелеп тора иде. Чыннан да кыз күңелендә ниләр генә ятмас!

Кул эшләрен карап бетергәннән соң, сүзебез мине монда алып килгән мәсьәләгә күчте.

## VI

Хәбирә апа, юк йомышын бар итеп, Кәлимнәргә ике тапкыр барган, ләкин Фаизә белән сөйләшә алмаган. Кәлимнең әнисе Хәтимә тәтәй, нәрсәдер сизенеп, аларны бер минутка да үзләрен генә калдырмаган. Шулай да Хәбирә апа хәйләсен тапкан, карчык йомыш белән почмакка кереп киткән арада Фаизәнең колагына пышылдап өлгергән:

— Җанкисәгем, я бүген, я иртәгә ничек тә минем янга кереп чык, бик кирәкле сүзем бар,— дигән.

Фаизә озак көттермәгән, иртәгесен йомыш белән каядыр барганда Хәбирә апа янына берничә минутка гына кереп чыккан һәм шунда, аның күкрәгенә ятып үкси-үкси, үзенең хәлен сөйләгән. Хәбирә апа миңа шуларны, берсен дә калдырмыйча, бик тәфсилләп сөйләп бирде:

— Алар бергә тора алмаслар, ахры,— диде ул.— Бер көннән соң Кәлим аны тагын кыйнаган. Тәнен ачып күрсәтте. Кара янмаган җире юк. Исем-акылым китте. Я алла, ерткыч та булыр икән! Җитмәсә тагы: «Синең тирәдә Бака шайтан белән теге ертык шинель нигә искәнеп йөриләр?» дип кыйный икән. Бака дигәне Госман була инде. Кушаматлары шулай аларның.

— Ә ертык шинель дигәне?

Хәбирә апа уңайсызланып кына:

— Анысы син буласың инде, Зариф энем,— диде һәм күңелле генә көлеп җибәрде:— Баядан бирле карап торам, шинелең бер дә ертык түгел ләбаса. Бик әйбәт шинель. Тик җиң тирәләре генә бераз туза төшкән. Хәер, җылы булса, андый кимчелеге берни түгел.

Мин дә, Хәбирә апа белән бергә көлемсерәп, шинелемне күздән кичердем. Шинелемнән зарланмыйм. Эш шинельдә түгел, бәлки аны кемнең һәм нинди максат белән киюендә. Мин бөтен дөнья алдында

рурланып әйтә алам: бу шинельләрне без,— ертыкмы алар, түгел- :,— ин бөек максатлар өчен киеп йөрибез, шул максатларыбызга өешми торып, аны салачак түгелбез!

Хәбирә апа сөйләвендә дәвам итте:

— «Әллә аларның дөньяда торасылары килмиме?» дип, бик каты генә, икегезне дә хурлый, эттән алып этка сала икән. Фаизә бик рка, кыйнап, гарип итеп калдырмаса, ярар иде, ди. Ялына: ташла- з, зинһар, котыртмагыз шул этне, ди. Госманга әйт, Хәбирә җанкисә- м, ди, безнең арага керә күрмәсен, ни буласын белә бит ул, ди. Күз ьләре белән җылый. Көмәне булса кирәк. Булмаса, ул кадәр бор- лмас иде, ташлар да китәр иде...

Бу сүзләрне ишеткәч, бөтенләй аптырап калдым. Без, үзебезчә ты- шып, бу караңгы авылда татар хатын-кызларының хокукларын лап йөрибез, кабахәт җанны, коновалны акылга утыртырга, шуның лән башка хатыннарга көч бирергә телибез. Ниятебез яхшы, изге, ма нәтиҗәсе начарланганнан начарлана бара. Уйлаган чараларны kapyгә Кәлим генә түгел, Фаизә дә каршы килә. Ялына, җылый. ишләргә?

Мин әле генә бу өйдә, чәчәкләр арасында идем. Хәбирә апаның илә тарихын, аның башланып китүен, ишәюен чагылдырган, шатлык- рын, моннарын, күңел кичерешләрен җанландырган хатирәләрен раган идем, ул хатирәләрдә мин саф мәхәббәт җылылыгын, аның ихри көчен, мәңгелеген, бөеклеген тойган идем. Аларны караган ми- утларда туган хисләрем күңелемне рәхәтләндергән, баеткан, канатлан- ырган иде,— яшермим, ул хисләр мине дә мәхәббәткә чакырган, ана грылыклы булырга, аны чәчми-түкми, җил-яңгыр тидермичә, тап тө- ермичә, йөрәк түрендә саклап, киләчәккә алып барырга дәртләндер- ш, өндәгән иде. Тормышлары, көнкүрешләре башка гаиләләрдән бер рсә белән дә аерылып тормаган гади кешеләрнең — Хәбирә апа бе- н Гафият абыйның шундый тирән, саф мәхәббәт белән яшәгәнлекл- , шул мәхәббәт хатирәләрен җәймәләр, япмалар, сөлгеләр рәвешендә, ләчәк буыннарга калдырулары күз яшьләрен китерерлек тәэсир- е иде.

Ул хатирәләрне караганда Хәбирә апа нәрсә уйлагандыр,— белмим, экин мин, күңелем белән, бу кечкенә өйдән чыгып, кайдадыр бакча- арда, болыннарда, чәчәкләр арасында йөрдем, рухланып, һаваларга үтәрелдем, җылы кояш нурлары белән өретелгән алсу болытлар ара- ында йөздем, ә хәзер менә, Фаизә турындагы күңелсез сүзләрне ишет- әч, янадан җиргә, салкынга, каршылыклы, сикәлтәле, тискәре яклары елән ыжгырып, җанны туңдырып торган тормышка килеп төштем. Ничектер кинәт канатларымны кистеләр, кыркыдылар, инде оча алмыйм, шкынулы күңелем белән һаваларга күтәрелә алмыйм. Күз алдымда Фаизә тормышы, аның бәхетсез язмышы. Ул да бит бу җирдә яши, аның һавасын сулый, суын эчә. Ул да кеше. Аның да дөньяда күңелле, әхетле яшисе, эшлисе, игеннәр, бакчалар үстерәсе, балалар тәрбия- лисе, алар күңелендә, авылда, тирә-күршеләрендә үзе турында яхшы хатирәләр калдырасы килә торгандыр. Аны бу бәхеттән мәхрүм итәргә кемнең хакы бар?!

Нишләргә?

Күңелемә килгән бу сорау Хәбирә апа теле белән әйтелде.

— Нишләргә инде хәзер? — диде ул.

Мин ана сорау белән җавап бирдем.

— Госманга әйттеңме моны?

— Әйтмәдем.

— Нигә? Әйтергә кирәк иде. Белеп торсын.

— Әйтмәдем әле,— диде хатын.— Ничектер телем бармады, борчый- сым килмәде. Болай да эше күп. Кәлим эше белән генә шөгыльләнә

алмый ич ул. Әле тегесе, әле бусы дигәндәй... Аннары бит, Зариф энем, монда син белмәгән бер нәрсә бар... Аны да искә алмыйча ярамый.

— Нәрсә бар?

Хатын тиз генә җавап бирмәде. Күзләрен түбән төшереп, уң кулы белән алъяпкыч итәген бөтерә-бөтерә, әйтимме икән, юкмы икән дигәндәй бераз уйланып торды.

— Бар, дидем дә, телгә алып сөйләрлек әллә ни юк... Тик болай гына әйтүем,— диде һәм, нигәдер уңайсызланып, миңа сәер карап алды. Аның нәрсәдер белеп тә, аны миннән яшерүе, әйтергә теләмәве күз карашыннан, хәтта бөтен торышыннан күренеп тора иде. Мин, моны сизеп:

— Хәбирә апа, әгәр әйтергә ярый икән, әйтегез, яшермәгез,— дидем.— Үзегез беләсез, бу эшне тикшерү миңа да йөкләнгән. Гадел хөкем итәр өчен миңа барысын да белергә кирәк.

Сүзем Хәбирә апага тәэсир итте булса кирәк. Тынып, күзләремә төбәп, бераз карап торды да:

— Әйт, берәүгә дә сөйләмәссеңме? — дип сорады.— Вәгъдә бирәсеңме?

Мин, вәгъдә биргәнлегемне белдереп, башымны идем, телем белән дә әйттем.

Хәбирә апа нигәдер ишеккә карап алды һәм, тавышын акрынайтып:

— Беләсеңме нәрсә, Зариф энем, Фаизәне Кәлим явызлыктан гына түгел, көнләшүеннән дә кыйный булса кирәк,— диде.

Өйдә без икәү генә идек. Ул мич буенда, артсыз урындыкта, ә мин ян сәкедә. Шулай да ул пышылдап кына, бары миңа ишетелерлек итеп кенә сөйли башлады.

— Әйтсәм әйтим инде. Фаизә белән Госман арасында күптәнге мәхәббәт ята. Бер-берләрен бик яраталар иде алар. Сүнгәндер, беткәндер дип уйлаган идем, бетмәгән, сүнмәгән икән...

Мин моны көтмәгән идем. Бик гаҗәпләнеп, аптырап калдым һәм беркадәр шомланып сорадым:

— Яшерен йөрешәләрме әллә?

Хәбирә апа, соравымны яратмыйча, миңа карап алды да, кинәт тавышын көчәйтеп:

— Юк, ни дигән сүз ул, авызыңнан җил алсын! — диде һәм, шунда ук аңына килеп, янадан пышылдап кына сөйли башлады:— Нигә йөрешсеннәр! Элек йөрешкәннәр иде. Фаизә кыз чакта. Герман сугышы алдыннан. Госман да яшь егет иде әле. Хәер, ул әле дә өйләнмәгән... Кушыла алмый калдылар, мескеннәр. Сугыш башланып китте. Госманны шунда ук сугышка алдылар. Бер елданмы, ике елданмы, анысын ачык әйтә алмыйм, Госманның үлгән хәбәре килде. Командиры язган мөһерле кәгазь иде. Аннары озакламады, аның белән бергә сугышта йөргән кеше, үзебезнең авыл егете кайтты, Госманның ничек үлүен үз күзе белән күргән икән. Кайдадыр, Карпат дигән җирдә үлеп калды, дип сөйләде. Барыбыз да ышандык, билгеле. Фаизә дә ышанган, күрәсең. Уйлап кара, ничек ышанмаска кирәк. Үз күзем белән күрдем, дип кайтып сөйләсен дә. Тик күмеп кенә булмады, ут эченнән алып чыга алмадык, диде, бик каты сугыш бара иде, чигенгән чакка туры килде, диде... Фаизә, моны ишетеп, бик кайгырган, елаган... Фаизә ул Иске Артышныкы түгел. Өтәкнеке. Моннан егерме-егерме биш чакрымнар чамасында шундый бер авыл бар. Бәлки, белә торгансың?

— Беләм, ишеткәнем бар. Әле кичә генә аннан уналты олау арыш китерделәр,— дидем мин, Хәбирә апаның сүзен бүлмәскә тырышып.

— Шулаймыни? — диде Хәбирә апа.— Мин дә бит шул авылдан төштем. Шуңа күрә Фаизәне бала чагыннан ук беләм. Күршеләр идек без. Кереп-чыгып йөри идек. Герман сугышына кадәр Госман Өтәктәге бер байда ялчы булып эшләде. Шунда танышканнар алар. Бик яшерен

әхәббәт иде аларның. Аны бераү дә белмидер иде диярлек. Безнекеәр күрше булганга сизгәннәр... Әнинең әйтүенә караганда, Фаизә ескен, Госманның үлүе турындагы хәбәрне ишеткәч, үз-үзен белешмиэ елаган. Ел әйләнәсе беркая чыкмаган, кеше белән сөйләшмәгән, үтәрелеп карамаган, тиле кеше сыман йөргән. Әти-әниләре бик кайыргашнар, үз-үзенә кул салмаса ярар иде дип, куркыша башлаганар... Шулай итеп, еллар үтеп китте, Госманнан хат-хәбәр булмады. Ничек булсын? Үлгән дип саный идек аны... Патша төшерелгән елны ашу вакытында Кәлим төрмәдән кайтты. Күп тә тормады, өйләнде. әллә инде авылдан өйләнәсе килмәде, әллә инде Иске Артыш кызлары на чыгарга теләмәделәр, ничек булгандыр, анысын әйтә алмыйм,— леге Өтәктән, минем туган авылдан, Фаизәне утыртты да кайтты. Кыз ышкты бичара. Күрәсе газаплары булган икән. Ул матурлыгы белән гет таба алган булыр иде. Менә дигәннәрнең берсе иде ул. Хәзер күләәсе генә калды. Язмыштан узмыш юк, диләр, язмыш, күрәсең. Аның Кәлимгә чыгуында әти-әниләренең дә куллары уйнамаган түгелдер дип йлыйм. Бераз юанмасмы, кайгысын онытмасмы дип, тизрәк бирергә ашыкканнар, ахры. Хәер, аларны да гаепләп булмый. Әти-әни беркайан да балага начарлык теләми... Фаизә әйткән, имеш, миңа инде баыбер, дөньяның яме, кызыгы калмады, кемгә чыксам да ярый, ашаып-эчертеп, бераз киендереп торса, шул җитә, дигән, имеш. Дөресме, экмы, әйтә алмыйм. Дөрес булуы да ихтимал. Дөньядан кул селтәгәч, шулай уйлагандыр.

— Тукта әле, Хәбирә апа,— дидем мин, аның сүзен бүлеп.— Ачыграк әйт әле, аңлап бетермәдем. Фаизә аның төрмәдән кайткан икәнен, аннары аңа кадәр ике тапкыр өйләнгән булуын ишетмәгән идеме әллә?

— Кем белә аны,— диде Хәбирә апа, бераз уйланып.— Бәлки, ишетмәгәндер дә. Соңыннан мин, ул кияүгә чыккан елны, кызыксынып, бу турыда аның үзеннән бер-ике тапкыр сорадым. Әйтмәде, сүзне икенчегә борды... Шул елны, Фаизә кияүгә чыкканнан соң күп тә үтмәде, Госманнан хат килеп төште. Германиядән. Әсирлектән. Бөтен авыл шау килде. Менә бит ул ничек! Хикмәти хода, исән булып чыкты бит... Шуннан соң күпме вакыт үткәндер, белмим,— бер заман Фаизәне күрдем, танымадым. Яңаклары батып кергән, күз төпләре күгәргән иде. Йөрәгендә бик авыр хәсрәте барлыгы сизелеп тора иде. Мескенем, Госманны көтмәвенә бик кайгыра ул. Бик үкенә. Сорашмадым, күңел ярасын кузгатырга теләмәдем. Аннары шунысы да бар: Фаизә үзенең кайчандыр Госманны яратканын халыктан бик яшерә. Бераүгә дә әйтми. Мин аны тик әтиләребез күршесе булганга гына беләм. Юкса, белмәс идем. Үзең уйлап кара, Зариф, ничек яшермәсен. Хатын-кыз ич ул. Исеме-чабы чыгудан курка. Халык теленә керсә, харап. Алла сакласын!

— Әллә Кәлим аның кыз чакта Госман белән йөргәнен белгәнме?

— Кем белә бит аны,— диде Хәбирә апа һәм бераз уйланып торганнан соң өстәде:— Ир кеше ич ул. Ирләр сизенәләр алар. Бәлки, кемнән булса да ишеткәндер. Югыйсә, бик яшерен мәхәббәт иде ул. Өтәктә дә белмиләр иде аны.

Хәбирә апа сүзләре миңа тагын бер нәрсәне ачты: мин Госманның бу эшне тикшерүгә катнашырга теләмәвенең сәбәбен аңладым. Менә ни өчен икән ул! Ә мин, юләр, күңелемнән әллә ниләр уйлап, аны гаепләп йөрдем. Хәер, хәзер дә әле, бу сүзләрне ишеткәннән соң да, аны аклый алмыйм. Ничек аклыйм? Авыл советы председателе бит ул — власть кешесе. Шулай булгач, ул, бернәрсәгә карамастан, хәтта бер нәрсә белән дә исәпләшмичә, өстенә йөкләнгән бурычны үтәргә тиеш түгелме соң?

Шуның белән бергә, күңелемнен бер читендә, ерακта, ниндидер шик туа башлады: шулаймы икән? Фикерем дөресме икән? Йөрәкләрне гомергә әрнетергә, сыкратырга мәҗбүр иткән бу бәхетсез мәхәббәтне бер читкә куеп, аңа бөтенләй игътибар итмәгәндәй булып, бу катлаулы эшне мин уйлаганча ансат кына хәл итү мөмкинме икән? Ялгышмыйммы икән мин?..

Бу минутларда күңелемдә шундый икеле уйлар иде. Госман белән Фаизә арасындагы мөнәсәбәтне аңласам да, Кәлим белән Фаизә арасын житәрлек күз алдыма китерә алмый идем. Шуны ачыклар өчен Хәбирә ападан:

— Әллә алар Госман кайткач кына бозылыштылармы? — дип сорадым.

— Юк, аңа кадәр дә тыныч тормыйлар иде алар,— диде Хәбирә апа.— Ләкин Госман кайтканнан соң аралары бөтенләй бозылды. Эт кеше ул Кәлим. Гаеп анда. Фаизәдә түгел. Фаизә ул — ефәк шикелле хатын. Сыйпаган саен яхшыра, матурлана. Ә Кәлим...— Хәбирә апа, аны хурлап, ниндидер каты сүз әйтергә теләде булса кирәк. Сөйләвеннән туктап, уйланып торды, ләкин әйтмәде, «юк инде, юк, кеше түгел ул» дигән кыяфәт белән кулын селтәде.— Элекке хатыннарын да бик рәнжетте. Сөйләгән идем ич. Кем белә аны, бәлки, Госманның авылда булуы да араларын бозадыр. Фаизә әйтә: ул председатель булганнан бирле көн күрсәтми, ди. Орышмаган, бәйләнмәгән көне юк, ди. Әллә син Фаизә кыйналганга, кыерсытылганга күрә шулай газаплана дип уйлыйсыңмы? Юк, Зариф энем, тән газабына түгел, күңел газабына түзә алмый ул. Көтмәвенә үкенә. Шуңа көя. Тән ярасы төзәлә, күңел ярасы төзәлми. Кем белгән бит аның кайтасын... Гаҗәп еллар бит хәзер. Кешеләр кабердән дә кайталар... Аннары тагын ул Кәлим Госманга андый-мондый явызлык эшләмәсен дип тә курка булса кирәк. Шулай сизелә.

— Фаизәнең кияүгә чыкканын Госман кайчан ишеткән соң?

— Әсирлектән котылгач. Башта авылга кайтмакчы булган икән. Ләкин Фаизә турындагы хәбәрне ишеткәч, кайтмаган. Кызыл Армиягә язылган. Анда кайтып, нишлим дигәндер, мескен. Аны да кызганам...

Ике яшьнең каһәр суккан сугыш аркасында теткәләнгән, тар-мар ителгән мәхәббәте, фаҗигасе бу. Моны хәзер берничек тә төзәтергә, күңелләрдән сызып ташларга, онытырга мөмкин түгел.

Хәбирә апа аларның икесен дә кызгана. Миңа, барыннан да бигрәк, Фаизә кызганыч. Нәрсә әйтсән дә, Госман ир кеше. Түзәр, онытыр, өйләнер, гаилә корып җибәрер, балалары булыр. Бер нәрсә дә мәңге яшәмәгән кебек, йөрәктәге кайгылар да мәңге яшәмәс, еллар белән басылыр, онытылыр...

Күңелемне юатырга теләп, шулай уйларга тырыштым. Ышанырмы әйтим: моңа мин үзем дә ышанып бетермим. Никадәр ышанырга теләсәм дә, ышанып бетерә алмыйм. Бәлки, моңа Фаизәнең өзлексез күз алдында торуы комачаулыйдыр: чәчләре тузган, авыз-борыны канаган, зур кара күзләрендә әрнүдән, газаплανудан башка бер нәрсә дә юк... Кем белә, бәлки, бу аның йөрәк әрнүе, бәхетсезлегенең йөзенә, күзенә бәреп чыгуыдыр. Госман ничек кичерә икән бу фаҗигане? Ул да аны оныта алмыймы икән? Терелеп житү белән үк сугышка китәм, монда тормыйм, диюе шул әрнүнең, газаплануның нәтиҗәсе түгелме икән? Шуны белергә теләп, Хәбирә ападан:

— Госман ничек соң? Оныткан мы? — дип сорадым.

— Оныткандыр дип уйлаган идем, онытмаган икән. Бер көнне Кәлимнең Фаизәне кыйнавы турында барып әйткәч, исем-акылым китте, бер агарды, бер күгәрде, шулай да сер бирмәскә тырышты. Һаман ярата, курәсең. Оныта алмый. Ни әйтсәң дә, яшьли сөйгән яр шул. Җырда да бар бит. Ничек әле, «яшь вакытта кемне сөйсәң, күңелең

шунарда була», диләр түгелме? Дөрес булса кирәк. Халык белми чыгармас. Аннары, Зариф энем, кеше күңеле бик тирән ул. Анда нәрсәләр барлыгын үзеннән башка берәү дә белми. Ай, тирән!..— Хәбирә апаның тавышы яңадан моңсуланып, сагышланып китте, ул яңадан тирән көрсенеп куйды.

Нәрсә ул, кеше күңелендәге билгесез серләр өчен көрсенәме, әллә үзенең күңелендә дә нинди дә булса башкаларга ачып бирергә, белдерергә мөмкин булмаган моң, сагыш, хәсрәт уты ятамы? Ул, нәрсә турындадыр уйланып, тынып калды, күзләрен идәнгә, билгесез ноктага текәп, бераз сүзсез торды, аннары, йокысыннан уяңгандай башын күтәреп җибәреп, пышылдап кына сөйләвендә дәвам итте:

— Кеше күңеле бик тирән, Зариф энем... Әгәр кешеләр күңелләрен ачып сала торган булсалар, бераз җиңеләеп китәрләр иде. Күпләр кайгыларын эчләрендә йөртәләр, тышка чыгармыйлар, шуңа көяләр, саргаялар. Фаизә дә шуңа саргая...

Юк, бу хатын Фаизә турында гына сөйләми, үзе турында да сөйли, йөрәгеп, күңелен тәмам бушатканчы, тынычланганчы ачып, сөйләп бирә алмавына борчыла, көрсенә. Мескен хатын, әгәр ул күңелендәге ачынуларны тәмам бушатканчы сөйләп бирә алса, йөрәгенә таш булып кереп каткан кайгыны йомшатып, киметеп булыр дип уйлый, күрәсең. Ялгыша. Ирен югалту хәсрәтен ул, гомере буенча алып барып, үзе белән бергә салкын кабергә алып керәчәк, шунсыз онытмаячак.

Тукта, бәлки, бу аның бетмәс кайгысы, хәсрәте, көрсенүе түгелдер, ә иренең исән-сау кайтуын өметләнеп көтүе, бу көтүнең озаклыгы, чиксезлеге өчен пошынуы, борчылуыдыр. Әйтте бит: «Кешеләр хәзер кабердән дә кайталар»,— диде. Гафиятнең сугышта һәлак булуы турында күптән хәбәр алгаң булуына карамастан, ул аның кайтуын, ишекне киң итеп ачып керүен, аны яратып, сөеп, кочып алуын көтә торгандыр.

Гаҗәп кеше бу Хәбирә апа! Үзенең эчендә шундый тирән хәсрәт ятуына карамастан, кеше кайгысы, аның бәхетсезлеге өчен яна, аның өчен көя, сызлана.

— Госманга авыр,— диде ул, һаман да пышылдап кына.— Бу турыда ул бер нәрсә эшли алмас. Фаизәнең хәлен генә начарлатыр. Моны белә ул. Юкса, Кәлимне ул, ботарлап, тетеп ташлар иде. Соңыннан теге кабахәт җан Фаизәгә көн бирмәячәк, терелэй кабергә кертәчәк аны. Госман — ике ут арасында ул. Аңа алай да вай, болай да вай. Ә Фаизәне барыбер бәхетле итеп булмый. Киселгән телем ул, никадәр теләсәң дә, ябышмый. Ялгыш иттек без. Моны Госманга белдермәскә кирәк иде. Мин дә җүләр, бер көнне, Фаизәне кызганып сөйләп, йөрәген әрнетеп кайттым. Әй бу, сөйләшә белмәгән авыз!..

Мин Хәбирә апа янынпан тагын да борчылыбрак чыгып киттем. Ике яшьнең бәхетсез мәхәббәте, трагедиясе юл буе башымнан чыкмады. Тынгысыз уйларымны куарга никадәр тырышсам да, булдыра алмадым. Инде күз алдымда Фаизә генә түгел, кай минутларда кайгылы, моңсу күз карашы белән Госман да килеп баса. Аннары Кәлимнең безнең турыдагы сүзләре дә борчый. «Әллә аларның дөньяда торасылары килмиме?» — дип, нинди максат белән әйтә икән ул? Бу аның безне куркыту өчен гади шапырынуымы, әллә чыннан да бу сүзләре артында нинди дә булса берәр явыз ният ятамы? Моны ничек белергә? Госманга әйтергәме, юкмы? Әйтсәм, аралары тагын да бозыла төшеп, Фаизәнең көннәре тоташ утка, җәһәннәмгә әверелмәсме? Нишләргә?..

## Әминә Бикчәнтәева

### Көзге моңнар

Көзге моңнар жырын жырлаганга,
Моңсу диеп уйлый күрмәгез,
Моңсу күңел — нурсыз гомер бит ул,
Моңаябыз шуңа күрә без.

Хушлашабыз кошлар киткән чакта,
Тик беләбез язда кайтасын,
Елгаларда кимеп калган сулар
Беләбез ич язын артасын.

Моңаябыз бакчаларда гөлләр
Көзге кырау төшеп сулганга,
Куанабыз кышлар үткән саен,
Саф һавалы язлар туганга.

Төннәр житсә, жирне нурландырып,
Ай калка да, йолдыз кабына,
Чын күңелдән сөя белгәннәргә
Үз йолдызы жирдә табыла.

### Җилләрең, бураннарың...

*Жыр*

Шатланып көтә күңелләр
Яңа ел туганнарын,
Ябынсын кырлар, болыннар
Ак мамык юрганнарын.
    Кадерле безгә, туган ил,
    Җилләрең, бураннарың.

Күңелле карап торырга
Зур йортлар төзелгәнен...
Онытмыйк авыр елларда
Үзәкләр өзелгәнен.

Тынычлык — ул кадерле сүз,
Әй, газиз туганнарым,
Хәтерләп үтик батырлар
Дошманны куганнарын.
    Күңелгә рәхәт, туган жир,
    Җилләрең, бураннарың.

## Клара Булатова

### Шушы яктан, шушы туфрактан без

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Читтә йөрсәк, шуңа күрәдер,
Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,
Таллар җырлап төшкә керәдер.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Озак йөрсәк ерак юл алып,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр көтә моңаеп.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шушы җиргә тизрәк кайтырга,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр шаулап чакыра.

### Февраль

Бу көннәр, ничектер,
бик тымызык, бик йомшак.
Кыш сынып, февральгә кергән чак.
Язларны гел дәшеп,
гел чакырып йөргән чак.
Карлардан яз исе килгән чак.
Яз житкәч, ярларда
бу көртләр шиңәрләр.
Карларда сукмаклар югалыр.
Туасы таңнарда
бу тыныч ярларда
Тулышкан бөреләр уяныр.
Ах, февраль аенда
кыш сынган чагында
Язларны сагынучы аз димсен?
Уем кар ярларда,—
сукмаклар карларда,—
Ярдагы карларда яз исе.

Пушкин белгән, Пушкин сөйгән нәсел!
Бу якларга кайдан килгәннәр?
Шаулап үскән Әлмәт эргәсендә
Табор корып ята чегәннәр.

Зәй буенда соры чатырларда
Чегән җыры — хөрлек чаткысы.
Чиратлашып факел нуры белән
Зәйгә төшә учак яктысы.

Кызлар йөри. Чая күзләрендә
Көньяк төннәренең бәрхете.
Кулларында карта, багу көче,—
Бу нәселнең кыргый бәхете.

Гасырлардан калган горефләрен
Саклый килә һаман бу халык.
Далаларның, урманнарның барлык
Серен белә алган бу халык.

Пушкин белгән, Пушкин сөйгән нәсел,
Үзләренчә горур, матурлар.
Әллә нинди тылсым көче белән
Үзенә тарта соры чатырлар.

Читтән генә күпме күзәтсәм дә,
Сезнең серне төшенә алмам мин.
Ник килдем дә әле, ни өчен соң
Китә алмыйм сезнең яннан мин?

Язмышымны билгеләтү өчен
Килмәдем мин сезнең таборга.
Ул билгеле күптән, мин өйрәнеп үскән
Үз бәхетемне үзем табарга.

Безнең язмыш карталарда түгел,
Көзгедән дә багып карама!
Кызлар йөри... Бәлки Земфиралар,
Мариулалар бардыр арада.

Табигатьнең көйле, назлы җаны
Бу кызларда яши шикелле...
Далалардан килгән чегән җыры
Дәшеп мине монда китерде.

Кара чутыр чегән балалары
Итәгемә сырышыпябыша.
Белә алар: кумыйм, ачуланмыйм.
Бала күңеле сирәк ялгыша.

Якты, яңа кала эргәсендә
Зәй буенда соры чатырлар...
Үзләренчә алар бәхетлеләр,
Үзләренчә горур, матурлар.

Без белмәгән күпме хозурлык бар
Шул таборда, чатыр-куышта.
Пушкин белгән, Пушкин сөйгән нәсел
Ул һаман шул шаулы тормышта.

# Бишек җыры

Аланнар, яланнар,
Урманнар, урамнар —
Бөтен җир тынлыкта,
син йокла.

Күктә тын ай гына,
Йолдызлар җай гына
Җемелди тынлыкта,
син йокла.

Тын тора алмагач,
Сайрамый сандугач,
Бакчалар тынлыкта,
син йокла.

Дулкыннар йөгерми,
Тәңкәләр күренми,
Инеш тын җил юкта,
син йокла.

Син йокла, борчылма,
Әнкәң баш очында
Урамнар, аланнар
тынлыкта.

Тын тора алмагач,
Сайрамый сандугач,
Инеш тын җил юкка,
син йокла!..

ıııııııııııııı

Сажидә Сөләйманова

# БЕЗНЕҢ АПАЙ— КОРОЛЕВА

хикәя



Мәскүрәләр ягында Казан татарлары сыман «бармыйм», «чыкмыйм» дип, кинәттән кырт кистермиләр. «Бармаем», «чыкмаем», «булмай» дип, сузыбрак, башкортларга хас назлану беләнрәк сөйләшәләр. Башкорт татарлары алар. Сөйләмнәрендә башкорт алымнары очрый. Үзләрен башкорт дип йөргән авыллар да бар. Ләкин болар әле чын башкортлар түгел. Сөйләшү нигездә татарча, мәктәптә уку — татарча. Газета-журналларны Уфадан башкортчаны алдыралар.

Пионер газеталары укый башлаганнан бирле, бераз үз, бераз ят телгә мәхәббәте уянган иде Мәскүрәнең. Вузны бетергәч, ул диплом комиссиясе тәкъдим иткән башкорт авылына китәргә булды. Район үзәге. Унъеллык мәктәп. «Башкортча укыта алмам, булмый», диебрәк караган иде дә кыз, «без сезне үз милләтегез белән эшләүдән баш тартыр өчен укытмадык», диделәр. Милләте башкорт дип язылган ич Мәскүрәнең. Әдәбият буенча гына белгән чын башкортларны күрү теләге икеләнүне җиңде. Тагын бер сәбәп бар иде бугай — теге, Агыйдел буенда, очраган егет. Узган җәй Мәскүрә Агыйделне кичеп чыкканда очрашканнар иде алар. Очраштылар дип, Мәскүрә хәл җыеп комда утырды, егет шактый читтә йөренеп торды. Мәскүрә аңа хәтта күтәрелеп тә карамады. Ярым ялангач килеш егетләр белән танышып йөрмәссең бит инде. Гомумән, егетләр кайгысы юк иде Мәскүрәдә. Берсекөнгә экзамен. Теге ярда калган кызлар да китапларын күтәреп кайтыша башладылар. Комда кызынып яту рәхәттер лә ул... Мәскүрә кайтыр якка чыкканда егет якынлашмый да, ераклашмый да, «алай-болай була калса, монда мин бар» дигәндәй ара куеп йөзде. Мәскүрәне «ә» дигәнче калдырып киту аңа берни тормый иде югыйсә. Колачлары ярыш көймәсенең ишкәкләре кебек. Ярга аяк баскач, һәркем үз юлыннан китте. Кызык, шул ук көнне кич фәнни китапханәнең уку залында очраштылар. Мәскүрә китапларын тапшырырга тора иде.

— На вас сегодняшний загар,— диде берәү.
Мәскүрә аны бөтеркәч кара чәчләреннән чамалап алды.
— Ах, ул сез идегезмени?
— Ә һез татар кызымыни?
Кулындагы китап исемнәренә караганда, егет авыл хуҗалыгы институты студенты булырга тиеш. Механика факультетыннан, мөгаен.
Баскычтан бергә төштеләр.
— Сез яхшы йөзәсез.
— Ә сез татарча да беләсез икән.
— Нәмәһе бар уның? «h» ны «с» менән генә алмаштыраһы: «Сандугаслар сайрый савада...» Көлештеләр. Менә шул. Бүтән очрашмадылар. Диплом, дәүләт имтиханы. Эш урынын сайлаганда Акъярга китү турында сүз чыккач, әлеге башкорт егете хәтеренә төште. Акъярның текә ярлары мәһабәт буй-сынлы шул егет белән бергә күз алдына килде.
— Язмыш безне көтмәгән җирдә очраштыра, тагын очрашырбыз әле,— дигән иде егет китапханәдән чыкканда.
— Агыйделнең аръягында,— дигән иде Мәскүрә эре генә. «Агыйделнең аръягы» бәлки шул Акъяр булыр әле? Егет үзен Акъяр ягыннан дигән иде бугай. Ах, барыбер түгелмени? Егетләр кайгысы юк әле монда. Бөтен укыганнарың өчен сынау тотасыларың алда әле.

Мәскүрә инде Акъярда. Авылга юл дала ягыннан килеп керә. Ике якта биек-биек таулар тезмәсе, өченче якта — текә ярлы елга. Ярлары биек булса да, Иөгерек елгасы тар гына, өч-дүрт адым атласаң, теге ярда буласың. Авылның иң уртасында иске мәктәп белән янәшә яңасы салынып ята. Ихата тулы таш, бүрәнә. Уку елы башына яңа бина өлгерергә тиеш булган, күрәсең. Кызганычка каршы, укуны иске бинада башлап җибәрергә туры килә.
Башкортча китапларны су кебек эчсә дә, сөйләшүе алай җиңел түгел икән. Тел күнекмәгән. Уку башланганның беренче көнендә алты сәгать буе гел сөйләп торудан тел кыймылдатып сүз әйтер хәле калмады Мәскүрәнең. Квартир апасы бик сүзчән булып чыкты, җитмәсә бераз саңгырау. Бар икән күрәселәрем дип торганда, җае табылды. Рус теле укытучысы Вера Васильевнага аерым квартир биргәннәр, ул Мәскүрәне үз янына чакырды. Вера тау-тау дәфтәрләр алып кайта, көне-төне чекерәеп шулар өстендә утыра. Мәскүрәнең бишенчедән унынчыга чаклы тарих дәресләре, әзерләнеп кенә өлгер! Хаммурапи законнарыннан алып Потемкин восстаниесенең көне-сәгатенә чаклы яттан белергә кирәк. Университет бетереп килгән башың белән шпаргалкага карап сөйләп булмый бит инде. Мәскүрә беренче дәрестән үк һичнинди китап-дәфтәр алмыйча, кулына указка гына тотып керергә карар итте. Университетта яңа тарих укытучысы шулай керә торган иде. Очлы җиз башлы указкасы бар иде аның. Бер кулы белән шуңа таянып, икенче кулын селтәп килеп керер иде. Карт кеше инде ул. Дөньяның кай почмагында ни бар, барысын белә. Мәскүрә дә үзенең белеме белән Акъяр укучыларын берьюлы яулап алмакчы булды. Өлкән классларда моңа чаклы тәүге укытучылары инде укытучыларның... Өлкән классларда моңа чаклы тәреште дә ул. Малайлар тарихны яраталар. Аларга сугыш булсын да революция булсын. Кызлар иң башта яңа укытучыларының килеш-килбәтенә, киеменә карап тын калдылар. Кулбашларына тияр-тимәс дулкынланып торган сары чәч. Күе зәңгәрдән тегелгән жилет белән юбка, ак нейлон блузка. Сәхнәгә генә чыга торган биек нечкә үкчәле ак туфли. Чирәмле урамнардан бу кадак үкчәләр белән килүе бик ансат булмаса да, укучылар алдында калкурак күренү теләге көчле иде шул Мәскүрәнең. Беренче сентябрь көненә озак әзерләнде ул. Узган җәй эшләп алган акчалары да, соңгы стипендияләре дә шуңа китте.

Әйбәт тәэсир калдырды Мәскүрә өлкән классларда. Үзенә булган кызыксыну тора-бара аның сөйләгән сүзләренә күчте. Хәзер бу кызыксынуны югалтмаска гына кирәк. Их, менә бишенчеләр булмаса! Ичмаса шунда Мәскүрәне класс җитәкчесе итеп куймасалар! Кирәк бит әле, нәкъ кирәк җирдә абруй казана алмады яшь укытучы. Кергәндә үк гөжләшеп каршы алдылар. Биек үкчәләр дә, сырлы указка да ярдәм итмәде. Усал тавыш белән тәртип урнаштырырга туры килде. Тегеләрнең маш килгәннәрен телсез кешедәй карап торып булмый бит инде. Тавышны калынайтып кычкыра төшәргә туры килде шул. Кычкырдынмы — бетте, көчсезлек билгесе инде бу. Ярый ла күк күкрәведәй, берьюлы өнсез итә торган тавышың булса. Алай котны ала торган тавыш юк шул Мәскүрәдә. Салмак кына, басынкы гына сөйләп җанны эретә торган ягымлы тавыш аңарда. Болар бит әле сиңа сөйли башларга да ирек бирмиләр. Булмады, баштан ук үз итмәделәр бишенчеләр класс җитәкчеләрен. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, бер ялгыш сүз дә ычкындырды Мәскүрә. Инде классны тынычландырып сөйли башлагач та әледән-әле кыбырсып утырган чандыр малайга:

— Бәлки һинең посмакта басып тораһың киләдер? — диде.

— Апай, нәмә ул посмак?

Белә иде бит Мәскүрә, «посмак» түгел, «мөеш» бит. «Ч» урынына «с» куеп кына башкортча булмый бит, «Сандугаслар сайрый савада» килеп чыга. Ябылырга да өлгермәгән авызларын ерырга җитә калды тегеләргә. Безнең якта шулай сөйләшәләр дип кенә котылып булмады. Сүз нәкъ танышуга терәлеп калган иде.

— Апай, һез кай яктан?

— Апай, нисә яшьтә һез?

— Ун йете лә юктыр әле?

— Апай, ул туфлиден үксәһе ничек һынмай?

Мәскүрә урынында уен-көлке белән торган кеше булса, бу мәзәк сорауларга аннан да мәзәгрәк сүз әйтеп балаларны көлдерер иде. «Синең белән минем яшьне бергә кушып урталай бүлсәң, нәкъ унҗиде була», дияр иде, мәсәлән. «Сезнең мәктәп ихатасында аяк сынганчы, үкчә сынсын дип кидем мин бу туфлине», дияр иде. Бәлки шулай аңлашып та китәрләр иде. Юк шул, кешесе бик җитди. Укытучы бит ул, университет тәмамлап килгән, нишләп мәзәк сөйләүдән башласын ди шул чаклы җитди эшне.

— Бу сүзләрнең берсе дә дәрескә кагылмый. Эшкә күчәбез,— диде Мәскүрә. Дөрес тон алмаган җырчы сыман азапланып, борынгы кешеләр турында сөйли башлады. Балалар яшь укытучыны кәмит иткән кыяфәттә тыңлап утырдылар. Шулай итеп, беренче дәрестән үк аралар бозылды. Өлкән дә итмәделәр, дус та күрмәделәр бишенчеләр Мәскүрә апаларын.

Ят итүнең сәбәбе «посмак» кына түгел икән. Башка сәбәпләр дә бар икән. Класс җитәкчесе буларак, Мәскүрә берәр эш оештыра башласа, «беззең апай улай итмәй ине, беззең апай болай итмәй ине», дип тотыналар. Бигрәк тә Айрат исемле чәтерчән малай күз дә ачырмый. Класста аның сүзе үтә, күрәсең, үзен гаскәр башлыгы кебегрәк итеп тота. Класс активына сайларга кирәк Айратны, сәләтле, иптәшләре ихтирам итәләр үзен. Класс җыелышында шушы турында сүз чыккач, әлеге Айрат:

— Беззең Таңһылу апай...— ди башлаган иде, Мәскүрә аны шундук туктатып урынына утыртты.

— Хәзер сездә Тансылу апай түгел, ә Мәскүрә Кәримовна!

Укытучылары сөйләгәндә Айрат үзалдына мыгырданып бер-ике сүз кыстырды. Бу таркатучыдан ярдәмче чыкмастыр. Активка кермичәрәк торсын әле, үзе үк читтә аерылып калачак.

Ялдан соң Мәскүрә дәресләр башланганчы класска керсә, тагын шул сүз:

— Таңһылу апай беренселәрде походка алып барды. Мин юл күрһәтүсе булдым,— ди Айрат.

Балалар белән тауларга чыгып керергә дигән уй килгән иде инде Іаскүрәнең башына. Таңсылу апайлары өлгергән дә икән. Житмәсә, Айратны да алып барган. Кем соң ул телдән төшмәс апай? Мәскүрә үзенең бу «көндәшен» озын кара толымнарын баш түбәсенә өеп куйган, зифа буйлы, көмеш тавышлы сылу башкорт кызы итеп күз алдына китергән иде. Бакса, Таңсылу дигәннәре Мәскүрәдән дә бәләкәйрәк, чипкелле генә бер кыз булып чыкты. Махсус игътибар итәрлек бер жире да юк. Аны хәтта күрми узарга да мөмкин. Дөрес, озын кара чәчен Іаскүрә уйлаганча түбәсенә өеп куйган. Аягында тәбәнәк үкчәле кара туфли, өстендә кара трикотаж костюм. Яше Мәскүрә чамасы булыр. Китапханәче кыздан сорашып, көндәше турында кайбер мәгълүматлар да алды Мәскүрә. Гаиләләре ишле икән, Таңсылу — иң өлкәне. Уны үстергәч, мәктәптә пионервожатый булып эшләгән. Читтән торып педучилище тәмамлаган, хәзер пединститутта читтән торып укый икән. Балаларны шаккатырырлык белеме дә юк үзенең. Мәскүрәнең бит Мәсәү, Ленинград музейларында экскурсиядә булганы. Мисыр мумияләрен үз күзе белән күргәне бар. Вузда уку дәверендә ничаклы күргәзмә әсбапар жыйды ул. Һәркемне жәлеп итәрлек итеп сөйли белә. Психологиядән дә бишкә генә укый иде, хәтта шул фән буенча аспирантурада калырга тәкъдим иттеләр. Үз өеннән ары берңәрсә күрмәгән шул кызый аклы да булдыра алмас микәнни Мәскүрә?

Беркөнне Мәскүрә балаларга мәктәптә тарих музее оештыру нияте барлыгын әйтте. Тирә-як белән танышу өчен якшәмбедә бергәләп тауларга чыгып керербез, диде.

Экскурсия көне бик уңышлы сайланмаган булып чыкты. Сентябрь урталары узуга бәрәңге казый башлыйлар, безнең бишенчеләр бу эштә бик кирәкле халык икән. Бер ният иткәч, планны бөтенләй сүтмичә, гелгән балаларга гына килергә кушты ул. Әйбәт тә булды әле, күмәк халык белән озаклап йөреп булмас иде. Менмәгән тау башы, кермәгән тау куышы калмады. Бер куышта Салават батыр кешеләре яшеренеп яткан дип тә сөйләделәр балалар. Бәлки, арттыралардыр, белергә кирәк булыр. Акъярның тарихын язарга, альбом төзергә сөйләшеп кайттылар. Айрат башта ук: «Беренчеләр сугыш уены уйныйлар, Таңсылу апай мине командир итеп чакырды», дип игълан иткән иде, Мәскүрә ишетмәмешкә салынды. Әйдә, йөрсен әле Таңсылу апае белән. Мәскүрә аңа артык игътибар итмәскә булды. Үзе үк бер көйгә килер, ахмак малай түгел, кызыксынучан. Дәрестә иң күп сорауны ул бирә:

— Монголлар белән татарларның теле охшашмы?

— Кытайлар нишләп борынгы культураларын югалтканнар?

— Чехлар — славяннармы?

Тема буенча да, темадан ерак сорауларга да жаен табып жавабын бирә Мәскүрә.

— Башкортстаннан кала иң күп нефтьне кайсы республика таба?

Моның ише сораулар борынгы кешеләрнең шөгыле турында сөйләгәндә сүз уңаеннан килеп чыга.

— Хәзер безнең илдә иң күп нефтьне Татарстан бирә: йөз миллион тонна, бөтен Союз нефтенең өчтән берсе.

— Ә безнең апай әйтә...

Әһә, боларның апайларында мәгълүматлар шактый искергән икән. Балаларга моны бераз сиздереп алу зыян итмәс иде дә, кеше дәрәжәсен төшерү исәбенә абруй аласы килми Мәскүрәнең.

— Башкортстанның беренче чаклары бар иде,— ди ул, тегеләрнең

апаларына кагылмый гына. Хәзер аны Татарстан узып китте. Татарстанны озакламый Төмән узып китәчәк.

— Аларның Салават кебек батырлары юк,— ди Айрат, нефть буенча Башкортстанның артта калуына кәефе кырылып. Таңсылу апалары балаларда башкорт халкы белән горурлану хисе уяткан икән. Бу хисне дә үстереп, башка халыкларга ихтирам тәрбияләргә кирәклеген сизеп ала Мәскүрә.

— Һәр халыкның үз батыры бар,— ди ул. Ләкин Айратка чак кына булса да төрттереп китүдән тыела алмый.— Агыйделнең аръягында да тормыш бик кызыклы, бик катлаулы. Без өйрәнә торган тарих фәне — гаделлек белән гаделсезлек көрәше турындагы фән. Бу көрәш барышында дөньяда күп батырлар булган, батырларның иң батырлары белән без дә танышырбыз.

Үз темасына ипле генә кереп китүенә сөенеп, Мәскүрә сүзен дәвам итә. Дәрестә хәзер балалар шым гына утыралар. Ләкин Мәскүрә теләгән тынлык түгел бу. Тыңлау гына бу, күңелне аңлау юк. Күзләреннән күренеп тора — ят итәләр. Шулай да Таңсылу белән башта ук сөйләшергә кирәк булган. Ни әйтсәң дә, ул Айратларның беренче укытучылары. Дүрт ел аз гомер түгел. Дүрт атнасында гына даниләр кичермәде Мәскүрә мондый яу белән. Ул кыз үзе дә кире беткән, килеп дәшми дә бит ичмасам. Мәскүрәне читләтеп, балалар белән генә эш йөртә. Мәскүрәнең бишенчедәге хәлләрен, мөгаен, белә инде ул. Мәскүрә шул кыз алдында уңышсызлыкка очрагач кына баш исенмени? Башта ук киңәшкән булса, бер хәл иде. Хәзер инде үзе ерып чыгарга тиеш. Бәп-бәләкәй Айратны җиңмәскә соң? Ә сораулар ява тора. Сынап та, кызыксынып та.

— Апай, нишләп шахматта королева корольдән шәбрәк йөри?

Һиндстан темасы буенча бу. Шахмат уены Һиндстаннан чыккан, атлылар, филләр Һиндстан гаскәрләреннән шахматка кергәннәр дип сөйләгән иде Мәскүрә. Ә менә королева сугышта нишләп йөри? Җитмәсә, иң шәп йөрүче шул королева? «Белмим» дип әйтергә һич ярамый. Башка класста ярар да иде, монда ярамый.

— Сугыш барганда король күзәтеп, киңәшләр биреп торган. Гаскәр башлыгы — гадәттә корольнең якын кешесе, улы яки энесе булган. Легенда буенча, сугышларның берсендә король дә, гаскәр башлыгы да, каты җәрәхәт алганнар. Король белән бергә сугыш барышын күзәткән королева чигенә башлаган солдатларны үзе һөҗүмгә алып киткән. Король янәшәсендәге королева шахматка шулай килеп кергән.

Үзе уйлап чыгарган легендага Мәскүрә үзе дә ышанды. Нигә, бик табигый хәл. Индира Ганди ил белән идарә итә бит әнә.

«Беззең апай» әкренләп сирәгәйде. Аның урынына Мәскүрәнең җанын өткән бүтән сүз барлыкка килде.

Мәскүрә белән Вера Васильевна яшәгән квартир галәмәт салкын булып чыкты. Элекке хуҗалары да җылыту ягын карамаганнар. Мәскүрәләр турында әйтәсе дә юк. Мәскүрә тормыш итү рәтен аз-маз белә иде әле, авыл кызы. Вера бөтенләй авыл тормышына яраклашмаган. Суга буяу тәме чыга торган бер чиләкләре бар, шуны тотып чишмәгә үзе генә бармый, Мәскүрәне дә нәртү ягын карый. Болай да вакыт тар, минут арасына кыл сыярлык түгел. «Алай булгач, суга мин барам, син мичкә яга тор»,— ди Мәскүрә. «Бераз каен утыны чапкалыйсы булыр»,— ди. Верамы соң утын чапкалар кеше! Сыңар чиләк тотып суга китә. Утын дигәннән, кызык иткән кызларны Хуҗа абыйлары. Завхоз ул.

— Сезгә нинди утын китерим, каенмы, усакмы? — ди бу бер көнне. Вераның мондый эштә нейтраль икәнен аңлап, сөйләшүләрне Мәскүрә белән алып бара.

— Кайсы әйбәт соң аның? — ди Мәскүрә.

— Кайсы әйбәт дип, усак кисәргә йомшак инде ул, каен катырак.

— Усак китерегез,— ди Мәскүрә, эшне җиңеләйтмәкче булып.

Бер жылысы да юк икән ул усакның, мунчала кебек яна да бетә. Кызларны кызганып, бераздан каен утыны китерткән тагын Хуҗа абый. Анысы киселмәгән әле. Шуларның нәзекләрен балта белән чапкаламакчы Мәскүрә, өйләре бераз җылынмасмы. Электән болай балта тотканы булса да, утын кисәргә ул чаклы осталыгы юк икән. Утынга батмый балтасы, өскә сикерә.

— Кая, бирегез әле, бераз ял итеп алыгыз.

Эш белән мавыгып, янына кеше килгәнен дә сизмәгән Мәскүрә. Булат исемле егет бу, редакциядә эшли. Лекторлар бюросында танышканнар иде. Редакция Мәскүрәләр өенең каршысында гына. Тәрәзәдән Мәскүрәнең булдыксызлыгын күреп, эче пошып чыккандыр. Мәскүрә ун чапканны егет бер чаба, балтаны турыга төшермичә, кыйгачлатып кистерә. Ә дигәнче бер өем утын өелде. Кискән утыннарны кертеште дә әле Булат. Дөнья хәлләре турында фәлсәфә корырга да нияте юк түгел иде, Мәскүрәнең кәефе башкачарак булды. Өй салкын, карын ач, комсомол җыелышына барасы бар, кичкә тагын төне буе утырсаң да эш бетәрлек түгел.

Булатка:

— Физзарядка өчен рәхмәт! — дип, чыгып китүдән бүтән җай калмады.

Иртәгесен дәрес башланганчы класска керсә, әле ул мөештә, әле бу мөештә «Булат» та «Булат». Дәрескә керсә, кара тактага акбур белән шул исем язылган. Җен ачулары чыкты Мәскүрәнең. Дәресе дәрес булмады. Укытучы булдым дигәч тә ир заты белән сөйләшергә дә ярамыймыни инде Мәсүрәгә? Ә Таңсылу ничек икән? Ул да кыз кеше бит, балалар үртәрдәй беркеме дә юк микәнни?

Кышкы каникул җитте. Җитте дә, узып китеп тә бара. Чаңгыда чыгарбыз, шәһәргә барып кайтырбыз дигәннәр иде, берсенә дә өлгереп булмады. Отчет, педсовет, ярты елга план төзү, конференция... Алай да Вера өч көнгә Уфага кайтып килде. Мәскүрә бер тапкыр чаңгыда чыкты. Булат ике пар чаңгы күтәреп килгән иде. Үзенә, Мәскүрәгә. Урамда бер очрашкач, тауларга чыгасы иде дә, чаңгы юк дип сөйләнгән икән шул Мәскүрә. Булатның кайгырткан булуы инде бу. Вера җәл калды, аңа чаңгы җитмәде. «Чаңгы булса да чыкмас идем, секция утырышына докладым әзер түгел», дип калды тагын үзе. Мәскүрәнең дә докладкы әзер түгел дә, кеше чаңгы күтәреп килгәч, чыгып китте бит әле. Бик яман чаңгычы сыман кыланган иде дә Мәскүрә, таудан шуганда әллә ничә егылып адәм көлкесе булды. Мәктәптә укыганда әйбәт шуа иде, онытылган. Мәскүрәләр янннан гына Айратлар да выжт итеп узып киттеләр. Каһәр генә төшсен, тагын Булат белән бергә күрделәр инде. Балалар күңеленә якынлашам дигәндә генә... Мәскүрәнең кәефе кырылды. Кайтып якка юнәлделәр. Кышкы көн кыска бит, кичкә дә авыша башлады. Булат белән сөйләшеп йөрүе күңелле генә. Горькийга гашыйк икән ул. Вера да Горькийны ярата. Кызык, Вера Блокка гашыйк, Булат та Блокны ярата. Мәскүрә Есенинны өстен күрүен әйткәч, «деревенщина» дигән иде Вера. «Мин үзем дә авыл кызы бит», дип җавап биргән иде Мәскүрә. Булат менә авыл егете, Блокны якынрак күрә. «Сезгә Вера белән сөйләшү күңелле булыр, зәвыкларыгыз тәңгәл килә,— ди Мәскүрә,— мин сезне таныштырам әле». «Миңа сезнең белән дә күңелле», ди Булат.

Икенче көнне кичләтеп Булат тагын килгән. Чаңгысыз гына. Мәскүрә егетне ишек янынннан уздырмый гына:

— Вера өйдә юк,— ди. Үзенең «мин сезне Вера белән таныштырам әле» дигән сүзенә ишарәли, янәсе.

— Сезнең янга килергә ярамыймыни? — ди Булат. Үзе уңайсызланып, кызарып китә. Яравын ярый ла ул, бишенчеләр тагын «Булат»

та «Булат» дип җанны кыярлар инде, соңгы вакытта тыныбрак торалар иде. Мәскүрәне үз итә башлаганнар иде инде. Авылның кай тыкрыгында ни бар, барысын да күреп торалар бит шул елгырлар...

— Эшкә утырырга тора идем, иртәгә секциядә минем чыгыш, бер әйберем дә әзер түгел...

— Гафу итегез... Кич кинога да чыкмыйсызмы? — ди Булат, китә башлаган җиреннән Мәскүрәгә карамый гына.

— Чыкмаем,— ди Мәскүрә, назландыргандай итебрәк.

Булат ник керүенә үкенгән кыяфәттә чыгып китә. Уңайсызрак булды да, нишлисең, егетләр кайгысы юк Мәскүрәдә. Болай җаңга ятышлы кеше ул Булат үзе. Ләкин Мәскүрәнең идеалына туры килми. Буйга биек түгел, талчыккан йөзле, күзлекле. Җиргә карап йөрүдән бүе үзенекеннән дә тәбәнәгрәк күренә. Әнә, тагын башын иеп чыгып китте мескен. Мәскүрә үзенең гыйшкы төшәр кешесен горур, көчле итеп күз алдына китерә. Агыйдел буенда очраган башкорт егете сымаграк. Сирәк булса да Мәскүрәнең исенә төшеп куя ул егет. Агыйдел аша чыкканда Мәскүрәне саклап барган сыман йөзүе һаман-һаман күз алдына килә. Шундый көчле дусның ихтыярына язмышны тапшырасы килгән чаклар була. Теге вакытта якыннанрак танышасы калган да бит. Тик ул чибәр егет йөгерек күңелле түгел микән, шәһәр җирендә сылу кызлар күп бит? Шуны сизенеп тә якынлашасы килмәгәндер ул чакта Мәскүрәнең. Булат белән дусларча сөйләшеп йөрергә генә мөмкин. Мәхәббәт темасына кагылмасаң да, сөйләшер сүз бетмәгән. Тик менә бишенчеләр...

Мәскүрә бер җыелыштан кайтканда Таңсылу белән юлын бергә туры китереп, аны-моны уйламагандай гына сорап куйды:

— Таңсылу, синең сөйгән егетең бармы?

— Бар,— дип, бу сорауга күптән әзер сыман җавап бирде Таңсылу.

— Очрашасызмы?

— Монда юк ул... Хат алышабыз.

— Ә-ә... Күптәнме?

— Хат алышумы?

— Күптән танышсызмы дим?

— Бәләкәй чактан. Күршеләр без.

— Ә-ә...

Тынсылуның эш башка. Күрше белән очрашсаң, сөйләшсәң дә гаеп итмәсләр.

Сүз бишенчеләргә күчте. Зарланыбрак та алды югары белемле укытучыбыз. Айрат турында сүз чыккач:

— И шул йән көеге! — дип, көлемсерәп куйды Таңсылу. Шундый җылы итеп әйтте ул бу сүзне; яраткан баласы турында сөйләгән ана кебек. Яратмаслык бала түгел ул. Үзе генә Мәскүрәне яратып бетерми.

— Яраталар алар сезне,— ди Таңсылу,— телләрендә сез генә. Сезне бүтән класслардан көнлиләр алар, үзләренә генә каратып торасылары килә. Өйрәнгәннәр башлангычта...

Бишенчеләргә игътибар азрак шул. Тарих дәресләре дә атнага ике генә сәгать. Күбрәк булырга иде алар белән. Таңсылу бит дүрт ел гомерен гел аларга багышлаган. «Көндәше» белән шулай гади генә итеп сөйләшкәч, Мәскүрәгә җиңел булып китте. Эчен тырнап торган көнчелектән арынды ул.

Февраль аеның кояшлы бер көнендә класс активы белән күрше авылдан йөреп укыган өлгермәүче балаларның өйләренә барырга булдылар. Мәктәп ихатасына байтак укучы җыелган, барысы да чаңгыда. Айрат чаңгысын кими генә шул тирәдә урала. Үзен махсус чакырганны көтә. Мәскүрә юри игътибар итми моңа. Таяк бауларын беләзегенә киеп кузгалырга торганда, мәктәп капкасыннан кергән ак бүрекле берәүгә күзе төште Мәскүрәнең. Теге башкорт егете ич бу, эпекәем, шул! Каникулга кайткан! Әнә, ап-ак тешләрен елтыратып көлеп килә. Мәскүрә чаңгы

таякларын ике якка кадап, колачын җәйгәндәй хәрәкәт ясады, ләкин кузгалмады. Күрде бит, үзе килә! Чү, башка якка китте бит ул. Мәскүрә балалары белән бер читтә калды, кунак егет мәктәп ишегенә таба юнәлде. Баскычтан Таңсылу төшеп килә ич! Әнә алар ике куллап күрештеләр. Гади күрешү генә түгел бу. Кара-каршы биегән сыман кулларын тотышып, бер-берсенә карашып торалар. Әнә алар җитәкләшеп бәләкәй капка ягына киттеләр. Елмаешып, бер-берсенә карашып алалар.

Менә сиңа очрашу!.. Агыйделнең аръягында... Мәскүрә аңына килеп, тегеләрдән күзен алды, йөзендәге үзгәрешне балалар күрмәсен дип, чаңгы бавын яңадан чишеп бәйләргә тотынды. Кайда икәнеңне онытма әле син, Мәскүрә Кәримовна!

Бәхетле пар артыннан күзен алмый карап калучы тагын берәү бар иде. Тилмереп караган күзләрне күреп, таң калды Мәскүрә. Айрат иде бу. Кемне, кая озата бу сабый? Беравык хәрәкәтсез торгач, Мәскүрә күптәнге сердәшенә дәшкәндәй:

— Айрат, ки чаңгыларыңны, кузгалдык,— диде.

Кузгалдылар. Мәскүрә алдан китте. Кырга чыккач, Айрат классташларына карап, указ укыган тавыш белән игълан итте:

— Безнең апай бүген королева, гаскәрне һөҗүмгә алып бара!

«Безнең апай...», «Королева...» Мәскүрә турында бит бу! Айрат үзе, димәк, гаскәр башлыгы, яралы...

— И йәп көеге! — диясе килде Мәскүрәнең, Таңсылу сүзләрен исенә төшереп. Әйтмәде. Айратка беренче тапкыр елмаеп карап куйды. Җиңү тантанасы да, бала өчен борчылу да, кешегә ихтирам да бар иде «королева»ның карашында.

## Марзия Фәйзуллина

### Җәйнең тынлыгы

Инеш буе, бөдрә тал төбендә
Калгый иде җәйнең тынлыгы,
Кинәт яшен булып аяз көндә,
Килеп житте сугыш шомлыгы.

Ул сугышка китте, көрәшләрдә
Мең үлемнән калды котылып:
Актарылды аяк астында жир,
Өскә кургаш яуды котырып...

Күзләреннән тик яшь чыгармады,
Басалмады дәһшәт коллыгы.
Жиңеп кайткач...
Аның күз яшьләрен мөлдерәтте
Тал төбендә җәйнең тынлыгы.

### Нәни поши

Ату тавышы... Урман сукмагыннан
Чабып чыкты барлык көченә,
Килеп керде нәни бала поши
Көтмәгәндә лагерь эченә.

Сез яклагыз мине, дигән кебек
Безгә таба караш ташлады,
Аннан янгын өчен куйган суны
Чүмерә-чүмерә эчә башлады.

— Безнең янда кем дә тимәс! диеп,
Барыбыз да аны юаттык...
Күп вакытлар бездә кунак булды,
Тик бер заман кинәт югалттык.

Кайгырдылар нәни пионерлар
Нәни поши өчен шул чакта.
Тик бер көнне шатландылар күреп
Сигез тояк эзе сукмакта.

Шул эзләргә карап пионерлар
Исәнлеген аның белделәр.
— Ул үзенә иптәш тапканлыгын
Күрсәтте,— дип, шау-гөр килделәр.

## Роза Хәлиуллина

### Төсләр

Кайсы төс матур дисәләр,
Әйтер идем хагын:
Мактар идем ал, кызылын,
Сары, яшел, агын...

Зәңгәренә мәхәббәт зур
Минем күңелемдә,
Башка төс теләмәс идем
Туган ил күгенә.

Ә кайсын алыйм үземә,
Кайсы миңа кулай?
Кирәкми төннең карасы,
Бул син йолдыз, бул ай!

Акка каралар тимәсен,
Акны алам инде.
Нахак әйтелгән сүзләрдән,
Кил, арала мине?!

Зәңгәр һава төсе белән
Алыр идем алны —
Таңнарымны уртаклашыр
Алма кебек ярны.

### Түгим әле...

Түгим әле ак кәгазьгә
Эчемдәгеп барысын да:
Яратуым, яратмавын —
Үпкәләрне, сагышны да...

Яратуымнан алланам,
Миңа алай карама син,
Яратмыйсың, дип каралам,
Каралардан арала син.

Эзлим. Эзлим... Сине эзлим.
Эзләремдә таш ярала.
Тутлы миң булып калкасың
Ике кара каш арама.

Әллә юкка йөрим микән,—
Алда бәлки салкын томан?..
Ни сәбәптер, мин шулай да
Һәр таң саен юлга чыгам.

Иртәрәкме, әллә соңмы?
Иркәлекме соң бу, моңмы:
Кочагыма җилләр кергән,
Дулкын убә керфегемнән.

Кем белән кемнәр дус булмас?!
Гөлләргә гөлләрдер юлдаш.
Куктән болыт күзен кыса:
Юлың уңар... юлың уңмас...

Иртә түгел түгелен... Соңмы?
Иртә уңмаган — кич уңмас...
Иртәләрен уңмасам да,
Кичләрен бер уңмый булмас.

Юлларыма ник салдым соң
Өзеп күңел кылларымны?
Җилләр, җилләр, җуймассызмы
Минем зәгыйфь җырларымны?

Кырлар буйлап җилләр исте,
Инләп исте, иңрәп исте.
Басып торам урталыкта,
Җилләр игән сөмбел төсле.

Наз гынамы! Җәзасын да,
Ярасын да бирә җырлар.
Бер сагыштан, бер шатлыктан
Җаным җылар әле, җылар.

Мирхәт Хөснимәрдәнов

# ЮГАРЫ НОКТА

ОЧЕРК



Смена вакытында телефонга сирәк чакыралар иде. Кайбер шалтырауларга артык игътибар да итмисең, чөнки аппаратлардан күзне дә алырга ярамаган минутлар күп була. «Парткомнан сорыйлар»,— дигәч кенә Василий Иванович Юшков: «Нигә шулай ашыгыч кирәк булдым икән?» — дип, тиз генә трубкага тотынды. Партком секретаре Юрий Петрович Маслов икән. Хәл-әхвәлләрен бер-ике сүз белән генә сорашып, секретарь шунда ук төп мәсьәләгә күчте:

— Кара әле, туганкай, син Имаметдиновны беләсеңме? — дип сорады.

— Шамилнеме? Белмәскә, бергә, бер цехта эшлибез ич...

— Белсәң, әнә шул егеткә характеристика кирәк. Ничегрәк...

— Әйбәт эшли, норманы арттырып үти, җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Орденлы...— Василий Иванович шулай җиңел генә котылырга уйлаган иде.

— Тукта, тукта,— дип бүлдерде аны секретарь,— син миңа язмача бир.

— Ә-ә, язмача кирәкмени?

— Әйе. Кыска булсын, эше дә, кем булуы да тулы чагылсын. Сменаң бетүгә керәп чыгарсың.

Трубкада ишетелә башлаган кыска-кыска гудок тавышыннан аптырап калгандай, Василий Иванович бераз нишләргә белми басып торды һәм трубканы, кулында әйләндергәләп, сак кына итеп рычагка элде. Һе, алай икән, язмача кирәк икән. Үзең белән бергә эшләгән кеше турында характеристика язудан да кыен эш юк шикелле. Кешегә бәя бирергә мораль хакың бармы соң синең? Берәр югары урынга, җитәкче эшкә күчерәләрме икән әллә Шамилне? Юкка сорамый торганнардыр инде. Цехтан китә калса, кызганыч. Егете шәп, менә дигән! Цехта иң алдынгы аппаратчыларның берсе. Секретарь Александр Иванович Дуров үзе әйдә булса, бик тиз язып биргән булыр иде аны. Ялда шул. Ә ул, Юшков, цех партия бюросына күптән түгел генә сайланды. Шамил Имаметдинов кебек эшче кеше. Секретарь урынбасары итеп сайлап куюы белән генә әле бөтен нәрсәгә кул бара дигән сүз түгел бит. Әлегә кадәр бетенесе гап-гади иде: бер-береңне ярты сүздән аңлыйсың, кимчелеге булса, тел яшермичә иптәшләрчә итеп, күзенә карап әйтәсең, берниндн дә гаеплаш юк. Ә хәзер



ничек була инде: өнә шул бергә эшләгән цехташың турында, аны я яхшы, я начар, дип бәяләп, документ тутыр. Дөрес, Шамил турында беркем дә яман сүз әйтә алмас. Әмма мактау сүзләрен дә тиктомалдан гына, түшәмнән генә алып язып булмый бит. Бәлки ул характеристика бик мөһим җиргә китәдер, бәлки кешенең киләчәк язмышы хәл ителәдер?..

Беренче карауга цехта бөтенләй эш юктыр шикелле. Аппаратчы кызлар стенага ябыштырылган приборлар янына басып эч серләрен генә бүлешәләр төсле. Каршы яктагы тәрәзәгә якын урында кечкенә өстәл тирәсендәге берничә егет тә эшсезлектән аптырап басып торалардыр кебек. Шамил дә алар арасында. Ул ара-тирә генә килеп, кызлардан нидер сорап, аппаратларга, приборларга күз төшереп китә. Ул арада кызлар чәчелеп үз урыннарына барып басалар һәм прибор сызган сызыкларга, алар күрсәткән саннарга карап, кулларындагы кечкенә блокнотларына үзләре генә аңлый торган катлаулы саннар, химик формулалар язалар. Шулай итеп, алар тышкы ачык установка — изопрен цехының тәгәл эшләвен күзәтеп торалар. Кайдадыр берәр урында төгәлсезлек килеп туса, авария сигналлары шунда ук тревога суга башлый һәм шул вакыт кызларның йөзенә җитдилек бәреп чыга, алар яшен тизлеге белән төгәлсезлекне бетерү урынына ташланалар.

Смена начальнигы өстәлендә кабул итү дәфтәрләре. Анда цех хәрәкәткә килгән көннән алып һәр сменада килеп туган вак кына кимчелекләр дә язылып барыла, ул кимчелекләрне китереп чыгарган сәбәпләр күрсәтелә. Кем гаебе белән булганлыгын да теркиләр, төзәтү юлларын, яңадан булдырмау чараларын тәкъдим итәләр.

Вахтада икенче смена. Әлегә барысы да тәртиптә. Авария сигналлары ишетелми. Аппаратчыларның күзләре дә, колаклары да бик сизгер. Изопрен цехы тыныч сулыш белән сулый.

— Кызлар, мин тышкы установкаларны тикшереп керәм әле,— дип, Шамил чөйдә эленеп торган каскасын алып киде, брезент плащы кесәсендәге «аварийный» дип йөртелгән шөреп ачкычларын барлады һәм салмак адымнар белән тимер баскыч буйлап түбәнгә төшеп китте.

Аппаратчы кызлар аның бу гадәтенә күнегеп беткәннәр инде. Шамил приборлар күрсәткәнгә генә ышанмый, установкага үзе менеп карамыйча күңеле тынычланмый аның, диләр. Ләкин күңелдәгенең барын да башкаларга ярып салып буламыни? Әй-

тәрсең, үз итеп сөйләрсең, алар аңламаслар. Һәр кешенең үзе генә аңлый торган, үзе генә ләззәтләнә торган хисләре бар ич. Шамилдә дә бар алар. Комбинат күренешенә сокланып туя алмый ул. Бигрәк тә хәзер. Комбинат беренче еллардагы төзелеш пычрагыннан арынып килә. Цехлар арасында сузылган чәчәк түтәлләре, яшел скверлар, цехлар арасындагы юлларның ике ягы буйлап утыртылган нәфис ак каеннар күңелгә рәхәтлек бирәләр. Бүтән заводлардагы кебек, техника ыгы-зыгысы да юк, машиналар да тыз-быз чапмыйлар. Иң гаҗәбе — кешеләр сирәк, бик сирәк күренә. Әйтерсең лә, комбинат туктап калган. Әмма комбинат эшләвеннән бер генә көнгә дә, бер генә сәгатькә дә туктап тормый. Шимбә, якшәмбеләр дә юк биредә. Эшчеләр билгеләнгән сменаларына график буенча киләләр, приборлар каршысына басалар, комбинатның йөрәк тибешен, сулышын бик сизгерлек белән күзәтеп торалар.

Кич белән комбинат бигрәк тә серле булып әверелә. Сул яктагы биек трубадан чыгып янган газ ялкыны, берсеннән берсе узыша-узыша күккә күтәрелгән башнялар, колонналар, цехлар арасында үзара тоташкан эреле-ваклы трубаларны яктыртып, бөтен комбинатны нур белән күмгәндәй итә. Менә бу 44 метр биеклегендәге башня — тышкы установка — Шамил участогы. Аның бормалы-бормалы баскычларыннан акрын гына югары күтәрелергә ярата Шамил. Менгән саен тирә-як киңәя, колачын җәя бара, үзеңне очып китәр коштай сизә башлыйсың. Күңелең канатланып — тагын бер рәт баскычны үтәсең. Күрше цехларның биек колонналары өстеннән комбинат артындагы куе урман күренә башлый. Менгән саен менәсе, һаман югарыга таба атлыйсы килә. Тез буыннарың калтыраса да, тының кысылгандай булса да, туктап каласы килми, алга, югарыга үрмәләргә тырышасың. Чөнки сине анда — 44 ноктада гаҗәеп күренеш көтә: үсеп, киңәеп килә торган яңа шәһәр, киң Кама елгасы, яшел болыннар, асфальт юллар, тирә-яктагы иген басулары — никадәр матур аның туган ягы. Бигрәк тә өченче сменада — таң атканда күзәтсәң искиткеч. Кама буеннан күтәрелгән аксыл томан урман артыннан шуышып килеп сиздермичә генә яшьлек шәһәре — Түбән Каманы, аның таң йокысы белән рәхәтләнеп тиңгән хезмәт кешеләрен үз кочагына ала, иркәли, назлый төсле. Кайчандыр кайсыдыр бер китапта укыганы бар аның: күп катлы йортлары булган зур шәһәр кешеләренә хат ташучы почтальон 48 көндә Мон-Бланга күтәрелә алырлык юл үтә. Ә Шамил бу еллар эчендә, санап карасаң, шушы баскычлар буйлап айга менеп җитәрлек ара үтмәдеме икән? Кем җыеп кына үлчәгән аны!

Тормыш баскычларыннан да Шамил һаман шулай югарыга таба гына атлады. Нык басып, шикләнмичә... Атлаган саен, яшәгән саен тормышның мәгънәсен, аның матурлыгын, күркәмлеген күбрәк тоя барды. Намуслы хезмәткә зур хөрмәт икәнлеген сүздә генә түгел, чынбарлыкта татыды Шамил. Үз-үзеңә генә хуҗа булудан битәр шушы зур комбинатка хуҗа булу, бу минеке бит, моны булдыруда мин дә өлеш керттем, дип уйлый һәм тоя белү анда үзенең эшче булу халәтеннән зур канәгатьләнү, ләззәтләнү хисе уята иде. Аларны син очраган бер кешегә сөйләп бирә алмыйсың. Бу хисләр һәр эшченең йөрәк түрендә саклана. Завод коллективы белән бергә үткәргән соңгы кыенрак еллар аны бернинди кыенлык алдында да туктап калмаска, шүрләмәскә, һәр төрле авыр хәлдән дә ерып чыгу юлларын табарга өйрәттеләр. Гомер әле аз үтелгән, аз хезмәт ителгән. Шулай да хезмәт кенәгәсендәге буш юллар акрынлап тула бара. «Фәлән җирдә эшләгән вакытта мактау кәгазе алды», дип язылып куела икән, димәк, бу тикмәгән түгел. Ул сүзләрнең тирән мәгънәсе бар.

Моннан ун еллар элек Шамил Зеленодольск шәһәрендә киң профильле тимерчеләр әзерли торган һөнәр мәктәбен тәмамлады. Аңа туган ягы Мамадышка, райпромкомбинатка кайтып эшләргә юнәлеш кәгазе бирделәр. Ләкин һөнәр мәктәбендә үк инде кечкенә мәктәптә йөреп унынчыны тәмамлаган, тагын да укырга, хезмәт итәргә, дип энергиясе ташып торган яшь егет өчен ат дагалау, арба-чана кору, тәгәрмәч бөгү кебек бүген бик үк күңел тартмый торган эшләр генә башкару, шулар белән генә канәгатьләнеп яшәү тормышта төп максат була алмады. Күңеле үзе дә күз алдына китермәгән ниндидер зуррак эшләргә ашкынды. Әйе, күңел эзләнә, колач җәеп, бөтен көчеңне җигеп, бирелеп эшләрлек хезмәткә омтыла. Яше җитеп флотта хезмәт итеп кайткач, тынгысыз күңеле Шамилне Казандагы органик-синтез заводына алып килде. Менә, ичмасам, завод дисәң дә завод. Эченә кереп бөтен мәйданын җәяү йөреп чыгыйм дисәң, бер көндә генә булдыра алмыйсың. Әле һаман төзелә бара, ки-

һәя. Һәм Шамил, диңгездә йөзеп чыныгып кайткан егет, онытылып дәртле хезмәт дулкынына чумды. Изопропел-бензол цехында аппаратчы булды. Новокуйбышевск шәһәренә барып, стажировка үтте, имтихан тотты. Химия серләре бик четрекле иде. Шулай да Шамил сынатмады. Кайткач аңа тагын да зуррак эш йөкләделәр: өлкән аппаратчы иттеләр. Яңа цех сафка басты. Беренче продукция — изопрел-бензол аның сменасында алынды. Котлауларның, мактаушуларның исәбе-хисабы булмады ул чакта. Ләкин ул мактауларны Шамил үзе исеменә түгел, цех коллективы исеменә кабул итте. Алардан исерә торган чак түгел. Аз, бик аз әлеш кертте ул зур эштә. Шушы заводта аны коммунистлар партиясе сафына кабул иттеләр. Шунда эшләгәндә ул семья да корып җибәрде. Тормыш юлдашы да тырыш кыз булып чыкты. Эштән аерылмыйча икесе дә кичләрен укый башладылар. Шамил химия-технология институтына керде, ә хатыны Флера авиация техникумын сайлады. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын сузасың, диләр бит. Ә Шамилнең көндәлек тормыш арбасы шундый иде: хезмәт, уку, спорт, җәмәгать эшләре, китаплар... Бүтәнчә яшәүне күз алдына да китермәде ул. Бүтәннәрдән нинди аерымлыгы булгандыр, хезмәттә нинди батырлык күрсәткәндер, бусын һич тә башына сыйдырмый Шамил, җидееллык планны үтәүдә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен дип, аны 1966 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләделәр.

Җәе чыгып кына тора кайбер кешегә, диючеләр булгандыр, бәлки. Ләкин бу химия гигантын торгызганда Шамилнең йокысыз төннәрен, борчу белән тулы көннәрен, сменадагы бәхәсләрне берәү дә исәпкә алып бармаган. Җәе чыгар әле, дип кенә ятса, ай-һай, рәтле эш кыра алган булыр идеме икән? Алма пеш, авызыма төш, дип ятканчы, ул алманы үзең үстерү яхшырак. Яңага омтылыш аның тормыш кагыйдәсе, яшәү мәгънәсенә әверелде. Шулай булмаса, үзенә дан китергән, рухи канәгатьлек биргән, туган йортыдай булып әверелгән заводын калдырып, төпләнә башлаган семьясын урыныннан кубарып, тагын башка шәһәргә күчәргә, һәммәсен яңа баштан башларга батырчылык итәр идеме кеше?..

Комбинатның иң төп цехларыннан берсе булган дүртенче цех — изопрен цехы төзелә генә башлаган иде. Шамилне шушында монтажчылар эшенә күзәтчелек итәргә куйдылар. Ул монтаж эшләренең дөрес үтәлешен барлап торырга тиеш иде. Аның үткен күзеннән, үз эшенә җаваплы карашыннан, таләпчән һәм сизгер булуыннан киләчәктә цехның нормаль эшләве тәэмин ителәчәк. Цех коллективы әле оешып кына килә. Көн туган саен яңа кешеләр арта. Бер-берсен сынашалар. Кайдан син? Кем син? Нәрсәгә яраклы?..

...Шамил унсигезенче ноктага менеп җитеп, андагы приборларны карап чыкты, краннарны тикшерде. Барысы да тәртиптә. Барысы да әйбәт, тегәл эшли. Шуның өчен тырыштылар бит инде алар. Тегәл булсын, дип, монтажчыларның үзегенә үтәрлек тегәллек таләп итеп, бөтен көчләрен биреп тырыштылар.

Үткән елның карлы-буранлы феврале дүртенче цех кешеләренең күңелендә якты истәлек булып әле дә саклана. Ул көннәрдә һәркем аеруча киеренке хезмәт дәрте белән яшәде. Салкынга һәм күз ачкысыз буранга карамыйча, алар һәр метр трубаны (суза башласаң, аларны бу участокта гына да кырык километрга җитә, диләр), аерым һава басымы биреп, сабын эмульсиясе белән сынап-тикшереп чыктылар. Төн димәделәр, арыдык дип зарланмадылар. Сабын суы салкынга чыдамый ката башлагач, аңа спирт кушып трубаларны сынауны дәвам иттерделәр.

Цех сафка баскан көн чыннан да бәйрәм төсен алды. Бик озак шул күтәренке хисләр белән яшәделәр. Бу эшләр турында хәзер инде бары тик беркетмәләрдәге саран сүзләр генә хәтергә төшерәләр. Мәсәлән, цех партия оешмасының үткән отчет-сайлау җыелышы үзенең беркетмәләренә шундый сүзләр язды:

«Бу чор эчендә коллективның тырышлыгы көйләү-җибәрү эшләрен башкаруга һәм цехны эшләтә башлауга хәзерләнүгә юнәлтелгән иде. Коллектив цехны уңышлы рәвештә эшләтә башлады һәм Владимир Ильичның тууына 100 ел тулу көне алдыннан Түбән Кама комбинатында беренче изопрен алынды».

Шамил онытмый әле: үткән отчет-сайлау җыелышында аның исеменә мактау сүзләре әйттеләр, аңа йөкләнгән җәмәгать бурычларының да вакытында һәм тегәл

үзелеп баруын күрсәтеп үттеләр. Тик болар барысы да артта калдылар шул инде. Цех эшли башлагач та эш җиңеләймәде, таләпчәнлек көчәя төште. Аппаратлар тревога сузып кайсыдыр биеклектә, ниндидер трубаның гамәлдән чыгу куркынычы барлыгын, авария булу мөмкинлеген хәбәр иткән минутларда, кулларына кайнар пар килә торган резин шланг тотып хәбәр килгән биеклеккә — унсигезгә яки егерме дүрткә, утыз алтыга яисә кырык дүртенче ноктаның нәкъ үзенә — иң биеккә тиз-тиз йөгереп менүче аппаратчы кызларны күреп, кайчак Шамил үзе дә калтырап китә иде. Әгәр башлары әйләнеп китсә... Әгәр менеп җитә алмасалар? Юк, кызлар әле бер генә тапкыр да калтыранып калмадылар. Аларның һәркайсы инструктаж алган, белә: реактор блогында, мәсәлән, 0,6 атмосфера басымы даими булырга тиеш. Аның артып китүенә яки кимүенә юл куярга һич тә ярамый. Андый хәлнең ахыры хәерле булмаячак. Комбинат инде тиздән каучук эшләп чыгарачак. Каучук нәкъ менә алар, Шамилләр, әзерләгән изопреннан алыначак.

Каучукның нәрсәгә кирәклеген хәзер бала-чага да белә. Ләкин аның ничек тууын Шамил күптән түгел генә укып төшенде.

Менә тарихтан кайбер юллар: чын каучук агачы Бразилиядә үсә икән, аның исеме «гевея». Аннан чыккан сок, һавада тиз катып, сыгылмалы массага әйләнә. Бразилия сере акрынлап дөньяга таралган һәм Россиягә дә килеп җиткән. Ләкин үсемлектән каучук алу өчен Россия кырысрак ил шул. Анда аның чатлама суыклары да, карлы-бозлы яңгырлары да була. Кыскасы, каучук үсемлеге бездә көткән нәтиҗәне бирмәгән. Аннары колхоз басуларында тигез тасма булып «күксагыз» исемле үсемлек үстерелә башлый. Шушы үлән тамырыннан сузыла торган җилем (резинаны шулай дип атыйлар) алына икән, дип шаккатып сөйли халык. Соңга таба бик үк продуктив булмаган «күксагыз» тасмалары юкка чыкты. Чөнки 1932 елның июнь аенда Советлар Союзында беренче тапкыр ясалма каучук алына. Кушма Штатларда мондый каучукны ун елга соңга калып кына эшләргә мөмкин булган. Беренче ясалма каучук үзенең сыйфатлары белән натураль каучуктан түбән булган, билгеле. Ләкин галимнәр эзләнүдән туктамаганнар һәм, ниһаять, 1964 елда безнең илебездә беренче тапкыр изопрен газыннан каучук эшләнә. Бу инде фәннең яңа сүзе була. Ә Түбән Кама нефть-химия комбинатында алыначак каучукның аерымлыгы шунда: ул үзенең күп сыйфатлары белән натураль каучук белән ярыша ала.

Үткән елның беренче август төне вакыйгасы күпләрне аякка бастырды. Төнге сәгать уникеләр якынлашып килгәндә, күрше цехта (аны «Изопрен-3» дип йөртәләр) көтмәгәндә компрессорлар туктап калган һәм дүртенче цехта җитештерелгән изопрен газын кабул итүче булмаганлыктан, аны факел линиясенә тоташтыру өчен, запас кран задвижкасын ачарга кирәк булган. Аппаратчыларның берсе бик тиз тышкы установкага йөгергән һәм баскычлар буйлап югары үрмәләгән. Вакытында ачып өлгермәдеңме — шартлау булырга мөмкин. Өлгергәннәр. Аварияне булдырмый калганнар. Бу гадәттән тыш хәл уңае белән завод директоры приказы белән саксызлык, игътибарсызлык күрсәткән кешеләргә тиешле җаза бирелгән бирелүен. Ләкин ике сәгать буена әрәмгә янган кырык сигез тонна газны кире кайтара алмыйсың бит.

— Минем сменада да шундый хәл булгалады,— ди Шамил гаепле сыман,— ләкин ул безнең цех гаебе белән түгел. Күршеләр шулай кыен хәлгә куя.

...Күршеләр... Ә никадәр күп алар күршеләр! Әнә, Шамил инде утыз алтынчы ноктага менеп җиткән. Аннан барысы да аермачык булып күренә. Изопрен-3, Изопрен-5, Изопрен-6 цехлары түбәләрен күккә сузганнар. Әнә шунда — Изопрен-6 цехында — тиздән каучук алынырга тиеш. Ун еллык тырыш хезмәтнең җимешен күрү бәхетенә ирешүчеләрнең берсе булуы белән Шамил үзен бәхетле саный. Комбинат кешеләренең телендә бу көннәрдә бүтән сүз юк та. Бары тик каучук турында гына сөйлиләр. Завод идарәсендәге машбюро кызлары, беркемнән берниндн эш кабул итмичә, дәүләт комиссиясе өчен техник документлар басалар. Түбән Кама мәктәпләреннән укучылар цех тирәләрен чистартырга өмәгә килгәннәр. Шәһәр гостиницасында яңа кунаклар. Мәскәүдән дә, Казаннан да бар. Газета хәбәрчеләре, радио, телевидение операторлары, кинохроника режиссерлары комбинат парткомын әледән-әле борчып, соңгы яңалыкларны теркиләр. Җирле радио каучук алу буенча төзелгән махсус штабның оператив мәгълүматларын әледән-әле коллективка, бөтен шәһәргә җиткереп тора, тоткарлык булган урыннарны әйтеп бара, җаваплы кешеләрне кисәтә.

һәммәсендә бер уй: бер теләк: тизрәк, тизрәк! Комбинат коллективының партиябезнең егерме дүртенче съезды хөрмәтенә алынган йөкләмәсен үтәү алдында торган бу көннәрдә — сентябрь—октябрь айларында — дүртенче цех кешеләрен ничектер исәпкә алмаган да шикелле булдылар. Барлык игътибар алтынчы цехка юнәлде. Ләкин комбинат кешеләре беләләр: каучук изопреннан алына һәм аны комбинатның дүртенче цехындагы уңган куллар җитештерә.

...Шамил тышкы установканың иң югары ноктасына менеп баскан. Комбинат аның каршысында бөтен тулылыгы белән җәелеп ята. Уң якта Түбән Кама утлары җемелди.

Җиңү октябрь аенда килде. Ай башларында каучук ала башлау өчен барысы да әзер иде инде. Аппаратлар хәрәкәткә килделәр... һәм изопрен каучугының беренче 30 килограммы өстәлгә куелды. Таң алды иде. Берсе дә китмәде, күзгә йокы кермәде. Митинг булды. Мактау сүзләре яуды, партия өлкә комитетыннан, Татарстан хөкүмәтеннән һәм җәмәгать оешмаларыннан килгән котлау телеграммаларын укыдылар.

Бу көнне комбинатның дүртенче цехы начальнигы бүлмәсендә Шамил Имаметдиновка КПСС Түбән Кама шәһәр комитеты соравы буенча характеристика яздылар. Озын булмады ул. Машинка кәгазенең яртысын гына биләде.

«...Комбинатта эшләү дәверендә үзен намуслы, хезмәт сөючән, дисциплиналы итеп күрсәтте. Цехны эшләтә башлауга әзерлек һәм аны җибәрү чорында аеруча тырыш булды, үз эшен оста белүче итеп танытты һәм бик актив эшләде. Җәмәгать эшләрендә бирелеп катнаша. Иптәшләре арасында зур ихтирамга ия. Быел комбинатның партия комитеты составына сайланды...»

Бөтенесе менә шул. Кыска гына җөмләләр белән язылган бу гади һәм саран сүзләрнең тирән мәгънәсе бар. Комбинатның дүртенче цехындагы кешеләр, алар башкарган күркәм эшләр турында олы сүзләр бу.

◇◇◇◇◇◇◇◇◇

Мөхәммәт Садри

# НУРИ АРСЛАНОВ ПОРТРЕТЫНА БЕРНИЧӘ СЫЗМА[1]

Шагыйрь Нури Арслановның «Моңсар» дигән легендасы бар. Моңсар — халыкның, илнең турылыклы улы, аның моңын, теләген җырлаучы үткен телле, туры сүзле, батыр йөрәкле, ирек яклаучы җырчы-көрәшче.

Җил — җилмени, нык исеп,
Болытларны кумаса?!
Ир — ирмени, ил яклап,
Яуга каршы тормаса?!

Нури Арсланов үз сүзенә, үз антына турылыклы ир була: Бөек Ватан сугышы башлангач, кара көчкә каршы яуга китә, һәм сугыш кырында илен яклап батырларча сугыша, яралана. Госпитальдән соң кабат алгы сызыкка бару насыйп булмый, әмма ул көрәш сафыннан чыкмый, халыкка каләме белән, җыры белән хезмәт итә башлый. Моңа ул җырның көчле булуына, аның үлемсезлегенә чын күңелдән ышанып керешә:

Җырны чабар балта юк
Бөтен дөнья йөзендә.
Хакыйкать бар, хата юк
Минем шушы сүземдә!
...Бер кабынса — җыр сүнми,
Җырчы үлә, җыр үлми!

Нури Арсланов поэзия мәйданына «Мәхәббәт» [1942] һәм «Рус кызы» [1943] поэмалары белән килеп керә. Аның госпитальдә язган беренче поэмасында Тамара исемле рус кызының сугышта яраланган татар егете Батырҗанов белән зур дуслыгы, мәхәббәте тасвирлана. Ә «Рус кызы»н да шагыйрь баһадир Зояга бөтен халык мәхәббәтен җырлый. «Рус кызы» поэмасы, авторның әле тәҗрибәсе җитенкерәмәвенә, анда купшы-риторик строфалар өстенлек итүенә карамастан, ул вакытта бу темага язылган җитди, зур әсәр, чын йөрәктән туган, заманның типик, патриотик кайнар хисләре чагылган әсәр буларак, укучылар күңелендә тирән эз калдыра.

Аннан соң ул «Йөрәк» исемле поэма яза. Бу поэмада искиткеч саф йөрәкле, көчле иктыярлы, гүзәл татар кызы Гөлсемнең үз мәхәббәтенә турылыклы булуы сокландыра. Гөлсем, үзенең Сәлиме дип ышанып, госпитальдән аяксыз-кулсыз, хәтта телсез калган, йөзе дә танып булмаслык хәлгә килгән, инде йөрәге, җаны гына булган бер солдатны өенә алып кайтып тәрбияли. Чынлыкта исә ул Сәлимнең фронтташ иптәше разведчик Шакир булып чыга. Соңрак партизан Сәлим үзе дә өйгә кайтып төшә.

[1] Шагыйрьнең быел чыгачак сайланма әсәрләре кульъязмасын укыганда уйланулар

зур батырлыгы, кешелеге Сәлимне дә таңга калдыра. Яңа җәмгыять, кешеләрнең яңача мөнәсәбәтләрен чагылдырган, тирән гуманизм рухы белән сугарылган, тетрәткеч эчтәлекле бу әсәр Нури Арслановның иҗади уңышы, яңа үсеш баскычы булды.

Шунысы да характерлы, Арсланов үзенең поэтик иҗади эшен, эзләнү, яну, сызлануларын икенче бер хезмәт белән рәттән алып бара. Бөек Ватан сугышына кадәрле сәнгать техникумыннан килеп Кукмара ФЗС мәктәбендә рәсем һәм сызымнан укыткан, аннары «Пионер» журналы белән «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә рәссам булып эшләп, шул вакытта ук Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян кебек шагыйрьләрнең үзләрен якыннан белеп, иҗатларын өйрәнгән Нури Арсланов Бөек Ватан сугышыннан соң «Социалистик Татарстан» газетасының рәссаме була.

Ләкин аның зур һәм кайнар хисләре рәсем сәнгатендә генә чагылып, сурәтләнеп бетә алмый. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә:

Диңгезнең дә хәтта бар чиге,
Тик чиге юк хисләр агымының!

Хисләре шулай ташыганга күрә, ул яңадан-яңа поэтик киңлекләргә чыга, үзенең төп көчен яңа поэтик әсәрләр иҗат итүгә, яңа образлар тудыруга туплый. Әйе, Нури Арсланов чынлап та «шигъри рәсемнәр» ясауга күчә. Бөек совет халкының тиңдәшсез җиңүле көрәшен күрсәткән «Мәхәббәт», «Рус кызы», «Йөрәк» поэмаларыннан соң, ул башка халыкларның азатлыкка омтылышларын чагылдырган әсәрләр иҗат итә. Америка илбасарларына каршы көрәшкә күтәрелгән Корея халкына мәхәббәт белән сугарылган «Айхян белән Ли», «Давыл кызы» [Корея легендалары], «Корея гөле» дигән тылсымлы әкиятләр язып бастыра. Шул ук 1950—1955 елларда без аның «Яшьлек чишмәсе», «Көзге», «Рәссам» дигән әкиятләрен укыйбыз. Газеталарда һәм журналларда кыска-кыска, ләкин тирән эчтәлекле, күтәренке рухлы шигырьләре, тәрҗемә әсәрләре ешрак күренә башлый. Совет халкының лаеклы улы булуына шагыйрь шатланып туя алмый:

Шатланам туган халкымны
Сөя белгәнем өчен,
Бергә куанып, елмаеп
Көлә белгәнем өчен.
Ил кайгырса, бергә янып
Көя белгәнем өчен,
Чакырса мине — утларга
Керә белгәнем өчен!

Аның «Дустымны сагынганда», «Зөя», «Баулылар», «Таң», «Хәерле иртә, Казан!» «Кырчы егет — бурильщик», «Зөбәрҗәт», «Идел диңгезендә», «Салих Сәйдәшевне озатканда», «Шат күңеллелек сере», «Дулкыннар», «Казан», «Син елмайсаң сабый бала сыман...», «Республикам минем», «Башкорт кардәшемә», «Үгет» кебек шигырьләре композиторлардан Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Нәҗип Җиһанов белән бергә язган җырлары уңыш казана. Авторның лирик парчаларында рәссамның төгәл күзәтүчәнлеге осталыгына табигый рәвештә шагыйрь йөрәгенең тибеше килеп кушыла:

Пушкин үзенең Петроградын мактап,
Ак төннәрен мактап туймаган...
Мин урамнан барам аны ятлап,
Тирән хискә чумып уйланам.
Күргәнем бар минем ак төннәрне.
Ә Казанда менә ак таңнар:
Агачлары — гүя таң гөлләре
Ап-ак кардан чәчәк атканнар...

Поэзия сүз сәнгатенең иң югары төре санала. Чын шагыйрь исә үзенең шагыйрьлек бәхетен, заманының алдынгы идеяләре белән баетып үз лирикасында чынбарлыкны җырлый, кешеләрне алга, яктылыкка өнди, кара көчләргә каршы яшен булып ташлана. Шагыйрь сүзе—изге сүз. Борын заманнарда шагыйрьгә изге кеше итеп кара-

ганнар һәм «аллалар белән шагыйрьләр генә иҗат итә» дип торган булганнар. Чөнки зур көч иясе шагыйрьнең ялкынлы поэтик юллары йөрәкләрне тетраткән. Поэзиягә энә шулай югарылыктан карап якын килгәндә, заманыбызда бу мактаулы эш белән шөгыльләнүчеләргә теге яки бу планда ташлама ясау, ялган авторитетларга түземлелек күрсәтү, «типография станокларыннан чыккан бөтен нәрсәне дә» поэзия дип санау — бөек традицияләребезгә каршы килү һәм безнең танылган әдәбиятыбызның авторитетын төшерү булыр иде. Бу юлларны, бу фикерләрне мин, аңлы рәвештә, Нури Арсланов чын шагыйрь, алдына зур таләпләр куярга лаеклы шагыйрь булганга язам. Авыр сынау елларында Ватан өчен утны-суны кичкән, дошманны җиңү эшенә үзенең канын коеп өлеш керткән шагыйрь, поэтик осталыгын чарлаган саен чарлап, кыю һәм актив иҗат итеп үзен, башында бөек Тукай торган яңа зур поэтик культурабызны тагын да баету өчен көрәшүче солдат итеп танытты.

Киң катлау укучылар Нури Арслановны аның партияле әсәрләре өчен, коммунистлар партиясе эшенә бирелгәнлеген практик эштә күрсәткәне өчен якын итәләр. Аның шигырьләре, җырлары, поэма һәм легендалары халыкчан яңгырый, аларда партия рухы, Ватанга мәхәббәт көчле.

Берничә ел буена күп көч салып, шагыйрь «Егет яуда сынала» дигән эпик әсәр язды. Бу әсәрдә Нури Арсланов халкыбыз улларының тиңсез батырлыкларын, халыклар дуслыгын олылый, Ватанга, Татарстанга, Казанга мәдхия җырлый, татар халкы белән рус халкының мәңге какшамас дуслык тамырлары тирәндә булуын сәнгатьчә эшләнгән поэтик юллар, фикерләр белән дәлилли. Кайбер урыннарда күзгә чагылып үткән кимчелекләренә дә карамастан, «Егет яуда сынала» поэмасы безнең чорның елъязмасы булып яңгырый. Һәм ул, минемчә, бигрәк тә шуның өчен игътибарга лаеклы әсәр дә.

Татар кем ул? Эштә, көрәштә,
Дуслар белән бердәм киңәштә,
Азатлыкның якты нурында,
Бөек остаз Ленин юлында
Фидакарьлек өчен антын ул
Каны белән язган халкым ул.

Рус халкының бөек юлында,
Бергә барган татар, кулына
Үч кылычын бергә сайлаган,
Азатлыкны бергә даулаган.
Шул бердәмлек өчен антын ул
Каны белән язган халкым ул.

«Егет яуда сынала» дигән поэмада мондый камил эчтәлекле юлларны һәм строфаларны күп очратырга була.

Нури Арсланов соңгы елларда «Казан утлары» журналы редакциясендә эшли, аның поэзия бүлеген җитәкли. Шул ук вакытта ул иҗатында да искиткеч активлык күрсәтә. Шул активлык өстенә, аның әдәби кичәләрдә, атналыкларга еш катнашып, әсәрләрен халык бәяләвенә куюын өстәсәк, шагыйрьнең алга барудагы иңкенче бер өйбәт юлы да ачыкланыр. Аның бу соңгы елларда язган «Гамьсезлектән җырлый диләр мине...», «Үз-үземә ризасызлык», «Яшьлегемнең чая аты», «Яр буйлатып чаба дулкын», «И, бичара, корган агач», «Йорт казлары», «Өмет», «Чегән кызы», «Нигә хаҗәт», «Үрдәкләрем-дүдәкләрем», «Майра», «Әти белән сөйләшү» шикелле уйландыручан, фәлсәфи, сәнгатьчә нәфис эшләнгән, формалары белән шактый камил шигырьләрен кайта-кайта яратып укыйсың. Менә аның «Казан кызы»нда нинди халыкчанлык:

Атлыйсың тиз-тиз генә,
Аякларың тәз генә,
Укчаларең без генә,
Тимәс микән күз генә...
Үзәкләрем өзелә лә
Әйтсәнә бер сүз генә!

сафта эш белән янып, әнә шулай иҗат итә.

Шагыйрьнең тәрҗемә өлкәсендә дә күп эшләвен әйтергә кирәк. Ул илебез һәм дөнья халыклары шагыйрьләренең даһи юлбашчы В. И. Ленин турында язган әсәрләрен тәрҗемә итеп бастыра. А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов, Д. Г. Байрон, И. В. Гете, Гомәр Хайям, Мәхтүмколый, Я. Райнис, Р. Г. Гамзатов һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләре аның тәрҗемәсендә мәгънәләрен һәм нәфисләкләрен тулы саклыйлар.

В. Г. Белинский үзенең «Иван Андреевич Крылов» дигән мәкаләсендә, бөек мәсәлченең ике хезмәтне бер-беренә бәйләп алып баруын мактап, ә кайбер бушбугаз кешеләрне тәнкыйть итеп, болай дип язган: «Хәзер без әдәбият өчен казна (хәзергечә — дәүләт. М. С.) хезмәтен ташлаучы буп-буш кешеләрне еш очратабыз, хезмәттә алар ичмаса юньле генә писарь була алырлар иде, ә әдәбиятта беркем дә була алмыйлар».

Күрәсез, бөек тәнкыйтьче туар-тумас ук «профессиональ» булырга ашыгучылар бакчасына таш ташлый. Нури Арсланов кебек, берәр эштә эшләп тә иҗат итүче кешеләрне бик хаклы мактау бу. Утыз ел буена дәүләт эшендә эшләп, утыз ел буена иҗадыңны актив дәвам иттерү — бу бит үзе бер батырлык. Ләкин безнең шагыйребез һаман да әле яшьлек дәрте белән эшли һәм иҗат итә:

Картая төштем инде шул бераз:
Биш гомер булмый, бер гомер — бик аз.
Бәхет яшәртә, өмет яшәтә.
Туймадым, туймам йөзне яшәп тә!

Бу мәкаләне язып утырганда, «Казан утлары» журналының чираттагы саны килде. Нинди яңа әсәр бар икән дип, берничә битен ачкан идем, Нури Арслановның яңа поэмасын күреп алдым. «Романтика» дип атала ул. Минем аны кульъязма хәлендә үк укыганым бар иде. Тагын укыйм. Чыннан да дулкынланып укырлык поэтик әсәр, сокландыргыч әсәр язган шагыйрь. Бала чагында күргән революция солдатларын, революция көннәрен, даһи Ленин турында беренче ишеткәннәрен, күңеленнән кичергән саф хисләрен бүгенге чарланган каләме, олы йөрәге, олы хисләре белән язган. Шагыйрь яңа иҗат иткән поэмасын утыз еллык хезмәтен туплаган җыентыгындагы поэмаларга беренче итеп, әйдәп баручы командир итеп куйган. Минемчә, дөрес эшләгән. Чөнки анда бөек Октябрьга, даһи Ленинга, җиңүчән революцион халыкка шагыйрьнең үткәндәге онытылмас кайнар карашы гына, якты хисләре генә түгел, ә бүгенге зур мәхәббәте, бүгенге кредосы чагылган. Поэма, шагыйрьнең зур уңышлы эше, иҗади бәхете. Ә «бәхет — яшәртә» ди шагыйрь. Димәк, «Романтика» Нури Арслановның яңа бәхете, яңа яшьлеге ул!

# ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ИҖАТЫ

Шагыйрьләрнең язмышы төрлечә була. Кайберәүләр, яшьтән сәләтле булсалар да, иҗтимагый яктан әһәмиятле шигырьләр язып, җәмәгатьчелек тарафыннан танылганчы, шактый озак эзләнү чоры кичерәләр. Ә кайберләре исә үз тавышларын таба алмыйча, вак-төяк белән мавыгып йөриләр һәм шул килеш бөтенләй югалып калалар.

Ләкин шагыйрьнең таланты кайчан гына ачылмасын, аның әдәбиятны аңлый белүе, сүзнең нечкәлеген тоюы, зур һәм әһәмиятле темаларны яктыртырга омтылуы яшьтән үк формалаша. Сәләтле яшь кешеләрне әнә шул юнәлештә тәрбияләүгә Горький исемендәге әдәбият институтында, бигрәк тә аның лаборатория-семинарларында, еруча күп вакыт бирелә. Болардан тыш, безнең институт, аерым алганда безнең семинар, бик күп милләт вәкилләрен берләштерә һәм, шулай итеп, аларны үзара рухи якынайта, аларның уй-фикерләрен киңәйтергә ярдәм итә.

Безнең семинардагы кызыклы студентларның берсе — татар егете Разил Вәлиев. Үзенә һәм иптәшләренә таләпчән, күпсүзлелекне һәм риториканы сөйми торган бу егет үзе белән бергә укучы иптәшләренең шигырьләрен татарчага тәрҗемә иткән һәм аларны «Казан утлары»ның таләпчән укучылары хөкеменә тапшыра.

Разил Вәлиев шигырьләрен журнал укучылары, мөгаен, укыганнары бардыр. Аның әсәрләре хәтта безгә, авторның туган телен белмәгән кешеләргә дә кызыклы.

Журналның бу санында шигырьләре урнаштырылган шагыйрьләр характерлары белән дә, язган әйберләре белән дә төрлесе төрлечә. Аларның байтагы, мәсәлән, тынгысыз алтайлы Бронтой Бедюров, уйчан кумык кызы Шейит-ханым Алишева, нык ихтыярлы һәм кайнар дәртле балкар Али Байзуллаев татар теленә тугандаш телдә язалар.

Бу журналда шигырьләре белән катнашучы иптәшләр әле яшь әдипләр. Аларның күбесенең хәтта беренче китаплары да басылып чыкмаган. Ләкин алар әдәбиятка һәркайсы үз тавышлары, үз темалары, үз уй-фикерләре белән килүчеләр. Шуңа күрә миңа алар белән эшләү кызык та. Мин аларның барысын бертөрле уйларга түгел, бәлки һәркайсын үзенчә уйларга, һәркайсына үз сукмагын табарга ярдәм итәргә тырышам.

Холыклары һәм язган әйберләре ягыннан төрле-төрле булсалар да, бу яшь әдипләрнең барысына да хас уртак сыйфатлары да бар: алар һәркайсы замана балалары, үз туган илебезнең уллары һәм кызлары, барысы да алга, якты киләчәккә омтылучылар.

Поэзиядә үз тавышыңны яшьтән үк эзләргә, яшьтән үк иң авыр эшләргә тотынырга, бер-береңнең әсәрләрен тугандаш халыклар телләренә тәрҗемә итешеп яшәргә кирәк. Шул җәһәттән караганда, иптәшләренең әсәрләрен туган теленә тәрҗемә итеп һәм шулар янына үзенең бер шигырен дә кушып, «Казан утлары»на тапшыруы белән Разил Вәлиев бик күркәм эш башкара.

ЛЕВ ОШАНИН.

## Александр Гаврилов

Русчадан

### Эзләр

Кеше үтте диңгез яры буйлап,
Чылбыр булып япты эзләре...
Дулкын юа — эзләр барыбер кала..
Юылмастыр кебек үзләре!

Диңгез дулкыннары һәм кешеләр
Көрәшәләр мәңге тир түгеп...
Ә мәңгелек бар эзләрне юа
Һәм эзләрдә кала мәңгелек.

## Александр Антонович

Русчадан

### Яз белән саубуллашу

Нишлим инде,
Тагын үз күңелем,
Нишлим инде, тагын үз җаным...
Кошлар җыры тиздән онытылыр —
Көзгә таба инде юл алдым.
Яз аенда — иң зур рәхәт, ләззәт,
Серле тавышларда сихер бар.
Урманнарда дәрвишләнеп йөрү,
Учак янындагы юлчылар...
Урманнарга язын күк төс керә,
Урман аша кырлар күренә.
Манарасы белән күзгә кереп
Чиркәү тора аның түрендә.
Ул чиркәүдә безгә җырларга да,
Озатырга да хәтта үлгәнне,
Башны орып бәхет ялварырга,
Еларга да туры килмәде.

Яз аенда дөнья шундый гади!
Ә шулай да никтер ялгышам.
Бар агачлар олы юлга озата,
Шигырьләргә сеңә сагышлар.

## Али Байзуллаев

Балкарчадан

### Зәңгәрсу кыялар

Гөр килә сабыйлар уены,
Чияләр чәчәге коела.
Аларган тауларга күз салам:
Алдымда зәңгәрсу кыялар.

Җырлады егетләр туйларда.
Чем-кара күзләрдә — дөньялар.
Аналар, апалар куанды,
Дәшмәде зәңгәрсу кыялар.

Китәләр дөньядан бабайлар,
Үзәннәр кайгыга урала.
Ә таулар һаман да бер көе,—
Тик тора зәңгәрсу кыялар.

Гомерләр, дәверләр узалар.
Сугыш бар... каберләр... туйлар бар...
Мәңгегә торырлар бу таулар,
Торырлар зәңгәрсу кыялар.

## Зөлфәт Шаһбазов

Башкортчадан

### Кайтмадыгыз

Янгыр яуган чакта перроннарда
Күпме көтте сезне әсәйләр[1].
Янгыр яуган чакта перроннарда
Калды сезгә дигән чәчкәләр...
Кайтмадыгыз...
Сездән башка үсеп
Орлык тулды яшел арышка,
Сездән башка, билкәйләрен сузып,
Ярсу атлар китте ярышка.
Кайтмадыгыз сабан туйларына,
Печән өсләренә, уракка...
Кабатлансын өчен җирдә алар
Күмелдегез көлсу туфракка.
Юкка гына алма кебек кызлар
Перроннарда сезне көттеләр.
Тәгәрмәчләр авыр сагыш тулы
Йөрәк сыман кагып үттеләр.
Кайтмадыгыз...
Туган бусагадан
Унҗидедә киткән оланнар,
Кин Рәсәйдә һаман көтә сезне
Яңгыр яуган чакта перроннар...

## Бронтой Бедюров

Алтайчадан

### Тулган ай әкияте

Ястык итеп язымны
Ятам мин күккә карап.
Җылы сүзләр табалмыйм...
Җил, сагышымны тарат.

Серле, сихерле сүзләр
Йөри колак янымда.
Тотам дип кулым суздым —
Очты-китте тагын да.

[1] Әсәйләр – әнкәйләр (башкортча).

Баш очымда, биектә,
Илемнең тау-ташлары.
Күзләремнең төбендә
Илемнең аккошлары.

Күзем ачам,
Күзем йомам...
Тыңлыйм күкнең тавышын,
Кошлар оча,
Кошлар кайта
Барысы — илем кошы!

Ап-ак, көмеш канатлар
Җилгә тиеп сызгыра.
Телләремә алтайча
Иң кадерле сүз куна.

Яшел ястык язымны
Онытып кошлар санадым.
Кошлар булып кайтучы
Сүзләремне таныдым.

Җанымдагы сагышлар
Яшькә кушылып актылар.
Чит телләрдә адаштым...
Кошлар килеп таптылар.

## Альгирдас Комендантас

Литовчадан

●

Төн. Тынлыкка чумган бөтен дөнья,
Атларыбыз дагаланмаган,
Җирләребез әле сөрелмәгән,
Кошларны да курку алмаган.

Ә мин әле шушы көнгә кадәр
Куркынычның үзен күрмәдем.
Табигатьтән күпме нәрсә алдым!
Ә үзенә берни бирмәдем.

Мин табигать баласыдыр, ахры,
Кошлар мине сүзсез аңлыйлар...
Урманнарым шундый кешелекле! —
Бар афәттән мине саклыйлар.

## Анатолий Старостин

Якутчадан

●

Мин Себер, тундра улы,
Телим тынычлык, тынлык.
Мин әзер боздай эрергә,
Я яшәргә үз илемдә
Бер кәрлә каен булып.

●

Бүлмәм минем ялгызлыктан тилмерүче йөрәк кебек.
Өстәлемдә саф чәчәкләр—дустым китте мина биреп.
Тәрәзәмнән ил күренде, чәчәкләрдән бозлар эреп.

## Мурат Калмыкаев

Нугайчадан

### Сагыну

Кайтсам икән, Җиленчәгем[1], катына,
Күрсәм икән дулкынында ай юлын.
Күмәр идем хәсрәтемне комына,
Бүләр идем җан дусындай кайгымны.

Кайтсам икән, Җиленчәгем, ярына...
Шифа суың җан гөлемә охшаган.
Кобан[2] иле сеңгән минем каныма,
Тамырларым эсселектән сусаган.

Кайтсам икән, Җиленчәгем, янына...
Күңелләрем тартыла гел аклыкка.
Бер утырсам дулкын юган ташына,
Тулыр иде киң күкрәгем шатлыкка.

Җиленчәгем хәләл сөттәй кадерле,
Ул мәңгегә тугры калган ярына.
Җырчы килеп сиңа колак сала да
Яңа моңнар таба үз җырларына.

## Шейит-ханым Алишева

Кумыкчадан

●

Еллар үтә,
Айлар үтә,
Үтә сәгать, минутлар.
Җитә дә күк,
Җитми дә күк
Морадына өметләр.

Бераү туа,
Бераү үлә,
Шатлыкка кушыла бала.
Ә җир шары
тыныч кына
Әйләнә дә әйләнә.

### Берәүгә

Укыганда
Шигырьләрем
Нигә борының чөясең?
Сөюне куй,
Башка нәрсә
Язып кара диясең.

Мәхәббәттән
Авырыйм мин,
Ләкин кәтмим азагын.
Хәзер язмый
Бу сөюне,
Әйт сон, кайчан язармын?

[1] Җиленчәк — нугайлар яши торган Кавказдагы елга.
[2] Кобан — Кубань (нугайча).

Разил Вәлиев

## Әнкәйгә хат

Мне страх не нравится,
Что ты поэт...
С. Есенин.

Үпкәләмим, сөйләмәдең, диеп,
Уитмен һәм Лорка турында,
Сорый идең: «Улым, Зәй артында
Күк белән җир нигә орына?»
Матурлыкны аңлый белү өчен
Нигә сиңа белү Шишкинны!
...Хәлең ничек, билең сызламыймы?
Безнең монда алты эш көне.
Шәһәр матур, анда яшәү рәхәт,
Анда бәхет, диеп алдадым.
Моңсуланып банан ашап йөри
Балан ашап үскән малаең.

Гүргә түгел, илгә китәбез бит,
Елап бардык ләкин юл буе.
Озатып калды кое, синең өчен
Иң кадерле нәрсә шул кое.
Шул коеда синең бар фәлсәфәң —
Без мәңгелек, дисең, кое күк.
Ә шулай да күз алдында йөзең
Еламсырап тора, боегып.

Өй алдында, сиренага охшап,
Гүли микән һаман багана?
Тәрәз аша синең күз нурларың
Кояш нуры белән ялгана.

Киттек инде, киттек, теләп киттек.
Туган йорттан беркем кумады.
Кая барсак ай ияреп барды,
Һәр урманда бүре улады.
Без китүенгә юллар сөенделәр,
Җирләр гизеп аяк арыды...
Улларыңны саклый алмадың син,
Инде үзеңне сакла, ярыймы?!

||||||||||||||

Рафаэль Мостафин

# «ОЖҪМАХ»ка СӘЯХӘТ[1]

## Сулда — Африка ярлары



Кайчагында кечкенә генә бер вакыйга да синең теге яки бу кеше турында инде ныгып барган фикерләреңне чәлпәрәмә китерә.

Матрос В. миндә башта әйбәт тәэсир калдырды. Мин аны бернинди хәйләсез, киң күңелле, авыл кешеләренә хас булдыклы, аек акыллы, һәр нәрсәне файдалы булырлык итеп, уйлап кына эшләүче кеше дип күңелемә беркетә башлаган идем инде. Ул безнең Чарлик турында бөтен кешедән дә күбрәк кайгырта. Көчекне иң яраткан ашамлык — тозлы кыяр белән сыйлый, аңа чи йомырка эчертә, арыш ипиеннән сохари киптерә. В. палубадагыларның барысыннан да өлкәнрәк — ул инде утызның теге ягында, ике бала атасы. Аның эшләвен карап торуы үзе бер гомер: хәрәкәтләре салмак, ләкин эшне тиз һәм җиренә җиткереп башкара. Күгәрек чистарта башласа, җиһазларның иң кысен урыннарына кадәр кереп, бер генә тап калдырмыйча ялт иттереп куя. Бортны буяганда пумаланы кыл өстендә йөрткән кебек төгәл йөртә һәм, бераз буягач, бер-ике адым артка чигенеп үз эшенә сокланып карап тора. Кыскасы, бетмәс-төкәнмәс палуба эшләре остасы ул. Һәм менә мин аны

[1] Дәвамы. Башы икенче санда.

Латакиядә, базар почмагындагы үтмәс товарлар яки, бездәгечә әйтсәк, бәясе төшерелгән әйберләр сатыла торган бер кибеттә күрәм. Ул кара җирлеккә юл-юл булып төрле төстәге ялтыравык җепләр төшкән япон тукымасы сайлап тора. (Диңгезчеләр бу тукыманы «оек» дип йөртәләр. Одесса чегәннәре аннан гаять дәрәҗәдә модалы һәм, минем карашымча, гаять дәрәҗәдә зәвыксыз галстуклар тегеп саталар.) В. тукыма кисәкләрен бер-бер артлы кулына ала, тартып-тартып ныклыгын тикшерә, яктыга куеп карый һәм кызып-кызып сатулаша. Ул бу эшне шул кадәр бирелеп эшли ки, хәтта тирә-ягында кемнәр бар икәнен дә күрмәс дәрәҗәгә килә, куллары калтырый, күзләре ялт-йолт итә башлый. Үз корабымдагы диңгезченең бу кыланышыннан мин уңайсызланып куям һәм аңа күренмичә генә кибеттән чыгып китәргә мәҗбүр булам.

Соңыннан миңа В.ның кооператив квартирага акча җыюы турында сөйләделәр. Чит илләргә йөзгәндә диңгезчеләргә валюта[1] бирелә. Атналар буе тукталышсыз килгәндә шактый гына җыелган акчага диңгезчеләр төрле истәлекле әйберләр, бүләкләр алалар. Ә менә В. шикелле кайберәүләр шушы мөмкинлекне илгә кайткач акча җыю өчен файдаланалар. (Әлбәттә, таможня нормаларын бозмыйча...)

В.ның бу эшен ничек бәяләргә? Фатир алырга теләү бик табигый теләк. В. урламый, үз куллары белән эшләп тапкан акчага сатып ала. Чит ил диңгезчеләре бу эшне тулысынча законлы рәвештә акча табу юлы дип исәплиләр икән. Ләкин бит ул чит ил диңгезчеләре! Мондый юл белән акча җыю, нинди генә изге теләкләр белән эшләнсә дә, күңелдә ниндидер ямьсез тойгы калдыра.

Шул ук В. турында миңа тагын бер нәрсә сөйләделәр. Җәлилчеләр беренче мәртәбә Берләшкән Гарәп Республикасына килгәч, борынгы пирамидаларга экскурсия оештырырга уйлыйлар. Һәркемнән берничә фунт акча җыеп махсус автобус яллыйлар. Ә В. ниндидер чүпрәкләр сатып алуны артыграк күрә, экскурсиягә бармый.

* * *

Латакиядә булган тагы бер вакыйга истә калды.

Төшке аштан соң берәүләр каюталарында черем итеп яталар, икенче берәүләр капитан белән ярга чыгып киткәннәр. Шул чакта «Җәлил» янына бер көймә йөзеп килде. Көймәдәге ике кара гарәп егете, бер шешә гарәп брэндие күрсәтеп, бездән такта сорыйлар (Сүриядә агач бик кыйммәт.) Ә безнең палубада йөк бушатканнан соң калган терәткеч такталар һәм бүрәнәләр бар иде. Трап янында вахтада торучы матрос Редько дусты Кожиновка кычкыра:

— Коля, ыргыт шунда бер-ике такта, зинһар, үз юлларында булсыннар.

Кожинов, әлбәттә, икене генә түгел, ә күбрәк ыргыта. Гарәпләр ярты көймә диярлек такта төяделәр. Дөрес, без ачык диңгезгә чыккач, бу чүп-чарны барыбер ыргытып калдырган булыр идек, порт суына ыргытырга ярамаганга гына палубада калган иде ул. Гарәпләр исә шатлыкларыннан биемиләр генә һәм, куллары белән ишарәләп, бау төшерүне сорыйлар. Кожинов каяндыр бер бәйләм бау табып алды да очын тегеләргә ыргытты. Көймәдәгеләр шешә шуып төшмәсен өчен җайлабрак бәйләргә генә тотынганнар иде, каяндыр матрос Кошечкин килеп чыкты да ачу белән бауны тартып та алды. Гарәп малайлары эшнең нәрсәдә икәнлеген аңламыйча яңадан бауны төшерүне сорый башладылар.

— Син нәрсә? — ди Кожинов Кошечкинга.

— Шулай! — дип кырт кисте тегесе,— спекуляция белән шөгыльләнми тор әле.

[1] **Валюта** — теләсә кайсы ил акчасына алыштырыла торган акча.

— Менә инде,— дип каршы килә Кожинов.— Нинди спекуляция булсын бу? Без аларга бүләк иттек, алар да менә бүләк белән җавап бирергә телиләр. Такталарны барыбер диңгезгә ыргытачакбыз ич...

Ләкин Кошечкин һаман үзенекен итте:

— Такталарны бир, аңа сүзем юк, ләкин шешәне алма. Чөнки бу спекуляциягә керә.

Шуннан Кожинов, җиде-сигез катлы итеп сүгенеп, тегене иңбашы белән этеп җибәрде дә, бауны тартып алып яңадан аска ыргыта башлады. Гарәп малайлары аста берни дә аңламыйча һаман бау сорап кыбырсыйлар.

Баштан Кошечкин Кожиновның бау тоткан кулын җибәрмәскә тырышып карады, аннары, эш җитдигә килеп терәлгәч, кискен генә әйтеп куйды:

— Шешәне алсаң, остага әйтәм!

Һәм аның йөзенә караганда, чыннан да, әйтәчәге күренеп тора иде. Шуннан Кожинов сүгенеп бер төкерде дә («Тончыгып кит шул шешәң белән, аннан башка да яшәрбез әле...» янәсе) бау бәйләмен ачу белән бер якка ыргытып, зур-зур атлап китеп барды. Ә Кошечкин әле һаман шешәне бирмичә китеп барырга теләмәгән гарәп малайларын куа калды. Гарәпләр аның нигә болай кылануларын һич тә аңлый алмыйча бераз гаҗәпләнеп тордылар да, ярый, алмасагыз алмассыз инде, без аңа ничек тә урын табарбыз дигән сыман, кораб янында китеп бардылар.

Әгәр дә мин роман яки повесть язсам, Кожиновны кире, Кошечкинны уңай герой итеп сурәтләп маташкан булыр идем, бәлки. Ләкин тормышта мәсьәләләр катлаулырак шул. Нәкъ менә Кожинов — корабта иң киң күңелле, шәхси файдага төкереп тә бирми торган кешеләрнең берсе. Ә Кошечкин әле яңа кеше, ул элек кит аулау корабларында йөзгән, анда комсомол секретаре булган һәм монда гади диңгезчеләрнең аның белән хисаплашмауларын яратып бетерми. Күптән түгел булып узган комсомол җыелышында ул, үзе өчен яңа булган эшләрнең үзенчәлекләрен белмәгән көенчә, «Җәлил»дә хезмәт житештерүчәнлеген күтәрү турында бик озын итеп нотык сөйләгән иде. Комсомоллар аның чыгышын хупламадылар (үзен-үзе күрсәтергә тырышканын аңладылар булса кирәк) һәм аны бюро составына да сайламадылар. Шуна күрә әлеге кечкенә вакыйгада аның ни өчен тырышуын аңлап бетерүе дә кыен иде — әллә чыннан да намуслы ул, әллә данга гына омтыламы?

* * *

Латакиядән кузгалып, юлыбызны дәвам итәбез. Безгә туп-туры көнчыгышка барырга кирәк булса да, без нәкъ көнбатышка таба йөзәргә мәҗбүрбез. Сүәеш каналы янәшәдә генә, ләкин ул ябык һәм тиз генә ачылуга өмет тә юк. Моннан ике ел элек «Муса Җәлил», Израиль гаскәрләренең коралы һөҗүменнән берничә генә сәгать алдан, корабларның соңгы кәрваны белән Сүәеш аша үтеп киткән. Дөньякүләм әһәмиятле бу каналны Израиль ябып ук куяр дип ул чакта беркем дә башына китермәгән. Ләкин бу юньсезлек эшләнде. Канал инде ике елдан артык тик тора, юшкын һәм ком утырудан аның төбе һаман саега бара.

Диңгезчеләр әйтмешли, «чабата тирәли әйләнәбез» (Африка материгын әйләнеп узабыз, дигәннәре). Ә бу «чабата» көньяк ярымшарның яртысына кадәр сузылган! «Җәлил» хәтле «Җәлил»нең көчле моторларын тулы көченә эшләткәндә дә, безнең юлыбыз 22 тәүлеккә озая. Кайту юлына чыккач, «чабатаны» урау тагын шул кадәр вакыт сорый. Ә безнең корабны бер тәүлек эшләтеп тору гына да дәүләткә алтын белән өч мең ярым сумга төшә!

* * *

Без күбекләнеп торган зәңгәр киңлеккә омтылабыз.

Юлдашларыбыз — җил һәм биткә чәчрәп торган тозлы тамчылар.

Зәңгәрсу диңгез күгенә ак күбектәй болыт җилкәннәре эленгән. Офыкта кораб моржалары төтенли һәм балыкчы көймәләренең пытырдавы ишетелеп-ишетелеп китә.

Безне бер көтү дельфин озата килә. Алар бер мизгелгә генә ялтыравык кара сыртларын һәм төрек хәнҗәре сыман кәкре йөзгечләрен күрсәтеп, дулкыннар арасында әүмәкләнәләр, дуңгыз балалары кебек акрын гына пошкыралар. Кораб борыныннан ике-өч метр гына алда, бауга бәйләнгәндәй тип-тигез ара калдырып, бер матур, мәһабәт дельфин йөзеп бара. Менә-менә корабның тимер гәүдәсе аны куып җитәр дә бу гүзәл җан иясен сытып китәр шикелле тоела. Ләкин дельфин үзенең көченә һәм житезлегенә ышана булса кирәк — һич тә исе китмичә ансат кына йөзә бирә. Дельфиннар шактый озак, берәр сәгать чамасы безнең белән йөзеп баралар. Аннары алар кинәт кенә көтүләре белән читкә борылалар да артта калалар. Бары тик акчарлаклар гына элеккечә безнең өстә уйнаклый-уйнаклый очалар.

Сул якта, нәкъ офык читендә, сыек шәмәхә болытлар сузылып киткән. Алар астында болыт күләгәсе сыман куе шәмәхә төшкән озын сызык төсмерләнә. Монсы инде ерак Африка ярлары. Коры көньяк җиле эсселектән кызган ташлы чүлләр сулышын алып килә.

* * *

Кечкенә генә социологик тикшеренү уздырдым.

Безнең корабта барлыгы 52 кеше бар: 47 экипаж члены, 4 практикант һәм мин.

Экипаж членнары **хезмәт вазифалары** буенча түбәндәгечә бүленәләр:

**Капитан.**

**Капитанның беренче ярдәмчесе**, яки замполит, корабта политик-агарту эшләренә җаваплы кеше.

**Капитанның баш ярдәмчесе**, палуба командасы һәм корабтагы **бөтен** административ-хуҗалык эшләре өчен җавап бирүче. Ул беренче штурман вахтасында тора.

**Икенче, өченче** һәм **дүртенче штурманнар.**

**Кораб врачы.**

**Рация начальнигы.**

**Радист.**

**Боцман.**

**11 матрос.**

**Баш механик**, диңгезчеләр телендә — «бабай», бөтен машина командасы өчен җаваплы кеше. Машина командасына «бабай»дан башка түбәндәгеләр кирә:

**Икенче, өченче** һәм **ике дүртенче механиклар.**

**Дүртенче механикның дублеры.**

**Электромеханик.**

**Өч электрик.**

**Токарь.**

**10 моторист.**

Корабта көнкүреш хезмәте күрсәтүчеләр:

**Баш пешекче.**

**Икмәк пешерүче.**

**Буфетчы.**

**Дневальный.**

**Җыештыручы.**

Шулай итеп, экипаж членнарының күбесе квалификацияле белгечләр. Матрос булу үзе дә шактый катлаулы хезмәт, шуның өстенә, һәр диңгезченең диярлек тагын өстәмә берәр вазифасы була. Алар арасында берничә рулевой (шуларның берсе баш рулевой), балта остасы (ул үзенә күрә боцманның беренче ярдәмчесе һәм урынбасары да), әртилче (ул азык-төлек кабул итә һәм бүлә, диңгезчеләргә шырпы, тәмәке, минераль сулар, соклар һәм башка төрле вак-төяк әйберләр җибәреп тора), киномеханик, китапханәче һәм башкалар бар.

**Женес буенча:** 48 ир-зат һәм 4 хатын-кыз.

**Милләте буенча:** 44 рус, 5 украин, 1 татар, 1 әзербәйҗан, 1 еврей. Шулай итеп, безнең милли состав бик үк чуар түгел. Бу — диңгезчеләрнең күбесе одессалылар булу белән аңлатыла.

«Муса Җәлил» экипажы членнарының **уртача яше** 28 тирәсе...

Безнең корабта **иң карт кеше** — электромеханик Георгий Степанович Алферов, аңа 52 яшь. Шунсы игътибарга лаек, безнең арада ул иң шат күңелле һәм күтәренке рухлы кеше.

**Иң яшь диңгезче** — практикант Кириченко. Шушы көннәрдә аңа 17 яшь тула.

**Кырыктан иллегә кадәр** 5 кеше (замполит, баш механик һәм өч хатын-кыз).

**Егерме яшьтән түбәннәр дә бишәү** — дүрт практикант һәм пешекче Надя. Аларның барысына да 17—18 яшь.

Штурманнарның күбесе **утыз белән кырык арасында.** Утыз тирәсендәгеләр күбрәк. Мәсәлән, капитанга — 36, баш ярдәмчегә — 32, икенче штурманга — 30, дүртенче штурманга — 27 яшь.

Матрос һәм мотористларның күбесе **егерме белән утыз арасында**, кайберләре генә утыздан узган.

**Белем буенча:**

**Тәмамланган югары белемле** 12 кеше (капитан, беренче һәм баш ярдәмчеләр, баш механик, доктор, механикларның барысы да, электромеханик һәм электрикларның берсе — аны озакламый башка корабка электромеханик итеп күчерергә тиешләр. Дүртенче штурманның дублеры буларак, мин үземне дә шушында кертәм).

**Югары уку йортларында** өч кеше укый (икенче штурман, рация начальнигы һәм бер моторист. Моннан тыш, безнең дневальная тәмамланмаган югары белемле).

10 кеше **махсус урта белемле.** Өченче һәм дүртенче штурманнар, дүртенче механик дублеры, бер электрик һәм дүрт моторист диңгез училищесы тәмамлаганнар. Бу училищеның программасы нигездә югары уку йортыныкыннан аз аерыла һәм аның уку срогы да шулайрак— ун классны тәмамлагач 4 ел укырга. Шеф-пешекче аш-су осталыгы буенча махсус урта белем алган. Хәтта җыештыручыбыз да махсус урта техник белем алган кеше.

**Махсус урта белем бирүче уку йортларында** 9 кеше укый — боцман, ике моторист һәм дүрт практикант. Пешекче Надя унынчыдан соң аш-су осталары училищесында укый. Матрос Виктор Релько техникумның өченче курсыннан китеп барган. Шулай итеп, бездә тәмамланмаган махсус урта белемле ун кеше булып чыга.

13 кеше **10 яки 11 класс тәмамлаганнар.** Аларның күпчелеге укуларын дәвам иттерергә уйлый. Кайберәүләр бу көздән үк югары яки махсус урта белем бирүче уку йортларына гариза бирергә хәзерләнәләр.

Корабта өч кенә кеше **тәмамланмаган урта белемле.** Матрослар арасыннан берсе 8, икенчесе 9 класс тәмамлаган һәм буфетчыбыз Нина Андреевна кайчандыр җиде еллык мәктәпне тәмамлаган булган. Матросларның икесе дә урта белем алырга уйлыйлар, бары тик Нина Андреевна гына, миңа соң инде, дип кул селти.

Шулай итеп, белем ягыннан кораб экипажының гомуми хәле түбәндәгечә:

**Югары һәм тәмамланмаган югары белемлеләр** — 16 кеше, ягъни экипажның 30 проценттан артыгы;

**Махсус урта һәм тәмамланмаган махсус урта белемлеләр** — 20 кеше, ягъни 40 процент чамасы;

Гомуми белем бирүче урта мәктәп тәмамлаучылар — 13 кеше, ягъни 25 процент тирәсе;

Тәмамланмаган гомуми урта белемлеләр — 3 кеше, ягъни түгәрәкләп алганда 5 процент чамасы.

* * *

Кичә мин туган көнемне Урта диңгезнең зәңгәр киңлекләрендә каршыладым. Мин бу турыда беркемгә дә әйтмәгән идем, ләкин, исемлектән карап белгәннәр дә, иртәнге аш вакытында мине радио аша котладылар. Доктор: «Сиңа туксан яшеңдә генә минем коллегаларыма мөрәҗәгать итәргә язсын...» — дип шаярта. Штурманнар, матрослар, мотористлар килеп кулымны кысалар. Кичке чәйгә баш пешекче минем исем-фамилиямнең баш хәрефләре язылган купшы торт пешереп китерде. Мин кинәт дулкынланып киттем. Тортны кают-компаниядәгеләр белән бүлештек. Монда һәр кешенең туган көнен шулай билгеләп үтәләр икән.

...Миңа 38 яшь. Күпме бу яки азмы? Практикант Кириченко өчен инде мин бар тормышы артта калган өлкән бер кеше. Ләкин мин әле үз җилкәмдә узган гомер авырлыгын тоймыйм... Киресенчә, миңа тормышның иң кызыктыргыч, иң мавыктыргыч мизгелләре алдадыр шикелле тоела. Мин әле зур планнар корам, киләчәк тормышның ерак офыкларына омтылган хыялларымнан баш тартмыйм. Дөрес, бәлки мин аларны тормышка ашыра да алмам. Дөньяда бар хыяллар да җиңү белән генә очланмыйлар. Ләкин әле аларның тормышка ашмавына ниндидер башка сәбәпләр сәбәп булу — җиңелү дигән сүз түгел. Үз максатыннан үзең баш тарту, үсмерчак хыялларыннан чигенү, элекке идеалларга хыянәт итү — менә болар инде чын мәгънәсендә җиңелү. Тәндә җан бар чагында кеше хыялланырга, нәрсәгә дә булса омтылырга тиеш. Тормыш ул — хәрәкәт. Туры фәлсәфи мәгънәсендә дә, күчермә мәгънәсендә дә бу шулай. Тормыш ул материя хәрәкәтенең бер формасы. Бу хәрәкәтнең тукталуы — тәнең никадәр генә сау-таза булса да, сине рухи үлемгә алып килә.

* * *

Томанлы соры иртә. Акчарлаклар, ак төнбоеклар шикелле, дулкыннар өстендә тирбәлеп утыралар.

Еракта калган туган Татарстанымны торган саен ныграк сагынам. Казан тирәсендәге кояшлы нарат урманнарын, аларның тамак төбен бераз гына ачытып ала торган сыткы сагыз исле саф һавасын, шул урманнар эчендә җәелеп яткан коңгырт сары пыяла китегедәй Аккош күлен, салмак дулкыннары белән ямь-яшел ярлар арасына тулган, җыр кебек киң Иделне сагынам. Урман аланында иртәнге кояш нурларына чумган түндербаш таҗын, үлән сабакларына сырышкан көмеш чык тамчыларын сагынам...

Быел инде мин аларның берсен дә күрә алмаячакмын...

Өч тәүлек тоташтан көнбатышка таба барабыз — иртәнге кояштан качабыз, баеп баручы кояшны куабыз. Көн һаман саен соңрак яктыра һәм соңрак караңгылана бара. Инде иртәнге вахтадагылар караңгыда эшлиләр. Бүген сәгать тугызда корабтагы бөтен сәгатьләрне бер сә-

татька чигереп куйдык. Кызык, бүген инде бер мәртәбә сәгать сигез тулган иде, менә тагын сигез тулып килә. Мин гомеремдә беренче тапкыр бер үк сәгатьтә ике тапкыр яшим. Монда әллә ниткән мажаралы хыялларга бирелергә була: әйтик, планетаара сәяхәт вакытында кеше бер үк айны, елны, бернична елны икешәр мәртәбә яшәргә мөмкин. Әгәр да кешегә, элеккеге тәҗрибәсе булган хәлдә, бер яшәгән гомерен икенче кат яшәп карарга мөмкинлек бирсәң, ниндирәк тормыш килеп чыгар иде соң? Менә, мәсәлән,. әгәр миңа былтыргы елны яңадан яшәп карарга мөмкин булса?.. Әмма узган гомергә кире кайтып төзәтмәләр кертеп булмый шул. Димәк ки, баштан узганнарың өчен кызармаслык итеп яши белергә кирәк



## Атлантикага чыгабыз. Беренче давыл



Гибралтардагы Британ крепосте. Ерактан ике үркәчле дөягә охшап күренгән гаять зур кыя. Тауның яңгыр сулары агып төшә торган ягы, яртылаш цементланып, су саклагычка әверелдерелгән — Гибралтарда табигый су чыганаклары җитешми. Күккә ашкан телевизор һәм радио антенналары артында, кыя белән материк тоташкан тар гына урында аэродром эшләнгән. Анда әледән-әле хәрби самолетлар төшеп утыра. Кыя итәгендә чиста гына ак өйләр, кызыл кирпечтән салынган казармалар, бетоннан эшләнгән яр буе ныгытмалары. Бухтада хәрби кораблар тора.

* * *

Диңгездә егерменче көнем.

Двигатель бер көйгә генә гөрләп эшли бирә. Шлюпкаларга ябылган киндерне җил шапылдата. Ашханәдә савыт-саба шалтыравы ишетелә— кичке ашка хәзерләнәләр. Минем астагы каюта радиосыннан дәртле марш яңгырый. Рубкага җыелган штурманнар нәрсә турындадыр кызып-кызып бәхәсләшәләр.

Диңгезнең җиңелчә зәңгәрлеге акрынлап көлсу төскә керә бара, җил күзгә күренеп сафлана. Кер юу тактасы сыман сырлы-сырлы су өстеннән күбек сыртлы тар дулкыннар еракларга сузылып китә. Бу инде — Атлантик океан.

Иллюминатор каршыннан Испаниянең таулы ярлары, ак таштан

төзелгән чиста шәһәрләре, вакыт җилләре белән каралып беткән борынгы заман хәрабәләре үтеп китә...

Көн караңгылана. Яр буе утлары яктырткыч бөҗәкләр кебек җемелдиләр. Җил төн караңгылыгы аша ниндидер моңлы авазлар китерә. Алар миңа испан моңы булып тоелалар.

* * *

— Я, котлыйм,— диде миңа капитан.— Сезгә беренче сугышчан чыныгу алу мөмкинлеге булырга тора. Һава торышы турындагы соңгы мәгълүматларга караганда, безгә каршы көчле давыл килә. Канар утраулары тирәсендә безне эләктерер, ахры...

Алты сәгатьтән соң яңа хәбәр алдык — Азор утрауларыннан килүче давыл кинәт кенә төньякка борылган да Бискай култыгына табан юнәлгән. Мин җиңел сулап куйдым, ләкин иртәрәк шатланганмын икән. Давыл күтәргән биек, текә дулкын барыбер безне куып җитте һәм мин гомеремдә беренче мәртәбә үле чайкалуның нәрсә икәнен аңладым...

Җил юк диярлек, күк йөзе сорыланып тора. Су өсте майлы япма җәелгән сыман ялтырый. Һәм офыкның буеннан буена сузылган ике-өч катлы йорт биеклегендәге зур, салмак дулкыннар бер-бер артлы безгә таба тәгәрәп киләләр. Без аларга ян белән барабыз һәм кораб акрын-акрын уңга-сулга чайкала башлый. Чайкалу һәр яңа дулкын бәрелгән саен көчәйгәннән көчәя бара. Аяк астындагы палуба чайкала, чыгыр мачталары, антенналар, кораб морҗасы һавада ярым түгәрәк ясап яктан-якка авышалар. Күктәге соры болыт кисәкләре кинәт кенә өскә очып менеп китә, аннары упкынга төшеп югала, яңадан күккә омтыла. Аксыл-сары кояш түгәрәге, болытларга ияреп, сәгать теле сыман як-якка селкенеп тора.

Башта бу тирбәлү хәтта рәхәт кебек. Әйтерсең лә коточкыч зур таганда атынасың — йөрәкләр дәртләнеп китә. Ләкин озакламый бу рәхәтлек туйдыра башлый. Ә палуба һаман биегрәк менә-менә атына бирә... Инде таганны тизрәк туктатасы, аннан төшәсе килә, ләкин кая төшәсең? Баш томанлана һәм авырая, маңгайга салкын тир бәреп чыга, күңел болгана башлый... Ә таган һаман саен ныграк атына...

Булдыра алган җирдә ике аяклап, булдыра алмаганда дүрт аяклап каютага таба юнәлдем. Кинәт палуба минем аякларым астыннан каядыр төшеп китте, траплар үрә торып бастылар. Мин, тәгәрәп китмәс өчен, тизрәк шуларны кочаклап алдым һәм нәрсәгәдер башым белән килеп бәрелдем. Һич «тиктормас» палуба буйлап бару бөтенләй мөмкин булмый башлады. Шулай да абына-мүкәли каютага кайтып җиттем. Башта юынгычка килеп биткә кушучлап җылымса су сиптем дә көзгегә карадым Аннан миңа газапланудан яшел-зәңгәр төскә кергән, күзләре яшь белән тулган ямьсез йөз карап тора иде. Шуннан ыңгырашып ятагыма аудым.

Минем янга доктор кергәндә көн инде кичкә авышкан иде. Ул керү белән шаярта да башлады: «Монда бер язучы җан биреп ята, диләр. Дөресме бу?» — ди. Минем хәтта аңа елмаеп җавап бирергә дә хәлем юк. «Я-я-я,— ди доктор, мине караган булып,— монда симулянтлык чиренең бөтен билгеләре дә бар, ә шуларның иң әшәкесе — юмор хисен югалту». Ул минем генә газапланмавымны, әле тагын дүрт практикантның, замполитның һәм яңа дневальныйның үз каюталарында кисеп ташлаган агачлар шикелле селкенә дә алмыйча ятуларын әйтеп мине тынычландыра. Төшке ашка да, кичке ашка да килмәгән өчен ачуланып та ала: «Диңгез авыруыннан иң шәп дару — ашау»,— ди ул. Миңа берничә төймә дару бирә, кайчакта ярдәме тия, янәсе. Ләкин барыбер мин ул даруларны эчә алмадым. Таң алдыннан гына тәмам хәлсезләнеп тынгысыз йокыга талганмын.

* * *

Чайкалу вакытында да яшәп була икән. Дөрес, авыздан көн буе бакыр тәме килә, баш махмырдагы шикелле авыр. Йомшарган аяк буыннары сине тынларга теләми. Ләкин бу инде кичәгегә караганда яхшырак, күп мәртәбәләр яхшырак. Әкренләп бертуктаусыз чайкалып торучы палубада йөрергә дә өйрәнеп киләм. Бу бик ансат эш түгел икән. Кичә мин егылмаска тырышып, кораб кая авышса, шунда таба ава идем. Шуңа күрә башымны да бәргәнмен. Ә монда киресенчә кирәк икән — аякларны җәеп басарга да корабка капма-каршы якка авышырга. Идән уңга китсә, сулга ау, сулга китсә — уңга. Шунсы да бар, бер өйрәнгәч бу үзеннән-үзе шулай килеп чыга икән, каяле, бу якка авыйм дип уйлап та тормыйсың.

Җилнең көче инде җиде-сигез баллга җитте. Антенна чыбыклары сызгыра һәм кыл кебек тартыла. Уң як борттан тау чишмәседәй чәчрәп дулкын күтәрелә һәм ысылдап палуба буйлап ага. Палуба өстенә ак күбекләр утырып кала. Акчарлаклар кычкыра-кычкыра безгә ияреп баралар, күбекләнеп кайнап торган дулкын сыртларына утырып-утырып алалар. Аларның тавышы үзәк өзгеч сагышлы һәм моңсу. Акчарлаклар — суга баткан диңгезчеләр җаны алар, дигән сүз юктан гына тумаган, күрәсең.

* * *

Кызыл почмак. «Кәҗәче»ләр дәртләнеп шакы-шокы домино сугалар һәм иренеп кенә сөйләшәләр.

— Менә бу җил, ичмасам...

— Нинди җил? Һава әйбәт ләбаса...

— Әйе, нәкъ безнең тормышыбыз кебек, «шәп» инде...

Мин радиоланы кабызам да татар халык җырлары язылган пластинканы куям. Котырынган Атлантика сулары өстендә Илһам Шакировның көчле баритоны яңгырый. Кызыл почмакта утыручылар бердән тынып калалар һәм җыр тыңлыйлар.

Акрын-акрын диңгезче хезмәтенең никадәр авыр икәнен аңлый барам. Менә психологик ягын гына алып карыйк. Кичләрен, бигрәк тә һава торышы бүгенгедәй әшәке булган көннәрдә, кая да булса барасы, бераз гына башка берәр нәрсә белән шөгыльләнәсе, кафеда тыныч кына кофе эчеп, таныш булмаган кешеләрне күреп утырасы килә. Ә монда синең дөньяң берничә дистә квадрат метр белән чикләнә. Шуңа күрә һәркем нинди дә булса яңа шөгыль эзли. Берәү нәрсәдер юныша, берсе кокос чикләвеге кабыгыннан әллә ниләр кыландырып тәмәке көле кага торган савыт ясый, икенче берәүләр имтиханнарга әзерләнә, кайберәүләр домино сугалар яки шахмат-шашка белән җенләнәләр. Электрик Дышловенко үзенең попугаен сөйләшергә өйрәтә. Попугай инде «исәнме», «сау бул» дигән сүзләрне һәм, бераз сакауланып булса да, «Кокочка» дип үз исемен әйтә ала. Икенче механик Анатолий Щербатюк кичләр буе китаптан баш күтәрми. Ләкин ул, кайберәүләр кебек, кулына нәрсә эләкте, шуны укымый, ә бары тик Бөек Ватан сугышы турындагы әдәбиятны гына, бигрәк тә истәлекләрне укый. Аның белән сөйләшүе кызык, ләкин шактый кыен — үзе ятлап бетергән искиткеч күп исемнәрне һәм даталарны тезә генә. Җәлил темасы буенча эшләгәнгә күрә минә да сугыш турында байтак укырга туры килде, шулай да бу мәсьәләдә мин Анатолий Петровичтан калышам икән әле. Куен дәфтәремә берничә китап исемен язып алдым — ярга кайткач укырга кирәк булыр.

Давылга һәм каршы агымнарга очравыбызга карамастан, тизлекн киметмибез — сәгатенә уртача унсигез ярым узел барабыз. Тизлекн арттырмыйча гына Англия, Франция, Италия, Норвегия корабларь узып китәбез. Бу вакыт эчендә безне нибары өч мәртәбә генә узып кит теләр һәм аларның өчесе дә Америка кораблары. Капитан: «Нишлисе бит инде? Аларның двигателе безнекенә караганда бер ярым мәртәбә көчлерәк. Алар әле двигательләрне тулы көченә эшләтмиләр»,— ди кулын гына селки. Ә «чиф» американлылар узып киткән саен шартлар дай булып кала: «Ай, бу американлыларны... Күзгә төтен җибәрергә яра талар да инде... Ярый, ашыкмагыз әле, без дә сезгә күрсәтербез!..» Әгә дә шул чакта баш механик рубкада булса, баш ярдәмче аны котырт башлый: «Нәрсә, бабай, әллә кочегарканны бераз кыздыра төшәсеңме Безгә бит тизлекне нибары ярты узелга гына арттырырга кирәк, һә без аларга бирешмәячәкбез»,— ди. Ләкин «бабай» сәер итеп елмае кына куя: «Ярамый... Режим бит... Нигә миңа машинаны артыгын кө чәндерергә?.. Ә син борчылма, Зонд бугазына без барыбер алардан алда барып җитәбез... Ашыккан ашка пешкән, ди, ашыга бирсеннәр...»

Һәр вахта азагында капитан штурманнарга бер үк сорауны бирә «Күпме юл уздың?» Җавабына карап ул аңа яки канәгатьләнүен бел дереп баш кага, яки: «Нишләп алай аз? Дүртенче булып дүртенче дә синнән күбрәк юл үтте»,— дип тегене оялтып куя яки: «Кайда икән легебезне билгеләми тор әле, кичтән үзем карармын...» — дип мыгыр дана гына.

Без инде күптән ачык океанга чыктык һәм җир шарының кайсы нок тасында икәнлегебезне сектан ярдәмендә кояшка һәм йолдызларга карап кына билгелибез. Бу эш шактый катлаулы. Күктә беренче якты йолдыз кабынган һәм офык төн караңгылыгына күмелеп өлгермәгән бер кыска гына вакыт эчендә сектан окулярына өч йолдызны эләктерергә дә алар ның офык өстендә ни биеклектә икәнен билгеләп калырга кирәк. Аннан соң инде катлаулы хисаплаулар башлана. Ләкин иң төгәл исәпләгәнд дә ике-өч мильгә ялгышу котылгысыз. Шуңа күрә капитан корабның кайсы ноктада икәнлеген берничә тапкыр тикшергәннән соң гына билгеләп куя.

* * *

— Экипаж игътибарына! Әһәмиятле хәбәр тапшырабыз! Сигез сәгат утыз минутта ашханәдә яңа нәфис фильм куелачак. Кабатлыйм...

Мин дүртенче штурманның тавышын танып елмаеп куям. Ул һәр вакыт Левитанга охшатып сөйләргә тырыша. Туйдырып бетергән китап ны читкә атам да, аска төшеп, киномеханик Пивоваренко будкасына сугылам.

— Бүгенгә нәрсә таптыгыз анда, Витя?

— Кайсы булыр әле, мин өчне сайлап куйдым: «Көнчыгыш коридо ры», «Әһәмиятле дәлил» һәм «Малиновкадагы туй». Капитанны көтә без...

— Соң бит инде «Малиновкадагы туй»ны ике тапкыр күрсәттең!

— Булса ни... Егетләрнең тагын карыйсылары килә...

Капитанны көткән арада Пивоваренко егетләргә гамәлдән чыгарыл ган иске кинотасмалардан җыйган үз киножурналын күрсәтә тора. Б шул кадәр кызык һәм үзенчәлекле күренеш, минем әле мондый кино журналны гомеремдә дә күргәнем юк иде.

Өстәл өсте кебек тип-тигез, иксез-чиксез дала буйлап өстенә ки итәкле чапан, башына озын йонлы бүрек кигән кәҗә сакаллы казак карты бара. Менә ул туктала да гаҗәпләнеп чүгәләп куя һәм экранд кинәт кенә дәртле чегән биюе башлана. Биючеләр кычкыралар, сызгы ралар, иңбашларын калтыраталар, дөбер-дөбер барабан сугалар һә гитара чиртәләр. Казакъ карты башын чайкап юлын дәвам итә. Ул кинә

кенә биек таулар башына менә, бер атлауда зур-зур елгаларны кичә һәм янадан шаккатып авызын ачып кала. Бу юлы экранда Италиянең иниидер неореалистик фильмыннан шук бер күренеш башлана. Нәрсәгәдер ачуланган халык төркеме бер кызның йокы бүлмәсенә бәреп керә. Кыз акрын-акрын гына, теләр-теләмәс кенә кыска одеалын тартып шәрә күкрәген яба, ләкин шул вакытта аның аяклары, ботлары ачыла бара. Карт казакъ һаман юлын дәвам итә һәм әле Париждагы ялангач ботлы кызлар тулы төнге барга килеп эләгә, әле пляжга килеп чыга, әле бер егетнең яшь кызга бәйләнүен ошатмыйча карап тора. Бу киножурналда чарльстон һәм румба биниләр, Одесса жырлары жырлыйлар һәм бәскә күмелгән каеннар астында үбешәләр.

Рейс вакытында журналның кайбер өлешләре янара бара һәм бу кинофильм тамашачыны һич кенә дә биздерми — диңгезчеләр инде аны унар мәртәбә карасалар да һаман көләләр, иң киеренке күренешләргә кычкырып-кычкырып үз фикерләрен белдерәләр.

Нәкъ тугызынчы яртыда капитан килә, беренче рәттәге яраткан урынына утыра һәм фильм башланып китә. Күпчелек соравы буенча тагын «Малиновкадагы туй»ны әйләндерәләр.

* * *

Бүген күз алдымда бер гыйбрәтле хәл булып алды.

Диңгезчеләрне эшкә бүлүче боцман:

— Матрос Кошечкин! Резина итекләр, чиләк һәм кирәк аласың да, трюмга төшеп, льялаларны[1] чистартасың! — дигәч, тегесе кинәт кызып китте:

— Мин инде ике тапкыр чистарттым бит. Нигә һаман миңа гына кушасың? Әнә, Кожинов бер мәртәбә дә чистартмады, Редько да. Бармыйм. Теләсәгез нишләтегез. Тапканнар бер бозау...

Әлбәттә, льялалар чистарту бик үк рәхәт эш түгел. Билдән пычрак суда, житмәсә ярым караңгы урында эшләргә туры килә. Бәлки боцман тагын Кошечкинга кушып дөрес тә эшләмидер — бөтен диңгезчеләр кебек үк, ул да Кошечкинны өнәп бетерми. Ләкин әле корабта бер генә кешенең дә кушкан эштән баш тартканы юк иде. Боцманның сипкелле йөзенә кинәт кызыл таплар бәреп чыкты. Хәтта баш тиресе дә кызарып китте. Редько, киеренкелекне йомшартырга теләп:

— Боцман, үзем барыйм булмаса... Кеше теләми икән, ни эшлисең инде...— диярга ашыкты.

Ләкин боцман ачулы йөз белән аңа таба борылды:

— Син үзган рейста льялаларны ничә тапкыр чистарттың? Ә-э-ә, санамадыңмыни? Һәм беркем дә санамады. Ун тапкыр чистартырга кирәк икән — ун тапкыр чистарттык, егерме мәртәбә кирәк икән — егерме мәртәбә. Ә ул саный, анасының баш малае! Уйлап кына кара, ике мәртәбә бит! Ә мин флотта хезмәт итә башлаганда рәттән ике ел буена гел бәдрәфләр генә чистарттым. Һәм бөтен диңгезче дә шундый юл үткәндер дип уйлыйм. Ә сине соң кая куярга кушасың? Чыгырга сине куеп булмый, электр жиһазлары белән танышлыгың юк... Палуба юаргамы? Юк инде, әнненнең баш малае, мин кая кушсам — шунда барырсың. Я хәзер үк трюмга төшәсең, яки мин сине эштән читләштерәм. Баш ярдәмчегә жалу белән бара аласың.

Кошечкин чиләген атып бәрде дә баш ярдәмче каютасына китте. Озакламый ул кып-кызыл булып әйләнеп килде һәм дәшми-тынмый гына трюмга төшеп китте.

---

[1] Льялалар — трюмның түбән өлешендәге тирән караңгы бәмпр.

# Тропикларның зәңгәр кайнарлыгы




Ниһаять, җил басылды. Тыныч, бөркү төн. Ай шундый зур, шундый якын булып күренә ки, кулыңны сузсаң, бармакларың ай тузанына буялыр төсле. Куе зәңгәр һавада әллә ниткән балкышлар тирбәлеп китә. Зур дулкыннар, диңгезнең тыгыз мускуллары тартышкандай, уралып-уралып тәгәриләр.

Бүген Марокко башкаласы Рабатны үтеп киттек. Иртәгә Касабланка яныннан узачакбыз.

* * *

Нигәдер өйдән бернинди хәбәр юк. Улым белән кызымны сагынуга түзәр хәл калмады. Хат язып салу турында уйлама да — аны кем артыннан саласың? Кыска радиограммалар җибәрергә була инде булуын, ләкин, радиостанциягә артык эш ясамас өчен, аксын да сирәкләргә туры килә. Әгәр радиограмма булса, шундук хәбәр итәселәрен белсәм дә, мин тагын бер мәртәбә радистларның «күгәрчен оясы»на күтәреләм.

Түшәмнән алып идәнгә кадәр төрле приборлар белән «бизәлгән» кечкенә бүлмә эчендә бертуктаусыз шытырдау, чыелдау, өзек-өзек морзе сөйләше ишетелеп тора. Бер кулы белән колагына түгәрәк тыңлагыч куйган радист, икенче кулы белән бер төймәне бора-бора әле генә югалткан радиодулкынны эзли. «Күгәрчен оясы»нда әле сагышлы-йомшак джаз моңы, әле гөлдерәвек негр җыры, әле сак кына итеп чит ил телендә сөйләшкән авазлар ишетелеп китә. Ниһаять, радист кирәкле дулкынны тота да, колагына тыңлагыч куеп, радиограмма текстын машинкада баса да башлый. Эш арасында минем өметле-сораулы күз карашымны күреп баш чайкый — юк, янәсе, сиңа түгел. Мин, аңа комачауламас өчен, ишекне шыпырт кына ябып чыгып китәм.

* * *

Без, уңай агымнан файдалану өчен, Африка ярларына якынрак киләбез. Эссе. Чүлләрдән искән җилнең коры сулышы битләрне пешерә һәм палуба өстен юка гына алсу ком пудрасы белән каплый. Тиздән тропикларга килеп җитәбез инде.

* * *

Мин, суыктан калтыранып, уянып киттем. Күзләремне ачмый гына юрганга тәренеп яттым да, бүген төнлә Кысла тропигын үтеп, тропикларга керергә тиешлегебезне искә төшердем. Ә каян килә соң бу кадәр

салкып? Бернича минуттан һава сафландыргычның тигез гүләвеннән мин корабта климат җайланмасын тоташтыруларын аңлап алдым. Иллюминатор астындагы ак әрҗәдән бәреп торган коры салкын җил белән пәрдәләр җилфердәп тора. Пыялалар, салкын сентябрь иртәсендә бәрәнге буыннан тирләгән авыл өе тәрәзәләре шикелле, суланып тора. Мин кулым белән иллюминаторны сыпырып алдым, ләкин пыяла барыбер чистармады — тәрәзә тышкы яктан тирләгән иде.

Тиз генә киенеп, палубага чыктым. Бер-ике адым атладым да гаҗәпләнеп туктап калдым. Монда шундый эссе — әйтерсең лә мин ялгышып мунчаның пар бүлмәсенә килеп кердем. Тончыктыргыч кайнар, дымлы һава минем үпкәләремне пешереп алды һәм бөтен тәнем, кайнар мамык юрганга төренгәндәй, кызыша башлады. Бер мизгелгә бөтен җирем ябышкак бу белән капланды. Палуба идәне һәм шлюпка киндере юп-юеш, ә трюм түбәләренә уйдык-уйдык су җыелган. Зәңгәрсу бу аша океан шәмәхәләнеп һәм майлангандай булып күренә, аның өстендә вак дулкыннар йөгерешә. Әле иртә. Кояш та чыкмаган, шулай да инде эсселектән бөтен диңгез өсте парга әйләнә. Менә нинди икән син, тропикларның зәңгәр кайнарлыгы!

* * *

Өченче көн инде тропик сулар буйлап йөзәбез. Диңгез суының җылылыгы 29—30 градус. Ә һава температурасы тәүлекнең теләсә кайсы вакытында 30 градустан кимеми, ләкин 35 градустан югары да күтәрелми. Теңкәне корыткан дымы булмаса, алай ук эссе дә түгел инде. Бу пар эчендә үзеңне яңгырдан череп баручы эскерт төбендәгедәй хис итәсең. Монда елның теләсә кайсы вакытында шундый көйдергеч кояш, дымлы бөркү, җилсезлектер дип ышанасы да килми.

Ә кайдадыр ерак Антарктидада мәңгелек кыш, ак бозлар, сиксән градуска кадәр җитүче салкыннар. Безнең гүзәл планетабызда никадәр төрлелек һәм без, башка дөньялар турында хыялланучы кешеләр, аны никадәр аз беләбез...

Безгә диңгез ярлары бөтенләй күренми. Аяк астыбызда да биш чакрым калынлыктагы су гына. Кабарынкы алсу болытлар һәр иртә саен су астыннан калкып чыгалар да көн барышында акрынлап яктыра баралар, ә кичләрен инде алтынсу-кызыл төсләргә манчылып, яңадан су астына чумалар.

Һаман саен экваторга якынлаша барабыз. Тимер казык йолдызы һәр төн саен офыкка якынрак төшә бара, ә Чүмеч йолдыз инде тозлы суны чумырып алырдай булып океанга якынлашты.

Һаваның дымлылыгы йөз процентка җитә. Кичен йокларга ятканда юеш простыняны өскә ябынасы килми, ул инде бөтенләй дым сеңдерә алмас дәрәҗәдә суланган. Өстәлдә калган ипи сыныгы бернича сәгатьтән ап-ак булып күгәреп чыга. Бернича көн элек мин дүртенче штурманнан каләм очлау өчен лезвие сорап алган идем. Ике-өч көн эчендә ул күгәреп беткән һәм кулга тоту белән пыяладай уалып китте.

Бары тик сәгать уникеләрдә генә эссе кояш диңгез өстендә эленеп торган буны куып тарата. Ниһаять, палубалар кибә һәм шул кадәр нык кыза, чучканы тереләй кыздырырга мөмкин. Палуба өстендә көнозын дерелдәвек рәшә тора — кайнар һава шулай эрегән пыяла сыман күзгә күренеп күтәрелә.

Төш вакытында кояш нуры газ плитәсеннән чыккан ялкын кебек көйдереп ала. Кичә икенче механик моржа палубасына менеп китап укып яткан. Әйтүенә караганда, кырык минуттан артык кызынмаган да булырга тиеш. Ә бүген инде ул ята да алмый, күлмәк тә кия алмый. Тәне комачтай кызарган, урыны-урыны белән ап-ак булып кабарып чыккан. Доктор аның юеш яраларына стрептомицин сибә һәм, соңлап булса да, аңа кояшта кызыну кагыйдәләрен өйрәтә.

Ә матрос Редько тагын да кыенрак хәлгә эләккән. Редько — ике метр озынлыктагы таза егет, элеккеге кит аулаучы, һәрвакыт елмаеп йөрүче сакаллы бер әзмәвер — коеп куйган әкият батыры инде. Докторның кисәтүенә карамастан, билдән чишенеп ярты көн буе палубада эшләгән. Янәсе, ул узган рейста да кызынган, янәсе, аның калын тиресен берничек кояш та ала алмый. Төшке ял алдыннан гына ул тимер арканның бер башын иптәшенә тоттырган да палубага сыдырылып төшкән. Иптәшләре аңа диңгездән берничә чиләк су алып сипкәннәр, шуннан соң гына аңына килгән. Аны кояш суккан булган. Соңыннан Редько безгә болай дип сөйләде: «Чигәләрдәге ниндидер тамырлар бүрткәннән-бүртә бардылар, кинәт берсе шартлагандай булды һәм мин аңымны югалттым». Хәзер ул үз каютасында ята. Доктор әйтүе буенча, әле тагын берәр атна чамасы ятар. Әйе, тропик кояшы белән шаярырга ярамый!

Безнең бердәнбер коткаручыбыз — һава суыткыч җайланма. Бу җайланманың чиксез рәхәтлеген тропикларда булып карамаган кешегә аңлатуы да кыен. Палубадагы эссе кояш һәм кайнар һавадан каютага килеп кергәч, үзеңне искиткеч рәхәт хис итәсең!

Тропикларда диңгезчеләргә тагын бер газап — күгәрек. Дымлы эссе һава һәм ачы диңгез тозы тимер-томыр күгәрү өчен менә дигән уңайлы шартлар тудыра. Бөтен команда көннән-көн буе күгәрек чистарта. Күгәргән урыннарны махсус кечкенә чүкеч белән тукмыйлар да, тимер чыбыктан ясалган щетка белән ышкыйлар. Чистарткан урыннарга кургаш катыштырылган кызгылт буяу сөртәләр. Бортлар, култыксалар, бусагалар, трюм түбәләре акрын-акрын кызыл ямау ябыштырылган кебек чуарлана бара. Соңыннан бу «ямау»лар ике мәртәбә махсус буяу — грунт белән капланачак һәм рейс азагында бөтен теплоход яңадан майлы буяу белән буялачак. Әгәр дә күгәрек белән әнә шулай көрәшмәсәң, ул берничә рейс эчендә бөтен корабны ашап бетерергә мөмкин.

*
* *

Кичә шулай күперчек канатында басып торганда кинәт суга тияртимәс кенә очып баручы ялтыравык караләҗым бер сәер кош күреп алдым. 30—40 сантиметр чамасындагы нәзек озын гәүдә, нәкъ сыртына урнашкан, чикерткәнекедәй ярым үтә күренмәле ике канаты туктаусыз дерелдәп тора. Мин океанның ярдан шушы кадәр ерак урынына бу кошчык ничек килеп җитә алды икән, инде бит акчарлаклар да әллә кайчан бездән аерылып калдылар, дип баш ваткан арада «кошчык» дулкыннар арасына кереп чумды һәм бөтенләй күздән дә югалды. Шунда гына мин аның оча торган балык икәнлеген аңлап алдым.

Ә бүген бу гаҗәеп балыклар су өстендә көтүләре белән очып йөриләр, бортка сикерәләр, хәтта палубага очып менәләр. Иртән пешекче палубадан егермеләп балык җыеп алган һәм зур табада кыздырып та куйган. Оча торган балыкларның ите симез, йомшак, тәме күлләрдәге карп балыгын хәтерләтә.

*
* *

Төнге океан өстендә яшенле яңгыр Авыр, яңа савылган сөт кебек җылымса су тоташ агым булып палубага, иллюминаторларга, тәрәзәләргә ага һәм бөтен җирне ак күбек белән тутыра. Фосфор утыдай яшен камчылары дөм-караңгы күк йөзен кисеп үтә һәм бер мизгелгә генә океан өстендә, ак стенадай булып, көчле яңгыр агымы күренеп кала. Күк күкрәгән аваз ишетелми, бары тик күкерт исе генә килә. Бу шундый гаҗәеп бер күренеш ки, әйтерсең лә әнә тегендә генә, океан өстендәге дөм-караңгылык артында, күкрәү дирижеры Мефистофель үзе басып тора.

Вахтадагы штурман локатор һөм сиренены тоташтыра. Күперчеккә йокымсыраган капитан күтәрелә.

— Тизлекне киметәбезме? — дип сорый аннан штурман.

Капитан авызын зур итеп ачып исни, иренеп кенә приборларны карый, бик битараф кыяфәт белән котырынган күккә бер караш ташлап ала да ялкау гына:

— Кирәкмәстер. Кирәгеннән артык котырына, үз башына кылана ул — озакламый үтәр,— дип куя.

Һәм чыннан да күк йөзендәге котыруны озак дәвам итә алмый. Унунбиш минуттан соң яңгыр кинәт туктый, болытлар бик тиз таралып китәләр (әйтерсең, алар гомумән булмаганнар да!). Һәм кара бәрхеттәй күк йөзендә күгәрчен күкәе кадәр тропик йолдызлар балкый башлый.

* * *

Икенче штурман Иваныч иртәдән үк бүген уникенче параллельне кичәчәгебезне һәм анда кояш нәкъ баш түбәсендә булачагын әйтеп куйды. Көндезге сәгать уникедә без Иваныч белән палубага чыктык. Кояш нәкъ баш очында тора һәм әгәр ул ялгыш күктән ычкынып китсә, түбәнә генә килеп төшәр кебек. Беркайда да бернинди дә күләгә юк. Кораб бер якка авышып китсә, мачталар һәм моржа төбеннән кечкенә генә бер күләгә кисәге йөгереп чыга һәм кораб тураю белән ул янадан кереп югала. Мәктәптә чакта минем география дәреслегеннән иң тирән кое төпләренә дә «төшә» ала торган кояш турында укыганым бар иде. Ләкин бу хәл еш түгел, елына нибары бер мәртәбә генә була икән. Һәм менә минә бүген нәкъ баш түбәмдә асылынып торган кояшны күрергә туры килде.

Суга карасаң тагын да кызыграк. Океан өстенә туп-туры төшкән кояш нурлары суны әллә ничәшәр метр тирәнлектә яктыртып торалар. Су астында йөзеп йөргән балыклар, медузалар һәм суүсемнәр аермачык булып күренеп тора, гүя махсус кием киенеп үзең шулар арасында йөзеп йөрисең.

Кичкә таба күзләремнең бик нык ачытуын тойдым, әйтерсең лә күз кабакларым астына ком тулган. Озакламый күзләремә кан сауды һәм кабакларым шешә башлады. Кичке аш вакытында доктор, мине күргәч, кычкырып ук җибәрде:

— Шулай булыр дип уйлаган идем аны, тәки күзләрен нур суккан бит!

Ул мине үзенең медпунктына алып китте, күзләремә нәрсәдер тамызды, кабакларыма юеш мамык куйды һәм палубага кара күзлексез чыгуны бик катгый итеп тыйды.

* * *

Экваторга якынлашуыбызны эссе һава гына белгертми, моны корабтагы бәйрәм алды ыгы-зыгысыннан да сизеп була — диңгезчеләр Нептун бәйрәменә хәзерләнә башладылар.

Скипер буенча әледән-әле бәлдерү тапшыралар: «Җен-пәриләргә беренче ярдәмче каютасына җыелырга!» Электромеханик Алферов әзерләгән шаян программа буенча диңгез алласы һәркемгә аерым бер җәза билгеләячәк. Таякның авыр башы инде, әлбәттә, безгә, экваторны моңарчы глобустан гына күреп белгән «гөнаһлы» бәндәләргә төшәчәк. Буяу бүлмәсе янында кичке аштан соң ук кара төнгәчә шау-гөр киләләр. Анда бәйрәмгә әзерлек эшләре бара. «Чәчтараш» үзенең гаять зур агач пычагын буйый, «Пират» үзенә яңа агач аяк ясый һәм «Ямай ромы» дип язылган коргаксыган мичкәсен ныгыта. «Су анасы» булырга теләгән моторист Валановский сүс бауны сүтеп аксыл чәч толымнары әмәлли. Дүртенче трюм түбәсендә сират күпере ясыйлар. Ул өсте киндер

белән капланган ике баскыч арасында булачак. Палубаның бер читендә безне диңгезгә манчып алу өчен, махсус урын әзерлиләр.

Экваторны без төнге сәгать икедә кичтек. Мин бу минутны капитан күперчегендә көтеп тордым. Хәер, барыбер тирә-яктагы дымлы, бөрку караңгылыктан башка берни дә күренмәде. Икенче штурман Иваныч озын гудок бирде һәм без җирнең көньяк ярымшарына чыктык. Шуннан соң гына мин йокларга киттем.

Бәйрәм сәгать бергә, көндезге аштан соң билгеләнгән иде. Бәхеткә каршы, көн бик эссе түгел. Каршыдан искән көньяк җиле салкын һава алып килмәсә дә, тирләгән тәнне азмы-күпме киптерергә ярый. Шактый эре дулкыннар корабны әле бер, әле икенче якка янтайталар һәм диңгез алласының кичә ясалган бассейныннан су түгелә. Шуна күрә аңа әледән-әле су тутырып торырга туры килә.

Рулевой һәм машина вахтасындагы кешеләрдән кала барысы да өске палубага чыгып тезелделәр. Баштанаяк кар кебек ак, купшы киемнәр кигән капитан безгә җирәнгәндәй карап куйды. Чөнки без төрлебез-төрле иске-москы киемнәрдән идек — бөгәрләнгән иске чалбарлар, юа-юа уңып беткән ертык майкалар, кайберәүләр гомумән трусиктан гына. Диңгез алласы безне суга манчып алгач, бу киемнәрне ыргытып калдырачакбыз. Капитан безне тантаналы вакыйга — экваторны үтеп чыгу белән котлады да бәйрәмне башларга боерды. Шакылдавыклар шакылдый, тырылдавыклар тырылдый, мөгезләр гүелди һәм кулдан ясалган башка төр уен кораллары уйный башлады. Ул да булмады, палубага әллә ниткән әкәмәт киемнәр кигән чуар төркем — «Җен-пәриләр» килеп керде. Җеннәр ямьсез итеп бии-бии, акырып-бакырып, кәкрәеп-бөкрәеп безгә таба якынлашалар. Иң алдан шатланып өрә-өрә этебез Чарлик чабып килә. Бүген аны да бәйрәм киеменә киендергәннәр— өстендә буй-буй диңгезче тельняшкасы, киң балаклы флот чалбары, баш түбәсенә чөеп куелган мичманка. Аның артыннан тәннәрен күмер белән буяп бетергән, чучка борынлы дүрт җен тәхеттә бик горур кыяфәт белән хәрәкәтсез утыручы диңгез алласы Нептунны — баш механик Морозовны алып киләләр. Аның башында алтын таҗ, үкчәләренә кадәр җитәрлек итеп иске ак җәймәләрдән тегелгән чапан, кулында алтынланган өч япьле сәнәк. Шәлпәп таралган ак сакалы җиргә тиеп тора. Алар артыннан пират, чәчтараш, доктор һәм ике су анасы килә. Аларның берсе — пешекче Надя, ә икенчесе — ясалма күкрәкле һәм йонлач ботына «ир эзлим» дип язылганы — моторист Валановский.

Менә «җен-пәриләр» безнең янга килеп җиттеләр, пәри музыкасы тукталды, җеннәр тәхетне палубага куйганда Нептунны борт артына төшереп җибәрә яздылар. Капитан Нептунга честь бирде һәм барысын да әйбәтләп сөйләде — бу нинди кораб, кайда һәм нинди йөк төяп бара, корабта ничә «алласыз» кеше бар. Нептун капитанга экваторның алтын ачкычын бирде һәм үз биләмәләренә керергә рөхсәт итте. «Җен-пәри»ләрнең барысына да берәр чәркә шәраб өләштеләр, шуннан соң Нептун яңадан тәхетенә менеп утырды һәм безнең гөнаһларыбызны йолу башланды.

Җеннәрнең берсе озын бөр төргәк — экипажның гөнаһлар китабын укый башлады, Нептун җәза билгели барды. Соңгы тукталышларның берсендә бераз салып кайткан бер диңгезченең муенын зур мунчала белән сабынлап куйдылар. Йокларга яратучы икенче бер диңгезченең йомшак җиренә «йокыга каршы укол» салдылар. Әле бер, әле икенче корабта эшләп йөрүче берәүнең сыртына майлы буяу белән мөһер суктылар. Анда безнең корабның исеме язылган иде — кайда эшләгәнен онытмасын, янәсе. Миңа, яңа кеше буларак, тулы программа бирделәр: «кырдылар» да, «компресс» та куйдылар, мөһер дә суктылар, сират күперен дә кичерттеләр. Киндер белән капланган һәм буеннан-буена мазутка манылган чүпрәк кисәкләре эленгән күперне кичкәндә инде мин

зем дә ин әшәке җен кебек буялган идем. Сират күперен кичүгә, улларымнан-аякларымнан эләктереп алдылар да, суга томырдылар. ыпырчына-тыпырчына судан чыгып та өлгермәдем, туп-тулы итеп коры әраб салынган зур агач бокал китереп тоттырдылар. «Җен-пәри»ләр- ен сызгыруы һәм акыруы астында шәрабны чөмереп бетерергә туры илде. Шуннан соң гына минем җанымны тынычлыкта калдырдылар. Мазутлы киндер кисәкләре авызыңа һәм борыныңа тиеп-тиеп торган ар сират күпере аша мүкәләп үтү бик үк рәхәт түгел түгелен. Анын аравы, шул юлдан чыгып килүче башка кешеләрне карап тору гаҗәеп ызык. Ике практикантны сират күперенә кара-каршы кертеп җибәрде- ләр. Тегеләр брезент астында очраштылар да тар юлдан узу өчен бер- берсен төртешә-төртешә бөтенләй пычранып беттеләр. Җеннәр икенче бер практикантның трусигын сыдырып төшерделәр дә йомшак җиренә юып та бетми торган буяу белән ике мөһер бастылар. Ярты көн буе эчләребез катып көлештек.

Соңыннан котырынган җеннәр Нептунның үзен дә, тәхетеннән алып, бассейнга ыргыттылар һәм, башка кеше калмагач, бер-берсен суга этеп төшерә башладылар.

Көннең калган өлешен юынып үткәрдек. Душларда кайнар су җитәр- лек иде. Мазутларны башта солярка белән юдык, аннары пычрак тап- ларны бетерә торган сыекча белән ышкыдык, шуннан соң гына бер- беребезне сабынлап, мунчалалап юдык. Ләкин барыбер минем чәчләр укмашып-укмашып калды.

Озакламый скипер аша барыбызны да бәйрәм ашына чакырдылар. Шеф-пешекче бик нык тырышкан — өстәлләрдә бәрәңге белән кызды- рылган тавык, тәмле балык, лимон белән шпрот, Латакиядә үк алып бүгенге көн өчен сакланган алмалар һәм әфлисуннар да бар иде. Төнге уникегә кадәр утырдык. Диңгезчеләрнең борыңгы җырларын җырладык, биедек, әллә ниләр кыланып беттек. Гомумән, бу көн безнең артык бертөрлеләнеп киткән көндәлек тормышыбызны бизәп, безне дәртлән- дереп җибәрде.

## Романтиклар хыялы...




Гаҗәеп матур булып таң ата.

Экваторның көньягы төньяк ярымшардагыга караганда салкынчарак кебек тоела. Дөрес, океан суының җылылыгы 32 градус һәм һава да

юеш чүпрәк сыман дымлы тора, шулай да көньяк җиле инде битка рәхәтлек биреп исә башлады.

Бүген сәгать унберләр тирәсендә офыкта тотенләп баручы моржалар сафы күренде. Матрос Редько аларны шунда ук танып алды һәм шатланып: «Безнекеләр!» — дип кычкырып җибәрде. Тегеләр кит аулаучы «Совет Украинасы» флотилиясе булып чыкты. Менә инде борыннарына гарпун пушкалары куелган, дулкыннар өстендә сикерә-сикерә баручы зур булмаган судноланр аермачык булып күренә башлады. Редько алар белән рация буенча бәйләнешкә керергә азапланып карады, ләкин ул сөйләшергә өлгергәнче судноланр тизлекләрен киметмичә төньякка табан китеп бардылар.

— Тизрәк кайтып җитәргә ашыгалар,— дип куйды Редько сокланып һәм бераз гына көнләшеп.— Әйтергә генә ансат бит — җиде ай ярым буе гел суда йөргәннәр. Коры җир һәм туган-тумачаларны күрмичә җиде ай үткән...

*
* *

Миндә әллә нинди гаҗәеп бер тоем яши. Әйтерсең лә мин су океаны белән күк океаны арасындагы иксез-чиксез зәңгәр киңлектә түгел, ә үземнең узганым белән киләчәгем арасында эленеп торам. Монда вакыт шундый акрын уза ки, миңа тормыш турында озаклап уйланырга тулысынча мөмкинлек бар.

Мин үземнең туганнарым, дусларым, якыннарым, гомумән, илебез халкы белән турыдан-туры бәйләнештән башка яши алмавыма торган саен ныграк инана барам. Бу бәйләнешләр никадәр ныграк һәм тирәнрәк булса, кеше рухи яктан шул кадәр баерак, кызыграк була һәм аның тормышы да мәгънәлерәк корыла. Хәтта каберлектәге мәет тә үзе белән тиңнәр арасында ята. Шулай булгач, тере кеше ничек япа-ялгыз була алсын инде?! Ләкин кешеләрнең сиңе ихтирам итүләрен теләсәң, син үзең дә кешеләргә кирәкле, хәтта зарури бер зат булырга тиешсең. Дан һәм дәрәҗә бик рәхәт нәрсәләр. Ләкин алар дан өчен махсус рәвештә омтылучыларга түгел, бәлки ничек тә булса кешеләргә файда эшләү турында уйлаган адәмнәргә генә килә. Үзеңнең кешеләргә кирәклегеңне тоюдан да рәхәтрәк нәрсә юк, минемчә.

Хәзергә минем бүгенге татар әдәби хәрәкәте белән бәйләнышларым вакытлыча өзелеп тора. Минем өемдә Сибгат Хәкимнең яңа поэмасы турында яза башлаган мәкаләм очланмыйча калды. Мин әле бу әсәрне сәяхәткә чыгып китәр алдыннан гына укыган идем. Бу поэма — Хәким поэзиясенең фәлсәфи һәм гомумиләштерү көченең гүзәл үрнәге, анда чын кеше йөрәгенең игелекле җылысы тупланган. Кызганыч, ләкин матбугатта мин аның турында сүз әйтергә өлгермичә калдым. Сүз юк, поэманы миннән башка да бәяләрләр. Ләкин аны беркем дә нәкъ минем тойгыларым белән укый алмас, нәкъ мин кичергән хисләрне кичерә алмас. Юк, башкалар миннән акылсызрак дип әйтүем түгел, ә җирдә кешеләрнең нәкъ бер төрле тойгы кичермәүләре, нәкъ бер төрле итеп хисләнмәүләре турында гына әйтәсем килә. Бәхеткә каршы, кешеләр төрле, шулай булгач, минем фикерләр дә башкаларныкына охшамас һәм мин матбугатта нәкъ әнә шул үз фикерем белән чыгарга тиешмен.

Гариф Гобәйнең «Коръән серләре» дигән китабы турында да күптән фикер әйтәсем килеп йөри. Сүз юк, бу китап безнең пропагандистлар өчен ипи кебек үк кирәкле һәм файдалы хезмәт. Автор аңлаешлы тел белән, кызыклы итеп һәм бик вакланмыйча гына мөселманнарның «изге китабындагы» бүгенге фән белән каршы килгән фикерләрне һәм мәгънәсез гореф-гадәтләрнең асылын ачып бирә. Ләкин аның тәнкыйтенә

тарихилык житми. Автор безнең бүгенге карашка бөтенләй юк-бар булып күренгән теге яки бу гореф-гадәтнең ни өчен килеп чыкканлыгын аңлатмый. Ә бит ул гореф-гадәтләрнең килеп чыгуы үз вакытында ни белән булса да акланган булган, югыйсә ул гомумән килеп тә чыкмаган булыр иде. Бу уразага да, сөннәткә дә, дуңгыз итен ашауны тыюга да, аракы эчүне тыюга да (хәер, монысын һич кенә дә мәгънәсез гореф-гадәт дип булмый!) һәм хәтта феодаль җәмгыять үсешенең бер чоры тудырган күп хатын алуга да карый. Шушындый фәнни-тарихи күзлектән чыгып карамаганда Коръәнне дөрес аңларга да, ышанычлы итеп тәнкыйтьләргә дә мөмкин түгел. Кызганычка каршы, Г. Гобәй китабына рецензия язучыларның күбесе моны күрми узалар.

Илһам Шакиров турында Татарстан радиосы өчен языла башлаган музыкаль очерк та тәмамланмыйча калды. Мин анда, галим һәм язучы халыкның интеллектуаль тормышын чагылдырса, чын милли җырчы халыкның хисси тормышын чагылдырырга тиеш дигән фикер әйтмәкче идем. Илһам Шакиров тавышында халык тарихын, аның традицияләрен, үзенчәлекле һәм бай культурасын тоям мин.

Әнә шундый тәмамланмаган бик күп эшләрем миңа тынгылык бирми, өерелешеп күз алдыма киләләр дә үзләренең барлыкларын сиздерәләр.

* * *

Экваторны узып китүгә инде ике тәүлек булды, ә мин әле көньяк ярымшарының йолдызлы күген һаман күргәнем юк иде. Болыт дисән болыт түгел, күктә әллә ниткән төтен сыман дымлы бөркүлек тора һәм аның аркылы бер генә йолдыз да күренми иде. Мин инде көньяк ярымшары йолдызларын күрү турындагы хыялымны оныта ук башлаган идем. Ә бүген кинодан соң палубага чыгып күккә карасам: мәңге онытылмаслык гүзәл бер күренеш! Баш очымда, өлгергән йөзем тәлгәшләредәй тезелешеп, бөтенләй таныш булмаган ят йолдыз төркемнәре асылынып тора. Һич бер таныш йолдыз булсачы! Күңел кинәт шомланып ук китте — әйтерсең, мин икенче бер планетага килеп эләккәнмен.

Ә кая соң әле төньяк ярымшардагы бөтен романтикларның хыялы булган «Көньяк тәресе?»

Мин капитан күперчегенә күтәреләм. Капитан миңа бик үк балкып янмый торган дүрт йолдыз күрсәтә. Аларны туры сызык белән тоташтырсаң, офык читенә чак кына янтаеп торучы тәре барлыкка килә. Бу йолдызлар океан чоңгылларына күмелгән билгесез диңгезчеләр кабере өстенә куелган мәңгелек тәре сыман янып тора. Ләкин мин күңелдә җиңелчә канәгатьсезлек тоям. Көньяк тәресе күк гөмбәзендә әле кан төсле кып-кызыл булып, әле зөбәрҗәттәй ямь-яшел төскә кереп, әле зәңгәрләнеп җемелдәгән бихисап эре йолдызлар арасында бөтенләй югалып кала. Капитан миңа көньяк ярымшарның иң якты йолдызын — Конопусны күрсәтте. Ул падишаһ таҗындагы ялтыравык асылташ кебек балкып тора. Шунда ук мин Центавр йолдызлыгының йомылмый калган күзләр шикелле җемелдәүче ике йолдызын һәм кара күк бәрхетенә сибелгән тагын әллә никадәр гаҗәеп йолдызлар күрдем. Мондагы йолдызлар төньяк ярымшардагыга караганда эрерәк тә, яктырак та булып күренәләр, ә Киек каз юлы ялтыравык бәс шикелле, эчтән яктырып торган тузан бөртекләредәй йолдызлар белән җемелди. Игътибар белән озаклап тыңлап торсаң, шушы бөздәй йолдызларның бер-берсенә ышкылып кыштырдаганнарын ишеткәндәй буласың.

# Изге Өмет борыны




Изге Өмет борынына кадәр ике көнлек юл калды. Капитан 15 ел буе йөзү дәверендә бу тирәдәге диңгезнең азмы-күпме тынычрак булуын нибары бер мәртәбә генә күрдем, дип сөйли. Гадәттә монда туктаусыз давыллар котырына. Шуңа күрә булса кирәк, борынгы диңгезчеләр бу кыялы ярымутрауны Давыллар борыны дип атаганнар. Соңыннан португалиялеләр шушы борын яныннан үтеп, Һиндстанга барырга өметләнеп кенә аны Изге Өмет борыны дип исемләгәннәр.

Диңгез кошларын күрмәвебезгә байтак вакыт үткән иде инде. Шуна күрә диңгез акчарлакларының иң эре төре, канатларын җәйгәч ике метр чамасы булган ап-ак альбатросны күрүгә барыбыз да шатландык. Ул канатларын җәеп нәкъ мачта янында эленеп тора, җилгә каршы тору өчен генә канатларын чак-чак кымшатып куя һәм сары каймалы чем-кара күзләрен текәп безгә карый. Аның күз карашыннан кошларга гына хас ниндидер акыллылык сирпелә. Альбатросларның күренүе ярга якынлашуның беренче билгесе ул.

Кичкә таба кораб сизелерлек чайкала башлады: һава тып-тын диярлек торса да, безгә каршы ерактан биек-биек дулкыннар тәгәрәп килә. Көнбатыш ягындагы болытлар канга манчылган мамык кисәкләре кебек кып-кызыл төскә керделәр — бу инде һава начарлана дигән сүз.

* * *

Шушы ук көнне бездә кечкенә генә күңелсезлек булып алды — юнәлешне идарә итү җайланмасы чыгымлый башлады. Рульне теге яки бу якка борган саен бөтен кораб дерелди, нәрсәләрдер шытыр-шытыр килеп бер-берсенә ышкылалар һәм кинәт корабның тизлеге кими. Шунсы начар, механиклар берничек тә төзексезлекнең сәбәбен таба алмыйлар. Миңа капитан белән баш механикның түбәндәге сөйләшүен тыңлап торырга туры килде:

**Баш механик.** Роман Александрович, бәлки Одессадан Кейптаунга керергә рөхсәт сорарбыз? Алда Һинд океаны, хәбәрләр начар һава вәгъдә итәләр, мин юнәлешне идарә итү җайланмасыннан куркам. Хәзер безгә профилактика менә моннан кирәк. (Ул кул сырты белән муенын ышкып күрсәтте.)

**Капитан.** Анатолий Петрович, ә сез газета укыйсызмы?

**Баш механик.** (Кәефе китеп.) Ә монда газетаның ни катнашы бар?

**Капитан.** Газета укымасагыз, хет радио тыңларга кирәк...
**Баш механик.** Мин чынлап әйтәм, Роман Александрович.
**Капитан.** Мин дә чынлап әйтәм. Мин моны сездән ишетүемә гаҗәпләнәм. Сез бит дөньяга кичә яки бүген генә килмәгән, һәм дөньяда нигәр булуын беләсез. Сезгә Көньяк Африка республикасында расачыл политика алып барылуы турында лекция сөйләп торырга кирәк түгелдер бит инде?! Кейптаун хәтта безнең илнең бу тирәдә сигезәр-тугызар ай йөзүче кит аулау флотилиясенә дә ябык. Ә сез керергә телисез... Юк, тәзексезлекнең бөтен сәбәпләре ачылмыйча һәм аны бетерүдә соң чиккә кадәр үз көчебезне куймыйча торып, Одессага хәбәр итү түгел, бу турыда сөйләшеп тә тормыйм. (Ул күзләренә бинокль китерде һәм сөйләшү тәмам дигән сыман баш механикка арты белән борылды.)

* * *

Иртәнге сәгать алтынчыда мине вахтенный уятты:
— Торыгыз, Рафаэль Әхмәтович, югыйсә Изге Өмет борынын күрми каласыз,— ди.
Аннан-моннан гына киенеп, палубага йөгереп чыгам. Кинәт йөземә чиләкләп салкын су сиптеләрмени — Антарктиданың бозлы сулышын алып килүче, сөякләргә үтә торган салкын каршы җилдән буылып калдым. Өстенә ясалма мехтан тегелгән куртка кигән баш механик күперчек буйлап әрле-бирле йөри, вахтенный җылы бушлатына төренгән. Миңа да тиз генә пальто алып чыгарга туры килде.
Әнә ул, китаплар һәм география дәреслекләре буенча миңа бик тә таныш булган атаклы борын! Кара яшел кыялы ярларга ярсыган соры дулкыннар килеп бәрелә. Яр читенә ап-ак күбекләр җыелган, анын өстенә болыт булып су тузаны күтәрелгән. Ерактагы канонада шикелле гүләү авазлары безгә кадәр килеп ишетелә. Өстәрәк, кызыл балчыклы киртләч ярлар артында, түбәсе өстәл шикелле тип-тигез булган зур тау. Аның «Өстәл тавы» дигән исеме дә шуннан алынган. Тау өстендә зәңгәрсу-кызгылт болытлар өере.
Матрослар һәм мотористлар да, җылы каюталарыннан чыгып, бөргәләнып киткән соры яр буен күзәтәләр һәм, сигаретларын җилдән җиң эченә яшереп, дәшми-тынмый гына тәмәке тарталар. Без инде ничәмә көннәр буе коры җир күрмәгән идек һәм тагын тиз генә күрергә туры килмәячәк. Алда — Һинд океанының иксез-чиксез киңлекләре.
Зур, текә дулкыннар бер-бер артлы безгә табан тәгәрәп киләләр. «Җәлил», борынын өскә чөеп, тауга күтәрелгәндәй, дулкын өстенә менә. Дулкын сыртына менеп җиткәч кенә борыны белән аска чөймәләп китә һәм каршы килүче дулкынга килеп кадала. Шул мизгелдә корабның бөтен гәүдәсе буйлап калтырану йөгереп үтә: койрыктагы ишкәк валы судан чыга да, бик нык дерелдәү хасил итеп, һавада буш әйләнә. Моңсы инде буйга чайкалу дип атала. Моңа син үзеңне тиз йөрешле лифттагы кебек хис итәсең: әле кинәт кенә авырлыгыңны югалтып каядыр түбән төшеп китәсең, әле сине кинәт кенә өскә ыргыта, үз гәүдәңнең авырлыгыннан тез буыннарың сыгылып куя. Минем яңадан күңел болгана башлады: берни дә эшләп булмый, буйга чайкалуга өр-яңадан күнегергә кирәк, диләр диңгезчеләр.

* * *

Метеорологлар күптән инде вәгъдә иткән давыл безне озак әзәрләкләп килде һәм, ниһаять, Мадагаскар утрауларына җитәрәк куып тотты.
Җил улавы һәм баулар сызгыруы астында бер-беребезнең сөйләшкәнен дә ишетмибез. Океан, офыктан офыкка сузылып, кайный, бызыр-

дый, котырына. Дулкын сыртлары бер-берсе белән кушылып, коточкыч зур су таулары хасил итәләр. Алар өстендә кар кебек ак, тигезле-тигезсез күбек тасмалары сузылган. Һавага бертуктаусыз чәчрәп торган су тузаны һәм күбек офыкларны тарайтып күрсәтә. Сорыланып торган куркыныч караңгылык эченнән биниһая зур дулкын тауларының кораб гәүдәсенә сугуыннан безнең егерме мең тонналы тимер тавыбыз калтырап куя. Дулкын бортка бәргәч чәчрәгән яшькелт соры су фонтаны тыелгысыз рәвештә өскә күтәрелеп китә һәм су өсте тигезлегеннән 17 метр биектә урнашкан йөртү рубкасы тәрәзәләрен юып төшерә. Без тизлекне бик нык акрынайтырга һәм курсны үзгәртергә мәҗбүр булабыз. Хәзер без сәгатенә 3—4 миль тизлек белән генә барабыз.

Гәрчә без давыл якынлашуын алдан ук белеп, аны каршыларга әзерләнеп торсак та, шторм шактый зыян китерде. Башта буяу бүлмәсе янында буш мичкәләрне бәйләп куйган баулар өзелде һәм мичкәләр дөбер-шатыр килеп палуба буйлап тәгәрәп йөри башладылар. Боцман палубага чыгып аларны җыярга теләгән иде дә, баш ярдәмче рөхсәт итмәде:

— Тик кенә утыр, үзеңне дә юып төшерүен телисеңмени? — диде.

Озакламый мичкәләр «исән-сау гына» диңгезгә агып киттеләр. Анна-ры кают-компаниядәге яхшылап ныгытылмаган утыргыч кинәт кенә урыныннан кубып киткән дә шифоньер пыяласын бәреп ваткан. Дүртенче штурманның магнитофоны, өстәлгә шөрепләр белән беркетелеп куелуга карамастан, идәнгә очып төшкән. Баш механикның язу машинкасы ватылган.

Яңадан диңгез авыруы интектерә башлагач, мин, аста азрак чайкый дип, кают-компаниягә төшеп яткан идем, тимер шытырдаган тавыш ишетеп куркып киттем. Ул да булмады, матрослар йөгерешә башлады һәм ишек астыннан идәндәге чип-чиста линолиумга су җәелде. «Әллә корабның төбе тишелде инде»,— дип уйладым мин диванның каты култыксасыннан башымны күтәрә алмыйча. Соңыннан гына белдем, көчле дулкын кораб маңгаендагы өске корылманың корыч ишеген бәреп чыгарган, аны кәгазь кебек итеп бөгәрләп ташлаган булган икән.

* * *

Шактый рәхимсез Һинд океаны безне инде өченче көн каккалап-суккалап йөртә.

Шулай булуга карамастан, Муса Җәлил турындагы әңгәмәләр циклын дәвам итәм. Мин аның иҗатын татар әдәбиятының бөтен тарихы белән бәйләп сөйләргә тырышам. Диңгезчеләр кызыксынып тыңлыйлар. Аларның күбесе моңа кадәр безнең халкыбыз тарихын һәм аның күп гасырлы культурасын шактый зәгыйфь итеп күзаллаган булганнар.

* * *

Шушындый шыксыз көннәрдә өй, гаилә, балалар бигрәк тә нык сагындыра. Мин генә түгел, барысы да сагыналар. Үзләре бөтенләй башка нәрсә турында сөйләшкән булалар, шахмат, шашка, домино уйныйлар, кызыл почмакта газета-журнал төпләмәләрен караштыралар. Шул чакта бер уч радиограмма тоткан радист кына керсен, хәзер барысы да тынып калалар һәм өметле карашлары белән аңа текәләләр.

Ерак сәяхәттәге экипаж зур бер гаилә кебек ул, анда кешенең кайгышатлыклары уртак.

Мәсәлән, Бердичевскийның хатыны авырып киткән. Бердичевский хәтта аның хәле ничек икәнен дә белми. Әнисе: «Хатынынны шифаханәгә салдылар, авыруын тикшерәләр»,— дип хәбәр итте дә бетте-китте. Менә ун көн булды инде, ни өчен тикшерәләр, нинди авыру икән, дип

бик кайгыра. Һәркем сүзсез генә аның кайгысын уртаклаша, аны гадәттәгечә юк-бар шаярулар белән борчымыйлар.

Икенче штурман Одессадан чыгып киткәндә кызының үпкәләре шешеп калган иде. Дөрес, ана борчылмаска кушып радиограммалар килә тора, ләкин әти кеше нигәдер бу тынычландыруларга ышанып бетми. Моннан берничә ел элек баш электромеханик Алферовка да гел шундый әйбәт радиограммалар гына килгән, ә Одессага кайткач ул үзенең бердәнбер баласы, гел әйбәт билгеләр генә алып укыган уналты яшьлек кызын бер аяксыз килеш күргән. Кыз ялгыш машина астына эләккән һәм аның аягын кисәргә мәҗбүр булганнар.

Коля Кожиновның хатыны бөтенләй язмый башлады, юлга чыгып киткәч тә ике радиограмма җибәрде дә бетте-китте. Ә бит Колянын хәләл җефете яшь, чибәр, баласы юк... Кичә, корабның эчке ягын буяп маташканда, Коля бер-ике минутка каядыр китеп торган, ә шул чакта кемдер яңа гына буялган идән буйлап үткән. Коляның моны күреп тәмам җене чыкты («Кайсы сукыры кеше эшләгәнне бозып йөри икән...») Ул ачуыннан җилләнеп буяу савыты белән пумаланы тибеп җибәрде һәм идәннәрне, стеналарны пычратып бетерде. Чынлап карасаң, бу эшкә үзе гаепле: буйый торган урынга җеп тартып, кәгазьгә кисәтү язып куйган булса, анда кем дә килеп кермәгән булыр иде. Ләкин аны беркем дә ачуланмады — күреп торалар, кешенең нервылары соң чиккәчә тартылган...

* * *

Ниһаять, давыл басылды. Җил, тормышның гадәти агымы белән килешкәндәй, тәмам тынычланып калды. Океан өстендә элеккечә бушлык. Күперчек канатына чыгып бассаң, тирә-якта бетмәс-төкәнмәс зәңгәрлек, алсу болыт өерләре һәм дулкын сыртларындагы кояш чагылышыннан башка бер нәрсә дә күрә алмыйсың. Диңгездән килгән иодлы саф һавага чип-чиста итеп юылган кояшлы палуба исе кушылып, күкрәкләрне киңәйтеп җибәрә. Һава торышы белән бергә кәеф тә үзгәрә тора. Диңгез ул гаять сизгер көзге. Анда синең күңелең дә чагылып тора. Әгәр диңгезгә карагач синең күңелеңә буш сагыш тула икән, син инде көзгегә үпкәләмә, диңгез синең күңелеңнең ярлылыгын гына чагылдырган булыр. Чын диңгезче диңгезнең ялтыравык матурлыгына сирәк соклана, күбесенчә ул аңа карамый да. Соклану сүзләрен ул тагын да сирәгрәк әйтә, күп вакытта диңгезгә карап сүгенә генә. Диңгез аның рухында, ул тормыш кануннының бер кисәге булып саклана һәм диңгезче шуннан башка яши дә алмый.

Тормышның ачысын-төчесен татыган диңгезчеләр миңа ял вакытларын ничек түземсезләнеп көтүләре, тиздән ярга чыгарга ашкынулары турында сөйләделәр. Ә ярга чыгып ике-өч атна да үтми, диңгезче күңелендә ниндидер бушлык, сагыш башлана, ул бушлыкны берни белән дә тутырып булмый икән. Чираттагы ялның икенче яртысында инде диңгезчеләр причалга килеп йөри башлыйлар, ерак сәяхәттән кайтучы корабларны каршылыйлар, кайчандыр үзләре йөзгән корабларны күреп, сабыйларча куаналар һәм еш кына чираттагы ялларын да бетермичә кадрлар бүлегенә килә лэр, акча бетте дип ялганлап, рейска иртәрәк чыгаруларын үтенәләр.

*Ахыры бар.*

**Мария Елизарова**

# КЕШЕЛӘР АҢА ЫШАНА

## 1913 ел.

Язгы кояш нурлары белән парланган җир өстеннән җылы дым күтәрелә. Урыны-урыны белән юл читләрендә үлән тишеп чыккан да алар әле эреп тә бетмәгән кара җир өстендә яшел утраучык булып күренәләр.

Кыйшаеп беткән йортларның салам түбәләре корт ашаган гөмбәләр күк каралып тора. Шунда ук авыл байларының нарат бүрәнәләрдән салынган калай түбәле йортлары утыра. Аларны кайсын кызылга, кайсын яшелгә буяганнар. Бу йортларның зур, якты тәрәзәләре карындык каплаган, чыралар кыстырып бетергән ярлы тәрәзәләргә чекерәеп карап торалар. Купшы наличникләр арасыннан ялтыраган ул пыяла күзләр ерак Мордовиянең Кәкрекүл авылында булган хәлләрнең барын да күреп торалар сыман.

Әле менә хәзер дә авыл иртәнге татлы йокыга талган, ә бай йортының ачык тәрәзәсе янында ике кеше көндез булган хәлләр турында сөйләшә.

— Галим Хәмзәсе егет ул, хатынның менә дигәнен эләктерде,— ди Хәйрулла, чепи күзләрен кыскалап.

— Әйе, кызык итте. Кызның суга баруы икән, атка салган да киткән тегене Хәмзә. Бик яшь инде,— ди Сәлим дустына. Тавышыннан аңлап булмый үзенең, әллә хуплый, әллә көнләшә.

— Яшь дисеңме? Ундүртенче киткән бит. Никахка Лотфи риза булмас. Нинди хатын ди ул. Курчаклы уйнар чагы гына.

— Зыян юк, никахсыз яшәрләр. Я алдымбирдем ясарлар. Аның каравы тамагы тук булыр. Киендереп тә җибәрерләр үзен, сәләмә йөри иде бит.

— Син үз кызыңны андый кәҗәгә бирер идеңме?

— Әйттең сүз!.. Минем кыз бит ул. Мәхфүзә ятим кыз бала... Мәчет янында теләнеп торганын күргәнең юкмыни...

— Әйе, язмышы авыр кызның. Өч яшьтән ятим калды, кешеләргә эшләп, тукмактан бүтәнне күрмәде, моннан да күп әләгер әле аңар.

— Хәмзәнең куллары авыр... Зыян юк, Мәхфүзә үзен рәнҗеттермәс әле. Соңгы елларда телгә бик чаяланды. Кирәген әйтер.

— Тел белән котылырсың бездән! Кичә син Фәридәңне ни дип кыйнадың?

— Кыйнадым? Башына бер-икене биреп алдым... Нәрсә, синеңчә, гафу итәргәме! Йөзен капламыйча ирләр ягына чыксын әле.

— Курыккандыр. Улың бишектән егылды бит.

— Яхшылап карасын иде.

— Аның үз баласымыни? Көндәшнеке лә. Аны болай да алла каргаган, бала китерми. Син тагы кеше балаларын каратасың.

— Миңа акыл өйрәтмә. Ни эшләргә кирәген үзем беләм.

— Алай булгач, Мәхфүзәгә дә тел тидермә. Икенче атна инде подвалда тоталар — әшмени бу! Кара, кара, сәләмәдән чыгып бара. Менә сиңа киендергәннәр! — һәм ул Галим бай капкасыннан чыгып барган кызга төртеп күрсәтте.

Зифа буйлы ул кыз өстенә камзул кигән, башына ак яулык япкан. Кара толымнары иэдән түбән төшкән. Бер кулы белән көянтә башына элгән чиләген тоткан, икенчесе белән, яулык очын чеметеп, йөзен каплаган. Яулык читеннән кызның дугаланып торган кара кашлары күренә.

Кое янына килеп, кеше юклыгын күргәч, Мәхфүзә, яулыгын җибәреп, чиләгенә су ала башлады. Күз карашы аның кырыс, нәзек иреннәре кысылган. Алар әле генә күргән шәфкатьсезлек турында сөйлиләр иде.

Чиләген тутырып ул өйгә китте. Менә шыгырдап капка ачылды. Мәхфүзә тиз генә йөзен каплады. Кулына юл капчыгы тотып, каршына Хәмзә килә иде. Ул хатыны янына туктап аның җилкәсеннән кагып куйды. Мәхфүзә чиләген куеп үкси башлады.

Хәмзә нидер әйтте, бу, күрәсең, аны юатуы иде. Тагын капка шыгырдады. Кара кәҗә сакаллы, кысык явыз күзле, илле яшьләрләк кеше чыкты. Ак күлмәк-ыштаннан үзенең эре сөякләре төртеп тора. Кара камзулын таякка элгән күк, баш түбәсендә — уңып беткән бәрхет түбәтәй. Тырпаеп торган бармакларын ул, кара калын кашлары өстенә куеп, як-ягына карана башлады. Ерактa Хәмзә белән Мәхфүзәне күргәч, авызын чалшайтып, елмаеп куйды.

— Нәрсә тәрәләп каттың, кайтар суыңны,— дип кычкырды ул Мәхфүзәгә.— Ә син барасы җиреңә атла, якты күздән тимер юлга җитәсең бар.

Мәхфүзә тиз генә чиләкләрен күтәрде, тагын бер тапкыр Хәмзәгә карап алды да өйгә таба китте. Хәмзә дә, капчыгын алып, юлга чыкты. Кайнатасы киленен ачык капкадан кертеп җибәрде, тиз белән бер тибеп алды да ачу белән капканы япты.

— Менә сиңа бәхет! Бу карт дуңгыз улын читкә җибәрде, ә Мәхфүзәне үзенә хезмәтче итеп калдырды,—диде Кара Сәлим, кызганып.

Шул көннән башлап михнәтле алты ел узды. Мәхфүзә кайнатасы йортында көн эшләде, төн эшләде, ял күрмәде, җылы сүз ишетмәде. Ире турында ул кайнатасы белән кайнанасы сүзеннән генә белә иде. Аның үзенә атап иреннән бервакытта да хәбәр килмәде. Хәмзәне фронтка алганнар икән, шунда югалган икән, дигән хәбәрләр йөрде. Австриягә пленга төшкән дип тә сөйләделәр.

Менә Хәмзә өйләнеп кайтты. Мәхфүзәнең кызы Мансура туды. Ул аның бердәнбер шатлыгы иде, ләкин анага баласы янында булырга ирек бирмәделәр. Мәхфүзәнең кызын кулына алуы гына була, шунда ук кычкыра башлыйлар.

— Тагын алган! Бай баласы түгел, кулга өйрәтмә!

— Ялап кына тора!

Ә Мансура елап кечкенә кулларын әнисенә сузса, китереп сугалар.

— Бу хәтле анасы булыр икән, каһәр төшкән елак!

Балага сүз әйтмәсеннәр дип, Мәхфүзә аның янына сирәк килергә тырышты. Аның караве, төннәрен, күз яшьләре белән юаюа, иркәли иде ул кызын.

Хәмзә икенче кат өйләнде. Көндәш килгәч, Мәхфүзәнең болай да караңгы тормышы түзә алмаслык хәлгә әйләнде. Бик еш кына аның башына әллә кызымны да, үземне дә бетерим микән, дигән уйлар килә иде.

Шул елларда революция башланды. Авыл тормышы көн саен үзгәрә барды, тик моны Мәхфүзә сизми иде. Иртә таңнан торып, төн уртасына кадәр ишле семьяга хезмәт итеп, ул кичкә урынына барып егыла иде. Алга таба ничек яшәргә дигән уйдан аның таңга кадәр күзен йоммаган чаклары бик күп булды...

1922 ел җитте. Ләкин Кәкрекүл авылында тормыш әллә ни үзгәрмәде. Байлар Советларга астыртын гына зыян салырга тырыштылар. Алар икмәк яшерәләр, ярлыларга эш бирмиләр. Әҗәткә сорап килүчеләрне мыскыллап:

— Ни дип Советыгызга бармыйсыз? Барыгыз, бар, алар сезне киендерерләр, ашатырлар,— дип, борып җибәрәләр иде.

Мәхфүзәнең ике туганы, Гайсә белән Муса Казаковлар, сеңелләренең авыр хәлен ишетеп, Бакудан аны алырга кайттылар.

Әмма эш аларча барып чыкмады. Кайнатасының карусыз хезмәтчене ычкындырасы килми иде. Шәригать буенча да килен кайнатa йортында торырга тиеш бит.

Авыл Советына мулланы чакырырга туры килә. Туганнары белән көрәштерергә

Мәхфүзәне кызы белән китерсен дип, муллага байны үгетләргә куштылар. Ниһаять, рөхсәт алынды. Мәхфүзәгә кайнана сандыгына бикләнгән асыл киемнәр кидерделәр. Иске-москыга өйрәнгән Мәхфүзә уңайсызланып, артыннан карап калган авылдашларына дәшмичә генә, авыл Советына килде. Тагын нәрсә уйлап чыгарды икән кайнатам?— дип борчылды ул юлда. Күзләренең ялтыравы гына аның эчендә кайнаган ачуын сөйли иде.

Ул килеп кергәндә, Муса абыйсы, ярсып, муллага:

— Хатын-кызларны изәргә байларга юл куелсынмы? — дип сөйләп тора иде.— Сезнең заман үтте инде. Бу эшләреңне туктатырга вакыт!

— Минем ни гаебем бар? Аллаһе тәгалә кайнатага буйсынып яшәргә боерган. Күреп торасыз бит, халык ачыга, ә аның тамагы тук, өсте бөтен. Галим байда ул таш стена артында яши.

— Әйе, таш стена шул,— дип, Мәхфүзәнең олы агасы Гайсә сүзгә кушылды. Яңа күлмәк киертеп кенә хәлне яшерә алмассыз. Карагыз сез аның кулларына, бәхетле тормыштан шулай булганмыни алар.

Мәхфүзә түзә алмады: ирләр алдында йөзне ачарга шәригать кушмаса да, ул абыйлары алдына килеп тезләнде:

— Коткарыгыз, туганнар! Артык түзәр хәлем калмады. Көне-төне эшләрмен, тик бу каһәр төшкән семьяга түгел,— дип ялынды ул, күз яшьләренә буылып.

— Елама, Мәхфүзә, елама!

— Авыл Советы сиңа таныклык бирде. Безгә бүтән берни дә кирәкми.

— Минем шушы күлмәктән башка берни ем дә юк. Чабаталарым яңа инде. Анысын да киеп торырга гына дип кайнанам биргән иде.

Муса аягыннан калошларын салды.

— Мә, ки. Чабаталарыңны кайнанаңа калдыр. Синең аңар хакың булса да, андый кешедән инә дә алырга ярамый.

— Киттек, сеңел!— диде Гайсә, кулына аның кызын алып.

Һәм җенләнгән мулланың күз алдында алар Мәхфүзә белән аның кызын алып чыгып киттеләр.

Шул кадәр үзгәрде Мәхфүзәнең тормышы, башта ул дөньяның ни өчен болай булуын да аңлый алмады. Иң элек аны йөзен каплаудан тыйдылар. Барысы да бергә утырып ашыйлар иде. Шунда ук кечкенә Мансура да утыра. Барысы да аны иркәлиләр, уйнаталар. Бүре баласы күк үскән Мансура зурлар өчен шатлыкка әйләнде.

Галим бай өендә аны урамга да чыгармыйлар иде. Ул елмаерга да куркып үсте. Ә бирсдә аның тавышы яңгырап торды, иптәшләре белән рәхәтләнеп урамда уйнап йөрде.

Бирегә килгәннең беренче көнендә Мәхфүзә абыйсыннан:

— Мансураны кулыма алыйм әле?— дип сораган иде.

— Нигә аны сорап торасың? Үз кызың бит. Теләсәң нишләт. Кыйнарга гына ярамый,— диделәр аңар.

Шатлыктан күз яшьләренә буылып, ул кызын күкрәгенә кысты.

Кичен активистка Нәфисә Бикбаева аңа киемнәр китерде. Мәхфүзә кара юбка, ак блузка киде, башына кызыл яулык бәйләде. Аны танырлык та түгел иде. Нәфисә аны клубка алып барды. Үзешчәннәр концертын карадылар.

Сәхнәгә солдат киеме кигән, кулына винтовка тоткан егет чыкты. Ул кычкырып шигырь укыды. Аның янына зәңгәр блузалы кызлар йөгереп чыктылар да җырлый башладылар.

Нәфисә Мәхфүзәнең авыз эченнән нәрсәдер пышылдап торуына игътибар итте.

— Мәхфүзә, син нәрсә пышылдыйсың? Концерт ошамыймы әллә?

— Бик ошый, бик. Миңа шундый шатлык биргән өчен аллаһе тәгаләгә рәхмәт укыйм.

— Әллә боларны сиңа алла бирде дип беләсеңме? Совет власте бирде аны. Ә концертны эшчеләр бригадасы куя. Менә күреп тор, син дә аларга катышырсың әле!

Боларны аңлау Мәхфүзәгә кыен иде.

Туганнары аны күп эшләтмәделәр. Өйнә чиратлап җыялар иде. Аны ликбезга йөрттеләр. Мәхфүзәнең куллары карандаш тота алмый интекте, хәрефләре кыек чыга иде. Өйгә кайткач та ул сәгатьләр буе грифель тактасына язып утырды.

Бераздан аны драмтүгәрәккә яздылар. Кызык кына иде: аны туфлядан йөрергә өйрәттеләр. Иске чабатасын салгач, ул шәһәр киеменә күнегә алмый интекте. Сөртенеп егылды, кулларын куяр урын таба алмый йөдәде, ә ролен бик тиз ятлап алды. Ышандырырлык итеп, кызып сөйләде. Бары тик җырлый гына алмый иде,— аның өчен сәхнә артыннан башкалар җырлады. Изелгән бер татар хатынының кайчан да булса

ләр сәхнәдә уйнавы кемнең башына килер иде.

Мәхфүзә җәмәгать эшләренә катышып итте. Ятим балаларны җыеп, аларны балалар йортына озатышып йөрде.

Сукбайлыкка өйрәнгән балалар еш кына әйбер урлап качалар иде. Бервакыт балалар йортында электр чыбыкларын кисеп утны сүндерделәр дә алты малай качып китте. Мәхфүзә аларны да табарга булышты.

Мәхфүзәне балалар йортында бик яратучылар һәм завхозлыкка эшкә алдылар. Ул ятимнәрнең тормышын ничек тә җиңеләйтергә тырышып, бөтен күңелен биреп эшли башлады.

Бервакыт иптәшләре аны бал-маскарадка барырга димләделәр. Унсигезенче гасыр киеменә киендерделәр. Мәхфүзәне клубта танырлык та түгел иде. Бәр хәрби егет аны биергә чакырды. Ә Мәхфүзә русча ике генә сүз белә иде: «әйе», «юк».

Мәхфүзәне хәрби егет озата кайтты. Егет никадәр генә сөйләшергә тырышса да, кыз һаман дәшмәде. Кайчагында гына, туры килсә дә, килмәсә дә, «әйе» я «юк» дип куя. «Бу әле һаман маскарадны дәвам итә,— дип уйлады егет.— Менә мин аны озатып куйыйм әле, кайда торганын күрим, аннары кем икәнен дә белермен».

Капка төбенә җиткәч, хәрби егет Мәхфүзәгә кулын сузды:

— Сау бул, дәшми торган кыз! Минем исемем Николай була. Ә сезне кем дип йөртәләр?

— Мәхфүзә. Хушыгыз,— диде Мәхфүзә һәм тиз генә капкага кереп югалды. Хәрби егет әкрен генә китеп барды, ә эченнән кызның исемен кабатлады: «Мәхфүзә, Мәхфүзә»...

Гадәттән тыш намуслы һәм эшчән кеше дип Мәхфүзәгә азык бүлүне тапшырдылар. Шул чагында ул үзенә тигән өлешне дә кыбыграк балаларга бирә иде. Исәп-хисап алып бару өчен математиканы белергә кирәк булды. Мәхфүзә тапкырлау таблицасын өйрәнергә тотынды. Аңар тәрбияче Назарова булышты. Озак та үтми, Мәхфүзәне Пензага, азчылык милләтләр өчен укытучылар әзерләү курсына укырга җибәрделәр.

Мәхфүзә яхшы укый иде, әмма сөйләшүен генә татарча сөйләште. Рус телен тиз генә өйрәнә алмады ул.

1924 елны Мәхфүзә делегатка булды. Партиягә керде. Билет алган көнен ул бер вакытта да онытмас — бу кадерле билетны ул шундый тантана белән кулына алды, аның кызыл тышын кечкенә баланы иркәләгән кук сыйпап торды. «Мин һәр вакыт синең белән булырмын. Син минем дустым, юл күрсәтүче йолдызым!»— дип уйлады ул.

— Казакова, Казанга барыгыз. Сезгә инде юллар ачык, укуыгызны дәвам итәрсез,— диделәр аңа партиянең Пенза губерна комитетында. Шулай итеп, Мәхфүзә Казанда коммунистик университетка укырга керде.

Беренче курсны бетергәндә үк ул яхшы укуы өчен бүләк алды, аңа Ленинград белән Мәскәүне күрергә путевка бирделәр. Икенче курстан башлап Казакованы бик еш кына командировкаларга җибәрә башладылар. Ул һәрвакыт тапшырылган эшне уңыш белән башкарып кайта торган иде.

Бервакыт ул командировкага ректор Вольфович белән бергә Арчага җибәрелде. Мәхфүзәне кунарга улы качып киткән бер кулакка керттеләр. Егетнең кая качканын белергә кирәк, аннары икмәкне кайда яшергәннәр икән?..

Мәхфүзә байның кызы белән дуслашты. Кыз аңа абыйсының фоторәсемен күрсәтеп, аның чит илгә китүен сөйләде. Әтиләренең икмәкне, алтыннарын, хәтфә келәмнәрен яшергән урынны күрсәтеп бирде.

Коммунистик университетны тәмамлагач, Казакованы Чаллы кантон комитетының хатын-кызлар бүлегенә эшкә билгеләделәр.

Мәхфүзәнең абруе көннән-көн үсә барды. Һәрвакыт җыйнак, гадел бу хатын эштә иренмәде. Аңа нинди генә йомыш белән килмәсеннәр, ул һәрвакыт җаен таба: берсен больницага салырга булыша, икенчесенең баласын яслегә бирергә ярдәм итә, өченчесенә чәчүлек орлык булдырырга юл күрсәтә иде.

Авылларда крестьяннар колхозларга оеша башлаган вакыт. Кулаклар астыртын, аяусыз көрәш алып баралар. Партия кантон комитетының бюро членнары авылларга китәләр.

Мәхфүзә барган авылда кулаклар крестьяннарны колхоздан чыгарга котыртканнар икән.

Мәхфүзә гариза тотып килгән крестьяннарны бик тыныч каршы алды:

— Әнә, тартмага салыгыз, соңыннан үзегез үк килеп алырсыз,— диде ул.— Ә хәзер әйдәгез, эш турында сөйләшик, бала тәрбияләү турында киңәшик.

Шул сүздән соң кешеләр икеләнеп калдылар: колхоздан чыгу турында гариза китереп дөрес эшләделәр микән?.. Ә Мәхфүзә үзенең сүзен дәвам итте:

— Икмәкне кая озаталар, дип кичә җыелышта кайсыгыз сорады әле? Шәһәргә, эшчеләргә, аларның семьяларына бара ул икмәк. Без барыбыз да шәһәрдән тозын булсын, шырпысын булсын алып торабыз бит. Я, ничек уйлыйсыз, аларны кем җитештерә? Кем безне киендерә? Ә сез, Илгиз абый, читкә киткән туганыгызга хат яздырырга дип кичә кулакка кердегез. Язмады бит ул сезгә. Ә үзегезнең ике малаегыз үсә, ник шуларны укытмыйсыз?

— Эшкә кирәк?

— Кайсысы эшләсен, кайсы укысын. Ә Совет власте ныгыгач, барысын да укытырбыз. Ә хәзер кечкенә балаларны укытырга кирәк, бездән яхшырак яшәсеннәр. Менә сезнең күршедә торган байның ике хатыны бар. Яхшы кеше эшеме бу? Ә сез шуның сүзен тыңлап колхозга керми йөрисез.

— Минем үз башым юкмы әллә?

— Алайса нигә колхозга кермисез?

— Җитешермен әле.

— Сезнеңчә ничек: Абдулла абзый яхшы атын карт алашага алыштырган. Өстәвен кесәсенә салган да үләксәне колхозга алып килгән. Яхшымы инде менә шул эш?

— Кая инде... Ниткән яхшы булсын. Дөрес әйтәсең, Мәхфүзә апа. Төшендереп бирдең. Йөрәккә кererлек итеп әйттең. Шулай да колхозга кермим мин.

Шул вакыт авыл Советына бер төркем хатын-кызлар килеп керделәр. Алар да колхоздан чыгу турында гариза алып килгәннәр.

— Нигә йөзегезне каплыйсыз,— диде аларга Мәхфүзә,— гаризагыздан барыбер кем китергәнен таныйбыз бит. Әнә тартмага салыгыз да китегез. Соңыннан үзегез үк үкенерсез...

Кинәт авыл Советына кычкыра-кычкыра берәү килеп керде.

— Мәхфүзә апа, Мәхфүзә апа! Югары урам яна. Клубтагы әйберләрне чыгарып өлгердек. Ашлык амбарына, сыерлар абзарына да ут төрткәннәр.

— Чаң сугарга куш. Халык җыелсын. Сүндерергә кирәк...

Ишектән исерек Ильясны төртеп кертт...ләр. Кулында керосин чиләге.

— Менә кем төрткән. Каһәр төшкән к...лак калдыгы! Шунда бәреп үтермәкче иде... уйладык та, сиңа алып килергә булдык.

— Дөрес эшләгәнсез. Закон буенча х... кем итәрбез. Ник шулай эшләдең?— ди... Мәхфүзә, Ильяска борылып.

— Касыйм кушты.

— Касыйм ул кулак. Ә син, Ильяс, яр... кеше бит. Нигә дип кулак җырын җы...лыйсың?

Ул арада авыл Советы йортын төрле я...тан кулаклар һәм аларның иярченнәре чо...гап алды. Алар Ильясны коткарырга һә... бер очтан Мәхфүзәне дә үтерергә җые...ганнар. Ләкин алар теләкләренә ирешә... алмадылар, милиция килеп җитте.

Амбарларга ут төрткән кулакларны т...тып алып киткәч, халык колхозга күпләп язылa башлады. Беренче булып Илги... керде.

— Авылда кулаклар барында без авы... ачарга да курыктык,— дип аңлатты ул.

Халык язмышын кайгыртып, йокысыз төн...нәр үткәргән, арган-талган Мәхфүзә кант...комга бөтен уполномоченныйлардан д... соңрак кайтып керде.

1933 ел. Мәхфүзә Казакованы Кукмар... район башкарма комитеты председател... итеп сайладылар. Яңадан йокысыз төннәр, тынгысыз хезмәт башланды. Хатын-кызлар... бүлеген исәпкә алмаганда, барлык җитәкч... урыннарда ирләр эшли. Ә ул — беренч... хатын-кыз, татар хатыны — район Совет... башкарма комитеты председателе. Кайбе...рәүләргә бу хәл ошмады: ничек инде и... башың белән хатын-кыз янына киңәш... киләсең?

Итек фабрикасы директоры Төхфәтуллин... туп-туры ук әйтә:

— Ишеккә хәтле барам да кире китәм... Хатын-кыз утыра бит. Чалбар кисә ика... ичмасам! Ничек керәсең инде янына!

Тагын шундый хәл була. Барлык предсе...дательләргә дә чалбар белән гимнастерка...лар бирелә. Халык Комиссарлары Советы...ның эшләр башкаручысына шалтыраттылар... председательләрнең берсе хатын-кыз би... ни эшләргә?

— Ике чалбар бирегез, шулардан юбк... тегеп кисен.

Райбашкармага җиңел машина белә... шофер бирделәр. Казакова көннәрдән бе...

…нне, авыл хуҗалыгы налогы турында …ылату өчен, авылларга чыгып китте. Янил …ылы крестьяннары Казакованы яман сүз…ләр белән каршы алды.

— Әйдә, әйдә, әйдә,— дип кычкырдылар …хатыннар бер-берсенә.— Шайтан арбасы …килгән, шайтан арбасы.

Казакова заготзерно председателе Габи…тов белән килгән иде. Бер өйгә кереп, …бәрәнге пешереп бирүне үтенделәр. Ләкин …аларның сүзләренә колак салучы да бул…мады.

— Тыңлагыз әле,— диде Казакова, кө…леп,— миңа хәзер иманыгызны укыгыз.. Әгәр мин шайтан булсам, шунда ук юкка …чыгармын. Менә син кыю гына күренә…сең,— дип мөрәҗәгать итте ул хатыннар…ның әчерәк тавышлысына.— Әйдә, машина…га утырып авылны бер әйләнеп кил. Ә мин …синең бияләеңне бәйли торырмын.

Килен утырырга булды. Габитов аны машинага утыртты да авыл буенча алып китте. Ә Мәхфүзә бармакларын җитез-…җитез йөртеп бияләй бәйли башлады. Ха…тыннарның исләре китте:

— Кара әле, комиссар безнең төсле ук бәйли белә икән ләбаса.

— Мин бик күп еллар батрак булдым. Заманында сезнең кебек ук йөземне кап…лап йөри идем. Тукмактан башым чыкмады. Ә хәзер халык, партия, Совет власте миңа сезгә җибәрде.

Сүз уңаенда сүз чыгып, Мәхфүзә үзенең элек ничек яшәвен дә сөйләп бирде.

Икенче көнне авыл халкы җыелышка җыелды. Халык күп килгән иде. Алдагы рәтләргә хатыннар утырган. Кычкырып сөйләшәләр, шау киләләр. Ирләр арттагы рәтләрдә генә урын алганнар.

— Нигә сез, ирләр, алга узмыйсыз?

— Утырсыннар әле... ирек бит,— дип көл…деләр ирләр, хатыннар артына качып.

— Я, ярый, дуслар,— дип сөйләргә ке…решә Мәхфүзә,— безгә бер мәсьәләне хәл итәргә кирәк. Сезнең авылда укый-яза белмәүче бик күп кешеләр бар. Мәктәп юк. Ә мәчет буш тора. Шунда мәктәп ачсак, ничек булыр.

Арттагы рәтләрдән:

— Изге урынга тияргә ярамый. Аллаһе тәгалә каргар,— дигән тавышлар ишетелде.

Гаҗәп, хатын-кызларның тавышы чыкмый. Балаларының надан калуына алар үзләре дә кайгыралар иде бугай.

— Нигә каргасын?— дип дәвам итте Мәх…фүзә.— Без анда начарлык кылмыйбыз бит... Алла үзе балаларны яратырга кушкан. Без аларны укытабыз. Балаларны надан калдырырга ярамый.

Күп бәхәсләрдән соң, күпчелек халык мәчеттә мәктәп ачарга ризалашты.

— Егетләр! — дип кабат сүз башлады Мәхфүзә, мәктәп хакында сүз беткәч.— Трактор кайтарттык, ә ул тик тора. Бу ни эш?

— Эшләми ул.

— Әйдәгез, алайса, трактор янына кит…тек, күрербез,— диде Мәхфүзә.— Алтын куллы берәр егет табылыр әле. Булышыр.

Барысы да җыйнаулашып трактор янына киттеләр. Дөрес, юри гаугa чыгарырга дип килгән кешеләрнең җыелыштан алай гына таралысы килми иде. Ә Казакова мәсьәләне шундый итеп куйды, беркем дә каршы ки…лерлек түгел иде. Җанҗалчылар да сукра…на-сукрана халык артыннан иярде.

— Нәрсә күреп бара торганнардыр?

— Трактор күргәннәре юк...

— Чүплек башына гына атасы иде ул тракторны.

Тимерче алачыгы янында бер агай җит…мәгән детальне ломнан ясарга тәкъдим итте. Кара төнгә кадәр тимер кыздырды…лар, чүкеделәр, тагын кыздырдылар. Ни…һаять, трактор эшләп китте. Ышанычлы кешеләрне каравылга куеп, халык өйләренә таралды.

Икенче көнне өмә ясап, сыер, ат абзар…ларын төзәттеләр. Аннары Мәхфүзә кырда эшләүчеләр, чүп утаучылар янына китте. Утаучылар көлешә-көлешә юл читендә сөй…ләшеп утыралар иде.

— Исәнмесез, иптәшләр! Утырабызмы? Эшегезгә карап уңыш буләрләр бит. «Кем эшләми, шул ашамый», диләр. Берәүләр йөк белән икмәк алып кайтканда, үпкәләш…тән булмасын.

Тагын көлкегә алдылар.

— Безгә дә җәлегер әле, аз булса да эш…либез бит.

— Болай утырсагыз, бик әзәкмәс тә. Әйдәгез, кайсыгыз минем белән ярыша ала?

— Кара, кара, комиссар безнең белән эшләмәкче була.

— Әйдә, җир башында калдырыйк әле үзен.

— Кара әле, комиссар, нәрсә бу — ярышмы, бодаймы?

— Борчак диләр иде моңар. Аннан соң, комиссар да түгел әле мин, сезнең апагыз

булырлык кеше. Гомерем буе батрак булдым. Әйдәгез, утыйбыз.

Җирне бүлеп алдылар. Мәхфүзә җир башына беренче булып чыкты. Ялга туктадылар. Бер кыз аны үз янына ашарга чакырды. Мәхфүзә баш тартуны яхшысынмады. Бер кечкенә кисәк икмәк сындырып алды да яңадан эшкә тотынды.

— Мәхфүзә апа, өйгә кайтыгыз!

— Үзебез утап бетерербез...

— Иртәгә тикшерергә килсәгез, үзегез дә күрерсез.

— Сезнең аннан башка да эшегез күп, барыгыз,— диештеләр яшьләр.

Шулай итеп, Янилдә артта калган бар эшләр дә җайга салынды. Бергәләп эшләүнең файдасын, җиңеллеген, күңеллелеген крестьяннарга үзе эштә күрсәтте ул.

Яхшы эшләгәне өчен Мәхфүзәне Кисловодскидагы «10 лет Октября» санаториясенә ялга җибәрделәр. Анда Коминтерн члены Вильгельм Пик ял итә иде. Вильгельм Пикка 50 яшь тулган көнне Татарстан һәм Казагыстаннан килгән кешеләр җыелып, аны тәбрик иттеләр. Ул аларны бик җылы каршылады, бик озак сөйләшеп утырды. Мәхфүзәгә ул болай диде:

— Сезнең белән танышуыма бик шатмын, иптәш Казакова. РСФСРның 16 нчы Советлар съезды делегаты буларак радиодан сөйләвегезне ишеткән идем. Шундый зур һәм катлаулы эштә хатын-кызлар гына түгел, ирләрнең дә теләсә кайсы булдыра алмый бит...

...Бу көннәрдән соң инде күп еллар үтте. Мәхфүзә Гайнетдиновага хәзер җитмеш яшь. Ул — персональ пенсионер, шулай да барлык вакытын җәмәгать эше белән үткәрә. Менә ун еллап инде ул иптәшләр судында эшли. Нинди генә хәлләрне тикшерергә туры килми анда.

Коммунистның үткән юлы, тәҗрибәсе ярдәм итә аңа. Кешенең күңеленә ничек якын килергә, ничек дөреслекне табарга, гадел хөкем чыгарырга, ялгышкан кешеләргә яңадан намуслы хезмәт юлына басуда ничек ярдәм итәргә икәнен Мәхфүзә Казакова бик яхшы белә.

Һәм кешеләр дә аңа ышаналар: эшең Мәхфүзә кулына эләксә, гадел хөкем буласын көт тә тор!

# БЕР ГЕНӘ КИЛСӘ ДӘ...



Байлар, алпавытлар тарафыннан кимсетелгән һәм талаиган гади халыкны яклап җырлаган атаклы рус шагыйре Николай Алексеевич Некрасовның 1846 елда безнең якларга килеп җитүен белүчеләр булса да, аның шул килүендә ниләр эшләвен, нинди тәэсирләр алып китүен, мөгаен, күп укучылар белми торганнардыр әле. Алдан ук әйтеп куйыйк: 1846 елда — май һәм июнь айларында — Казан губернасының Ново-Спасское авылына[1] килүе Николай Алексеевичның иҗатына да, рухына да зур тәэсир ясый. Алай гына да түгел, хәтта «Современник» журналының Некрасов тарафыннан чыгарыла башлавы да шагыйрьнең өлеге шул безнең якка килүенә турыдан-туры бәйләнгән.


Бу эш менә болай була.

Чит илләрдә байтак йөргәннән соң, 1845 елның көзендә, Казан губернасының Ново-Спасское авылындагы биләмәсенә кайтып килешли, алпавыт Григорий Михайлович Толстой юл уңаенда берничә көнгә Петербургка туктала. Григорий Михайлович үзе язу-сызу белән шөгыльләнмәсә дә, язучылар даирәсендә һәм югары катлау кешеләре арасында шактый еш ышкыланып йөрергә ярата торган үзенчәлекле бер кеше була. Иван Иванович Панаев аркылы ул Некрасов белән дә таныша. Танышып кына да калмый, хәтта аны киләсе язда үз биләмәсенә — Ново-Спасское авылына кунакка кайтырга да чакыра. Некрасовның ауга йөрергә яратуын белгәч, тагын да дәртләнеп китеп, үз биләмәсенә кергән урман-суларда кош-кортның бик күп булуын әйтә, теләгәнчә рәхәтләнеп ауга йөрергә мөмкинлек бирәчәген вәгъдә итә.

Некрасов моңа бик шатланып ризалаша һәм менә ни өчен: 1845 елны «Петербургский сборник» исемле китабы өстендә эшләгән чагында шагыйрьнең күңеленә революцион-демократик юнәлештәге үз журналын чыгара башлау уе килә. Моның өчен аның шактый зур мөмкинлекләре дә була. Журналның идея җитәкчесе итеп Белинскийны куярга мөмкин; шагыйрь фикерен якларлык һәм журналда яхшылап эшләрлек байтак кына талантлы сотрудниклар да күренеп тора; кәгазь фабрикантлары һәм тәҗрибәле нәширләр белән дә танышлыгы бар; крепостнойлык строена каршы сугышчан көрәш программасы да эшләнгән була. Максатны тормышка тизрәк ашырыр өчен тик бер генә нәрсә — акча гына җитми. Ә акчасыз — журнал чыгару турында уйларга да ярамый. Григорий Толстой исә, бердән, бөтен Европаны аркылыга-буйга йөреп чыккан, революция алды елларында Парижда яшәгән, рус декабристларын, күренекле көнбатыш демократларын һәм социалистларын шәхсән белә торган кеше һәм, икенчедән, күп акчалы бай алпавыт була. Шуның өстенә Толстой үзе дә Некрасовка Белинский фикерләрен яклаучы икәнлеген сиздереп куя.

Менә шуннан чыгып, оештыру мәсьәләсендә Григорий Михайловичка таянырга булыр, дип уйлый Некрасов һәм Толстойның тәкъдимен бик теләп кабул итә. Һәр-

[1] Хәзер республикабызның Алексеевский районына керә.



хәлдә, Николай Алексеевичның Ново-Спасскоега кайтуы ауга йөрер өчен түгел, бәлки үзенең әлеге планын тормышка тизрәк ашырырга тырышуда килеп чыккан хәл була. Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк, Толстой үзе дә әле 1845 елның көзендә беренче очрашулары вакытында ук, журнал мәсьәләсендә сүз кузгалгач, Некрасовка турыдан туры: «Бу эштә, ихтимал, мин артык булмам. Һәр алдынгы яңа башлангычка ярдәм итәргә мин һәрвакыт әзер. Бүген генә без бу эшне хәл итә алмабыз. Шушы көннәрдә мин үземнең биләмәмә кайтып китәм. Ләкин яз көне, рәхим итеп, минем янга авылга килегез һәм без шунда барысын да ахырынача хәл итәрбез», дип әйтеп куя. 1846 ел башында Григорий Толстой тагын бер мәртәбә шагыйрьне кунакка җәй буена үзләрендә торып китәргә чакыра.

Менә шуннан соң, тизрәк журнал чыгара башларга хыялланып йөргән Некрасов, җырләр кипкәнне дә көтеп тормастан, ирле-хатынлы Панаевлар белән бергәләп Петербургтан Григорий Толстой биләмәсенә — Ново-Спасское авылына килә. Аның Ново-Спасскоеда булуы турында «Волжский вестник» газетасының 330 санында (1887 ел) П. Юшков менә болай дип язган: «Н. А. Некрасов Григорий Михайловичка кунакка кайткан Ново-Спасское авылы Курлянка елгачыгы ярына утырган бай, зур авыл, куе агачлы зур бакчалы авыл. Кунаклар барында Григорий Михайлович ишеге бакчага чыга торган террасалы агач флигельдә яшәде. Җылы һәм матур көннәрдә, бигрәк тә кичләрен, Некрасов, Панаев һәм Толстой менә шул террасага чыгып, сөйләшеп утыралар иде һәм «Современник»ны Плетневтан арендага алу мәсьәләсе нәкъ менә шушында хәл ителде.

Шушы балконда алар ярты төнгә кадәр журнал турында, аның яңа программасы турында бик кызыклы әңгәмәләр алып баралар иде... Шунда өчесе дә бер-berенә журнал өчен тырышып эшләргә һәм һәркайсы хәленнән килгәнчә аңа ярдәм итеп торырга сүз бирештеләр».

Бу мәгълүмат дөрес булырга тиеш, чөнки Некрасов истәлекләрендә үзе дә шулайрак итеп яза: «1846 елның җәендә мин Казан губернасында, үземнең таныш алпавыт Г. М. Толстойда кунакта булдым. Ул чит илләрдә йөреп кайткан һәм беркадәр либеральрәк фикердәге кеше иде. Без аның белән, балконда утырып, еш кына әдәбият турында гәпләшә торган идек. Безгә күршедә генә семьясы белән Панаев тора, аның анда үз биләмәсе бар иде. Мин журнал чыгара башлау мәсьәләсен кузгаттым. Эш акчага барып төртелде. Панаев 25000 сум иркекле капиталы булуын әйтте, Толстой шулай ук 25000 сум биреп торырга вәгъдә итте. Шуннан соң мин Петербургка ашыктым»...

Ново-Спасскоега килгәндә Николай Алексеевич журнал чыгара башлау мәсьәләсен хәл итү белән генә чикләнми. Бу якның табигатен дә бик ошата ул. Иртүк тора да тирә-якка хуш ис аңкытып торган чәчәкле болыннар һәм кырлар буйлап хозурланып; уйланып йөреп кайтырга гадәтләнеп китә. Шулай йөргән чагында безнең якның кешеләре белән дә очраша һәм сөйләшә. Ул очрашулар шагыйрь күңелендә эзсез генә калмый, әлбәттә. Соңыннан алар шигырь булып шытып чыгалар. Ә шагыйрьнең әлеге Ново-Спасское тирәсендәге урманда йөргәндә бер авыл агае белән очрашып сөйләшүе исә аңа «Кому на Руси жить хорошо!» дигән атаклы поэмасын язу өчен сюжет бирә. А. Ложечко үзенең «Октябрь» журналында басылган (1958 ел, беренче сан) «Рассказы о Некрасове» исемле очеркында бу хакта менә болайрак итеп сөйли.

Гадәтенчә, иртүк торып, Панаева белән йөреп кайтырга чыккач, Толстой биләмәсеннән шактый ерактагы урманда алар аркасына биштәр, биленә кружка аскан, кулына кәкре таяк тоткан бер авыл мужигына юлыгалар. Шунда шагыйрь теге агайдан Толстой утарына ничек итеп тизрәк кайтып җитәргә мөмкин булуын сорый, чөнки ул инде шактый ерак киткән һәм бик озак йөргән була. Агай аңа бик яхшылап кыска юлны аңлата да, син соң безнең алпавытның туганы түгелме, дип сорый. Туганы түгеллеген әйткәч, Некрасов агайның ни эшләп йөрүе, кая юл тотуы турында сораша башлый. Агай, чал керә башлаган сакалын сыпыргалап бераз уйланып тора да, болай дип сүз башлый: «Мин сиңа, барин, тиз генә җавап бирә алмыйм, башта бер хикәят сөйләмәкче булам. Курыкма, озын булмас ул. Шулай ике мужик яшәгән. Берсе гел алдашып, гаделсезлек белән көн күргән. Ә икенчесе дөреслекне яклап, үз кул көче белән эшләп тереклек иткән. Бервакыт үз араларында сүз чыгып: «Ничек яшәү яхшырак: алдап-сулдап кеше өстендә көн күрепме, әллә гаделлек белән яшәүме!» — дип, үзара бәхәсләшеп киткән болар. Бәхәсләшкәннәр-бәхәсләшкәннәр дә, мәсьәләне үзара гына хәл итә алмыйча, юлга чыкканнар. Болай килешкәннәр: юлларында беренче булып очраган өч кешедән теге бәхәс чыгарган мәсьәләгә җавап сорарга. Иң элек байга эшләп көн күрүче бер мужик туры килгән боларга. Сораганнар: «Гаделлек белән яшәү яхшымы, әллә ялган һәм хәйлә белән яшәү әйбәтрәкме!» — дигәннәр. Аннары сәүдәгәрдән һәм поптан да шулай дип сораганнар. Кемнән генә сорасалар да, мужиклар гел бертөрле җавап ишеткәннәр: «Дөреслек хәзер чабатадан йөри, ә ялган күн итек киеп элдертә».

Менә шуларны сөйләп биргәч, теге агай тәмәке төрергә керешә, ә шагыйрь:

— Сөйләп бетердеңме хикәятеңне! — дип сорый.

Агай мәгънәле генә итеп елмаеп куя да:

— Юк, барин, шактый озын әле ул, мин сиңа барысын да сөйләп тормыйм. Тик шуны гына әйтәм, ахырдан ялганны дөмбәсләп ташлаганнар, ә дөреслек аннан өстенрәк булып чыккан,— дип җавап бирә һәм саубуллашып үз юлы белән китеп бара башлый.

Шунда Некрасов аннан:

— Ә син, атакай, үзең кая юл тотасың соң! — дип сорагач, агай аңа:

— Теге мужикләр шикелле, мин дә дөреслек белән ялган мәсьәләсен хәл итү өчен Казанның үзенә барырга булдым, югыйсә безнең яктагы ялган хәзер күн итек кенә дә түгел, бәлки чит илдән алып кайтылган штиблетлар киеп йөри башлады,— дип, алпавыт Григорий Толстойга төрттереп җавап бирә.

Ләкин Некрасов аның бу сүзләренең мәгънәсенә бик үк төшенеп җитми һәм:

— Аңлатыбрак сөйләсәң икән, атакай,— дип үтенә.

Шуннан соң агай туп-туры итеп:

— Син аны алпавыттан сора, бәлки, ул аңлатып бирер,— ди.— Нигә ул мужикларны бер яктан үзе үз кулы белән дәвалый икән дә, икенче яктан, алдау һәм ялган белән, шул ук мужикларның соңгы күлмәкләрен салдырып ала икән! Шундый хәлгә китереп җиткерде — юкә урынына тиреләрен генә сыерып аласы калды инде. Ярый, хәзергә хушыгыз. Югыйсә бездә: «Дөресен сөйләсәң, Себер китәсең»,— диләр.

Шулай ди дә агай урман эченә кереп китә, ә аның сүзләре Некрасовның күңелендә мәңгегә уелып кала. Барыннан да бигрәк агайның Григорий Толстойга карата әйткән каты сүзләре гаҗәпләндерә аны. Гаҗәпләнмәслек тә түгел ләбаса: кеше, ягъни алпавыт Толстой, үзе крестьяннарны авырудан дәвалаган була, үзе шул ук вакытта аларны шундый каты эшләтә, шундый каты кыса — әгәр түзә торган булсалар, хәтта тиреләрен дә тунап алыр иде!..

Агай киткәннән соң да шагыйрь менә шул хакта байтак вакыт уйланып тора. Аннары үзе белән бергә йөрергә чыккан Авдотья Яковлевна Панаевага күтәрелеп карый да, карт сөйләп киткән әлеге хикәятне тыңлагач, язачак зур әсәре өчен күңелендә сюжет тууын әйтә. һәм ул шул сюжетын тормышка ашырган да, дип уйларга нигез бар. Некрасовның «Кому на Руси жить хорошо!» исемле поэмасының сюжетын хәтергә төшерик. Анда олы юл чатында җиде мужик, Россиядә кемнең тормышы җиңелрәк, дигән сорауга җавап эзләп, хикәяттәге мужиклар кебек, үзара бәхәсләшә башлыйлар. Сорауларына анык кына җавап таба алмагач, ахырдан төрлесе төрле юлдан җавап эзләргә китәләр.

Күренә ки, поэманың сюжеты агай хикәятенә бик якын тора. Димәк, Некрасовның «Кому на Руси жить хорошо!» исемле иң яхшы поэмасының сюжеты безнең як җирендә туган булуына бернинди шик тә юк.

Биштәр аскан агайның хикәяте Некрасов күңелендә поэма сюжеты тудырып кына калмый, бәлки аны алпавыт Толстой турында да ныклабрак уйланырга мәҗбүр итә. Башта аңа агайның алпавытка карата әйткән сүзләре сәеррәк тоела һәм ул шул фикерен үзе белән йөрергә чыккан Панаевага да әйтә:

— Ә мәнә теге картның Григорий Михайлович турындагы сүзләре мине гаҗәпләндерде. Миңа калса, Толстой бөтен яхшылыкларны үзендә туплаган кеше шикелле тоела иде. Аннары ул алдынгы карашлы кеше дә бит әле, крепостнойларын иреккә чыгарырга тели,— ди ул.

Панаева аның белән сүз көрәштереп тормый.

— Ләкин ул бит әле бары тик тели генә,— дип җавап бирә дә бу хакта сүз шуның белән тәмамлана.

Ә шул көнне кич Григорий Михайлович, бик кәефләнеп, кунакларына чит илдә күргән хәлләр һәм ишеткән нәрсәләре турында сөйли. Кунаклары белән тәмам якты рыла башлаганчы утыра һәм шунда кемнән берәр яхшырак журнал сатып алырга мөмкин икәнлеге хакында сүз алып бара. (Яңа журнал ачарга мөмкин түгел, андый эш ул чакта хөкүмәт тарафыннан тыелган була.) Утырдашлар «Сын отечества» һәм «Финский вестник» журналларын телгә алалар, ахырдан Панаев заманында Пушкин тарафыннан чыгарыла башлаган «Современник» журналын хәзерге хуҗасы Плетневтан сатып алырга кирәк дигән тәкъдимне кертә.

Некрасов аның бу фикерен бик хуплап кабул итә. Ул төнне өчесе дә йокысыз уткәрәләр. Ә иртән, кояш чыккач, Некрасов куанып: «Карагыз әле, әфәнделәр, кояш дөньяны ничек матур яктырта! Өч көн болытлап торганнан соң аның кинәт шушылай балкып чыгуы безнең журналга уңыш вәгъдә итүедер инде ул! — дип кычкырып әйтеп куя. Аннары уйчанланып, балкон идәне такталары арасыннан үсеп чыгып килә торган юкә агачы үсентесенә карап тора да, Григорий Михайловичка мөрәҗәгать итеп:

— Бу юкәгә тия күрмәгез, үссен... Безнең журнал да бүген менә шулай яралды. Бәлки без дә аны зур һәм матур агач сыман итеп үстерербез,— дип өсти.

Йорт хуҗасы шагыйрьнең бу үтенечен чыннан да үти: алда телгә алынып киткән П. Юшковның 1897 елда газетада басылган бер мәкаләсендә теге юкәнең алпавыт флигелендә инде зур, юан һәм бик матур агач булып үсеп җиткәнлеге һәм «Некрасов агачы» дип аталып йөртелүе турында әйтелгән.

Әйе, агачны үстерә алпавыт Толстой, әмма сүзендә тормый: вәгъдә иткән 25000 сум акчасыннан Некрасов журналына 25 тиенен дә бирми. Акча урынына бер тиенгә дә тормаган вексель җибәрә дә шуның белән — аллаһы әкбәр!

Бу вәгъдәсезлегенә бик нык ачуланып, Некрасов Толстойга хат яза һәм шуннан соң аның белән мөнәсәбәтен бөтенләйгә өзә. Шагыйрь теге агайның алпавытны ни өчен ялганчы дип атаганлыгын әнә шуннан соң гына яхшылап аңлый.

Ләкин бу күңелсез вакыйга да шагыйрь күңелендә күмелеп калмый, бәлки соңыннан язган әсәрләренә төзү материалы буларак кереп китә. Хәтерегездә микән, Некрасовның «Три страны света» исемле романында Григорий Данков дигән бер тискәре тип-персонаж бар. Ихтимал, ул әлеге шул алпавыт Григорий Михайлович Толстойның прототибыдыр дип уйларга бик мөмкин. Ни өчен дигәндә, Григорий Данков та, Григорий Михайлович шикелле үк, тыштан караганда укымышлы һәм либераль булып күренә, ә асылда исә алдакчы һәм канэчкеч крепостник-алпавыт була.

Казан губернасының Ново-Спасское авылына килгән чагында Николай Алексеевич Спасс шәһәренә дә (Куйбышев районындагы иске Куйбышев шәһәре) кагылып, берничә көн торып китә. Шәһәр уртасындагы сазлыклы күлдән бер кыр үрдәге дә атып ала һәм соңыннан бу вакыйганы «Несчастные» исемле поэмасында сурәтләп тә бирә.

Кыскасы, безнең якларга нибары бер генә мәртәбә килсә дә, Некрасов аннан үз иҗаты өчен шактый бай материал туплап китә һәм, шул материаллардан файдаланып, соңыннан әйбәт-әйбәт әсәрләрен иҗат итә.

В. КЛИМЕНТОВСКИЙ

Фәрит Хатипов

# ЭПИК ЖАНРЛАРДАН ПОВЕСТЬ

Повестьны икенче төрле озын хикәя дип тә йөртәләр. Галимҗан Ибраһимов хикәягә билгеләмә биргәндә повесть сыйфатларын да күздә тота һәм мисалга Ш. Камалның «Акчарлаклар»ы кебек повестьларны китерә. «Мөндәриҗәсе бер яисә берничә аерым вакыйганы бәяндан гыйбарәт булган риваялар хикәя дип атала[1]», ди ул. Күрәсез, бу билгеләмә хикәягә хас сыйфатны да һәм повестька хас сыйфатны да үз эченә ала. «Озын хикәя» дип атау хикәя белән повесть арасындагы бәйләнешкә, кардәшлеккә ишарә ясый. Шундыйрак хәл рус әдәбиятында да күренә. Борын заманда руслар хикәяләүгә, повествовать итүгә корылган теләсә нинди әсәрне повесть дип атап йөрткәннәр. Чыннан да, повесть хикәянең кайбер хасиятләрен үстереп җибәрә, һәм нәтиҗәдә күләм яңа сыйфатка күчә. Повесть монда барыннан да бигрәк буйга үсә, ягъни бер генә вакыйгадан тормый, бәлки вакыйгаларның зур тезмәсен бирә, үзендә эретә, беркетә. Повестьта чынбарлык, хикәядәге кебек, бер генә мизгелдә түгел, бәлки дәвамлы, озын хәрәкәттә чагыла. Ул чынбарлык өлкәсенең озак вакыт эчендәге процессын күрсәтә. Шуңа күрә монда вакыт факторы, күренешнең вакыт эчендә барышы бик мөһим роль уйный. Бу мәгънәдә аңлаганда, бер повестька берничә хикәя материалы сыяр иде һәм безнең күз алдына чынбарлыкның вакыт эчендә шактый дәвамлы агышы килеп басар иде. Әмма повесть — ул үзара бәйләнешсез эпизодлар буыны түгел, бәлки бердәм оешкан, ситуация, тема рамкасында тәгәлләнгән, һәр компоненты үз урынына урнашкан бөтен организм. Ул чынбарлыкның теге яки бу тармагын дәвамлырак хәрәкәтендә күрсәтә, повесть өчен ситуацияне язучы тормышның озынрак агымыннан ала. Димәк, монда, хикәя предметы белән чагыштырганда, динамика, үсеш шактый көчле дигән сүз. Шуңа да бит повестьта сюжет элементлары, аеруча хәрәкәт үстерелеше һәм шулай ук образны сурәтләүдә кулланыла торган компонентлар (характер сыйфатлары, портрет, кичереш, диалог, автор хикәяләве, пейзаж) үзләрен иркенрәк сизәләр, иркенләбрәк урнашалар. Сәнгатьчә фикерләүнең бүгенге югарылыгында образны гәүдәләндерү өчен файдаланыла торган барлык әдәби чараларны, алымнарны, элементларны повесть үзенә сыйдыра ала. Бу хәл бер генә нәтиҗә бирә — повестьта образ кирәк кадәр җентекле тасвирлана, төрле яктан ачыла. Бу җәһәттән ике мәсьәләгә игътибар юнәлдерик: сюжет корылышы; характерны сурәтләү үзенчәлеге.

М. Гафуриның «Кара йөзләр» повестенда төенләнеш кинәт башланып китә, һәм каршылыклар бик тиз кискенләшеп, иң киеренке ноктасына җитә. Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ында конфликт акрын башлана һәм тора-бара Галиянең ул каршылыкны җиңеп, яңа югарылыкларга күтәрелүе тасвирлана. Ф. Хөснинең «Йөзек кашы», С. Батталның «Сигезенчесе кем?» повестьлары үтә каршылыклы, борылмалы, киеренке вакыйгалар хәрәкәтеннән тора.

Менә шушы хәл, ягъни сюжетның дәвамлы булуы, геройның күп кенә эпизодларда, күп вакыт эчендә күренүе характерны сурәтләүгә дә үзенчәлекле йогынты ясый. Хикәягә герой әзер характеры белән килеп керә һәм бу характерны артык үстерми иде. Анда тик шушы характерның билгеле бер вакыттагы аерым сыйфатлары гына

[1] Галимҗан Ибраһимов. Әдәбият кануннары. Казан. 1919 ел. 82 бит.

чагылып кала иде. Повесть сюжеты исә характерны динамикада күрсәтергә, аның яңа сыйфатлар хисабына баюын тасвирларга мөмкинлек бирә. Алып карагыз Галияне. Әсәр башында үтә оялчан, юаш-басынкы күренгән кыз повесть барышында мөһим каршылыкларны җиңеп үсүче, ил, җәмгыять турында тирән уйланучы белгечкә, көчле шәхескә әйләнә.

Шулай итеп, повесть геройлары дәвамлы хәрәкәттә күренәләр һәм шушы процесста үзләренең характер үсешен чагылдыралар икән. Ләкин бер шарт белән. Повестьта вакыйгалар нигездә бер сызык буенча үстереләләр. Менә шушы ягы белән ул хикәягә тартым. Ягъни, хикәя кебек үк, тармакланып үсми, бәлки, төз нарат сыман, буйга хәрәкәт итә. Димәк, повесть чынбарлык вакыйгаларын динамикада, хәрәкәттә күрсәтсә дә, ул аларның күбрәк аерым тармагын сайлый, чынбарлыкның тар бер өлкәсен хәрәкәттә күрсәтә. Шулай итеп, повесть буйга үсештә чикләнмәсә дә, иңгә җәелүдә үзен бер сюжет сызыгы белән чикли икән.

Жанрның йөзен формалаштыруда моның әһәмияте зур булганлыктан, әлеге кагыйдәне мисаллар белән ныгыту кирәклеге сизелә. Менә татар әдәбиятындагы тәүге повестьларның берсе — К. Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре. Биредә вакыйга үзәгендә бер язмыш — Әбүгалисина язмышы тора. Икенчерәк планда, анда да әле Әбүгалисинага бәйләнешле рәвештә, Әбелхарис һәм Хәлвәфрүш тасвирлана. З. Һадиның «Җиһанша хәзрәт»е, Ф. Әмирханның «Фатхулла хәзрәт»е, Ш. Камалның «Акчарлаклар»ы, М. Гафуриның «Кара йөзләр»е, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы, Ф. Хөсни, А. Гыйләҗев, Э. Касыймов, Н. Фәттах һәм Р. Төхфәтуллин повестьлары шулай ук сюжет сызыгын баш герой язмышына бәйләп, бер юнәлештә генә үстерәләр. Алар нигездә бер сюжет сызыгыннан торган тормыш материалын чагылдыралар. Моның мисалларын тагын Ш. Мөхәммәдовның «Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай», А. Шамовның «Рәүфә», И. Газиның «Катя Сорокина», Ә. Еникинең «Вөҗдан» һәм башка повестьларда күрергә була.

Сюжет характеры, киң планлылыкны, тармаклануны читсенеп, вакыйгаларны нигездә бер сызык буенча күрсәтергә омтылу — повесть жанрының әһәмиятле бер билгесе. Моннан бер нәтиҗә. Әдәби төрләрне барлыкка китерүдә сурәтләү материалының үзенчәлеге мөһим роль уйнаганлыгын күргән идек. Сурәтләү предметының характеры жанр чикләрен формалаштыруга да йогынты ясый. Ләкин монда турыдан-туры һәм мостакыйль рәвештә түгел, бәлки башка чаралар ярдәмендә тәэсир итә. Беренче чиратта сюжет ярдәмгә килә. Чынбарлык күренешенең характеры сюжетны башкача, бер генә сызык буенча үстерүне талап итә. Димәк, сурәтләү предметының үзенчәлеге барыннан да бигрәк сюжетта күренә, сюжетта чагыла һәм шулай итеп сюжет жанр чикләрен билгеләүгә катнашучы тигез хокуклы компонентка әйләнеп китә. Повесть жанрын күздә тотып, заманында Галимҗан Ибраһимов болай дип язган иде: «Романдагы шарт вә хосусиятләр монда да табыла. Аерма фәкать күләменең кечерәк булуында, вакыйганың романдагы кадәрле үк бөтен, киң вә тулы бирелеп җитә алмавындадыр» [1]. Гәрчә бу җөмләдә ачыклыйсы, конкретлаштырасы кайбер мәсьәләләр булса да, бәхәссез дөрес фикер бар: вакыйганы киң итеп алмауны Г. Ибраһимов повестьның мөһим сыйфатларыннан дип карый.

Повестьның шушындый табигатен ачыграк күз алдына китерү өчен, ике әсәрне чагыштырып карарга мөмкин. Аларның берсе Б. Полевойның «Кыргый яр буенда» романы, икенчесе А. Гыйләҗевның «Зәй энҗеләре» повесте. Беренчесендә Себердә гигант электростанция төзү турында, икенчесендә Зәй ГРЭСын кору хакында сүз бара. Икесе дә гаять зур төзелеш. Б. Полевой шуны бөтен киңлеге, катлаулылыгы, зур масштабы белән яктырта, ә Гыйләҗев тик бетончыларга, инженер Шамгин язмышына бәйле өлкәсен генә алып сурәтли.

Повесть сюжеты мәгълүм дәрәҗәдә драма сюжетына охшаган. Тегесендә дә, моннысында да хәрәкәт берлеге күзгә ташлана. Хәтта ул сыйфат, ягъни хәрәкәт берлеге, әсәрнең композицион төзеклеген күрсәтә торган мөһим билге итеп карала. Әмма бүтән яклары белән бу ике төр жанр берберсеннән нык кына аерылалар.

Сюжетның бер сызык буенча үсүе персонажлар санын чикләүне кирәк таба. Бу бик табигый. Чөнки сюжетның һәр тармагы, һәр сызыгы герой язмышына бәйләнеп туа. Бер язмыш сурәтләнсә, сюжет та бер генә сызыклы була, әгәр күп язмышлар бәйләнешкә кереп үрелешсәләр, сюжет сызыклары да тармаклана. Моның мисалын теләсә нинди киң планлы романнарда күрергә мөмкин. Повестьта исә бер, һәрхәл-

[1] Галимҗан Ибраһимов. Әдәбият кануннары. Казан. 1919 ел. 82 бит.

дә, аз санлы геройлар гына бөтен нечкәлекләре белән яктыртылалар һәм җанлы образ дәрәҗәсенә ирешәләр. Бу яктан хикәя белән повесть арасында шулай ук кан кардәшлеге бар. Ләкин хикәядә алар бер балку дәвамында гына күренәләр, повестьта вакыйгалар барышында, дәвамлырак, озынрак сюжет эчендә чагылалар.

Бу мәсьәләдә миңа каршы төшүләре ихтимал: әгәр повесть романга караганда таррак өлкәне чагылдыра торган булса, бу хәл жанрның чикләнгәнлеге, тагын да турырак әйткәндә, кимчелеге турында сөйләмиме соң? Сорауны турыдан-туры маңгайга терәп куймаган хәлдә дә, повесть авторын эпизодик геройларны да баш герой дәрәҗәсенә җиткереп сурәтләмәгән өчен тәнкыйтьләгән мәкаләләр күренгәләп тора. Моңа ничек дип җавап бирергә? Беренчедән, һәр жанрның үзенең специфик мөмкинлекләре бар. Икенчедән, чикләү гомумән сәнгатьнең әһәмиятле бер таләбе бит ул. Язучы тормышның теге яки бу күренешен, чынбарлыкның билгеле бер өлкәсен, сыйфатын сайларга ихтыярлы, ирекле. Ләкин инде бер сайлагач, ул үзен, иҗатчы буларак, тема белән, сюжет, композиция, жанр белән чикли. Һәм шушы чикләү әдипкә реальлеккә, тормыш картинасының бөтенлегенә ирешергә ярдәм итә.

Дөрес, әдәбият тарихында киңлеккә таба омтылган повестьлар да юк түгел. Мәсәлән, М. Әмирнең «Агыйдел», Г. Гобәйнең «Маякчы кызы», Г. Бәшировның «Сиваш» повестьлары вакыйгаларны киң генә планда яктырталар. Боларда, баш герой сызыгыннан тыш, тагын бүтән ярдәмче сюжет тармакларын күрергә була. Әйтик, «Агыйдел»дә Гаяз һәм Ильяс сызыгына тагын Артыкбикә, Күчәрбай, Имәли сукмаклары килеп тоташа. Ләкин шуның белән бергә боларда да повестьны оештыручы үзәкне күрүе читен түгел. «Агыйдел»дә шундый үзәк итеп Ильяс, «Маякчы кызы»нда Илсөяр, «Сиваш»та Әхмәди алынган. Повесть вакыйгалары әнә шул үзәк тирәсенә җыеп бирелгән. Тагын шунысы да бар. Бер сызыклы сюжет ягыннан повесть хикәягә якын торса, сюжетның озынлыгы җәһәтеннән ул роман белән янәшә тора. Шуңа күрә кайбер хикәяләрдә повесть билгеләре булган кебек, кайбер повестьларда роман билгеләре күренә. Киң планлылык — шуның чагылышы.

Әмма геройның дәвамлы вакыйгалар эчендә яктыртылуы хакындагы кагыйдә повесть жанрына багышланган кайбер традицион теоретик карашлар белән ярашып бетми. Байтак галимнәр геройның бөтен тормыш юлын сурәтләү мөмкинлеген романга гына биреп, повестьны бу мөмкинлектән мәхрүм итәләр һәм аның өлешенә герой тормышындагы берничә эпизодны тасвирлауны гына калдыралар.

Хикәя, повесть, роман жанрларын күздә тотып, Л. И. Тимофеев болай дип яза: «Кече форма кешене мәгълүм бер эпизодта гына күрсәтә, урта форма — аның тормышының билгеле бер **чорын**, этабын, шундый берничә эпизодны, олы форма кешенең **тормыш юлын** иңләп ала».[1] Шуңа охшаш фикер заманында Г. Сәгъди тарафыннан да үткәрелгән иде.[2] Билгеле, роман, повестьлар арасында шушы рәвешле төзелгәннәрен байтак очратырга була. Мәсәлән, А. Гыйләҗевның «Зәй энҗеләре», Н. Фәттахның «Мөдир Саҗидә», М. Әмирнең «Агыйдел», А. Шамовның «Рәүфә», Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестьлары чыннан да геройның бөтен тормыш юлын түгел, бәлки бер чорын, этабын, берничә эпизодны чагылдыра. Әмма бу фикердә, беренчедән, галимнәр арасында эзлеклелек, бердәмлек юк, хәтта кайбер иптәшләр үзләренә үзләре үк каршы төшәләр. Икенчедән, ул әдәбият практикасы белән ярашмый, ягъни аның бөтен байлыгына нигезләнмәгән, тик мәгълүм төр повесть, романнарга карата гына дөрес. Мәсәлән, икенче бер әдәбият белеме дәреслеге авторы Ф. М. Головенченко повестьта романга караганда азрак сандагы геройлар сурәтләнә, дип әйтеп китә дә, икенче бер җирдә М. Горькийның «Клим Самгин тормышы»н бер дә роман дими, повесть дип атый[3]. Г. Л. Абрамович та әсәрне шул ук термин белән билгели[4]. Әмма берничә китаптан торган бу әсәрне аз вакыйгалы дип әйтергә безнең бер төрле дә нигезебез юк. Монда геройның бөтен тормыш юлы яктыртыла. Ч. Айтматовның «Хуш, Сарыгөл», Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр», Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Ф. Хөснинең «Йөзек кашы», С. Батталның «Сигезенче:е

---

[1] Л. И. Тимофеев. Основы теории литературы. Рус телендә. Мәскәү. 1959 ел. 325 бит.

[2] Г-җан Сәгъди. Әдәбият теориясе. Казан. 1941 ел. 72 һәм 77 битләр.

[3] Ф. М. Головенченко. Введение в литературоведение. Рус телендә. «Высшая школа» нәшрияты. 1964 ел. 258 бит.

[4] Г. Л. Абрамович. Введение в литературоведение. 1956 ел. 244 бит .

кемі», А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повестьларына карата да шуны ук әйтергә мөмкин. Боларда да герой бик озак вакыт дәвамында хәрәкәт итә. Чөнки повестьтагы вакыйгалар тезмәсе берничек тә чикләнмәгән, аны чикләүче принцип та юк.

Әмма нәкъ шушы бәйләнештә безнең алга күләм мәсьәләсе килеп баса. Барлык галимнәр диярлек повестьны хикәя белән роман арасында тора торган, димәк, күләм ягыннан да романнан кечерәк жанр дип саныйлар. Монда логика бар. Әгәр дә повесть тар сызыклы, ә роман күп тармаклы вакыйганы тасвир итә икән, роман сюжетындагы һәр тармак үзе бер повесть кадәр, ә бөтен роман берничә повесть хәтле урын сорый. Бу мәгънәдә повестьның кечерәк булуы табигый хәл.

Ләкин һәр тармакта вакыйгалар тезмәсенең озынлыгы бердәй булганда гына югарыдагы пропорция саклана. Фактта исә романист та, повесть авторы да моны үзенә мәҗбүри шарт дип кабул итми. Әдәбият практикасында бик озын, дәвамлы вакыйгаларны сурәтләгән романнар булган кебек (Д. Лондон. Мартин Иден, Э. Войнич. Кигевен, Л. Леонов. Рус урманы. М. Ауэзов. Абай, К. Нәҗми. Язгы җилләр, һ. Дәүләтшина. Ыргыз), чагыштырмача азрак вакыт эчендәге хәлләрне сурәтләгән романнар да байтак (С. Серафимович. Тимер ташкын, Ш. Камал. Таң атканда, Матур туганда, И. Гази. Гади кешеләр, В. Гюго. Диңгез хезмәтчәннәре). һәм, киресенчә, кайбер повестьларда, алда күреп үткәнчә, геройның бөтен озын тормыш юлы күп вакыйгалар тезмәсе аркылы тасвирлана. Шуңа күрә геройның эш-хәрәкәтен, алда күреп үткәнчә, күбрәк эпизодларда чагылдырган кайбер повестьларның киң планлы, ләкин аз вакыйгалы кайбер романнарга тиң яки хәтта алардан зуррак булып чыгуы бик ихтимал, хәтта табигый, законлы күренеш. Мәсәлән, М. Әмирнең «Агыйдел», Г. Гобәйнең «Маякчы кызы» повестьлары күләм ягыннан С. Серафимовичның «Тимер ташкын» романыннан зуррак булып чыккан.

Бу бәйләнештә повестьлардагы хикәяләү рәвеше дә игътибарга лаеклы. Хикәяләү турында сүз йөрткәндә без аларның төрле формада: автор исеменнән дә, герой авызыннан да һәм башка күп төрле юллар белән дә сөйләтелү мөмкинлеген, ягъни бу җәһәттән форма төрлелеген, алымнар байлыгын күреп киттек. Бик сирәк булса да, романнарда да герой исеменнән сөйләтү алымын яки шуңа якын булган эпистоляр стиль формаларын очратырга була. Мисалга Э. Касыймовның «Гомер ике килми» романын күрсәтергә мөмкин. Ләкин шуның белән бергә, нәкъ менә шушы форма әсәрне повесть жанрына якынайтканлыгын да әйтмичә китеп булмый.

Повестьта исә мәсьәлә башкачарак тора. Бу жанрда язучылар вакыйгаларны персонаж исеменнән яктыртуны әйбәтрәк күрәләр. Чыннан да, байтак повестьлар, әйтик, М. Гафуриның «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында», Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр», Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Ф. Хөснинең «Йөзек кашы», Г. Әпсәләмовның «Дустым мәхәббәте», Ә. Еникинең «Йөрәк сере», «Вөҗдан», С. Батталның «Сигезенчесе кемі», Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында», барлык автобиографик повестьлар я герой исеменнән, я геройны алмаштыручы документлар ярдәмендә хикәя ителгәннәр. Боларның бер ишендә (мәсәлән, «Кара йөзләр», «Дустым мәхәббәте» һ. б.) персонажлар үзләре актив рәвештә вакыйгаларга катнашып бармыйлар. Әсәрдә алар тик үзләре күргән-белгәнне, күзәткәнне түкми-чәчми хәбәр итүче функциясен генә үтиләр. Икенче берләрендә исә, әйтик, Ф. Хөснинең «Йөзек кашы»нда моның киресе күренә. Ягъни биредә хикәяләүче персонаж читтән карап бүтәннәр турында сөйләми, бәлки үзенең башыннан узганнарын тасвирлый. Монда хикәяләүче герой төп образ буларак бирелә. Өченчеләрендә бу ике төрле позиция гүяки бергә кушыла. Ягъни герой үзе турында да, башкалар хакында да бердәй җентеклелек белән сөйли. (Мәсәлән, «Агыйдел» повесте).

Герой исеменнән хикәя итү язучыга мәгълүм стилистик бурычлар йөкли. Бу хакта без үз урынында сөйләрбез. Хәзер сүз аның жанрга мөнәсәбәте турында. Әлеге форманың повесть өчен уңай ягы шунда ки, болай иткәндә күренешләр, син теләсәң-теләмәсәң дә, бер үзәк-хикәяләүче персонаж тирәсенә җыела. Димәк, сюжет нигездә бер сызык буенча үстерелә. Ә күп тармаклы, киң планлы роман өчен андый алым кулай түгел. Персонаж үзенең күз карашы белән чикләнгән. Монда бөтенесен дә күреп торучы, хыялы белән бөтен өлкәләргә дә үтеп керүче автор кирәк.

Шуның белән бергә, әле сөйләгәннәр повестьның автор исеменнән хикәя ителү мөмкинлегенә дә каршы төшми, аны кире какмый. Бездә автор тарафыннан тасвирланган повестьларны да күп очратырга

мөмкин. Әмма анда да бер үзенчәлек күзгә ташлана. Әдипләр гәрчә турыдан-туры герой исеменнән сөйләмәсәләр дә, шулай да баш герой күргәннәргә нигезләнеп сурәтлиләр, ягъни чынбарлыкны төп образның күз карашы яктылыгында чагылдыралар. Сюжетны бер үзәккә туплау җәһәтеннән моның шулай ук әһәмияте бар.

Кайбер хезмәтләрдә жанрны сюжет оештырылышына карап билгеләргә омтылу күренеп кала. Г. Бәширов болай дип яза: «Повесть жанры бит ул бүгенге темага багышланган художество әсәре язу өчен иң уңайлы бер форма. Повестьның шул ягы яхшы, анда әһәмияте аз булган күренешләр белән бик мавыкмыйча һәм үткәнгә кат-кат борылып карамыйча, ярыйсы ук катлаулы һәм тирән эчтәлекле вакыйгаларны сурәтләргә, шактый сандагы геройларның характерлары бәрелешен күрсәтергә була»[1]. Бу фикердә, әлбәттә, дөреслек бар. Алайга Г. Бәшировның үзенең иҗатын гына. Аның романының сюжетында туктап торулар, үткәннәргә борылып караулар зур гына урын ала. «Туган ягым — яшел бишек»тә исә андый «борылып карау»лар юк, вакыйга фабула тәртибендә, ягъни сәбәп һәм вакыт эзлеклелегендә ага. Шундый ук хәлне «Кара йөзләр» дә, «Рәүфә» дә, «Саз чәчәгенндә һәм башкаларда күрергә мөмкин.

Ләкин шуның белән бергә, аны норма дип тә кабул итеп булмый. Чөнки әдәбият тарихында композицион яктан башкача төзелгән повестьлар да бар. А. Пушкинның «Капитан кызы», Ч. Айтматовның «Хуш, Сарыгөл», С. Батталның «Сигезенчесе кем?», А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» һәм башка повестьлар шул хакта сөйли. «Өч аршын җир»дә, кайбер романнардагы кебек, ике катламдагы вакыйгалар үрелешеп, аралашып баралар. Димәк, вакыт эзлеклелегендә генә тасвирлау повестьның үзенә хас сыйфат түгел, бәлки башка жанрлар белән уртак сыйфатларның берсе икән. Әлеге фикердә ачыклыйсы башка яклар да бар. Бүгенге теманы чагылдыру, әһәмиятсез күренешләр белән мавыкмау — болар шулай ук повесть өчен генә хас сыйфат түгел, бәлки башка жанрларда да табыла торган сыйфат.

Кайбер авторлар роман белән повесть аермасын конфликт характерына кайтарып калдыралар. В. Кожинов, мәсәлән, роман сюжеты өчен драматик киеренкелек хас, ә повесть ашыкмыйча-кабаланмыйча, тынычталгын ага[1], дип раслый. Әдәбият практикасында, әлбәттә, мондый карашка туры килә торган повесть-романнарны да очратырга мөмкин. Ләкин шуның белән бергә, салмак сюжетлы романнар да байтак. Хәтта рус романының атасы Л. Толстой да үзенең романнарында («Сугыш һәм тынычлык», «Анна Каренина») күренешләрне эпик талгынлык белән, бөртекләп сурәтли. Ш. Камалның «Таң атканда», Г. Бәшировның «Намус», Н. Фәттахның «Сезнеңчә ничек?», «Бала күңеле далада» һәм башка романнарда да салмак темпны күрү читен түгел. Һәм, киресенчә, байтак повестьлар (Мәсәлән, Н. Гогольнең «Тарас Бульба», Ф. Хөсниның «Йөзек кашы», С. Батталның «Сигезенчесе кем?» әсәрләре) үтә киеренке, җитез хәрәкәтне тасвирлыйлар. Шулай итеп, сюжетның талгынлыгы яки житезлеге, киеренкелеге аерым жанрга гына хас билге түгел, бәлки тегесе өчен дә, монысы өчен дә уртак күренеш икән, икенче төрле әйткәндә, ул жанрны аеруга хезмәт итми, бәлки жанрның үз эчендә төрлечә чагыла. Сюжетның киеренкелеге яки талгынлыгы күп вакытта язучының индивидуаль үзенчәлегенә карап йөри.

* * *

Җыеп әйткәндә, без повестьта эчтәлек белән форманың түбәндәгечә үзара күчешен, үрелешен күрәбез. Әдип игътибары чынбарлыкның билгеле бер төр өлкәсенә, бу очракта вакыйгалар ягына, аның да дәвамлырак, ләкин тар рак бер тезмәсенә туктала. Шушы тормыш материалы темага, сюжетка, ситуациягә йогынты ясый, ягъни аларның һәрберсенең шушы сурәтләү предметына яраклашуын таләп итә. Сюжет, мәсәлән, башлыча, бер сызык буенча үсә. Ситуация ул сызыкның озынлык чиген билгели. Алар бөтенесе (сурәтләү предметы, тема, сюжет) билгеле бер жанрны, бу очракта повесть жанрын формалаштыралар. Повесть жанры мәйданында сурәтләнгән берничә образ туа. Бу жанр геройлар санының күплегенә түгел, азлыгына омтыла. Хикәядән үзгә буларак, монда характер динамикада бирелә. Шулай итеп, повесть жанрында чынбарлыкның үзенчәлекле бер өлкәсе, шушы өлкәдә яшәүче мәгълүм бер кешеләре үзләреннең образлы гәүдәләнешен табалар.

[1] Г. Бәширов. Татар совет әдәбиятының хәзерге торышы һәм бурычлары. «Совет әдәбияты» журналы. 1954 ел. 6 сан. 68 бит.

[1] Краткая литературная энциклопедия. Рус телендә. 5 том. 1968 ел. 814—815 битләр.

# ХӨСӘЕН ФӘЕЗХАН УЛЫНЫҢ БЕР ХЫЯЛЫ

Татарлардагы мәгърифәт тарихы эзлекле рәвештә өйрәнелмәгән. Ә тикшерелгән кадәресендә исә төрле характердагы төгәлсезлекләр шактый күп очрый. Мәсәлән, мәгърифәт хәрәкәтебезнең башында торган кешеләрдән Шиһап Мәрҗани эшчәнлеге моңарчы я гел күпертелеп, яисә бөтенләй икенче планда тәкъдим ителеп килә. Аның шәкерте, иң якын дусты һәм фикердәше булган Хөсәенне өйрәнү дә үтеп барышлый исемен җөмлә җөенә кыстырудан узмады диярлек. Өстәвенә бер фикер, бер позициядә торган бу ике шәхесне үзара каршы кую фактлары да булды. Аннары мәгърифәтебез тарихын беренче түгел, бәлки икенче этабыннан гына башлау канунга әйләнә язды. Бәс, шулай икән, Фәезхановның туу елын бутап йөртү кебек кимчелекләр генә әллә ни гаҗәп тоелмаска тиеш [1].

Ләкин Фәезханов эшчәнлеген өйрәнүдә булган кимчелекләр аның туу елын бутау белән генә чикләнми. Кайбер тикшеренүчеләр, мәсәлән, агасы Хөсәенне бөтенләй икенче чорда яшәп иҗат иткән энесе Габделгалләмнән аермыйлар. Икенчеләребез исә аның Казан һәм Петербург университетларында нинди эшләр башкарып, нинди дәрәҗә биләвен белеп җиткермибез.

Шулай ук Фәезхановның соңгы көннәре, аның нинди шартларда вафат булуы турында да ялгыш фикерләр яши. Мәсәлән, моңарчы язган барлык авторлар аны казакъ сахрасыннан гыйльми командировкадан кайтышлый үз авылында үлгән дип язып килделәр. Чынлыкта исә Х. Фәезханов 1866 елда командировкага бару түгел, түшәктән тора алмаслык хәлдә каты авыру була.

Ә «гыйльми командировка» дигән нәрсәнең тарихы болай: каты авырып киткән Хөсәеннең дәваланыр өчен берниндн мөмкинлеге булмый. Патша хөкүмәте законнары исә аның кебек «инородец»ны пособие һәм пенсия хокукларыннан мәхрүм итә. Нәкъ менә шул вакытта ярдәмгә алдынгы рус галимнәре киләләр. Алар, «казакъ сахраларына командировка» дигән сылтау белән, Хөсәенгә биш айлык түләүле ял оештырып, дәваланыр өчен аны үз авылына кайтарып җибәрәләр. Бу хакта мәгърифәтче үз остазы Ш. Мәрҗанига 1866 елның 20 мартында җибәргән хатында кинаяләп кенә болай яза:

*«Халем гаять зәгыйфьтә» Университет начальствосы хыялыма килмәгән лотыф вә мәрхәмәтләр иттеләр. Кышның әксәрене (күп өлешен — М. Г.) хезмәткә йөрмәүемдән эгъмаз итүләрендән (күз йомуларыннан — М. Г.) башка бер бәһанә (сылтау — М. Г.) илә биш айга, 1 нче апрельдән 1 нче сентябрьгә, отпуска бирделәр. Бу хосуста илтимас кылмау гына түгел, бәлки иһам кылдыгым (гөман итеп карау да — М. Г.) хәтта хәтеремә килгәне дә юк иде».*

---

[1] 1966 елда атаклы мәгърифәтче һәм галим Хөсәен Фәезхановның тууына 145 ел тулу билгеләнгән иде. Ләкин ике елдан соң, ягъни 1968 елда, аның 140 яшькә җитүен тагы бер кат билгеләдек. Дата буталчыклыгы Р. Фәхретдинов мәкаләсендәге типографик хатадан «Татарстан тарихы»на һәм башка соңгы хезмәтләргә, шул исәптән бу юллар авторның бер мәкаләсенә дә күчеп керә. Галим туган елның 1821 түгел, бәлки 1828 булуы Ф. Сафиуллина тарафыннан ачыкланды («Вопросы татарского языкознания» исемле җыентык. II китап. Казан. 1965).

Туган авылына Хөсәен май башларында гына кайтып төшә. Шуннан соң ул үзенә хат язарлык та көч таба алмый... Ә галим үлгәч, башкала газеталарының берсе Хөсәеннең «казакъ сахраларыннан кайтышлый вафат булуын» хәбәр кыла. Менә шуннан башлап, бу ялгыш версия, китаптан китапка, автордан авторга күчеп, безнең көннәргә хәтле килеп җитә.

Беренчел чыганакларга тиешле игътибар итмичә, «официаль документлар»га шулай ияру нәтиҗәсендә, галим тормышындагы гаҗәп әһәмиятле, гыйбрәтле бер факт тиешле дәрәҗәдә яктыртылмыйча килә. Бу — прогрессив карашлы төрле милләт галимнәре арасындагы самими дуслык, теләктәшлек факты.

Ялкынлы патриот, демократ мәгърифәтче Хөсәен Фәезханов эшчәнлегендә әле ачыкланмаган фактлар тагы да күп булырга тиеш. Моның шулай икәнлеген, югарыда саналган каршылыклардан тыш, соңгы вакытларда табылган документлар да исбат итәләр. Сүз Хөсәен Фәезхановның моңарчы билгесез хатлары турында бара. Алардан галим эшчәнлегенең бөтенләй икенче, моңар хәтле мәгълүм булмаган яңа бер сыйфатлары ачыла. Әйтергә яраса, алардагы яңа фактлар ярдәмендә бер галим эшчәнлегенең генә түгел, бәлки татар иҗтимагый фикере тарихының да бөтенләй яңа сәхифәләрен тергезергә мөмкин.

Хатларның берсе галимнең авылдашы һәм шәкертләреннән булган Хәбибулла Сафаҗай (1830—1896) дигән кешегә, Бохарага адресланган. Бу хатны безгә 1964 елгы археографик экспедиция вакытында Красная Горка авылында (Х. Фәезханов туган авыл, аның әлекке исеме — Сабачай) пенсионер Габделбәр ага Хәбибуллин тапшырды [1].

Беренче карауга, бу хат әллә нинди хәбәр итми кебек: тәкәллефле гыйбарәләр, авыр стиль белән ярым шаярту, ярым җитди тонда язылган бер хосусый «мәктүп» кенә. Ләкин игътибар белән укып, автор фикерләренең аскы катламнарына үтеп керергә тырышсак, һәм, адресатның кем икәнлеген онытмыйча, хатның гомуми рухына җитсәк, икенчерәк картина ачылачак. Безнең алда чуклы-чачаклы гыйбарәләргә төрелеп бирелгән ачы ирония, яшертен полемика. Хат авторы, адресатның үз теле, аның стиле белән сөйләп, нечкәртелгән кинаяләр ярдәмендә тегенең схоластикасы белән бәхәсләшеп, тышкы купшылыгын тәнкыйтьли. Моның шулай икәнен аңлар өчен, Х. Фәезхановның Мәрҗанига адресланган бер хатында Хәбибулла турында нечкәртелгән ирония белән язган икенче сүзләрен китерергә мөмкин:

*«Безем ишан мелла Хәбибулла мәхдүм, ходай теләп, Сабачайга кайтса, үз ягымызда бер үрнәк булырлык гыйлем сөюче булачак имеш. Чөнки «мишәр» таифәсе «ишан» аталган затларга бик турылыклы булалар. Мәрхүм «Оры» Хәбибулла ишанның аяк баскан йирләрене үбәләр вә Орыга барганларында каберенең туфракларын ашыйлар, имеш.*

*Безем тарафымызның күпчелеге «Колаткы» Җәгъфәр ишанга турылыклы иделәр. Мелла Хәбибулла бәхетенә ул һәм үткән ел мәрхүм булыптыр. Хәзер урыны буш, килсен дә утырсын, яхшы кәсеп һәм эш итәр».*

Моны аның Хәбибулланы кеше, шәхес буларак кына яратмавы дип аңларга ярамый. Х. Фәезханов барлык «Бохара җимешләренә» карата шундый скептик караштa торган. Мәсәлән, Мәрҗанига җибәргән икенче бер хатында Нәҗип исемле сабакташы турында: «Нәҗип Бохарада череп калмаса ярар иде»,— дип яза. Шул ук Мәрҗанига юллаган өченче бер хатында исә ул татар руханилары турындагы үзенең тискәре фикерен шактый гомумиләштереп бирә: «авыл муллаларының күпчелеге бәдхү (эшәке холыклы — М. Г.), надан вә хәрамхурлар».

Хәтта чагылып киткән антиколониаль мотивлар да игътибарга лаек. Ләкин боларны Фәезхановның дини инануларына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Чөнки Хөсәеннең Ш. Мәрҗанига адресланган хатларында (аларны 1916 елда Р. Фәхретдинов бастырып чыгарган) [2] аның патша самодержавиесенең рус булмаган халыкларны социаль-политик максатлардан чыгып изүен шактый дөрес сиземләве чагыла. Икенче бер урында, мәсәлән, атаклы казакъ мәгърифәтчесе һәм галиме Ч. Вәлихановка язган хатында, 1863 елда студентлар хәрәкәтенең бастырылуын сөйләп, «азадә (игелекле —

[1] Документ хәзер Казан университеты каршындагы гыйльми китапханәнең кульъязмалар бүлегендә «1968 т.» номеры белән саклана.

[2] «Шура» журналы. 1916 ел. 14—19 саннар. Бу хатларга ясалган кыскача обзорны «Казан утлары» журналының 1966 елгы 9 саныннан карагыз.

М. Г.) фикер нясе яшьләр бу ел бераз басылынкырап торалар»,— дип, киная белән пошыну белдерә[1].

Хәбибуллага җибәргән хатның, ниһаять, Хөсәен үсеп чыккан даирәне дә, ул аралашкан татар укымышлылары сферасын күзаллау өчен дә әһәмияте зур.

Публикацияләнә торган өч хатның калган икесе тюрколог һәм миссионер Н. И. Ильминскийга (1822—1891) адресланган. Ул документларның оригиналлары Мәскәүдә В. И. Ленин исемендәге дәүләт китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә әле төгәл эшкәртелмәгән «Ильминский фондында» саклана (424 фонд. Икенче коробка. «Татарча хатлар һәм кәгазьләр» исемле папка).

Ильминскийга адресланган хатларның беренчесен автор 1860 елда җәен Оренбург якларына гыйльми командировка максаты белән барып кайткач яза. Аннан без иҗтимагый фикеребез тарихы өчен бик әһәмиятле яңа факт ачабыз. Бу — Х. Фәезхановның күренекле казакъ мәгърифәтчесе һәм педагогы Ибраһим Алтынсарин белән танышу һәм дусларча якын мөнәсәбәттә торуы. Димәк, бу табыш ярдәмендә татар-казакъ мәдәни багланышлары хакындагы белемебез яңа мәгълүмат белән баетыла (сүз уңае белән әйтеп китик, Фәезхановның И. Алтынсарин, Ч. Вәлихановка карата булган җылы хисе, ихтирамы түбәндә анализлана торган өченче хатта тагы да калкурак чагыла). Кечкенә генә күләмле бу документ Хөсәеннең эчке культурасын аңлау өчен дә гаять әһәмиятле.

Әлеге хатларның икенчесе ярдәмендә исә без бер Х. Фәезханов эшчәнлегенең генә түгел, ә бәлки XIX йөз урталарындагы бөтен татар иҗтимагый хәятының да мөһим вакыйгаларын ачыклый алабыз. Бу, җыеп әйткәндә, татар телендә вакытлы матбугат органы булдыру, шуның өчен көрәш һәм шул булачак дип өмет ителгән газета-журналның иҗтимагый бурычларын билгеләү мәсьәләләре.

Документтан Хөсәеннең «Казанда Ильминский татарча газета чыгара башлаган» дип ишетеп, шул яңа хәбәрдән сөенеп, шатлыгы белән уртаклашуын һәм яңа (чыга башлаган дип ышанган) газетаның сыйфатын күтәрү, аны халык өчен практик файдалы итү өчен зарури дип тапкан фикерләрен тәкъдим кылуын беләбез. Бер карауга монда әллә ниләр юк шикелле. Беренчедән, сүз бара торган газетаның чыкканы юк. Икенчедән, ата миссионер Ильминскийның гомум татарлар өчен газета чыгару ихтималы да бөтенләй мөмкин түгел. Ләкин мәсьәләнең төбенәрәк төшеп, шул вакытларда йөз биргән иҗтимагый хәлләрне күз уңында тотканда, бу яңа фактның, ягъни Х. Фәезхановның татарча газета турында якыннан кайгыртуының, иҗтимагый тарихыбыз өчен әйтеп бетергесез дәрәҗәдә кыйммәтле икәнлеген күрәбез.

Мәсәлән, билгеле булганча, татарча газета чыгару турындагы фикерне, беренче булып, 1808 елда Казан университеты адъюнкты И. И. Запольский дигән кеше күтәреп чыга[2]. Моннан соң М. Г. Никольский дигән гаҗәп кызыклы студент-ориенталистның «Бәхр-ел-әхбар» исемле татарча газета оештыру турында хыялланып йөрүләрен беләбез[3]. Бу ике омтылыш та патша самодержавиесенең дегет белән майланган итекләре астында кала... Шактый вакыт узгач, ягъни 1864 елда, татарча вакытлы матбугат мәсьәләсен Казан университетын бетергән прогрессив карашлы ориенталист П. Пашино кузгата, ул «Файда» исемле журнал чыгару турында махсус проект төзи[4]. Тик бу юлы да патша самодержавиесенең «лаканнан да юан тавышы» яңгырый... Китап белгече Ә. Кәримуллин тапкан документларга караганда, икенче, ягъни 1865 елда, шундый ук исемле татарча газета чыгару эшенә революционер Н. Г. Чернышевский даирәсенә якын торган В. С. Курочкин исемле алдынгы карашлы рус офицеры алына[5]. Ләкин һаман бер нәтиҗә.

Анализлана торган хатның 1862 елның 9 январенда язылуын, мәгәр моңар хәтле

---

[1] Бу хатларны казакъ галиме академик Ә. Х. Маргулан табып, әтрафлы анализ белән бастырып чыгарды: Известия АН Каз. ССР. Серия общественных наук. Алма-Ата. 1965. вып. 3. (Мәкалә казакъ телендә, Хөсәен хатлары исә оригиналда бирелгән.)

[2] Н. П. Загоскин. История императорского Казанского университета. т. 2. Казан. 1903. Рус телендә. 285—287 битләр.

[3] Вестник научного общества татароведения. Рус телендә. Казан. 1926 ел. 5 сан (М. Корбут мәкаләсе).

[4] Труды общества изучения Татарстана. т. 1. Рус телендә. Казан. 1930 ел. (Е. И. Чернышев мәкаләсе).

[5] «Казан утлары» журналы. 1970 ел. 7 сан. 150—151 битләр.

да татарча газета турындагы хыялнын Х. Фәезханов «вә дәхи ничә кешеләрнең күңелләрендә уйнаган» булуын игътибарга алсак, түбәндәге нәтиҗә килеп чыга: Никольскийның «Бәхр-ел-әхбары» уңышсызлыкка очрап, П. Пашиноның «Файда» турындагы проекты туганчы да (1864 ел) татарча газета чыгару омтылышы булган икән.

Бу фикерне тагы берничә дәлил белән куәтләргә мөмкин.

Югарыда Х. Фәезхановның Ч. Вәлихановка адресланган хатларын телгә алган идек. Менә шул ике хатта да, Хөсәен белән Чокан араларындагы самими дуслыкны, дәвамлы хезмәттәшлекне хәбәр иткән мәгълүматлардан тыш, татар вакытлы матбугаты өчен барган көрәш тарихын чагылдырган әһәмиятле моментлар да бар. Мәсәлән, 1863 елның 7 апрелендә салынган хатта Хөсәен болай яза: «Якын арада Казандан Мәхмүдовтан хат алдым. Анда берничә кешеләр (татарлардан) татарча газет бастырырга тырышып йөриләр, имеш. Бу хосуста прошение бирептеләр. Белмәймен — начальство рөхсәт бирерме? Бу хосуста тафсил белмәймен. Бу сәфәр Казанда белешермен».

Шул елның көзендә, ягъни Казанга барып кайткач, язылган хатта исә Фәезханов мәсьәләне ачыграк яктырта: «Казанда татарлардан компания булып, ике-өч кеше газет бастырмакчы булып йөриләр икән. Хәзер кагазьләре Министр внутренних делның советында икән. Белмәймен, аны бирерләрме? Аларның берсе литография остасы, әүвәл дәфгадә литография кылырга телиләр. Язардай кешеләр табылачак. Ильминский һәм аларга мәслихәтләре белән ярдәм бирәчәк: ушандак Мәхмүдов вә гайреләр»[1].

Шулай итеп, картина бераз ачыклана төшә. Беренчедән, газета чыгарырга тырышып йөрүчеләр Ильминский түгел, бәлки башка кешеләр икән. Икенчедән, газета чыгару өчен 1862—1863 елларда ясалган омтылышның аерым шәхесләр генә түгел, бәлки махсус компания тарафыннан оештырылуын аңлыйбыз.

Ләкин бу компаниягә кемнәр кереп, аның башында кем торган, ниһаять, булачак дип исәпләнгән газетаның максат-юнәлеше нинди булган? Бу сорауларга хәзер кистереп җавап биреп булмый, чөнки тиешле документлар әлегә табылмады. Ләкин эзләнүләре дә канәгатьләнерлек дәрәҗәдә булды дип әйтү дөрес түгел...

Шулай ук хәзергә Х. Фәезхановның фикердәшләренең кем булулары да тәгаен мәгълүм түгел. Мәгәр аларның берсе Ч. Вәлиханов булмады микән? дигән уй хыялга килә. Чөнки 1859—1861 елларда Петербургта яшәп, аннары еракка киткән Вәлихановның татар газетасы язмышы турында Хөсәеннең эзлекле рәвештә хәбәрдар итеп баруы очраклы гына түгелдер дип уйлыйсы килә. Бу — бер. Икенчедән, көнчыгыш телләре тәрҗемәчесе булып хезмәт иткән П. Пашиноның Петербург университеты ориенталистлары, ягъни Х. Фәезхановның хезмәттәшләре белән якын мөнәсәбәттә торуы мәгълүм. Югарыда Пашино проекты белән В. С. Курочкин планнары арасындагы уртаклыкны да (ике проектта да орган бер исем белән — «Файда» дип атала) күргән идек. Димәк, Х. Фәезханов белән фикердәш кешеләрнең алдынгы рус интеллигенциясе арасыннан, хәтта Н. Г. Чернышевский тирәсендә тупланган яшьләрдән булулары да ихтимал икән.

Бу әле генә әйтелгәннәр коры фаразлар гына түгел, бәлки аларның беркадәре нигезе дә бар. Мәсәлән, югарыда аталган В. С. Курочкинның «Файда» газетасы өчен билгеләнгән юнәлеш белән Х. Фәезхановның татарча газетага йөкләгән төп бурычы («асыл максуд халыкның күңел күзләрен ачып, мәгърифәт сачмак») арасында тирән эчке уртаклык сизелеп тора.

Хөсәен Фәезхановның «булачак» татар газетасы турындагы ялкынлы фикерләрен бары яңа хәбәр ишетелгәч туган җилкенеп алуларга гына кайтарып калдырырга да ярамас иде. Чөнки «чыгачак» дигән газетаның сыйфатын күтәреп, тактикасын, репертуарын билгеләп, тиражын тәэмин итү юлындагы Хөсәен тәкъдим кылган чаралар (укучы публиканың рухи инануларын мәсхәрәләмәү шарты, газета эчтәлеген төрләндерү, басту, шуның ярдәмендә подписчиклар тәэмин итү һәм моның өчен үсеп килә торган яңа сыйныф — буржуазиянең интересларыннан да файдалану) аның татарча басма сүз турында күп уйлап, тирәннән фикер йөрткән булуын күрсәтәләр. Бу әйтелгәннәрне куәтләр өчен, тагы бер дәлил китерергә мөмкин. Мәсәлән, Ш. Мәрҗанига язылган хатларның берсендә ул, Европа тибындагы татар гимназиясен ачу белән бергә, иҗтимагый эчтәлекле татарча журнал чыгаруны да күздә тота. Кыскасы, татар-

[1] Известия АН Каз. ССР. Серия общественных наук. 1965, выпуск 3. 22—23 битләр.

ча басма сүз органын нигезләү мәсьәләсе Х. Фәезхановның аңын күп еллар дәвамында биләгән.

Анализлана торган документлардан тагы бер нәрсә калку булып күренә: Х. Фәезхановның мәгърифәтчелеге крепостнойлык җимерелгән чорда, шул зур социаль үзгәрешләр дәвамында формалашып, куәтләнеп канат җәйгән. Татарлар өчен дөньяви мәктәп (гимназия), университет бүлеге, ниһаять, демократик рухтагы мәгърифәтче басма сүз органы булдыру хакындагы аның якты хыяллары 60 елларның башына, ягъни крепостнойлык богауларының өзелгән чорына туры килә. Бу очраклы гына туры килгән хәлләр түгел, әлбәттә, чөнки нәкъ менә шушы елларда Хөсәен Петербург университетында эшләп, үз сүзләре белән әйткәндә, «азадә фикер иясе яшьләр» дөньясында яши, алдынгы рус ориенталистлары белән якын мөнәсәбәттә торудан тыш, В. В. Стасов, Ч. Ч. Вәлиханов кебек шул чорның күренекле фикер ияләре, демократик рухтагы әһелләре белән тыгыз бәйләнештә була. Әлбәттә, бу әйтелгәннәрдән Фәезхановны алдынгы фикерләрне пассив рәвештә кабул итүче яисә башкаларга ияреп кенә баручы булган икән дип уйлау да дөреслеккә хилафлык итәр иде. Гомум татар җәмгыяте XIX йөз урталарындагы социаль үзгәрешләргә тиешле әзерлек белән килгән кебек, Ш. Мәрҗани мәктәбен узган Хөсәен Фәезханов та мәгърифәтчелек хәрәкәтенең бер идеологы булып әверелер өчен кирәкле дәрәҗәдә өлгереп җиткән була.

Ниһаять, анализланган документлар һәм барлык әйтелгәннәрдән шул нәрсә дә ачыла: мәгърифәтче Фәезханов фикеренчә, татар телендә чыгачак беренче газета бер татарларга гына түгел, бәлки бөтен ил өчен дә файдалы булачак («гомумән йортымызга вә, хосусән, татар халкымызга күп файдалар китерүендә шик юктыр»). Менә шуның өчен дә ул бер хәбәр ишетү белән шатланып, Ильминскийны «һиммәттә, кешелеклелектә» котлый, ә борчылулы уйлары, шөбһәләре турында ерак казакъ дусты Ч. Вәлиханов белән эчкерсез фикер алыша. Мондый сыйфат, әлбәттә, аң-белемне гомум кешелек эше дип ышанган чын мәгърифәтчеләргә генә хас. Чөнки мәгърифәтчелек идеясе милли кысаларны белми. Аңа беренче чиратта кеше һәм аң кыйбат.

...Ләкин тормыш катлаулы нәрсә икән. Рухи таләпләрдән тыш социаль интереслар да бар бит. Бу тирән хакыйкатьне һәм рухи омтылышларга сыйнфый мәнфәгатьләренең өстенлек итүен, бөек мәгърифәтчеләрнең барысы кебек, Хөсәен Фәезханов та ахыргача аңлый алмаган. Әмма мәгърифәтчеләрнең әһәмияте аларның бөтен каршылыкларын аңлап, шуларны җиңеп чыгуларында түгел, бәлки үзләренең якты идеяләре белән булачак көрәшчеләрне тәрбияләү өчен җирлек әзерләүдә, канатлы хыяллары белән үзләреннән соңгыларны илһамландырып калдыруда. Ә Хөсәен Фәезхан улы кичергән изге хыялларның берсе — ул халык өчен турылыклы хезмәт итеп, чын мәгърифәтчелек орлыгы сибүче басма сүз турындагы якты теләк иде. Тик бу өметләр тормышка ашсын өчен, крепостнойлык җимерелүдән тыш, тагы берничә революцияләр кирәк булды...

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

# Хөсәен Фәезханов хатлары

### ХӘБИБУЛЛА САФАҖАЙГА [1]

*«Алланың ризалыгын алган сөеклесе мәрхәмәтле борадәребез мелла Хәбибулла!*

*Җәнабы галиләрегезгә дуслык вә турылыкны белдергәннән соң, бу баштан аякка хәтле түбән һәм кимсетелгән дустыгызның хәл-әхвәлен игътибарга алып хәбәр сорагыз, аллага шөкер, сезнең һәр ике дөнья дәвамлы изге фатихагызда иртә-кич һәм даими сау-сәламәт булып, сезнең теләкне теләүдә дип белерсез.*

*Янә сез мөхтәрәм тарафыннан язылган датасыз бер хат мелла Фәйзерахман [2] ага аркылы без фәкыйрьгә бәхетле сәгатьләрдә ирешкән иде; аның бай эчтәлеге сез галиҗәнапларның Бохарадагы бөек галимнәрдән булуыгызны аңлатып, һәм [сез ул хатыгызда без] фәкыйрьне тәкәбберлек, үз-үзен белмәүдә вә ил тормышы турында хәбәрләрне аз язуда гаепләгәнсез. [Моннан без] фәкыйрьгә чиксез зур шатлык һәм канәгатьләнү булды. Чөнки безнең «Эт авылыбыз» [3] мондый камил кешенең ватаны булу бәрчабыз өчен дә сөенеч вә бәхеттер. Мондый дәүләткә ия булуыбыз, бәлки, үзебезне танымыйча, сез әйткәнчә, тәкәбберлек итүебезгә сәбәп булгандыр. Безнең төшенчәдә*

«кибр» үзен башкалардан югары күрү димәктер. «Һәркемгә үзенә лаек нәрсә белән килешергә кирәк»[4]. Үз-үзен танымау дисәгез, ул да булыр, чөнки без мөселман булмаган илдә торып, күзебез сукыр, күңелебез боз булган. Бәлкем сезнең кебек изгеләр бу якларга баш борып, игътибар итсәләр, күзләребез ачылыр иде. Илнең хәле турында хәбәрсез булу — бу да хак. Һәркем үзе белгән хәтле хөкем итә. Кешеләрнең күбесенең табигатендә шөбһәләргә аналогияләрнең булмавы моңа бик характерлы шаһидтыр. Хәтта кырмыска да үзендәге көчне ике мөгез кебек ике кисәктән гыйбаратттер дип, аллаһы тәгалә каршында исбат итә торгандыр дип, Җәлалетдин әд-Дувани «Исбаты вәҗиб» китабында язадыр[5]. Юкса төгәллекләргә өстәмәләр [ясау] бездәй вак кешеләрнең эше түгел.

Башка шелтәләрегез дә без фәкыйрьгә шатлык булды; сезнең дөрес гарәп гыйбарәләре белән язылган хатыгыз нихәтле озын һәм күп булса, шул хәтле җофар кебек хуш киләдер. Мәхдүмнәргә[6] озын итеп, сезгә кыска хат язуым өчен шелтә кыласыз, җавабы будыр: мәхдүмнәр үзләре икешәр хатның һәрберсендә җидешәр-сигезәр бит язалар. Аларның бу хәтле тулы хат язарга вакытлары булгач, ихтимал, тупас гыйбарәләр белән язылган минем хатымны укырга да вакытлары табылыр. Сез көне-төне төрле гаҗәеп, хикмәтле гыйлемнәр өйрәнү белән мәшгульбез дип аңлатып язгансыз. Сезнең кадерле вакытыгыз мәгърифәтсез кешенең хатын укып әрәм булыр дип, сүз кыска тотылды.

Тагын узган елны сезгә аерым һәм махсус бер хат язарга кыюлык ителгән иде. Әмма хәзергә хәтле тәгаен белмим: мелла Габделхәким аша «Мәкамәт» китабы эчендә җибәрелдеме, яисә мелла Габделхәким һәм мелла Фәйзерахманга Яманкальгага салынып[7], шунда җибәрелдеме, фикеребезчә, соңгысындадыр. Сез аны бөтенләй асылсызга исәпләп, мин фәкыйрьне ялганчыга чыгаргансыз һәм уегызда ачулангансыз. Бу, әлбәттә, җитмәс дигәнсез. Мин «вөҗүде зиһни» бәхәсләрен оныттым һәм «вөҗүде зиһнине» исбат кыла да алмам[8]; димәк, уйдан гына җибәрмәдем. Синең зиһнең ачык вакытта андый «вөҗүдләрне» исбат кыла алырсың. Шулай булгач, син ни өчен бу, әлбәттә, җитмәс дигәнсең? Җитүне фараз кыл, уйдан [булса да] җитәр![9].

Мөхтәрәм атагыз мелла Мөхәммәт аганы[10] «Эт» авылында да, Мәкәрҗәдә дә күрдем. Мәкәрҗәдә сездән хат алган икән, миңа күрсәтте һәм хат язып Мөхәммәт Шәрифкә бирермен диде. Алла теләсә, хәл-әхвәлне төгәл язгандыр. Кадерле остазыбызга[11] җибәргән хатыгызны да уку бәхетенә ирештек.

Сез сораган сүзлек китабы һәрвакыт хәтеремдә. Петербургка Истанбулдан илчеләр килгән, һәрвакыт шунда торачак имеш. Шулар аркылы Истанбулдан алдырып булмасмы дип торам.

Күңелле хатларыгыздан мәхрүм итмәссез.

Түбәнчелек белән үтенеп: Хөсәен бине Фәиз.

16 октябрь, 1856 ел».

---

## АҢЛАТМАЛАР

[1] Хат хәзерге әдәби телгә күчерелеп бирелде. Археографик экспедиция вакытында табылган башка документлардан күренгәнчә, Сабачай (хәзер — Кр. Горка) авылыннан чыккан элекке укымышлылар үзләренә фамилия-псевдоним итеп авыл исеменнән үзгәртелгән «Сафаҗай» сүзен алганнар (ягъни, «хуш урын»). Бу — Сабачай сүзен русча «собачий» дип уйлап, шул ямьсез сүздән качуларыннан килә.

[2] Урта Азиягә йөреп торучы сәүдәгәр булырга тиеш.

[3] Оригиналда «каръяи сәг»; карья — авыл, сәг — эт (фарсыча). Х. Фәезханов шаяртып Сабачайны (ягъни «собачийны») шулай механик рәвештә тәрҗемә итеп алган.

[4] Гарәпчә мәкаль.

[5] Җәлалетдин Дувани — XV гасырда яшәгән билгеле философ һәм теолог.

[6] Сүз Х. Фәезхановның сабакташ дуслары Нәҗип Байморат улы Мәнгәри һәм Гаязетдин Хәбибулла улы Рахманкуловлар турында бара. Аларның тарих һәм әдәбият белән якыннан кызыксынып, кайбер әсәрләр дә язулары мәгълүм. Икесе дә яшьли вафат булган (Р. Фәхретдинов. Асар. II том. 14 кисәк. 443 һәм 496—502 битләр).

[7] Ямankalьга (Яман кала) — Оренбург шәһәренең татар һәм казакълар арасында таралган бер исеме.

[8] Сүз формаль логика — мантыйкның кайбер алымнары турында бара.

[9] Хәбибулланың Фәезхановка үпкәләве хат авторына икенче бер каналлар аша ирешүенә ишарә булса кирәк.

[10] Мөхәммәт Салих улы — Хәбибулланың атасы, Хөсәен Фәезхановның авылдашы.

[11] Ш. Мәрҗани күздә тотыла. Күп кешеләрдән дәрес тыңлаган булуына карамыйча, Х. Фәезханов бары аны гына шулай «остаз» дип олылый.

## БЕРЕНЧЕ ХАТ

*«Галиҗәнап, газизе мөкәррәм Николай Иванович хәзрәтләренә күп изһаре ихлас бәгъдендә[1], гарзы мөхиббанә[2] будырки.*

*Фәкыйрь бу җәйдә сезнең Оренбург тарафына сәфәр итеп, ничә көннәр Оренбургта тәзаййыгы әүкат кылдым[3]. Ликән, хәйфки[4], җәнабы гыйззәтеңез берлән мөлякат мөяссәр булмады[5]. Мөкәррәмәе гаялыңызга[6] бинибая мәмнүнмен: фәкыйрьне кабул итеп, бинибая мәрхәмәтле булдылар. Дусларымның һәммәсенә сезнең кеби гаялыңдан бәхетле булуыны теләр идем.*

*Җәнабыңыз ни кыласыз? Петербургка тәшриф боерырга[7] ниятеңез юкмы? Бу якка килгәнеңез яхшы булыр иде.*

*Бу хат эчендә Ибраһим Алтынсаринга бер хат язып салдым. Белмәймен, хәзер ул кайдадыр. Мәрхәмәт итеп, бу хатны аңар йиткерсәңез, фәкыйрьгә күп миннәт куяр идеңез[8].*

*Бу тарафта һич яңа хәбәр юк. Һәр хосуста сез белгәнчә. Гаялыңызга миндән камале тәуазигъ[9] вә ихтирам илән күп сәлам укылды.*

*Үтенеп язгучы: Хөсәен бине Фәезхан.*

*4 октябрь, 1860 сәнә».*

---

## АҢЛАТМАЛАР

[1] Күп ихлас белдергәннән соң.
[2] Бирелә: түбәнчелекле белдерү.
[3] Вакытлар уздырдым.
[4] Үкенеч ки.
[5] Очрашу насыйп булмады.
[6] Мөхтәрәмә хатыныгызга (гаяль — хатын).
[7] Килергә; рәхим итәргә.
[8] Бурычлы итәр идегез.
[9] Зур түбәнчелек.

## ИКЕНЧЕ ХАТ

*«Газизем Николай Иванович!*

*Бу көннәрдә сез башлык бернична әһле мәгърифәт татар телендә газета бастыралар дип ишеттем. Мондый хәбәрдән, ирексез голамә таифәсене, гомумән, вә шәрык телләре галимләрне, хосусан, котламак кирәк буладыр.*

*Күп вакыттан бирле бу уй минем вә дәхи ничә кешеләрнең күңелебездә уйнай иде. Ликән яки һимматемез азлыктан, вә я мөмкин булмаганыңдан, барлыкка чыга алмаган иде. Ул булса, сезнең һимматеңезгә туктап торган икән. Афәрин әдәмчелегеңезгә вә тәхсин һимматеңезгә!*

*Ликән мин моны бик кыскалык белән, ягъни «мөдәррис Ильминский Казанда татарча газет бастыра», имеш, дип кенә ишеттем. Газетыңызның гонваны калай[1] вә дәстүрел-гамәле ничек[2], гарыз вә максуды ни[3] — моны бу чаккача белмәймен. Ликән татар телендә басылган газет һәрни төрле булса да, гомумән йортымызга вә, хосусан, татар халкымызга күп файдалар китерүендә шик юктыр. Алчаклык итеп, бер-ике юл язып, газетыңызның гонваныны вә дәстүрел-гамәлене, вә хәтта бер-ике басылган нөсхәсене бу тарафка җибәрсәңез, бик олуг мәрхәмәтеңездән сайылып[4], куанычлык белән бер нөсхәсене алырга язылыр идем.*

*Әгәр кабул боерсаңыз, белгәнемчә бу хезмәттә сезгә ярдәмче дә булыр идем. Җенесдәшләремнең хәле вә аннарның күңелләренә ни нәрсәләр әсәр кылуы миңа беләмсез түгел. Шуның өчен бу хосуста киңәш йөзендән бернична сүз язарга үземә рөхсәт бирәмен. Гәрчә сез үзеңез дә күп яхшы беләсез; әммә «бер гакыл яхшы, ике дәхи артыграк»,— диган урыс мәкале мине батыр итәдер.*

*әүвәл башлап, ислам диненә каршы гыйбарәтләр язудан бик сакланырга кирәк.*

*Икенче, Исламбул*[5] *вә Каһирә, вә Таһран газетларындан, кирәк яхшы, кирәк усал, ара-тирә сүзләр язарга кирәк. Аның өчен Исламбул газетының аты безнең илемез арасында бик олыдыр, анларның күңелләренә бик әсәр кыладыр. Вә бу газетлар Петербургта алынып торалар; мәгъкуль күрсәңез, ара-тирә мин дә күчереп, татарча язып йибәрермен.*

*Өченче, безнең халкымызның яза-укый белгәнләре күбрәк муллалар вә сәүдәгәрләр. Муллалар булса, нитәк татар мәсәле таныклык бирәдер: «мә» дигәнне ишетәләр, «бир» дигәнне ишетмәйләр». Алай исә, алардан газет алучы аз булыр. Газет алган сәүдәгәрләр булырлар. Аларга сату-алу хәбәре кирәк. Алай булганда ара-тирә генә түгел, бәлки еш-еш «Биржевые Ведомости»*[6]*дан хәбәрләр язу кирәк.*

*Бәли, бу югарыда әйтелгән матлаблар*[7] *халыкның күңелен газетка бәйләү өчен генә кирәк. Асыл максуд халыкның күңел күзләрен ачып, мәгърифәт сачмак булса кирәк.*

*Монда бер казакъ углы Вәлиханов бар. Аның энесе Казанда гимназиядә, имеш. Энесенә илтифат кылуыңызны утенүдә мине ирекле кылды.*

*Бу тарафта язарга лаек артык яңа хәбәрләр юк.*

*Алчаклык итеп язу язардай булсаңыз, минем адресым болай:*

*Мулле Хусеину Фейз-ханову.*

*На Петербургской стороне, в Съезженской улице, в. Д. Журиной № 4, С. Петербурге*[8]*.*

*Миндә сезнең төркичә «Кәлилә-Димнәңез» бар*[9]*. Бер форсат булганда йибәрермен.*

*Ибраһим Алтынсарин, казакъ баласы, бу заманда кайда каңгырып җөрә икән, белмәйсезме?*

*Газизем Николай Иванович, кыючылык кылып күп сүзләр яздым, әдәпсезлегемне багышлаңыз.*

*Чын күңелдән Сезгә буен сынучы: Хөсәен бине Фәезхан.*

*Гыйнварның тугызынчы көнендә, 1862 санә, Петербургта.*

*Сөекле гаялыңызга күп алчаклык белән сәлам гарыз итәмен».*

---

## АҢЛАТМАЛАР

[1] Исеме ничек.

[2] Юнәлеше ничек.

[3] Теләк һәм максаты нинди.

[4] Мәрхәмәтегездән сawалып.

[5] Истамбул шәһәре XVIII—XIX йөзләрдә төрекләр арасында шул исем белән дә аталган (янәсе «мөселман бул» дигән мәгънәдә).

[6] «Биржевые ведомости» — 1861—1879 елларда Петербургта чыккан, сату-алулар турындагы мәгълүматларга бай буржуаз газета.

[7] Таләпләр.

[8] Адрес шулай русча, шома гына почерк белән язылган.

[9] «Кәлилә-Димнә» — VIII йөздә яшәгән мәшһүр гарәп әдибе Ибне Мөкаффәгъ тарафыннан язылган дөнья күләм популяр әсәрләрнең берсе. Ләкин хатта аталган «төркичәнең» кем һәм кайсы регион тәрҗемәсе булуы хакында ачык мәгълүмат юк. Кайбер хәбәрләргә караганда, «Кәлилә-Димнә»нең урта гасырларга караган татар тәрҗемәсе дә булган.

# ЯШЬ УЛЬЯНОВ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАП

Ленин һәм Татарстан, Ленин һәм татар халкы бер-берләреннән аерылгысыз. В. И. Ленинның яшьлеге, революцион эшчәнлеге, тәпле марксист булып җитлегүе Татарстан белән бәйләнгән. Ул безнең Казан университетында укый, шунда революция юлындагы беренче адымнарын ясый. Татарстан республикасы Ленинның турыдан-туры катнашы белән, аның җитәкчелегендә төзелә. Шуңа күрә галимнәребез даһи юлбашчының тормыш юлын һәм иҗат мирасын, аның эшчәнлегенең Татарстан белән бәйле якларын өйрәнүне элек-электән үзләренең җаваплы һәм мактаулы бурычлары дип исәплиләр. Әле кайчан гына Мәскәүнең «Наука» нәшрияты тарих фәннәре кандидаты М. Сәйдашеваның «В. И. Ленин һәм Татарстанда социалистик төзелеш» дигән кызыклы монографиясен чыгарган иде. Күптән түгел китап кибетләрендә юлбашчыга багышланган тагын бер капиталь хезмәт күренә башлады. Ул — тарих фәннәре докторы, профессор Р. И. Нәфиковның «Революциягә беренче адым»[1] дигән китабы.

Яңа документларга һәм моңарчы билгесез булган архив материалларына таянып язылган бу кызыклы хезмәт В. И. Ленин тормышының һәм эшчәнлегенең Казан чорын өйрәнүгә багышланган. Хезмәттә яшь Ульянов тормышының бу чоры киң иҗтимагый фонда, Казан губернасындагы гомуми революцион хәрәкәт белән тыгыз бәйләнештә карала. Тикшеренүче үзенең төп игътибарын В. И. Ленинны ныклы марксист иткән алшартларны, Россиядәге революцион традицияләрне ачыклауга юнәлтә.

Китап зур-зур өч бүлектән тора. Һәр бүлек В. И. Ленин тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйләнгән берәр этапны тикшерүгә багышланган. Беренче бүлек «60—80 елларда Идел буендагы революцион хәрәкәттә Казан университеты студентларының роле» дип атала. Бу бүлектә революцион традицияләрнең, буыннан-буынга күчә килеп, һаман үсә, көчәя баруын тикшерүгә аеруча зур урын бирелә. XIX гасырның 70—80 елларындагы иҗтимагый-политик көрәшне автор Казан университеты һәм Ульяновлар гаиләсе белән тыгыз бәйләнештә өйрәнә.

Революцион традицияләрнең буыннан-буынга күчә килүен шулай киң итеп алу һәм җентекләп өйрәнү аңа яшь Ульяновның дөньяга карашын формалаштыруда хәлиткеч роль уйнаган тарихи шартларны һәм чыганакларны дөрес билгеләргә ярдәм иткән. Р. И. Нәфиков фикеренчә, Ленинның политик карашларына Н. Г. Чернышевский, Н. А. Добролюбов, Д. И. Писарев кебек революционерларның эшчәнлеге шулай ук көчле йогынты ясый.

1861 елгы реформадан соң Россия капиталистик үсеш юлына аяк баса. Үзәктә һәм провинцияләрдә шактый кызу темплар белән эшчеләр сыйныфы үсә башлый. Шулай патша самодержавиесенә һәм крепостнойлык күренешләренә каршы актив көрәш башлап җибәрү өчен уңай шартлар барлыкка килә. 1879—1881 елларда бөтен ил күләмендә көчәеп киткән эшчеләр хәрәкәте һәм аның беренче мөстәкыйль оешмалары Идел — Урал буендагы революцион хәрәкәтнең үсешен дә яңа баскычка күтәрә. Идел — Урал буендагы революцион традицияләрнең үсеп-көчәеп китүендә Казан университетының роле зур. Чөнки университет элек-электән революцион настроениеле яшьләрне үз тирәсенә туплаган уку йорты

---

[1] Р. И. Нафигов. Первый шаг в революцию. Рус телендә. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.

була. Сәяси карашлары өчен Мәскәү, Петербург, Варшава, Харьков университетларыннан куылган студентлар, кагыйдә буларак, Казан университетына җибәрелгән. Казан революционерларының Россиядә һәм чит илләрдә барган революцион вакыйгалар турында яхшы хәбәрдар булулары, «Рус эшчеләренең төньяк союзы»н, «Пролетариат» дигән поляк оешмасын белүләре, Дмитрий Благоев һәм Павел Точисскийларның марксистик группалары белән элемтә тотулары очраклы хәл түгел, әлбәттә. Алга таба автор үзенең төп игътибарын әнә шул мәсьәләләрне ачыклауга багышлый. Китапның бу бүлегендә шулай ук провинцияләрдәге уку йортларының Петербург һәм Мәскәү студентлары белән бәйләнеше карала, Идел буе һәм Урал эшчеләренең үзара дуслыгы хакында сөйли торган яңа материаллар китерелә. Болар һәммәсе бер максатка — Идел, Урал буендагы революцион вакыйгаларга Ульяновлар гаиләсенең һәм В. И. Ленинның мөнәсәбәтен ачыклауга буйсындырылган. Автор бик дөрес күрсәткәнчә, төрле тентүләр һәм арестлар вакытында революционерлар кулыннан алынган китаплар, документлар һәм кулъязмалар бу мәсьәләне ачыклауда зур әһәмияткә ия. Алар 60—80 еллардагы революцион традицияләрнең буыннан-буынга күчеп килүен расларга һәм бу еллардагы революцион хәрәкәткә Ульяновлар гаиләсенең мөнәсәбәтен тиешле дәрәҗәдә ачып бирергә ярдәм итәләр.

Архив материалларын җентекләп тикшерү, моңарчы басылган документларны, монография һәм истәлекләрне тәнкыйть күзе аша уздыру Р. И. Нәфиковка юлбашчыга багышланган кайбер әсәрләрдә җибәрелгән төгәлсезлекләрне, ялгышларны төзәтергә мөмкинлек биргән. Мәсәлән, Н. Рыжов хезмәтләрендә: «Сембер гимназиясендә Ульяновларның якын иптәшләре һәм дуслары юк иде», дигән фикер уздырылып килә иде. Яңа материалларга таянып, монография авторы моның ялгышлыгын исбат итә. Ул шулай ук Г. Хаит язмаларындагы аерым төгәлсезлекләргә ачыклык кертә.

Монографиянең Ульяновлар гаиләсенең Казанга күчеп килүен сурәтләгән битләре аеруча зур кызыксыну белән укыла, һәм бу аңлашыла да. Абыйсы Александр җәзалап үтерелгәч, Володяга башкаладагы югары уку йортларына керү юллары ябыла. Әнисе Мария Александровнага бу турыда ачык төшендерәләр. Шуннан ул Казан университетына керергә була. Владимир Ульяновның Казан университетында укый башлавы патша хөкүмәтенә каршы юнәлдерелгән иҗтимагый-политик хәрәкәтнең шактый кискенләшкән бер чорына туры килә. Студентлар арасында төрле якташлык оешмалары яшәп килә. Алар тыелган китаплар укыйлар, яшерен библиотекалар тоталар. Университетка кергән беренче көннәрдән үк Володя Ульянов андагы иң зур оешмалардан саналган Сембер — Самара якташлык оешмасының эшенә катнаша башлый, революцион карашлы якташлары белән танышып ала. Тиздән ул шәһәрдәге яшерен революцион түгәрәкнең берсенә йөри башлый. Сүз хөкүмәт тарафыннан «иң зарарлы» дип йөртелгән Мотовилов-Богораз-Скворцов түгәрәге хакында бара. Әлеге түгәрәкләрдә В. И. Ленин һәм аның иптәшләре Белинский, Чернышевский, Добролюбов, Писарев, Щапов әсәрләрен укыйлар. Аларның Карл Маркс әсәрләрен, шул исәптән «Капитал»ны өйрәнүләре билгеле.

Владимир Ульяновның Казан университетындагы эшчәнлегенә багышланган икенче бүлектә юлбашчының беренче революцион чирканчык алуын тасвирлауга зур урын бирелгән. Без Казан университетының актлар залында 1887 елның 4 декабрендә булган мәшһүр сходканы күздә тотабыз.

Р. И. Нәфиков бу вакыйгага кагылышлы материалларны да үзенә генә хас җентеклелек һәм игътибар белән тикшергән. Ул беренче карашка берни дә аңлатмаган кебек тоелган фактларның асылына, эчке мәгънәләренә төшенгән. Документларга тирән анализ ясау аңа сходка алдындагы һәм сходкадан соңгы, бигрәк тә бу вакыйга барган вакыттагы хәлләрне, анда катнашучыларның язмышларын ачык һәм тирән күрсәтергә мөмкинлек биргән. Владимир Ульяновка кагылышлы һәм аның белән тыгыз элемтәдә торган студентлар турындагы материаллар аерым игътибарга лаек. Сходкада катнашкан кешеләрнең сөйләвенә караганда, Владимир Ульянов анда ялкынлы речь белән чыга. Үз чыгышында ул патша хөкүмәтенең ерткычлыгын, суд органнарының гаделсезлеген фаш итә һәм бөтен университетларның студентларын яшәп килгән стройга каршы көрәшкә күтәрелергә өнди.

Тагын шунысы кызыклы, 1887 елның 4 декабрь сходкасында Россиядәге төрле милләт вәкилләре: руслар, белоруслар, украинлылар, грузиннар, еврейләр, немецлар, поляклар катнашкан икән. Алар арасында без литвалы Яков Мартинкусны һәм башкорт егете Мирсаяф Биишевны күрәбез. Бу

принципиаль әһәмияткә ия факт, авторның моңа басым ясавы бик урынлы һәм кирәкле диясе килә. Алдынгы карашлы революцион яшьләр инде ул вакытта ук үзләренең интернациональ бурычларын яхшы аңлаганнар.

Сходка бастырыла, шуннан репрессияләр башлана. Әмма күпчелек студентлар моны да батырларча каршылыйлар һәм революцион хәрәкәттә катнашуларын дәвам итәләр. Сходканың иң актив членнарыннан берсе — 17 яшьлек Владимир Ильич Ульянов өчен дә бу вакыйга зур сабак була. Ул чын революционер юлына баса.

Сходкада катнашучыларны каты хөкем көтә. Бер Казанда гына да 248 студент кулга алына, бик күбесе университеттан куыла. Сходкада катнашучы студентларның авыр язмышы, төрле җәфаларга дучар булулары турындагы битләрне укыгач, ирексездән, татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның 1905 елда язылган «Хөррият хакында» дигән шигыре искә төшә:

. . . . . . . . . . .

Күп яшь егетләр үлде,
Мәетләр дөнья тулды,
Намнары бакый булды
Та кыямәт тидия[1].

Шәкерт-студент бары,
Дарга асылганнары,—
Сез бу арысланнарый
Онытмагыз тидия.

Кызганмады малларын,
Корбан кылды җаннарын,
Җан биргәндә шатланып,
Көлә-көлә үлдия...

Мәҗнүн булсын рухлары,
Изге булсын духлары;
Боларның ах-ухлары
Хөрриятне бирдия[2].

Билгеле булганча, бу сходкадан соң Владимир Ильич Кокушкино авылына сөргенгә җибәрелә. Монда В. И. Ленин марксизм тәгълиматын тирәннән өйрәнү өстендә эшли, шулай ук Казанда калган иптәшләре белән дә революцион элемтәне югалтмый. Китапның бу соңгы бүлегендә Р. И. Нәфиков Владимир Ильич укыган әсәрләргә, журналларга һәм анда басылган мәкаләләргә тирән анализ ясый һәм кызыклы фикерләр әйтә. Озак тормый Ленин яңадан Казанга күчә, Россиядә беренче марксистик түгәрәкләрдән саналган Федосеев түгәрәкләренә йөри башлый. (Сүз уңаеннан әйтеп китәргә кирәк, Р. И. Нәфиков Н. Е. Федосеевның моңа кадәр билгеле булмаган мәкаләсен дә таба. Китапта бу мәкаләгә тулы анализ бирелгән.) Бу бүлектә укучылар марксистик яшьләрнең народникларга каршы көрәше турында сөйли торган кызыклы гына материаллар һәм фикерләр табачаклар. Китапны укыганнан соң ул гаять катлаулы еллардагы Казан-Урал студентларының иҗтимагый-политик тормышы, прогрессив һәм революцион карашлы яшьләрнең фидакарь көрәше һәм шул фонда яшь Ульяновның марксистик көрәш юлына басуы ачык күз алдына килеп баса.

Монографиядә дистәләрчә яңа исемнәр, моңа кадәр билгеле булмаган революцион түгәрәкләр белән танышабыз. Анда китерелгән документлар, фотографияләр һәм Ленинның студент вакыттагы фотопортретлары шулай ук зур кызыксыну тудыра.

Революцион традицияләрнең буыннанбуынга күчә бару закончалыгын ачу һәм моны XIX гасырның 80 еллардагы Казан студентларының революцион хәрәкәте мисалында конкрет күрсәтү, безнең уебызча, теоретик-методологик яктан да зур әһәмияткә ия. Киләчәктә бу мәсьәләне өйрәнү дәвам иттерелсен һәм бөек юлбашчы биографиясенең барлык чорлары да, бигрәк безгә якын булган Идел буе чоры, тагын да тирәнтен, киң фонда өйрәнелсен иде диясе килә. Автор бик дөрес күрсәткәнчә, Казан чорын өйрәнү дә дәвам иттерелергә тиеш. Озын сүзнең кыскасы шул: профессор Р. И. Нәфиков зур җаваплылык, профессиональ осталык һәм тирән белем таләп итә торган бу тарихи проблеманы уңышлы башкарып чыккан. В. И. Ленинның Казан университетында укыган чорын нәкъ менә шушы университет профессоры тикшерүе дә игътибарга лаек.

Монография В. И. Ленин биографиясен махсус өйрәнүче тарихчыларга да, югары һәм урта мәктәп укучыларына да, төрле политик түгәрәкләргә җитәкчелек итүче пропагандистларга да, һичшиксез, зур ярдәм итәчәк. Чөнки бүгенге яшь буынны бөек Ленинның якты тормышы мисалында, аның идеяләре нигезендә тәрбияләү барлык җәмәгатьчелек өчен әһәмиятле бурыч булып тора. Киләчәктә ул татар теленә дә тәрҗемә ителсә, яхшы булыр иде.

Рәмзи ВӘЛИЕВ,
Риф ХӘЙРЕТДИНОВ,
тарих фәннәре кандидатлары.

[1] Исемнәре мәңге калды мәгънәсендә.
[2] Габдулла Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. I том. Таткнигоиздат. 1955. 6—7 битләр.

# БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**С. ШАКИР. Абдулла Алиш. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.**

*Күпме кәгазь язылыр безнең хакта...*
А. Алиш.

Җәлилчеләрнең фашист палачлары тарафыннан вәхшиләрчә җәзалап үтерелүенә чирек гасырдан артык гомер узды. Шул вакыт эчендә әлеге коточкыч җинаять хакында сөйли торган бик күп яңа документлар табылды. Совет патриотларының фаҗигале язмышын, героик көрәш юлын ачыклау эше бүген дә өзлексез дәвам итә. Самат Шакирның күренекле балалар язучысы, татар халкының батыр улы Абдулла Алиш турындагы монографиясен шул юнәлештәге эзләнүләрнең берсе дип бәяләргә мөмкин.

Абдулла Алишның тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге, шулай ук аның фашист тоткынлыгындагы язмышы хакында моңарчы да байтак язылган иде. Монография авторы электән билгеле әйберләр белән генә чикләнмәгән. Ул китапханәләрдә, архивларда казынган, язучының туганнары, каләмдәш дуслары һәм замандашлары белән очрашып сөйләшкән, Алишны якыннан белгән кешеләрнең истәлекләрен җыйган. Шулай тырыша торгач, күренекле язучының тормыш һәм иҗат юлын ачыкларга ярдәм итәрдәй байтак яңа материал туплаган. Үзе тапкан һәм электән билгеле әйберләргә таянып, Җәлилнең якын дусты, көрәштәше турында кызыклы гына хезмәт язган.

Монография бәләкәй-бәләкәй аерым бүлекчәләрдән тора. Һәр бүлекчә Алиш тормышының берәр этабына яки аның иҗат эшчәнлеге белән бәйле теге яки бу мәсьәләне ачыклауга багышланган. Баштагы ике бүлекчә булачак язучының балалык һәм яшьлек еллары турында. Аларның «Балалык еллары» дип исемләнгән беренчесе аеруча уңай тәэсир калдыра. Автор Алишның әтисе Габделбарый абзыйның, әнисе Газизә апаның истә калырлык, мөлаем образларын күз алдына бастыра алган, Көек авылы тирәсендәге табигать күренешләрен оста тасвирларлык матур буяулар тапкан.

1927 елның көзендә Абдулла Алиш башкалабыз Казанга килә һәм бирәдәге Җир төзү техникумында укый башлый. Аның әдәбият-сәнгать дөньясында чын-чынлап кайный башлавы да нәкъ шул елларга туры килә. Казанга килүгә, ул Татар мәдәният йортында, университетта һәм башка уку йортларында уздырыла торган төрле әдәби кичәләргә, җыелышларга йөрергә тотына. Язучылар белән таныша, редакция эшчеләре белән аралаша, әдәби түгәрәкләргә йөри. Республика газета-журналларында Абдулла Алишның беренче мәкалә һәм очерклары, хикәяләре басылып чыга. Монографиянең «Таш калада — Казанда. Күңел җимешләре», «Якты күл буе», «Абдулла Алиш — әкиятләр остасы», «Киң колач белән» дигән бүлекчәләрендә патриот әдипнең Казанга күчеп килгәннән соңгы тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турында сөйләнә.

Киң катлау укучылар массасы Абдулла Алишны күбрәк балалар язучысы, бигрәк тә матур-матур әкиятләр остасы дип кенә белә иде. Хәлбуки, ул балалар өчен дә, зурлар өчен дә бер дәрәҗәдә иҗат итүче күпкырлы талант иясе булган икән. Алиш иҗатының укучыларга электән яхшы таныш якларына тукталу белән бергә, Самат Шакир үзенең төп игътибарын аның эшчәнлегенең моңарчы без белмәгән тармакларына юнәлтә. Ул, мәсәлән, бер дә иренмичә һәм озаклап, «Якты күл буе» повестена анализ ясый, зурлар өчен язылган хикәяләренә, очерк һәм тәнкыйть мәкаләләренә тукталa.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, соңгы елларда Абдулла Алишның һәм башка җәлилчеләрнең немец тоткынлыгындагы тормышы, көрәше турында шактый күп язылды. Самат Шакир үзенә кадәр язылганнарга әллә ни яңалык өстәми диярлек. Шулай да кайбер мәсьәләләргә күпмедер ачыклык кертә, электән мәгълүм нәрсәләрне тагын да тулыландыра төшә.

Патриот язучыбызның бай мирасына зур ихтирам, героик тормышына тирән мәхәббәт белән язылган бу монографияне укучылар яратып каршылар дип ышанырга мөмкин.

**Оҗмах сезгә, дөнья безгә. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.**

«Оҗмах сезгә, дөнья безгә» — Китап нәшрияты чыгарган яңа китапларның берсе әнә шулай атала. Халык арасында динга каршы пропаганда алып баручы агитаторларга һәм лекторларга кулланма төсендә чыгарылган бу китапка татар язучыларының атеистик мотивлар белән сугарылган әдәби әсәрләре: шигырь һәм фельетоннары, хикәя һәм новеллалары, эре күләмле проза әсәрләреннән аерым өзекләр тупланган.

Җыентык безнең арадан бик иртә киткән яшь галим, журналист Шәүкәт Сәйфетдиновның «Татар әдәбиятында атеистик фи-

керләр» исемле мәкаләсе белән ачыла. Аерым ачыкланып бетмәгән тезислары һәм тартып-сузыбрак китерелгән урыннары булуга да карамастан, мәкалә тулаем уңай тәэсир калдыра. Үзе күтәргән мәсьәләне автор күп көч куеп, игътибар белән, иренмичә өйрәнгән. Мәкаләдә татар язучыларының әсәрләрендәге дингә каршы мотивларга шактый киң һәм тулы күзәтү ясалган. Революциягә кадәрге язучылар иҗатына һәм 20—30 елларда басылып чыккан әсәрләрне тикшерүгә аеруча зур игътибар бирелгән. Тагын кереш мәкаләнең һәркемгә аңлаешлы гади, җиңел тел белән язылуын билгеләп үтәсе килә.

Мәкалә авторы бик дөрес күрсәткәнчә, ислам дине хезмәтчел татар халкының аңын һәм күңелен бервакытта да тулысынча яулап ала алмаган. Халыкның алдынгы вәкилләре дини ышануларның зарарлы, начар якларын, ә мулла һәм ишаннарның өрәм тамак, соры кортлар икәнлеген яхшы аңлаганнар. Хезмәт халкының дингә, аллага, руханиларга карата булган тискәре мөнәсәбәте аның поэтик иҗатында киң чагылыш тапкан. Безнең матур әдәбиятыбыз да элек-электән үзенең дөньяви характеры, дингә каршы мотивларының көчле булуы белән аерылып торган. Татар халкының күренекле сүз осталары күп кенә әсәрләрен дингә каршы, дини хорафатларга каршы көрәш мәсьәләләренә багышлаганнар. Алдынгы карашлы күп кенә язучыларыбыз дингә каршы көрәшне хезмәт ияләрен социаль яктан азат итү белән бәйләгәннәр, үз әсәрләрендә ислам дине пәрдәсе белән капланган экономик, политик һәм мораль изү күренешләренең тупас табигатен фаш иткәннәр, өстен катлауларның динне капитал туплау һәм халыкны талау коралы итүләрен ачып салганнар. Алар ислам диненең, татар руханиларының самодержавие белән берлектә хәрәкәт итүче көч икәнлеген, ягъни политик реакция белән дини реакциянең бергә кушылуын күрсәтеп биргәннәр. Китапның беренче өлеше революциягә кадәр яшәгән демократик карашлы язучыларыбызның әнә шундый әсәрләреннән төзелгән. Анда без Габдулла Тукайның «Мактанышу», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?», «Ысулы кадимче», «Муллалар», «Ишан», Мәхмүдә Мозаффариянең «Остазбикә абыстайларга», «Ханымнар», Галиәсгар Камалның «Милләтчеләр, динчеләр», «Капитал иярченнәренә», Мәҗит Гафуриның «Татар хатыны», «Юктырсың ла, алла», «Һәр фәнгә маһир мулла» кебек шигырьләре, К. Насыйри, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Ш. Усмановларның проза әсәрләре белән очрашабыз.

Татар совет әдәбияты хезмәт ияләре аңында дөньяга фәнни караш булдыру, яңа кеше тәрбияләү юлында тагын да активрак эш күрсәтә. Совет властеның беренче елларында, шулай ук социалистик төзелеш чорында татар язучылары үз әсәрләрендә бөтен искелекне һәм дини гореф-гадәтләрне камчылыйлар. Әдипләребез, диннең асылын, аның бөтен прогрессив нәрсәләргә каршы юнәлдерелгән булуын, милләтләр арасында дошманлык таратуын һәм шул ук вакытта аның заманга яраклашырга маташуын фаш итү белән бергә, үткән заман хорафатларыннан арынган алдынгы карашлы кешеләрнең — яңа тормыш төзүчеләрнең образларын иҗат итәләр. Һади Такташ, Муса Җәлил һәм Әхмәт Исхак шигырьләре, Галимҗан Ибраһимов, Мөхәммәт Гали, Мәхмүд Максуд, Гариф Гобәй һәм Газиз Мөхәммәтшиннарның җыентыкка кергән әсәрләре әнә шул турыда сөйли.

Сүз дә юк, шундый бер җыентыкны дөньяга чыгарып, нәшрият кирәкле һәм файдалы эш эшләгән. Динне, аның төрле уйдырмаларын, буйсынучанлык һәм коллык моралең фаш итүдә бу китап мөһим роль уйнаячак.

**Г. АХУНОВ. Әдәби язмышлар. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.**

Бүгенге укучылар Гариф Ахуновны күбрәк татар әдәбиятын «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» кебек романнар белән баеткан, повестьлар һәм күп санлы очерк һәм хикәяләр язган прозаик буларак беләләр. Хәлбуки, әдәбият мәйданындагы тәүге адымнарын ул тәнкыйть мәкаләләре язып атлый, үзенең әдәби иҗат эшчәнлеген нигездә тәнкыйтьче сыйфатында башлап җибәрә. Беренче рецензия һәм мәкаләләренә карап, күпләр аны әдәби тәнкыйть юлыннан китәр дип уйлыйлар. Ә ул хикәяләр, повестьлар язуга күчә һәм, еллар узу белән, хәзер без белгән прозаикка әйләнә. Әмма шул ук вакытта, үзенең тәнкыйть эшчәнлеген дә ташлап бетерми: каләмдәш дусларының яңа әсәрләренә рецензияләр языштыра, газета-журнал битләрендә бүгенге әдәбиятның актуаль мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре белән катнашып килә. «Әдәби язмышлар» китабына Гариф Ахуновның әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеген характерлый торган мәкаләләре тупланган.

Үзләренең характерларына һәм жанрларына, матур әдәбиятның кайсы тармагына багышлануларына карап, мәкаләләр кечерәк-кечерәк өч бүлеккә урнаштырылган. Беренче бүлек «Иҗат портретларына тәҗрибә» дип атала. Исеменнән үк күренгәнчә, бу бүлеккә Г. Ахуновның күренекле татар язучылары турындагы портретлары кергән. Барлыгы дүрт портрет, татар совет әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән дүрт язучының (Гомәр Гали, Шәйхи Маннур, Гомәр Бәширов һәм Ибраһим Гази) иҗат йөзен ачыклау нияте белән язылган дүрт зур мәкалә. Портретларның Гомәр Гали белән Гомәр Бәширов иҗатына караган икесе бигрәк тә аерылып тора. Әгәр беренчесе үзенең конкретлыгы, җыйнак һәм бөтен булуы белән игътибарны тартса, Г. Бәшировка багышланганы художник каләме белән язылган җылы, эмоциональ әсәр буларак әсир итә.

«Сәхнәдә утлар кабына» дип исемләнгән икенче бүлеккә авторның театр сәнгате турындагы аерым мәкаләләре, төрле спектакльләргә язган рецензияләре тупланган. Андагы мәкалә һәм рецензияләрдән Г. Ахуновның бу өлкәдә дә шактый тәҗрибә туплаган сәнгать белгече, усал телле

тәнкыйтьче булуы күренә. «Күзгә ачы җилләрдә», «Комедия кайчан туа?», «Кем драмасы бу?» кебек мәкаләләр шул фикерне куәтли.

Соңгы бүлек авторның төрле елларда төрле китапларга язган рецензияләреннән тора. Гариф Ахунов — вакытлы матбугат битләрендә бик күп рецензияләр бастырган кеше. Берегә шуларның заман сынавын уңышлы үткәннәрен, үзе әйбәтрәк дип санаганнарын керткән. Шәүкәт Галиевнең «Әнкәйгә хат» поэмасына багышланган «Җуелмас яралар», Сибгат Хәкимнең тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы чыгу уңае белән язылган «Сулыш кебек табигый» исемле рецензияләр, шулай ук «Хәсрәт дәрьясы»ның татарчасы һәм тәрҗемә практикабыз турында» дигән мәкалә барыннан да уңайрак тәэсир калдыра.

Гариф Ахунов — әдәби иҗат эшенең нечкәлекләрен тирәнтен сиземли һәм тоя белә торган сәнгать белгече, әдәби хәрәкәтнең өлгергән мәсьәләләрен үз вакытында күтәрә-кузгата барырга сәләтле җитди тәнкыйтьче икән. «Әдәби язмышлар» белән баштан ахырга кадәр танышып чыккач, тагын бер мәртәбә әнә шуңа ышанасың.

**М. РАФИКОВ. Сиңа ничә яшь!**
**Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.**

«Сиңа ничә яшь?» — Мәҗит Рафиковның икенче китабы. Аңа язучының соңгы елларда иҗат иткән хикәяләре, этюд һәм парчалары урнаштырылган. Әдәби эшләнешләре, жанр һәм характерлары белән никадәр генә чуар күренмәсеннәр, ул әсәрләрне бер-берсенә якынайткан, үзара охшаш иткән уртак сыйфатлар бар. Укучылар игътибарын күбрәк җыентыктагы әсәрләрнең әнә шул якларына юнәлтәсе килә.

М. Рафиковның барлык әсәрләре диярлек романтик алымнар белән язылган. Ул купшы, матур сүзләр кулланырга, ачык төсләр, куе буяулар белән эш итәргә ярата. Аның хикәяләренең төп герое, хәер, аны лирик герой дип атарга да булыр иде, артык нечкә күңелле, хискә бирелүчән кеше. Ул гүзәллеккә, табигатькә гашыйк, тормышка да күбрәк «гашыйклар күзе» белән карый. Тоннары, яңгырашлары белән китаптагы хикәяләр нәсерләргә яки шигъри әсәрләргә тартым. Бу — аларның көчле ягы. Әмма шуның ук куркыныч ягы да бар. Чама хисен аз гына югалттыңмы, әсәрең тәче бер язмага әйләнеп калачак, ышандырмый башлаячак. Шундыйрак нәрсә, урыны-урыны белән, М. Рафиков хикәяләрендә дә сизелеп кала. Бәхеткә каршы, андый урыннар күп түгел. Лирик геройның самимилеге, ихлас күңелдән януы тора-бара укучыга да күчә. Һәм ул, үзе дә сизмәстән, әсәрдәге тормыш стихиясенә кереп китә...

Җыентык «Биш пуля» исемле хикәя белән ачыла. Язылышы һәм характеры белән халык авыз иҗатындагы сөйләкләрне бераз хәтерләткән бу хикәядә Бөек Ватан сугышы елларында булып узган вакыйгалар хакында сөйләнә.

1943 елның август башлары. Яңа гына училище тәмамлаган егетләрне төяп, фронтка бер хәрби эшелон китеп бара. Хикәя безне әнә шул эшелондагы аерым кешеләр, аларның үзара мөнәсәбәте һәм алар кичергән хис-тойгылар белән таныштыра. Әсәрдә тагын кешене канатландыра һәм батыр эшләргә рухландыра торган җыр бар. Шул җыр образы хикәянең аерым геройларын һәм төрле кисәкләрен бер үзәккә җыйный, аңа бөтенлек хисе бирә. «Биш пуля» исемле әлеге җыр бөтен хикәягә ниндидер яктылык һәм романтик ашкыну өсти, аңа җылылык, тормыш сулышы кертә.

«Биш пуля»да кузгатылган мәсьәләләр «Илһам авазы» исемле икенче бер әсәрдә тагын да көчәйтелә һәм үстерелә төшә сыман. Сүз җыр-музыка сәнгатенең тормыштагы урыны, көче һәм кадере турында бара.

Кайдадыр Урал таулары итәгендә Өчтирәк исемле бер татар авылы бар. Шунда гомер буе дус булырга ант итешкән ике малай үсә. Икесе дә музыкага гашыйк, икесе дә оста гармунчы булырга хыяллана. Шул олы хыяллары тормышка ашып, егет булып килгәндә генә сугыш башлана. Әлеге егетләр дә фронтка китә. Берсе, яраланып, сыңар кул белән кайта. Галимҗан исемле икенчесе, сабан туйларында ярышып, барлык гармунчыларны җиңеп йөргәне, үлеп үк кала. Өчтирәк ике гармунчысыз кала, кешелек бөреләнеп кенә килгән ике талантын югалта. Бер сүз белән, бик гомумиләштереп әйткәндә, сугыш уты кабызучыларга карата тирән нәфрәт хисләре белән сугарылган бу хикәя әнә шул турыда.

Мәҗит Рафиков бөтен хикәяләрен диярлек беренче заттан, «лирик мин» исеменнән яза. Ул шулай ук төрле географик атамаларны: шәһәр, район, авыл, елга, күл исемнәрен үзгәртмичә — тормыштагыча ала. Бу — хикәяләрнең тормышчанлык көчен арттыра, аның әсәрләренә «чынлык» иллюзиясе бирә. Аның хикәяләренең тагын бер көчле ягы әнә шунда булса кирәк. Ләкин тормышта булган нәрсәләрне генә сурәтлим, тормыштагыча язам, дип артык тырыша торгач, автор икенче читкә дә ташлангалый кебек. Аерым әсәрләрендә тормыш материалы авторны үз стихиясенә буйсындыра. Нәтиҗәдә ул тормыш вакыйгаларының колы булып кала, чәчелә, тарала башлый. Шул хакта сөйли торган характерлы мисалларның берсе төсендә «Ишгилде» дигән әсәргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Ишгилде — Башкортстанның көньяк төбәгендәге авыл исеме. Әсәрдә шул авылның үткәне һәм бүгенгесе, аның кызык һәм олы язмышлы кешеләре турында сөйләнә. Хикәянең Ишгилде тирәсендәге табигать күренешләрен сурәтләүгә, авылның тарихына, кешеләренә, ул кешеләрнең тормышына багышланган баштагы өлешләре җылы һәм матур тәэсир калдыра. Әмма ахырга таба, бигрәк тә бүгенге Ишгилде хакындагы урыннарга җиткәч, әсәр шактый сүрелә һәм таркаулана, гади очеркка әйләнеп кала

яза. Ә болай ул «Биш пуля», «Илһам авазы» кебек хикәяләр рухында язылган әйбәт кенә әсәр...

«Синә ничә яшь?» җыентыгы Мәҗит Рафиковның әдәби иҗат эшенә җитди караучы, үзенчәлекле прозаик булуы турында сөйли. Аның инде үз темасы, үзенә генә хас алымнары төсмерләнеп килә. Безнең аңардан тагын да җитдирәк, тагын да камилрәк әсәрләр көтәргә тулы хакыбыз бар.

**Башкорт хикәяләре.**
**Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел.**

Татарстан китап нәшрияты илебез халыкларының рухи казанышларын пропагандалау, аерым милли телләрдә чыккан әдәби әсәрләр белән татар укучыларын даими төстә таныштырып бару эшенә зур игътибар бирә. Билгеле булганча, 1967 елдан башлап татар телендә «Дуслык букеты» дигән махсус серия чыга башлаган иде. Аннан бирле узган 4—5 ел вакыт эчендә тугандаш республикалар шигъриятенең иң яхшы үрнәкләрен туплаган унлап җыентык дөнья күрде. Татар укучылары прогрессив карашлы чит ил язучыларының яңа романнары, повесть һәм хикәяләре белән дә әледән-әле очрашып торалар. Иң куанычлысы шул: бу матур башлангыч елдан-ел көчәя, киңрәк колач ала бара. Күптән түгел нәшриятның шушы юнәлештәге тагын бер эше белән танышу насыйп булды — кибетләрдә «Башкорт хикәяләре» дигән яңа китап сатыла башлады.

Җыентык Башкортстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Вазих Исхаков тарафыннан язылган кереш мәкалә белән ачыла. Мәкалә авторы ярты гасырдан артык вакыт эчендә башкорт прозасы узган юлга кыскача күзәтү ясый, безне бүгенге башкорт хикәясенең торышы, характерлы үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре белән таныштыра. Китапка утызлап прозаикның нигездә соңгы ун-унбиш ел эчендә иҗат иткән хикәяләре, нәсер һәм юморескалары тупланган. Авторлар арасында төрле буын хикәячеләр бар. Аларның байтагын (С. Агиш, Ә. Вәли, З. Биишева, Ә. Бикчәнтәев, К. Мәргән, Н. Нәҗми, И. Абдуллин, Ф. Исәнголов, В. Исхаков һ. б.) татар укучылары электән белә, ә кайберләре белән беренче тапкыр шушы җыентыкта очраша. Авторлар коллективы шактый төрле һәм зур булган кебек, китапка тупланган хикәяләрнең характерлары, сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре һәм тема-проблемалары да гаять төрле-төрле. Башкорт халкының революцион көрәш юлын яктырткан әсәрләрне бүгенге көн мәсьәләләренә, бүгенге кешеләр тормышына багышланган хикәяләр алмаштыра, җитди, кырыс тонда язылган хикәяләр җылы, лирик парчалар белән, күңел көрлегә бөркәлеп торган юморескалар усал сатира белән чиратлаша. Монда ил, халык язмышы турында уйланулар да, башкорт халкының гореф-гадәтләре, чал Урал, сокландыргыч табигать күренешләре — һәммәсе дә бар. Кыскасы, төзүче алдына куйган максатына тулысынча ирешкән: җыентык башкорт прозасының үз табигатен, характерлы үзенчәлекләрен чагылдырырдай әсәрләрдән тора.

Хикәяләре белән бергә, һәр авторның фоторәсеме урнаштырылган, аның тормыш һәм иҗат юлы турында кыскача белешмә бирелгән. Җыентыкның тагын бер күркәм сыйфаты әнә шунда.

«Башкорт хикәяләре» белән танышкач, безнең тугандаш башкорт халкына, аның яхшы традицияләренә һәм гореф-гадәтләренә, яңа тормышта формалашкан интернациональ сыйфатларына карата булган ихтирам хисләребез бермә-бер куәтләнеп, көчәеп китә.

...Иң ахырдан кечкенә генә бер «ләкин». Китапта: «хикәяләр башкортчадан тәрҗемә ителде», дигән искәрмә бар. Димәк, кемнәрдер аларны татар теленә тәрҗемә иткән. Әмма, ни сәбәптәндер, тәрҗемәчеләрнең исем-фамилияләре күрсәтелмәгән. Бу исә, үз чиратында, тәрҗемәләрнең сыйфаты хакында адреслы сөйләшүне кыенлаштыра. Күрәсең, алга таба мондый практикадан баш тартырга, тәрҗемәчеләрнең исем-фамилияләрен конкрет күрсәтеп баруны гамәлгә кертергә кирәктер.

# М. МОЗАФФАРОВ

*(1901—1967)*

**Шушы елның 18 мартында Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның халык артисты, композитор Мансур Мозаффаровның тууына 70 ел тулды. Татар совет музыка сәнгатенең туу, үсү һәм чәчәк ату тарихы аның исеме белән тыгыз бәйләнгән.**

**Сәнгать өлкәсендәге тәүге адымнарын Мансур ага Мозаффаров Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк атлый. 1915 елда ул «Сәйяр» труппасына килә, труппа каршындагы ансамбльдә музыкант булып эшли башлый. Революция булып, халык арасыннан чыккан яшьләргә үсү өчен киң мөмкинлекләр ачылу белән, ул белемен күтәрергә тотына. 1919 елның көзендә М. Мозаффаров Казан музыка училищесына укырга керә. 1923 елда, кларнет классы буенча училищены уңышлы тәмамлап, Мәскәү консерваториясенең композиторлык факультеты каршындагы этнография бүлегендә укый башлый. Биредә ул А. Н. Александров, С. В. Василенко кебек атаклы профессорлардан дәресләр ала.**

**Мансур Мозаффаров татар халкының мәдәният эшләренә бик иртә — утызынчы елларның башыннан ук актив катнашып китә. Консерватория тәмамлауга, ул Мәскәүдәге татар театрының музыка җитәкчесе булып эшли. Аннан Казанга кайта һәм байтак еллар Татарстан радиосындагы музыкаль тапшыруларны алып бара. 1945 елда Мансур ага Мозаффаров укытучылык эшенә күчә. Аның шуннан соңгы гомере Казан дәүләт консерваториясе белән бәйләнгән. Биредә ул музыка теориясенә караган фәннәр буенча дәресләр алып бара, консерваториянең теория һәм композиция кафедрасына җитәкчелек итә.**

**Кырык елдан артыкка сузылган иҗат гомерендә Мансур ага Мозаффаров гаять бай мәдәни мирас калдыра. Атаклы композиторыбыз С. Сәйдәшев кебек үк, ул да яңа эчтәлекле татар совет җырларын башлап иҗат итүчеләрнең берсе исәпләнә. М. Мозаффаров иҗат иткән «Колхозчылар җыры», «Ударниклар маршы», «Сайра, сандугач» (М. Садри сүзләре), «Җиләк җыйганда» (М. Җәлил сүзләре), «Яшь егетләр, яшь кызлар» (Ә. Ерикәй сүзләре), «Син кайтмадың» (С. Урайский сүзләре), «Тик булса иде ирек» (М. Җәлил сүзләре), «Менәргә иде Урал тауларына» (Г. Зәйнашева сүзләре) кебек җырлар музыка сәнгатебезнең алтын фондына керде. Татар совет музыка сәнгате тарихындагы иң беренче һәм иң уңышлы романсларның берсен шулай ук ул иҗат итә. Сүз А. С. Пушкин сүзләренә язылган «Җырлама син миңа...» исемле романс хакында бара.**

**Мансур Мозаффаров опера сәнгатен үстерүгә дә билгеле бер өлеш керткән композиторларыбыздан. Аның «Зөлхәбирә» һәм «Галиябану» исемле ике операсы бар. Шулардан үзенең идея-тематик актуальлеге, сәнгатьчә эшләнеше белән «Галиябану» аеруча зур игътибарга лаек.**

**Композиторның иҗат диапазонын тулырак күзаллау өчен аның симфонияләренә һәм инструменталь әсәрләренә дә тукталып узарга кирәктер. Симфоник музыка өлкәсендәге эшчәнлеген композитор утызынчы елларда ук башлап җибәрә. Үзенә зур уңыш һәм мактау китергән Беренче симфониясен М. Мозаффаров 1944 елда тәмамлый. 50 елларда ул Тукай һәм Мулланур Вахитов истәлегенә багышланган зур симфоник поэмалар, скрипка һәм оркестр өчен ике концерт иҗат итә.**

**Партиябез һәм хөкүмәтебез Мансур ага Мозаффаровның иҗат эшчәнлегенә югары бәя бирде. Татар совет музыка сәнгатен үстерү өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен, ул «Хезмәт Кызыл Байрагы», «Почет билгесе» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнде.**

# ИБРАҺИМ ГАЗИ



Совет әдәбияты зур югалтуга дучар булды — талантлы татар язучысы, күренекле җәмәгать эшлеклесе — Татарстан язучылар союзы правлениесе председателе, РСФСР язучылар союзы правлениесе секретаре, СССР Верховный Советы депутаты, КПССның Татарстан өлкә комитеты члены, Тукай премиясе лауреаты Ибраһим Зариф улы Мингазиев (Ибраһим Гази) вафат булды.

И. Гази бөтен аңлы тормышын халыкка, Совет Ватанына, үзе 1927 елдан бирле член булып торган Коммунистлар партиясенә турылыклы хезмәт итүгә бирде. Ул үзенең зур талант көчен коммунизмның бөек идеаллары өчен көрәшкә багышлады. Саф намуслы һәм большевикларча принципиаль кеше буларак, И. Гази үз иҗатына татар совет әдәбиятының барлык үсеш этапларында социалистик реализм һәм пролетар интернационализм байрагын югары тотты.

Ибраһим Гази 1907 елның 5 февралендә Татарстанның хәзерге Кама Тамагы районы Иске Карамалы авылында ярлы крестьян семьясында туа. Бик яшьли ятим калып, ул кулакларда батрак булып эшли һәм бала вакытларыннан ук тормышның ачысын-төчесен кичерә. Совет власте аңа киң юл һәм якты тормыш ачты. Балалар йортында тәрбияләнеп, ул урта мәктәпне тәмамлады, аннары өлкә Совет-партия мәктәбендә укыды, аннан соң комсомолның кантон комитетына җитәкчелек итте. 1929—1931 елларда И. Гази ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында, «Кызыл яшьләр» газетасы һәм «Колхоз яшьләре» журналы редакторы булып эшли. Шушы елларда ук үзенең «Кичке алтыда», «Бригадир кыз», «Көмеш сулы Нурминка» кебек беренче әсәрләрен бастырып чыгара. Пролетар язучыларның татар ассоциациясенә член булып кергәннән соң аның почетлы органында — «Атака» журналы редакциясенең секретаре, соңрак Татарстан китап нәшриятының редакторы булып эшли. Язучыларның беренче Бөтенсоюз съездында делегат була. 30 еллар ахырында совет кешеләренең героик хезмәтен чагылдырган «Җилбәзәк Ярулла», «Ике дус», «Катя Сорокина» хикәяләрен иҗат итә.

Бөек Ватан сугышы елларында язучы фронтта була, армия газеталарында әдәби сотрудник булып эшли.

Соңгы елларда И. Гази бик яхшы әсәрләрен — «Алар өчәү иде», «Без әле очрашырбыз», «Алмагачлар чәчәк ата» повестьларын, Татарстан нефтьчеләре турындагы «Гади кешеләр» исемле беренче романын язды.

Язучының «Онытылмас еллар» трилогиясе бигрәк тә зур популярлык казанды, бу әсәре өчен автор Габдулла Тукай исемендәге республика премиясе белән бүләкләнде. Бу трилогия — авыр сыйнфый көрәш һәм җимереклек шартларында татар авылында Совет властен урнаштыру, гражданнар сугышы һәм тышкы хәрби интервенция елларында киләчәк буыннар өчен бәхет яулаган кешеләр турында гүзәл әсәр. Талантлы сүз остасының тирән партияле, чын художестволы китаплары халыкның һәм совет әдәбиятының мәңгелек байлыгы булып калды.

И. Гази матбугатта татар совет прозасының актуаль мәсьәләләре турында еш кына мәкаләләр белән чыкты, нәшриятта, «Казан утлары» һәм «Азат хатын» журналларында зур редакцион эш алып барды, яшь язучыларны тәрбияләүдә даими кайгыртучанлык күрсәтте, аларның әдәби уңышларына чын күңеленнән шатланды.

И. Гази рус һәм прогрессив чит ил классиклары әсәрләрен пропагандалау өлкәсендә дә күп эшләде. Ул А. Чехов, М. Горький, М. Салтыков-Щедрин, Г. Мопассан, Э. Золя әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте язучының эшенә лаеклы бәя бирделәр: ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, ике «Почет билгесе» ордены һәм медальләр белән бүләкләнде.

Ибраһим Гази зур җәмәгать-политик эш алып барды: күп мәртәбәләр Татарстан язучылар союзының партия бюросы һәм правлениесе члены итеп сайланды, 1968 елдан башлап язучылар оешмасын җитәкләде, РСФСР язучылар союзы правлениесе секретаре булды. 1970 елда ул Бөгелмә сайлау округы буенча СССР Верховный Советы депутаты булып сайланды. Партиянең XXXIV өлкә конференциясендә И. Гази КПССның өлкә комитеты члены һәм партиянең XXIV съездына делегат итеп сайланган иде.

Ибраһим Гази социалистик Ватаныбызның чын патриоты, язучы-коммунист, тынгысыз олы йөрәкле, якты һәм үзенчәлекле талантлы, гаҗәеп тыйнак, башкаларга тирән хөрмәт белән караучы кеше иде. Аны белгән кешеләр күңелендә ул мәңгегә әнә шундый булып саклаяыр.

**Ф. А. Табеев, С. Г. Батыев, Г. И. Усманов, Ф. И. Панин, С. Л. Князев, М. Ф. Вәлиев, М. Т. Троицкий, Б. П. Мартынов, Ә. Ә. Мильмөхәметов, Р. М. Мусин, М. М. Репеев, А. Х. Бичурин, В. С. Сластников, С. З. Япеев, Р. Ю. Ярмөхәметова, М. М. Мусин, Н. А. Андрианов, М. Х. Хәсәнов, Б. М. Гыйззәтуллин, Ш. Х. Хамматов, А. И. Клименков, Ф. Г. Надыйров, А. И. Бондаренко, А. Г. Кадыйрова, А. В. Сафьянов, И. Х. Хәбибуллина, Г. С. Әпсәләмов, М. М. Әмир, Г. А. Ахунов, Г. Б. Баширов, Ю. В. Белостоцкий, Н. Г. Җиһанов, Р. Ф. Ишморатов, Г. С. Кашшаф, З. Ш. Нури, Х. Ф. Туфан, Р. Г. Фәйзуллин, С. Т. Хәким, Ф. Х. Хөсни, А. Ш. Шамов, Х. Г. Якупов.**

## Гәрәй Рәхим

### Моңлы бер җыр

*«Йөрәктән чыккан гына йөрәккә керә.»*
*Шагыйрьләр әйтеме.*

Әгәр йөрәктән чыкканнар
Йөрәккә керә барса;
Әгәр йөрәккә кергәннәр
Кәгазьгә иңә барса;
Әгәр кәгазьгә иңгәнне
Укучы теләп алса —
  Күңелләр җырлап тора,
  Дөньялар зырлап тора.

Әгәр йөрәктән чыкканнар
Йөрәккә керә барса;
Һәм шул йөрәккә кергәннәр
Кәгазьгә иңә барса;
Ләкин кәгазьгә иңгәнне
Укучы сүгә барса —
  Күңелләр җылап тора,
  Дөньялар зың-ң-ңлап тына...

## Гайса Гатауллин

### Ышандыр

*Пародия*

«Юашмындыр, бәлки, кирәкмәскә,
Кирәкмәскә, бәлки, усалдыр.
Тик холкымның әйбәт булуына
Син ышандыр мине, ышандыр».
*Ш. Маннапов.*

Күпме кешеләр бар — исемнәре
Әхмәт, Зәйнәп, бәлки Хисамдыр...
Ләкин минем Шамил булуыма
Син ышандыр мине, ышандыр.

Кыска гына җырларымда, бәлки,
Фикер яклары да кысандыр.
Ләкин минем шагыйрь булуыма
Син ышандыр мине, ышандыр.

### МӘСКӘҮДӘ СӨЙЛӘШҮЛӘР

— Илебез әдәбиятларында театр, кино, радио һәм телевидение драматургиясенең хәзерге торышы ничек һәм аны тагын ничек яхшырта төшәргә?.. Балалар әдәбиятының төп герое — хезмәт кешесе булырга тиеш!.. Совет поэзиясендә гражданлык проблемасын ничек аңларга һәм ул хәзерге әдәбиятларда ничек чагыла?..

Шушындый гаять мөһим һәм актуаль өч темага Мәскәүдә СССР һәм РСФСР язучылары союзы үткәргән ике пленум һәм бер киңәшмәдә конкрет, житди, теоретик һәм практик планда сөйләшү булды. Анда Татарстан язучылары оешмасыннан РСФСР язучылар союзының идарә членнары И. Гази, З. Нури, Г. Ахунов, ревкомиссия члены Р. Фәйзуллин катнаштылар. Поэзиядә гражданлык һәм интернационализм хисләре чагылышын, яшьләрнең яңа эзләнүләрен һәм аларны үстерү проблемаларын ачыклап, Р. Фәйзуллин хәзерге татар әдәбиятыннан фактлар һәм үрнәкләр җирлегендә эчтәлекле чыгыш ясады.

### «ОКТЯБРЬ» ЖУРНАЛЫ КИҢӘШМӘЛӘРЕ

Мәскәүдә «Октябрь» журналы «Совет әдәбиятының милли һәм интернациональ яклары» дигән темага зур киңәшмә үткәрде.

Филология фәннәре докторы Г. Ломидзе доклады буенча фикер алышуда утызлап тәнкыйтьче һәм әдип катнашты.

Мәскәү тәнкыйтьчеләре белән бергә киңәшмәгә РСФСРның төрле өлкәләреннән һәм автономияле республикалардан да язучылар килгән иде.

Татарстаннан киңәшмәдә язучы Гариф Ахунов катнашты һәм ул Совет әдәбиятының милли һәм интернациональ үзенчәлекләре турында татар әдәбияты тәҗрибәсенә таянып сөйләде.

Шул ук журнал оештырган икенче киңәшмәгә исә «Казан утлары» журналының очерк һәм публицистика бүлегеннән язучы Мәлик Хәмитов барды. Көн тәртибе: бүгенге көн темасына очерклар турында теоретик һәм практик планда сөйләшү.

### ПАРТИЯ СЪЕЗДЫ АЛДЫННАН

Язучылар союзы башлангыч партия оешмасының отчет-сайлау җыелышында 1970 юбилейлар елында республикабыз язучылары башкарган зур эшкә йомгак ясалды. Коммунистлар партбюроның партияполитик эшен һәм оештыру эшчәнлеген унай бәяләделәр. Бюроның яңа составына И. Гази, З. Нури (секретарь), И. Юзеев (секретарь урынбасары), Л. Ихсанова, Ю. Белостоцкий, А. Хәсәнова (секретарь урынбасары) һәм В. Нуруллин иптәшләр сайланды.

* * *

КПССның Бауман районы партконференциясенә делегатлар булып коммунист язучылардан Г. Минский, Л. Ихсанова, Л. Хәмидуллин, В. Нуруллин катнаштылар. Конференциядә И. Юзеев КПССның Бауман райкомы членлыгына кандидат, З. Нури XX Казан шәһәр партия конференциясенә делегат итеп сайланды.

* * *

Үткән елның декабрь азагында үткәрелгән ачык партия җыелышында партиябезнең XXIV съездына хәзерлек чорында язучыларның конкрет бурычлары, Союз идарәсенең иҗади-оештыру эшчәнлеге турындагы мәсьәлә каралды (докладчы Г. Ахунов) һәм язучылар иҗат коллективында политик укуларны тагын да яхшырту чаралары билгеләнде.

### ЛЕНИНГРАДТАН БҮЛӘК

«Володя житез, зирәк, кискен. һәм — тапкыр. Бервакыт Кокушкинога барырга чыккач, пароходта ул артыграк шуклана-шаяра башлый. Әнисе аңа «шауларга яра-




мый» ди. Ә малайның исә үз җавабы җавап: «Пароход бит әнә үзе дә бик каты тавышлап бара».

Володя гадел. Тагын ничектер шаярып, Кокушкинода ул түтәенең графинын вата. Көне бик борчулы үтә. Ә кичен әнисе, һәрвакыттагыча, аның караваты янына килгәч, Володя аны кочаклап ала һәм колагына пышылдый: «Түтинең графинын мин ваттым бит, әни...»

Бу юллар кайчандыр Казанда туып үскән, бу якларны бик яхшы белүче һәм безгә бик еш килеп йөрүче, безнең поэзия

[illegible]ларен рус теленә тәрҗемә иткән Е. Н. Вечтомованың «Ана турында повесть» дигән яңа китабыннан китерелде. Елена Андреевна Ленинградта яши, шигырьләр, очерклар, публицистика һәм проза яза. Аның «Ульяновлар семьясы» сериясендә чыккан бу китабына (Мәскәү, Политик әдәбият нәшрияты, 1970 ел) Володя Ульянов һәм аның әнисе Мария Александровна турында, аларның Сембер, Казан, Кокушкино, Пенза, Самара һәм бүтән җирләрдәге тормышының конкрет фактларына нигезләп язылган яңа язмалар тупланган. Якташыбыз үзенең бу китабын беренче итеп Казанга һәм «Казан утлары»-на бүләк итеп җибәрде.

## МУЗЫКА ГИГАНТЫНЫҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Сөекле композиторыбыз, татар совет музыкасын башлап җибәрүче остаз, Татарстанның халык артисты Салих Сәйдәшевнең тууына 70 ел тулу бәйрәменә хәзерлек 1970 елның башларыннан ук җәелдерелгән иде.

Культура учакларында, уку йортларында һәм мәктәпләрдә лекцияләр, концертлар, музыкаль лекторий дәресләре оештырылды, матбугатта Салих Сәйдәшев иҗатына һәм тормыш юлына багышланган күп санлы чыгышлар бастырылды.

Композитор юбилеена бүләк итеп Татарстан китап нәшрияты әзерләгән ике яңа китап октябрь-ноябрь айларында бер-бер артлы чыкты. Аларның берсе — Салих Сәйдәшев дигәне — рус телендә. Ул үлемсез композиторның тормышы һәм аның үлемсез музыкасы турында кереш мәкалә белән башлана. Аннары укучыга Сәйдәшевнең бик күп фоторәсемнәре, Сәйдәшев турында тегеяки бу унай белән язылган этюдлар, истәлекләр, мәкаләләр букеты тәкъдим ителә. Аларның авторлары — музыка белгечләре, композиторлар, актерлар, җырчылар, педагоглар һәм, әлбәттә, музыка гигантының иң якын дуслары — әдипләр, драматурглар, шагыйрьләр. Китапта Г. Кутуй, М. Җәлил, Г. Минский, Г. Кашшаф, М. Садриның шундый чыгышлары композиторны бик яхшы белеп, ана язучыларның тирән мәхәббәтен чагылдырып язылганнар.

Бәйрәмнең икенче китабы күренекле татар драматурглары әсәрләренә Салих Сәйдәшев язган увертюралар һәм биюләрнең баян өчен эшкәртелгән нотальı язмасыннан тора. Менә ул драмалар һәм трагедияләр: К. Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар», «Кандыр буе»; М. Фәйзи. «Галиябану»; Ф. Бурнаш. «Таһир-Зөһрә»; Т. Гыйззәт. «Наемщик».

СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты белән Казан дәүләт консерваториясе гыйльми советларының һәм Татарстан композиторлар Союзы идарәсенең берләштерелгән утырышында Салих Сәйдәшевнең гомумән иҗат юлына, аерым алганда аның җыр иҗатына, Сәйдәшев һәм татар драма театры дигән темага сүз барды. Төп докладчылар П. Исәнбәт, З. Сәйдәшева, А. Ключарев иде.

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге үткәргән истәлекләр һәм музыка кичәсендә шулай ук Салих Сәйдәшев музыкасы яңгырады һәм аның турында кызыклы истәлекләр сөйләнде.

Композитор юбилеена багышланган тантаналы кичә 1970 елның 3 декабрендә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында уздырылды. Залда музыкабыз гигантына багышланган җылы сүзләр, аның үзенең күп санлы әсәрләре яңгырады.

## ТӘБРИКЛӘР, ТЕЛӘКЛӘР, БҮЛӘКЛӘР...

Өлкән шагыйребез, Тукай премиясе лауреаты Хәсән Туфанның тууына 70 ел тулу уңае белән аның адресына республикабызның төрле почмакларыннан, күп төрле җәмәгать оешмаларыннан һәм илебезнең бик күп якларыннан тәбрик сүзләре, матур теләкләр һәм истәлекле бүләкләр килде. Әдипләр һәм укучылар, шигырь сөючеләр һәм тамашачылар аларның күбесен 1970 елның 14 декабрендә Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театрында уздырылган тантаналы кичәдә ишеттеләр һәм күрделәр. Шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында гаять җылы һәм олы сүз белән филология фәннәре докторы Хатип Госман чыкты. Бәйрәмгә махсус килгән кунаклар арасында шагыйрь Михаил Львов (СССР язучылары союзыннан), Ямил Мостафин (РСФСР язучылары союзыннан), Рувим Моран (Хәсән Туфанның Мәскәүдәге тәрҗемәчесе), башкорт шагыйрьләре Мостай Кәрим белән Нәҗәр Нәҗми һәм башкалар бар иде.

## ЯШЬЛӘР РӘХМӘТЕ

Республика дәүләт күчмә театрында: «Йөрәк янар өчен бирелгән», Әлмәт татар драма театрында: «Диләфрүзгә дүрт кияү»... Болар — соңгы бер елда драматург Туфан Миңнуллин язган яңа пьесаларның премьералары. Бу автор турында сүз чыкканда, гадәттәге «Яшь» дигән эпитетны куллану әле дә урынсыз түгел. Ул үзенең активлыгы, иҗади рухы белән яшь һәм яшьләр тормышын, комсомоллар эшчәнлеген бу әсәрләрендә аеруча уңышлы чаралар белән, аеруча тирән итеп сурәтли. Шуңа күрә аңа күп санлы яшь тамашачылар рәхмәте аеруча зур.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ЯҢА ПЬЕСАСЫ

Узган ел азагында Казанның мехчылар клубында Муса Җәлил премиясе лауреаты Илдар Юзеевның «Бөркетләр кыяга оялый» исемле поэтик комедия-водевиленең премьерасы күрсәтелгән иде. Пьесаны республика дәүләт күчмә театрында ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Равил Тумашев куйган. Шул ук спектакль Арча районының Киров исемендәге колхозында күрсәтелгәннән соң авылда, автор һәм режиссер катнашы белән, тамашачылар конференциясе уздырылды. Хәзер аны бүтән бик күп районнарда һәм авылларда зур кызыксыну белән карыйлар.

## ШИГЫРЬ һӘМ ЖЫР БЕЛӘН КОТЛАУ

Зеленодольск районының Тукай исемендәге колхозында яңа Культура йорты ачылды. Бәйрәм тантанасында язучылардан Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Шәүкәт Галиев, композиторлар Мәсгут Имашев һәм Фасил Әхмәтов, яшь җырчы Вәфирә Гыйззәтуллина булдылар. Яңа йорт шигырь һәм җыр белән котланды.

## КИТАПЛАР ТУРЫНДА САННАР

Татарстан китап нәшрияты быел 338 китап чыгарачак. Нинди китаплар соң алар? Бу турыда «Тематик план» китабына теге яки бу басманың темасын, эчтәлеген киң аңлатып язылган күп төрле исемнәр һәм куанычлы саннар сөйли. Марксизм-ленинизм классиклары хезмәтләреннән, мәсәлән, В. И. Ленин әсәрләренең 42 һәм 43 томнары татар телендә чыгарыла. Сәяси һәм тарихи әдәбият әсәрләренең 40 китабын чыгару планлаштырылган. Фәнни-техник те-




мага, авыл хуҗалыгы, культура, туган якны өйрәнү темасына 36 китап чыга. Зурлар һәм балалар өчен матур әдәбият әсәрләренең саны — 121. Бу, элекке еллардагыча ук, һәр өч көн саен бер әдәби китап чыгып тора дигән сүз. Шуларның күбесе «Корыч шулай чыныкты», «Дуслык букеты», «Батырлык», «Туган җир», «Минем профессиям», «Кайда син, романтика?», «Шагыйрь китапханәсе» дигән серияләрдә чыгарга тиеш. Әсәрләрнең иң яхшылары рус теленә тәрҗемә ителә. Китапларның калганнары — дәреслекләр, ноталы җырлар, альбомнар, сукырлар өчен махсус басылган җыелмалар.

Тематик план китаплары, гадәттәгечә, башкарма комитетларның район культура бүлекләренә, китапханәләргә, кибетләргә, «Союзпечать» бүлекчәләренә инде үткән елда ук бушлай таратылды. Планны һәм план буенча чыгачак китапларны кирәк очракта Казаннан да соратып алырга мөмкин. Адреслар:

ул. Баумана, 19, магазин № 1, отдел «Книга-почтой».

ул. Октябрьская, 1 б, магазин № 14, отдел «Книга-почтой».

## МӘСКӘҮДӘ ЧЫГАЧАКЛАР

Татар әдәбиятының нинди әсәрләре кайда һәм нинди телләрдә чыкканын без ел саен хәбәр итә киләбез. Менә 1971 елның шундый китаплары да чыга башлады инде. Хөрмәтле укучыларыбызга, барыннан да элек, Мәскәүдәге үзәк нәшриятларда быел рус теленә тәрҗемә итеп чыгарылачак китаплар турында белдерергә телибез:

«Матур әдәбият» (Гослитиздат) нәшриятында Габдулла Тукайның сайланма әсәрләре.

«Совет язучысы» нәшриятында Гомәр Бәшировның «Туган ягым яшел бишек», Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» дигән повестьлары.

«Совет Россиясе» нәшриятында Гариф Ахунов белән Марсель Зариповның «Без Казаннан, Иделдән» исемле художестволы белешмәлек китабы, Рафаил Төхфәтуллинның «Зәңгәр кыңгырау» исеме белән бер китапка тупланган хикәяләр җыелмасы.

«Яшь гвардия» нәшриятының «Сайланма лирика китапханәсе» дигән сериясендә Зәки Нури китабы...

Республикабыз композиторларының әсәрләре ноталар белән «Совет композиторы» нәшриятында чыга. (Ренат Еникеев — «Соната», Анатолий Луппов — «Концертино-токката», Алмаз Монасыйпов — «Җырлар» һәм «Симфония»).

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Леон Небенцаль — Германия Демократик Республикасының танылган публицист-язучысы, «Тынычлык һәм социализм проблемалары» дигән халыкара журналның немецча басма редакторы, Муса Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыгы турында бик күп материаллар эзләп тапкан һәм матбугатта чыгарган эшлекле. Аның Казанда булганы, Җәлил һәм җәлилчеләр турында дулкынландыргыч чыгышлар ясаганы бар. Күптән түгел Леон Небенцаль тагын безнең илебезгә килде һәм Ташкентта Муса Җәлил көрәштәшләре Фәрит Солтанбеков, Гараф Фәхретдинов һәм башкалар белән очрашты. «Шәрык хакыйкате» газетасында аның түбәндәге белдерүе рус телендә басылган:

— Германия Демократик Республикасында Муса Җәлил истәлеген мәңгеләштерү өчен бик күп нәрсә эшләнә. Шагыйрьнең әсәрләрен без үзебезнең туган телебездә укыйбыз. «Моабит дәфтәре» шигырьләре аеруча күп тарала. Бездә Муса Җәлил исеме белән аталырга лаек булган пионер дружиналары, эшчеләр бригадалары бар. Әйтик, мәсәлән, Берлиндагы «Берлинер бремзенверке» исемле заводта (1918 елның ноябренда бирелә Берлин эшчеләренең беренче Советы оешта) Муса Җәлил исеме иң яхшы күрсәткечләр белән эшләүче бригадага бирелде. Шагыйрьнең тормыш иптәше Әминә ханым — шул бригаданың почетлы члены.

## КАЗАНДАГЫ ГОРЬКИЙ МУЗЕЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

1970 елда музей лекториенда «Матур әдәбиятта В. И. Ленин образы», Качалов исемендәге театр бинасында «Пушкин Казанда», Киров исемендәге культура сараенда «Шагыйрь Сибгат Хәким иҗатында В. И. Ленин образы» дигән тематик күргәзмәләр оештырылды. Музей хезмәткәрләре һәм «Китап дуслары» исемле клуб членнары хәзер зур активлык белән Габдулла Тукайның Кырлайда ачыласы музее өчен яңа материаллар туплыйлар. Моның өчен художник Х. Якупов «Шаляпин һәм Тукай», «Тукай һәм крестьяннар» дигән темаларга картиналар, Б. Урманче «Кисекбаш» рәсемен эшли. Күп кенә картиналар, скульптуралар һәм барельефлар сатып та алынды инде. Тукай әсәрләренең беренче басмалары табылды, язучылар һәм композиторлар үз әсәрләрен музейга автографлар белән бирделәр. Музей экспозициясендә Тукай бүләге лауреатларының эшләре һәм фоторәсемнәре күрсәтеләчәк.

## ДИПЛОМ АЛДЫЛАР

Мәскәүдә эстрада артистларының IV Бөтенсоюз конкурсы үткәрелде. Яшь талантларны сайлап табу, эстрада сәнгатенең иң яхшы үрнәкләрен популярлаштыру һәм аның идея-художество дәрәҗәсен тагын да күтәрү максаты белән оештырылган бу конкурс сынауларында катнашып һәм танылып Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе солисты Зиннур Нурмөхәммәтов һәм филармониянең эстрада ансамбле житәкчесе Владимир Березин диплом алдылар.

## «УЛ МУСА КЕБЕК БАТЫР ИДЕ...»

Грузиядән Татарстан язучылары союзына «Солдат язмалары» исемле китап килде. Аның авторы Георгий Кавтарадзе Ватан сугышында совет сугышчылары кичергән вакыйгалар һәм сугыш батырлары турында яза. Китапның «Күмелеп бетмәгән кабер» дигән бер бүлеге тулысынча татар егетенә багышлана. Автобиографик повесть авторы язган хатта аның турында мена нинди сүзләрне укырга мөмкин: «Ул Муса Җәлил кебек үк батыр көрәшче иде. Андыйлар исеме белән без барыбыз да горурланабыз!..»

## ЯШЬЛӘРНЕҢ ПОЭТИК ФЕСТИВАЛЕ

Казан университетындагы «Әллүки» әдәби берләшмәсенең студент-шагыйрьләре Фәнүр Сафин, Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансуров һәм Рөстәм Фәйзуллин Башкортстанның Бөре шәһәре педагогия институтында уздырылган шигъри фестивальдә булып кайттылар. Алар анда Башкортстан университетының һәм Бөре шәһәренең яшь талантлары белән, шулай ук шагыйрьләр Әнгам Атнабаев, Равил Шаммасов белән бергә берничә урында чыгышлар ясадылар. «Казан утлары» журналы һәм татар әдәбияты турында сөйләделәр.

Фестиваль «Казан — Уфа — Бөре дуслыгы тагын да ныгысын!» дигән девиз белән узды.

## КАЗАН ПАРКЫ — ЛАУРЕАТ

Илебездәге Культура һәм ял паркларының В. И. Ленинның 100 еллыгына багышланган конкурсы ике ел дәвам итте. Хәзер аның йомгаклары ясалды һәм җиңүчеләр билгеле: 1969—1970 елларда хезмәт ияләренең культуралы ялын оештырган өчен Казанның М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркы СССР Культура Министрлыгы, «Известия» газетасы редакциясе, ВЛКСМ Үзәк Комитеты, Культура работниклары профсоюзы Үзәк Комитетының истәлек байрагы белән бүләкләнде, аңа «Культура һәм ял паркларының Бөтенсоюз смотры лауреаты» дигән исем һәм акчалата бүләк бирелде. Шул ук вакытта Казан паркын ВЦСПС, ВЛКСМ Үзәк Комитеты, Бөтенсоюз «Белем» җәмгыяте, ДОСААФ Үзәк Комитеты һәм СССР Художниклар союзы үз дипломнары белән бүләкләүгә дә лаеклы дип таптылар.

## «АВАНГАРД»НЫ КОТЛАУ

Илебезнең бүтән кайбер өлкәләре һәм республикаларындагы кебек үк, Чувашстанның Батыр районында да татар телендә газета чыга. Күптән түгел «Авангард» исемле шул газетаны аның чыга башлавына 40 ел тулган көндә котлау өчен Казаннан Батырга шагыйрь Мәхмүт Хөсәен белән Кави Латыйпов барды.

## ТАМАШАЧЫ КИТАБЫ

Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар Дәүләт Академия театры узенең үткән сезонда күрсәтелгән һәм быел-



гы сезонда күрсәтеләчәк спектакльләре программаларын татар һәм рус телләрендә аерым китап итеп бастырып чыгарды. Тамашачыларга бик матур бүләк һәм бик кирәкле кулланма ул. Анда татар театрының шактый тулы язылган хроникасы да бирелгән, театр артистларының фоторәсемнәре дә урнаштырылган.

# И КҮҢЕЛЛЕ



ӘХМӘТ ЕРИКӘЙ сүзләре


ЛУИЗА ХӘЙРЕТДИНОВА музыкасы


*Әти-әниләрем мин дөньяга килгәнче үк миңа фортепьянода уйнау өчен әлифба алып куйганнар. Шулай итеп, минем музыкант булуым мин туганчы «хәл ителгән» булган инде.*

*Өч яшемдә фортепьянода уйный башлаганмын, биш яшемдә инде көйләр дә чыгара идем.*

*Казан консерваториясе каршындагы 11 еллык махсус музыка мәктәбен тәмамлаганнан соң, консерваториянең композиторлык бүлегенә укырга кердем.*

*Хәзер укуымны Уфа дәүләт сәнгать институтының композиция бүлегендә дәвам итәм.*






И күңелле, иртән уянганда,
Тәрәзәгә кояш караса.
Ефәк нурлар йомшак тарак белән
Чәчләреңне назлап тараса.

И күңелле, тәрәз каршысында
Шомырт чәчәк атып утырса.
Бүлмәләрне, хушбуй сипкән кебек,
Чәчәк исе белән тутырса.

И күңелле, бөтен көчне биреп,
Янып эшли торган эш булса,
Күкрәккә дәрт, хыялларга канат
Бирә торган көннәр еш булса.

*Хөрмәтле укучылар!*

«Казан утлары»ның 6, 7, 8 саннарында түбәндәге әсәрләр басыла:

Ф. Хөсни. «Мәйдан». Повесть.

Б. Камалов. «Ялыкмаслар». Повесть.

Д. Зөбәерова. «Кош өянке шаһит». Повесть.

С. Сөләйманова. «Йолдызларга йодрык». Хикәя.

И. Салахов. «Карлыгач». Хикәя.

Т. Миңнуллин. «Кульяулык һәм өч йөз сум акча». Хикәя.

Журналның тугызынчы саныннан Әхсән Баянның «Ут һәм су» романы басыла башлаячак.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210